# ӘДӘБИЯТ

5

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

ӘДӘБИЯТ
5

***…Халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә…***

*Габдулла Тукай*

**М. Ш. ҖӘЛӘЛИЕВА, Г. М. ӘДҺӘМОВА,**
**Д. Ш. СИБГАТУЛЛИНА**

# ӘДӘБИЯТ

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең
5 нче сыйныфы өчен
дәреслек-хрестоматия

*Татарстан Республикасы*
*Мәгариф һәм фән министрлыгы*
*тарафыннан тәкъдим ителгән*

Бишенче басма

КАЗАН • ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ • 2011

УДК 373.167.1:821.512.145*05
ББК 83.3(2Рос=Тат)я721
Ж84

Фәнни мөхәррире —
Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты
*А. Г. Әхмәдуллин*

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Җәләлиева, М. Ш.**

Ж84 Әдәбият : татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5 нче с-фы өчен дәреслек-хрестоматия / М. Ш. Җәләлиева, Г. М. Әдһәмова, Д. Ш. Сибгатуллина.— 5 нче басма.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2011.— 335 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-298-02067-1

УДК 373.167.1:821.512.145*05
ББК 83.3(2Рос=Тат)я721

ISBN 978-5-298-02067-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Җәләлиева М.Ш., Әдһәмова Г.М., Сибгатуллина Д.Ш., 2011

## КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!

Бишенче сыйныфтан сез татар язучыларының әсәрләрен өйрәнә башлыйсыз. Бу әсәрләр сезне гаҗәеп бай һәм мавыктыргыч, сихри һәм үзенчәлекле бер дөньяга алып керәчәк. Ул ***матур әдәбият*** дип атала.

Әдәбият дөньясына сәяхәт алдагы сыйныфларда да дәвам итәр. Сез төрле-төрле вакыйгалар, гыйбрәтле язмышлар шаһиты булырсыз, әдәби геройлар белән бергәләп шатланырсыз, аларның кайгыхәсрәтләрен уртаклашырсыз. Туган телнең гаять бай бизәк-сурәтләре белән очрашырсыз.

Әдәби әсәрләр сезне рухи яктан баетыр, әхлак һәм зәвык булдыруда ярдәм итәр, затлыны затсыздан, яхшыны яманнан аера белергә өйрәтер.

Китап һәрвакыт тугры юлдашыгыз булсын!

Уңышлы сәяхәт телибез сезгә, дуслар!

*Авторлар*

## Халык авыз иҗаты

Халыкның телдән сөйләнә торган поэтик әсәрләре **халык авыз иҗаты** яки **фольклор** дип атала. Фольклор — инглизчә «халык акылы» дигән сүз.

Халык авыз иҗаты әсәрләре язу сәнгате туганчы ук барлыкка килгәннәр. Борынгы чорда җыр, бию, уеннар, төрле йолалар үзара үрелгән хәлдә ыруг, кабилә иҗаты буларак яши. Заманнар үтү белән, кешеләрнең аңы да үсә бара. Шуның белән бергә, халык авыз иҗаты да үзгәреш кичерә, аның төрләре арта, әсәрләрдәге фикер тирәнәя бара. Алар мөстәкыйль сәнгать әсәре булып формалашалар. Халык авыз иҗаты әсәрләренә җырлар, такмак-такмазалар, әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, эпослар, мәзәкләр, бәетләр һ. б. керә. Аларда халыкның уй-хыяллары, гаделлек өчен көрәше, якты киләчәккә омтылышы гәүдәләнә. Шунлыктан фольклор әсәрләре һәркемгә якын, һәркемне дулкынландыра, яхшылыкка, әдәпле һәм намуслы булырга өнди.

Халык авыз иҗаты әсәрләре — күмәк иҗат җимеше. Аларның авторы билгеле булмый. Кем дә булса берәү җыр, мәзәк яисә әкият чыгара икән, алар шунда ук телдән-телгә күчеп йөри башлый. Һәр башкаручы кеше мондый әсәрләрне үзенчә эшкәртә, эчтәлеген тулыландыра, сәнгатьчә матурлый, бизи.

Фольклор — халыкның рухи хәзинәсе, ерак заманнарда яшәгән кешенең эчке дөньясын чагылдыра торган тормышчан чыганак. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә җанлы сөйләм теленең үзенчәлекләре, халыкның фикер байлыгы, сүз тапкырлыгы, күп төрле сурәтбизәк чаралары тупланган.

Әнә шуларны күздә тотып, Габдулла Тукай болай дигән: «Дөресен генә әйткәндә, халык — зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул».

Халыкның сүнмәс таланты белән иҗат ителгән фольклор әсәрләрен без бүген дә яратып укыйбыз. Язучылар, шагыйрьләр, композиторлар һәм рәссамнар өчен исә халык авыз иҗаты әсәрләре бетмәс-төкәнмәс илһам чишмәсе булып тора.

## ТАҢБАТЫР

### 1

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер патша. Бу патшаның булган, ди, өч кызы. Патша кызлары берсеннән-берсе матур булганнар, ди.

Көннәрдән бер көнне бу өч кыз болынлыкка йөрергә дип чыкканнар. Болар болынлыкта йөргән вакытта гына, бик каты җил-давыл чыга да кызларның өчесен дә күтәреп алып китә. Патша, кызларының югалганын белеп, бик зур кайгыга төшә. Көн эзләтә патша бу кызларны, төн эзләтә. Үз патшалыгында урманы, су буйлары калмый моның, бөтен җирдән эзләтеп карыйлар, кызларны таба алмыйлар.

Шул патша торган шәһәрнең читендәге кечкенә генә бер йортта яшәгәннәр икән, ди, бер ир белән бер хатын. Болар бик фәкыйрь булганнар. Боларның булган икән, ди, өч уллары. Олы улларын Кичбатыр дип, уртанчысын Төнбатыр дип, ә иң кечесен Таңбатыр дип йөрткәннәр, ди. Бу егетләр, ай үсәсен көн үсеп, ел үсәсен ай үсеп дигәндәй, бик тиз вакыт эчендә дәү булып җиткәннәр, ди.

Үсеп җитү белән, болар урамга уйнарга чыгалар. Яшьләр арасында болардан да көчле берәү дә булмый. Уйнаган вакытларында кешенең кай җиреннән генә тотсалар да умыралар да алалар, ди, болар.

Кәшәкә шаралы уйнаганда да, болардан да оста уйнаучы юк, көрәшә башласалар да, кешене имгәтми калдырмыйлар, ди, болар.

Бу өч туганның көчләрен кая куярга белми йөргәннәрен күреп, бер карт кына кеше әйткән, ди, боларга: «Сез, ди, анда-монда сугылып, урынсызга кеше имгәтеп

йөргәнче, әнә патша кызларын табып алып кайтып бирер идегез, менә шунда күренер иде сезнең батырлыгыгыз»,— ди.

Шуннан соң болар, өйләренә кайтып, ата-аналарыннан рөхсәт сорыйлар:

— Әти, диләр, патша кызлары югалган, дип әйтәләр, без шул кызларны алып кайтып бирик микән әллә?— диләр. Ата-аналарының боларны бер дә җибәрәселәре килми, ризалык бирмиләр икән, ди.

— Әй улларым, без сезне теләп кенә алдык бит инде, сез чыгып киткәч, безне кем карар, кем туйдырыр?— ди әтиләре.

Малайлары әйтә:

— Әй әти, без патша эше белән йөргәч, сезне патша тәрбияләр әле,— диләр.

— Юк инде, безгә патшадан бер рәхим дә, бернинди ярдәм дә буласы юк,— дип, әти-әниләре елашалар.

Бу өч батыр әти-әниләреннән бик ялынып сорыйлар да, рөхсәт алып, патшага барып әйтәләр:

— Менә без синең кызларыңны эзләргә чыгарга уйлыйбыз, безнең үзебез белән алып чыгарга бернәрсәбез дә юк, әти-әниләр дә бик фәкыйрь торалар,— диләр.

Патша боларга ашарга-эчәргә бераз азык бирергә була.

Әти-әниләре белән саубуллашып, өч егет чыгып китәләр юлга. Баралар, баралар болар, атна китәләр, бара торгач, барып керәләр бер урманга. Урманның эченәрәк керә барган саен, болар бара торган юл, тарайганнан-тарая барып, соңыннан тар гына бер сукмакка калган, ди. Шул тар сукмак белән бара торгач, болар барып чыккан, ди, бик матур бер күл янына. Ул вакытта инде ашарларына беткән була. Таңбатыр әнисе «юлда кирәк булыр» дип биреп җибәргән энәсен ала да, ут ягып, шул энәне утта кыздырып, бик шәп бер кармак ясый. Шуннан соң, су буена төшеп, балык тота башлый. Кичкә хәтле бер-ике пот балык тота да бу, шул балыкларын пешереп, абыйларын туйганчы ашата.

Хәзер тамак кайгысы бетте инде боларның. Таңбатыр әйтә абыйларына:

— Безнең өйдән чыгып киткәнгә бик күп вакыт үтте, ди, без кай җирләрдә йөргәнебезне дә белмибез, бернәрсә дә күргәнебез юк әле безнең,— ди. Абыйлары бер җавап та бирмәгән моңа. Шуннан соң бу, бик биек бер агач башына менеп, тирә-якны карый башлый. Таңбатырның агач башына менеп утыруы гына була, кузгала җил-давыл, кузгала җил-давыл, бу давыл шулхәтле көчле була, юлына туры килгән калын-калын агачларның башларын кыеп кына алып китә икән, ди. Таңбатыр бу җил-давылның котырганын карап тора да: «Әллә бу теге патша кызларын күтәреп алып киткән җил-давыл микән?» — дип уйлый. Озак та үтми, әлеге җил-давыл, бер җирдә бөтерелеп, котчыккыч булып өерелеп-өерелеп тора да биек тау башына барып тукты. Тау башында бик яман бөтерелеп тора-тора да бер бик ямьсез нәрсәгә — Дию пәриенә әверелә. Дию пәриенә әверелә дә бу, тау кырыена төшеп, шундагы бер зур тишеккә кереп китә.

Таңбатыр, тиз генә агач башыннан төшеп, Дию кергән тишекне эзләп таба. Бик зур тишек икән, ди, бу. Шуннан соң Таңбатыр, зур гына бер таш алып килеп, әлеге тишекнең авызын томалап куя да, тиз генә барып, агайларын уята. Абыйлары бер дә ашыкмый торган кешеләр булалар. Әкрен генә торып, Таңбатыр әзерләп куйган балыкны пешереп, туйганчы ашап-эчкәннән соң гына, теге тау тишеге янына китәләр.

— Менә ул шушы тишеккә кереп югалды, без аның артыннан төшәргә уйласак, башта менә шушы ташны алып ташлыйк,— ди Таңбатыр. Кичбатыр ташка барып тотына — кузгата алмый. Төнбатыр барып тотына — аннан да бернәрсә дә чыкмый. Шуннан соң Таңбатыр ташны күтәреп алып селтәп кенә җибәрә — таш тау астына тәгәрәп төшеп китә. Таңбатыр әйтә абыйларына:

— Безнең беребезгә, менә шушы тишектән төшеп, теге Диюне эзләп табарга кирәк, ди, патша

кызларын шул урламадымы икән? — ди. Өч агай бергәләп киңәшәләр дә, урманга кереп, кочак-кочак юкә суеп алып чыгалар. Шул юкәләрдән бик калын итеп аркан ишә башлыйлар. Өч көн, өч төн буена бик нык, бик озын итеп ишәләр болар арканны. Шул арканның бер очын Кичбатырның биленә бәйләп, аны тау тишегенә төшереп җибәрәләр. Төшеп китә бу. Кич булды дигәндә генә, арканны селкетә Кичбатыр: «Тартып чыгарыгыз»,— дип. Энеләре тартып чыгаралар.

— Төбенә җитә алмадым, аркан кыска булды,— ди Кичбатыр. Шуннан соң болар тагын бер тәүлек аркан ишәләр. Хәзер инде шул арканга бәйләп, Төнбатырны төшереп җибәрәләр. Көтәләр-көтәләр болар, тегеннән бер хәбәр дә юк. Бер көн, бер төн үтте дигәндә, теге арканны селкетә. Моны да тартып чыгаралар.

— Бик тирән икән, төбенә җитеп булмады, аркан җитмәде,— ди Төнбатыр. Шуннан соң болар тагын ике төн, ике көн буена утырып аркан ишәләр. Арканны тагын да озын итеп ишеп, аның бер очын Таңбатырның биленә бәйлиләр. Тау тишегенә төшәр алдыннан, Таңбатыр әйтә абыйларына:

— Тиз генә чыга алмасам, сез мине нәкъ бер ел көтегез, ди. Бер ел тулды дигәндә чыгып җитмәсәм, көтеп тормагыз, үз юлыгызны карагыз,— ди. Шулай ди дә бу Таңбатыр, абыйлары белән саубуллашып, тау тишегенә төшеп китә.

Ярар, Таңбатырның абыйлары шунда калып торсыннар. Без хәзер Таңбатыр белән аска төшик.

Төшә-төшә Таңбатыр, нихәтле вакыт төшеп тә, тау тишегенең төбенә җитә алмый, арканы тагын кыска була моның. Кире чыгасы килмичә, кылычын алып, арканны кисеп җибәрә бу. Бик озак очканнан соң, барып бәрелә бу бик каты нәрсәгә. Шунда ук һушыннан китеп, өч тәүлек аңына килә алмыйча ята, ди, бу. Шуннан соң, әкрен генә торып, тагын да китә бу. Бара, бара бу, шулай итеп бара торгач, моңа бер Тычкан

очрый. Бу Тычкан бер генә мәртәбә селкенә дә кеше була.

— Нихәл, Таңбатыр, нишләп йөрисең монда? — ди.

— Менә, — ди егет, — бер Дию пәриен эзләп төшкән идем дә, монда китәргә урын юк, чыгарга җай юк, — ди.

Тычкан әйтә:

— Ул Дию пәрие сезне алдады бит, ди, сезнең элекке арканыгыз да тау тишеге төбенә җиткән иде; Дию, сезне алдап, чокырның төбен аскарак төшереп җибәрде, ди. Хәзер син бик тирәндә инде, мин булышмыйча, моннан чыга алмассың, — ди.

Егет нәрсә эшләргә дә белмичә аптырап торганда, Тычкан әйтә:

— Менә мин сиңа дүрт полк тычкан солдаты бирәм, ди, алар җирне казып торырлар, ә син таптап менеп кенә торырсың, ди. Шулай итеп, алар сине менгереп җиткерерләр бер сукмакка хәтле, ди. Шул сукмак белән җиде көн, җиде төн буена, бернәрсә күрмичә, караңгыда барырга туры килер, курыкма, ди. Шул юл белән бара торгач, сиңа очрар җиде кат чуен капка, ди, шул капкаларны ватып чыга алсаң, якты дөньяга чыгарсың, вата алмасаң, сиңа бик авырга килер, ди. Якты дөньяга чыгу белән, янә бер сукмак булыр, син шул сукмак белән китәрсең. Шул сукмак белән җиде тәүлек барганнан соң күренер сиңа бер сарай, — ди. Шулай ди дә бу Тычкан, күздән югала.

Егет дүрт полк тычкан солдатлары казыган юл белән бик күп вакытлар барганнан соң барып җитә теге җиде чуен капка янына. Барып җитү белән, үзенең чукмарын алып, капкага бик каты итеп сугып җибәрә, чуен капка таралып китә. Шулай итеп, бу җиде капканы да бәреп үтеп китә. Бара, бара бу, барган саен, дөнья яктырганнан-яктыра бара, ди. Җиде тәүлек юл киткәч, моңа зур кирпечкә охшаган бер кызыл нәрсә күренә. Барып җитә бу, янына барып карый: зур бер кирпеч

икән бу. Кирпеч өстендә бакыр атка атланган, бакырдан коелган киемнәр кигән бер каравылчы тора икән, ди.

— Әй адәм заты,— ди каравылчы,— бу тирәдән кит җәтрәк, ди. Син бу тирәгә ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, Дию патша кайтып керсә тотып ашар үзеңне,— ди.

Егет әйтә:

— Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, анысын белеп булмый әле, ди. Хәзергә минем бик каты ашыйсым килә, китер әле берәр нәрсә ашарга,— ди.

— Сиңа ашатырлык бернәрсәм дә юк шул, ди, менә хуҗам кайткач ашатырмын дип әзерләп куйган бер түшкә үгез итем, бер мич ипием, бер мичкә эче суым бар, шуннан башка бернәрсәм дә юк,— ди.

Егет әйтә:

— Ярар, ди, хәзергә миңа шулар җитеп торыр, ә хуҗаңа ашап-эчеп торырга туры да килмәс,— ди.

Шуннан соң теге кеше, атыннан төшеп, бакыр киемен сала да Таңбатырга ашарга әзерләп бирә. Бу — солдат киеме кигән кыз кеше икән. Егет бу кыз китергәннәрнең барын да ашап бетерә дә йокларга ятарга җыена. Ятар алдыннан сораша инде бу кыздан:

— Ул Дию пәрие кайчан кайтыр икән? — ди.

— Ул иртәгә иртә белән менә шушы бакыр күпер өстеннән кайтыр,— ди кыз.

Егет әйтә:

— Менә сиңа бер без, ди, Дию кайта башлагач, шушы без белән минем чигәмә чәнчеп уятырсың,— ди. Шулай ди дә йокларга ята бу. Диюнең кайтыр вакыты җитү белән, теге кыз моны уятырга тотына — уята алмый. Без белән чәнчергә кызгана, уятмый калдырсам да яхшы түгел дип уйлый. Шулай да бик каты итеп уята башлагач, Таңбатыр сикереп тора:

— Әй, ди, мине без белән чәнчеп уятырга кирәк иде, ул вакытта мин тагын да зәһәрләнебрәк китәр идем,— ди.

Таңбатыр теге кыз әйткән бакыр күпер астына кереп ята. Бервакытны, җил-давыл куптарып, Дию бакыр күпергә якынлаша башлый. Күпер янына иң элек моның эте килеп җитә. Диюнең эте күпер янына килеп җитә дә, күпергә кермичә, шыңшып, хуҗасы янына кире китә. Дию, аңа камчысы белән генә селтәп, атына атланган килеш күпергә барып керә. Күпергә барып керү белән, моның аты да шып туктый. Дию, ачуы килеп, атына сугып җибәрә.

— Һәй, ди, нигә куркасың? Әллә монда Таңбатыр килеп яткан дип уйлыйсыңмы, ди, әле ул монда килү түгел, анадан да тумагандыр,— ди.

Диюнең шулай дип әйтеп кенә бетерүе була, бакыр күпер астыннан тып итеп Таңбатыр килеп чыга. Килеп чыга да:

— Таңбатыр анадан да туган, килеп тә җиткән,— дип, Дию пәрие каршысына килеп баса.

— Килсәң,— ди, Дию әйтә,— әллә ни олы гәүдәле түгел икәнсең әле, ди, ике кабып, бер йотарга гына җитәрсең,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Гәүдәсе чуклы булыр, алай тиз генә йота алмассың,— ди.

Дию әйтә:

— Күп сөйләшеп торма, ди, алыш бармы, көрәш бармы? — ди.

— Алыш агаң башына булыр, әйдә, көрәшик,— ди.

Шуннан көрәшергә тотыналар да алыша алмыйча шулкадәр озак йөриләр болар, шул тирәләр бөтенләй казылып, чокырга әйләнеп бетә. Йөри торгач, Диюнең хәле бетә башлый. Шулвакытта Таңбатыр моны күтәреп сала да, кылычын суырып алып, Диюне тураклап, әрдәнә итеп өеп куя. Шуннан соң бу, Диюнең атына атланып, аның сараена китә. Диюнең әлеге каравылчысы моңа каршы йөгереп чыга:

— Хәзер куркыр кешем юк, әйтергә ярый, ди, мин фәлән патшаның олы кызы идем, мине бу Дию пәрие

урлап алып киткән иде, зинһар, мине монда калдыра күрмә, алып кына кайта күр үзең белән,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Без, өч агай-эне, сезне эзләргә дип чыккан кешеләр,— ди. Патша биргән язуны кесәсеннән чыгарып күрсәтә. Патша кызы шатлыгыннан нишләргә белми. Таңбатыр әйтә:

— Атаңның вәгъдәсе буенча, син минем олы абыйга булырга тиешсең, хәзергә шушы бакыр сарайда торып тор, кайтышлый мин сине кереп алырмын,— ди.

Өч көн ял иткәннән соң, юлга чыгар алдыннан, Таңбатыр сорый теге кыздан:

— Синең сеңелләрең кая, аларны ничек эзләп табарга?— ди.

Кыз әйтә:

— Дию пәрие мине бик каты тотты, беркая да чыгармады. Минем барып күргәнем юк, уртанчысына хәтле җиде тәүлек юл барырга тиеш,— ди.

Таңбатыр, кызга исәнлек-саулык теләп, юлга чыгып китә. Тау-ташлар үтеп, җиде тәүлек киттем дигәндә барып җитә бу бер көмеш сарайга. Көмеш сарай кояшта ялт итеп тора икән, ди. Барып керү белән, көмеш атка атланган, көмештән койган киемнәр кигән бер солдат каршылый моны. Туктата. Таңбатыр янына килеп әйтә бу:

— Әй адәми зат, ди, син монда ялгышып кына килеп кергәнсеңдер, исән-сау чакта чыгып кит моннан, хуҗам кайтса ашар сине, бер генә йотар,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Хуҗаң тизрәк кайтсын иде әле, ди, әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, ди. Менә минем җиде тәүлек буена рәтләп ашаганым юк, иң элек син миңа ашарга китер,— ди.

— Сиңа ашатырлык бернәрсәм дә юк, хуҗама дип әзерләп куйган ике түшкә үгез итем, ике мич ипием, ике мичкә әче суым гына бар,— ди.

— Ярар, хәзергә җитеп торыр, китер әле шуларны,— ди.

— Хуҗама ничек дип җавап бирермен икән соң? — ди.

— Курыкма, ди, хуҗаңа ашап-эчеп торырга да туры килмәс, — ди егет.

Шуннан соң теге көмеш киемле солдат Таңбатырга ашарга-эчәргә китереп бирә.

Таңбатыр, туйганчы ашап-эчкәннән соң, яхшылап кына сораша бу солдаттан:

— Хуҗаң кайчан кайта? — ди.

— Ул иртәгәләргә кайтып җитәргә тиеш, — ди.

— Кайсы яктан кайта ул? — ди.

— Менә шушы сарай артыннан ага торган елга аркылы бер көмеш күпер булыр, ди. Һәрвакытта шул көмеш күпер аркылы кайта ул, — ди.

— Мин хәзер ял итәргә ятам, хуҗаң кайтып җитәрәк, мине уятырсың, ди. Әгәр дә бик каты йоклап китсәм, менә шушы без белән чигәмә кадарсың, — дип, солдатка бер без чыгарып бирә дә йокларга ята бу.

Таңбатыр бер көн, бер төн йоклаганнан соң, Дию пәриенең кайтыр вакыты җитә. Дию пәриенең якынлаша башлавын сизеп, теге каравылчы солдат уята башлый — уянмый гына бит теге. Уята алмый аптырагач, утырып елый бу моның янында. Без белән чәнчер иде, кызгана, башкача уята алмый. Инде без белән чәнчеп уятыйм дип кенә торганда, Таңбатыр моның елавын ишетеп уянып китә.

Солдат әйтә:

— Тизрәк тор, ди, югыйсә Дию пәрие кайтып җитә инде, кайтып керсә, икебезне дә харап итәр, — ди.

Таңбатыр тиз генә тора да, кылычын алып, теге көмеш күпер астына барып ята. Күп тә үтми, җилдавыллар чыгарып, Дию пәрие кайтып та җитә. Иң элек моның эте күпергә килеп керә. Бер-ике генә атлый да эт, шыңшып, хуҗасына таба кире чаба. Дию пәрие, моңа бик каты ачуы килеп, камчысын селти дә көмеш күпергә чабып кереп китә. Күпер уртасына җитүгә, ат

шып туктый. Дию атына тагын бер сугып җибәрә, аты урыныннан да кузгалмый моның.

— Их, син,— ди Дию,— котың чыккан икән, ди, әллә син монда Таңбатыр килеп җитәр дип уйлыйсыңмы? Таңбатыр анадан да тумаган әле,— ди. Диюнең шулай дип әйтеп бетерүе генә була, Таңбатыр көмеш күпер астыннан килеп тә чыга.

— Таңбатыр анадан да туган, килеп тә җиткән,— ди.

— Килсәң, бик шәп булган,— ди Дию,— мин сине ике кабармын, бер йотармын,— ди.

— Йота алмассың, сөяге каты булыр,— ди.

— Ярар, алай булса, алыштанмы, көрәштәнме? — ди.

— Алыш агаң башына булыр, әйдә, көрәшәбез,— ди Таңбатыр.

Шуннан болар көрәшергә тотыналар. Таңбатыр Диюне күтәреп ала да җиргә китереп бәрә, тегенең сөякләре өзгәләнеп-өзгәләнеп китә. Шуннан соң Таңбатыр моның сөякләрен әрдәнә итеп өеп куя да, Диюнең атына атланып, солдат янына кайта.

Солдат әйтә:

— Әй абый, ди, зинһар, син мине монда калдыра күрмә, ди, мин солдат түгел, шулай киендем генә, мин фәлән патшаның уртанчы кызы идем, син мине үзең белән алып кайта күр,— ди.

— Ярар,— ди егет,— минем уртанчы агама булырсың,— ди. Моңарга да патша биргән язуны чыгарып күрсәтә.— Син шушы көмеш сарайда торып тор, ди, мин сине кайтышлый кереп алып китәрмен, хәзер синең сеңелеңне эзләргә китәм, ди. Ул кайсы якта, моннан еракмы? — ди.

— Шушы көмеш атка атланып барсаң, моннан җиде тәүлек юл ул,— ди кыз.

Егет көмеш атка атланып китә. Җиде тәүлек дигәндә, теге алтын сарайга барып җитә. Алтын сарай калын стена белән әйләндереп алынган. Алтын капка төбендә

алтын кием кигән, алтын атка атланган бер сакчы йөреп тора икән, ди. Таңбатыр килеп җиту белән, теге сакчы әйтә:

— Әй адәми зат, монда нишләп йөрисең, ди, сине бит Дию ашар,— ди.

Егет әйтә:

— Әллә ул ашар, әллә мин аның башына җитәрмен, хәзергә минем бик нык ашыйсым килә, тамагымны туйдыр әле син,— ди.

Сакчы әйтә:

— Минем хуҗам өчен әзерләп куйган өч мичкә эче суым, өч мич ипием, өч түшкә үгез итеннән башка бернәрсәм дә юк,— ди.

— Миңа шушылар җитәр,— ди егет.

— Алай булса,— ди сакчы,— әнә тегендә чуен капка булыр, шул капканы ачып керә алсаң, ашарыңа бирермен,— ди. Шуннан егет чуен капканы сугып вата да сарайның эченә кереп китә. Сакчы моның көченә шакката. Бу сакчы Таңбатырны бер бүлмәгә алып кереп ашата, эчертә. Ашап-эчкәч, егет сораша бу сакчыдан:

— Хуҗаң кайчан кайта, кая таба китте?— ди.

— Әнә теге калын урман ягыннан кайта, ди. Анда бер алтын күпер булыр, ди. Дию пәрие, алтын атка атланып, әнә шул күпердән кайтыр. Үзенең этен иярткән булыр,— ди.

Егет әйтә:

— Мин хәзер ял итәргә ятам. Хуҗаң кайтыр вакыт җиту белән, мине уятырсың, уянмасам, менә шушы без белән чәнчерсең,— дип, сакчыга бер без бирә.

Егет яту белән йокыга китә. Бер көн, бер төн үтте дигәндә, Диюнең кайтыр вакыты җитә. Сакчы егетне уятып карый, кая ул, теге кузгалып та карамый. Шуннан соң сакчы егет биргән безне, алып, бот итенә чәнчеп җибәрә, егет: «Ай, рәхмәт, бик вакытлы уяттың әле»,— дип сикереп тора. Сакчы шундагы мичкәдән бер чүмеч су алып бирә:

— Менә бу суны эчеп кит, көч кертә торган су бу,— ди. Егет суны эчә. Шуннан соң сакчы Таңбатырны тагын бер бүлмәгә алып кереп әйтә:

— Диюнең үзенә килгән кешене өйгә алып кайта торган гадәте бар. Менә монда ике мичкә бар, аның берсендә көч кертә торган су, икенчесендә хәл бетерә торган су, ди, син шуларның урыннарын алыштырып куй,— ди. Егет, мичкәләрнең урыннарын алыштырып куйганнан соң, сакчы белән саубуллашып чыгып китә дә теге алтын күпер астына кереп ята.

Бер дә бер вакытны Дию, алтын атына атланып, этен ияртеп, күпергә кайтып җитә. Диюнең эте, күпергә кермичә, кире хуҗасы янына чабып, елаган сыман итә. Диюнең моңа бик каты ачуы килә. Бик нык камчы белән сугып җибәрә дә күпер өстенә кереп китә бу. Ат күпер уртасына килеп җитү белән шып туктый. Дию атын сугып та карый, ат бер генә адым да алга атламый, ди. Шуннан соң Дию, атына бик каты ачуланып:

— Нәрсә син, әллә монда Таңбатыр килер дип куркасыңмы, Таңбатыр анасыннан да тумагандыр әле,— ди. Дию пәриенең шулай дип әйтүе генә була, Таңбатыр күпер астыннан килеп тә чыга:

— Таңбатыр анасыннан да туган, килеп тә җиткән,— ди. Дию пәрие әйтә:

— Мин сине бик олы гәүдәлеме дип уйлаган идем, син бик бәләкәй икәнсең. Сине ике кабарга, бер йотарга була икән,— ди.

— Ашыкма, тамагыңа утырыр,— ди.

Шуннан соң Дию әйтә:

— Алай булгач, көрәштәнме, алыштанмы?— ди.

— Алыш атаң башына булсын, көрәш синең башыңа булсын, мин синең агаларыңны үтереп бетердем инде,— ди.

Шуннан тотыналар болар көрәшергә. Көрәшәләр, көрәшәләр, бер-берсен җиңә алмыйлар. Көчкә көч туры килә инде боларның. Бик озак йөри торгач,

Таңбатыр тегене арыта. Шуннан соң Дию пәрие сизенә башлый. «Тукта, ди, бу минем хәлне бетереп үтерә күрмәсен, өйгә кайтып ял итим әле мин»,— дип уйлый. Әйтә Таңбатырга:

— Өйгә кайтып, бераз ашап-эчик, ди. Аннан соң яңадан көрәшергә тотынырбыз,— ди.

Дию пәрие сараена кайтып ашыйлар-эчәләр болар. Дию пәрие, мичкәләрнең алыштырылганын белмичә, көч кертә торган су урынына көч бетерә торган мичкәдәге суны эчә. Таңбатырга көч кертә торган суны бирә. Шуннан соң болар китәләр яңадан теге күпер янына. Барып җитәләр.

Дию әйтә:

— Алыштанмы, сугыштанмы?— ди.

— Алышудан курыксаң сугышырга да була, әйдә, сугышабыз,— ди. Күпер янындагы аланга төшәләр. Шуннан шобага салалар — кемгә алдан сугарга килеп чыга. Дию пәриенә алдан сугарга килеп чыга. Иң элек Дию пәрие китереп бәрә Таңбатырга. Таңбатыр тубыгыннан җиргә кереп бата. Аягын җирдән тартып алып, Таңбатыр сугып җибәрә тегеңәргә, Дию пәриенең аягы тезеннән җиргә бата. Дию пәрие торып сугып җибәрә, Таңбатыр тезеннән бата. Таңбатыр яңадан сугып җибәрә, Дию пәрие биленнән бата. Дию пәрие кабалана-кабалана чыга да Таңбатырга китереп суга, Таңбатыр биленнән бата, чыгарга тырышып карый, чыга алмый.

Дию әйтә:

— Чык, чык, борча, ди, нишләп ятасың туфракта?— ди.

— Кайгырма, ди, борча чыгар ул, менә син ничек чыгарсың икән?! — ди.

Шулай ди дә бөтен көче белән бер селкенеп җибәрүе була — сикереп чыга бу. Дию каршысына килеп баса да кизәнеп, Диюгә сугып җибәрә, Дию муеныннан җиргә бата. Шуннан Таңбатыр әйтә:

— Чык, күсәк, ди, нишләп ятасың анда? — ди.

Дию пәрие тәмам хәлдән тая. Таңбатыр, кылычын алып, Дию пәриенең башын өзеп төшерә, гәүдәсен өстерәп чыгарып, вак-вак итеп тураклый да әрдәнә итеп өеп куя.

Таңбатыр, Диюнең атына атланып, алтын сарайга кайтып китә. Моны теге сакчы бик шатланып каршы ала:

— Әй егет, ди, мин сакчы солдат түгел бит, мине шулай киендерделәр генә, мин фәлән патшаның кече кызы бит, ди, мине дә алып кайт, үзеңнән калдырма,— ди.

Таңбатыр моңа патша язуын бирә дә әйтә:

— Мин синең апаларыңны да коткардым инде, ди. Апаларың абыйларыма чыкмакчы булдылар, риза булсаң, син минем җәмәгать булырсың,— ди. Риза булышалар да үзләренчә шунда ук туй да ясап алалар. Берничә көн кунак булып ял иткәч, туталары янына кайтырга әзерләнәләр. Юлга чыгар алдыннан, егет әйтә:

— Әй, бу алтын йортлар әрәм булып калалар бит,— ди.

Кыз әйтә:

— Син алар өчен кайгырма, җае табылыр,— ди. Шуннан соң болар юл кирәкләрен алып, атка атланып чыгып китәләр. Бераз киткәч, кыз, алтын сарайга таба әйләнеп, кулъяулыгын селтәгән иде, алтын сарай алтын күкәй булып тәгәрәп килеп керә кызның кулына. Кыз бу алтын күкәйне яулыкка төрә дә егеткә бирә:

— Мә, син сакла инде моны,— ди.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Интонация төсмерләренә әһәмият биреп, әкиятне укыгыз. Текстка бергәләп сораулар уйлагыз.
2. Таңбатырның кылган эшләре батырлыкмы? Сез ничек бәялисез?
3. Укылган өлештән сурәтләү чараларын табыгыз һәм укып күрсәтегез.

2

Баралар, баралар болар, җиде тәүлек үтте дигәндә барып җитәләр теге көмеш сарайга. Патша кызлары елашып күрешәләр. Өч көн, өч төн көмеш сарайда

кунак булганнан соң, әзерләнеп, юлга чыгып китәләр. Бераз җир баргач, патшаның уртанчы, кызы көмеш сарайга борылып, кулъяулыгын селкеп җибәргән иде, көмеш сарай, көмеш күкәйгә әверелеп, моның кулына тәгәрәп килеп керә. Патша кызы көмеш күкәйне, яулыгына төреп, егеткә бирә дә әйтә:

— Мә, ди, бусын да син сакла инде,— ди.

Баралар, баралар, ди, болар, җиде тәүлек киткәч барып җитәләр теге бакыр сарайга. Барып керәләр. Апалары белән елаша-елаша күрешәләр. Апалары сый-хөрмәт күрсәтә боларга. Бу сарайда да өч көн, өч төн кунгач, болар, хәстәрен күреп, юлга чыгып китәләр. Бераз җир киткәч, олы апалары, бакыр сарайга таба карап, кулъяулыгын селкеп җибәрә. Теге сарай бакыр күкәй булып йомарлана да тәгәрәп килеп керә кызның кулына. Патша кызы бакыр күкәйне, яулыгына төреп, егеткә бирә:

— Мә, ди, син сакла инде боларны,— ди. Таңбатыр бакыр күкәйне дә, алып, кесәсенә салып куя.

Ярар. Китәләр болар. Бара-бара барып җитәләр теге кое төбенә. Кое төбенә җитү белән, Таңбатыр арканның очыннан тотып селкетә инде, «тартып чыгарыгыз безне» дип белдерә. Иң элек олы апалары арканга тотына. Аны тартып чыгаралар. Ул килеп чыгу белән, Таңбатырның абыйлары үзара сугыша башлыйлар: «Бу миңа да бу миңа»,— дип. Патша кызы әйтә:

— Мин олы апалары, иң олыгызга булырмын, без өч кыз, өчебез өчегезгә булырбыз, сугышмагыз,— ди. Боларга арканны төшерергә куша. Арканны төшереп, уртанчы кызны тартып чыгаралар. Уртанчы кыз чыккач, болар тагын сугышырга тотыналар. Уртанчы кыз апасыннан матуррак икән.

Кызлар әйтәләр:

— Сез алай сугышмагыз әле, анда безне, табып, Дию кулыннан коткарган энегез бар, безнең сеңелебез бар. Аларны кое төбеннән тартып чыгарыгыз,— диләр.

Сугышып аргач, тегеләр арканны төшереп җибәрәләр. Аркан төшү белән, кыз әйтә:

— Башта сине тартып алсыннар, ди. Үзең чыккач, син мине тартып чыгарырсың, югыйсә алар сине тартып чыгармаслар,— ди.

Егет әйтә:

— Юк, ди, мин синең үзеңне генә җир астында калдыра алмыйм, башта син чык, аннан соң гына минем чыгу турында уйларга булыр,— ди.

Егет, аркан очын элмәкләп бәйләп, кызны шуңа утыртып чыгарып җибәрә. Кызны тартып алалар да, матурлыгын күреп, яңадан сугыша башлыйлар болар. Кыз әйтә:

— Мин барыбер сезгә булмыйм, ди, сезнең энегез Таңбатыр белән сүз куештык бергә булырга,— ди. Кызлар өчәүләп тегеләрне кыстыйлар Таңбатырны тартып чыгарырга. Ярар, тегеләр арканны төшереп җибәрәләр. Таңбатыр арканга ябышып чыгып җитәм генә дигәндә, абыйлары арканны кисеп җибәрәләр. Таңбатыр кое төбенә төшеп китә. Кызлар елашып калалар. Таңбатырның агалары юлга чыгарга җыена башлыйлар.

Ярар, инде без Таңбатырга килик. Таңбатыр, кое төбенә килеп төшкәч, бик озак вакытлар һушына килә алмый ята. Өч көн, өч төн ятканнан соң, бу әкрен генә кузгалып торып китә. Йөри, йөри бу, йөри торгач, тагын теге Тычканга очрый. Тычкан моның каршысына килеп чыгып тилпенеп җибәрә дә кеше сурәтенә керә:

— Нихәл, Таңбатыр, тагын бу хәлгә төшкәнсең икән син,— ди.

Таңбатыр әйтә:

— Шулай булды шул, ди, җир өстенә чыгарга юл эзләп йөрим дә, бер дә җай юк әле,— ди.

— Сиңа моннан чыгарга бу тирәдә бер хәйлә дә табып булмас,— ди Тычкан.— Теге соңгы Дию белән сугышкан җирдән узып китәргә тырышып кара, шул

тирәдән узып китә алсаң, бер-бер хәл булыр, ди. Шул алтын күперне узгач булыр бер биек тау, шул тауда йөрер ике кәҗә тәкәсе, ди. Ул кыр кәҗәләренең берсе — ак, берсе кара булыр. Алар бик йөгерек булырлар, ди. Менә шул ак кәҗә тәкәсен тотып атлана алсаң, ул сине җир өстенә чыгарып куяр, ди. Ә кара кәҗә тәкәсен тотсаң, ул сине йә үтерер, йә тагын да тирәнгәрәк алып төшеп китәр, ди. Аны тота күрмә,— ди.

Шуннан Таңбатыр, Тычканга рәхмәтләр әйтеп, әлеге юл белән китә. Атна китә, ай китә. Бара торгач барып җитә, ди, бу теге тауга. Кәҗә тәкәләрен эзләп табып, шуларның агын куып йөри башлый бу. Артыннан җитеп тотып алыйм гына дигәндә, кара кәҗә тәкәсе арага килә дә керә, тотарга комачаулый. Күп йөри торгач, ак тәкәне эләктереп ала. Тотылгач, тәкә сорый инде моннан:

— Йә, егет, син мине тотарга бик тырыштың инде, ди, нинди теләгең бар иде соң?— ди.

— Теләгем шул: мин якты дөньяга чыгарга телим,— ди. Ак кәҗә тәкәсе әйтә:

— Мин сине якты дөньяга чыгарып җиткерә алмам анысы, шулай да чыгу юлына төшереп җибәрермен, теге ягын синең үзеңә эзләп табарга туры килер,— ди.

— Озак барырга туры килерме соң безгә? — ди егет.

— Байтак җир барасы булыр, ди, син менә миңа атлан, ди, йом күзеңне, мин әйтмичә ачма,— ди. Шулай ди дә кыр кәҗәсе җилдәй чабып китә, ди, егет көчкә генә тотынып утыра, ди, моның өстендә.

Азмы-күпме вакыт үткәндер, теге кәҗә тәкәсе Таңбатырга әйтә:

— Ач күзеңне,— ди.

Күзен ачып җибәрсә, егет күрә: тирә-як яп-якты. Бик шатлана бу. Ак кәҗә тәкәсе әйтә егеткә:

— Вакытыңны үткәрмә, ди, әнә тау битеннән бер юл китәр, шул юл белән барсаң югалмассың,— ди. Шулай ди дә күздән дә югала.

Ярар, Таңбатыр китә шул юл белән. Бара, бара бу, бара торгач барып чыга бер ут ягылган урынга. Килеп, көлне актарып карый, көл астыннан бербөтен ипи чыга. Ипи өстенә «Таңбатыр» дип язылган була. Шуннан соң бу: «Әһә, мин болар артыннан төшкәнмен икән, өйгә таба кайтам икән»,— дип уйлый. Ипине алып ашый да шул урында ятып ял итеп ала. Торып китә бу, бара торгач, янә килеп җитә бу ут ягылган урынга. Көлне актарып карый, моннан да бербөтен ипи килеп чыга. Ипи пешәр-пешмәс кенә булып, җылы гына булып ята, ди. Ипине алып ашый да, ял итеп тә тормыйча, юлга чыга бу. Бара торгач барып җитә егет кешеләр туктап, утлар ягып, ашлар пешереп утырган бер җиргә. Көлне актарып карый, моннан бер чи ипи чыга. Әле ипи диярлек тә түгел, камыр көе генә, пешеп тә җитмәгән. «Әһә, ди, боларның артыннан җитеп киләм, ахры»,— ди. Китә бу, ару-талуны да белми. Бара торгач барып җитә урман буендагы аланлыкка. Бу барып җиткәндә, абыйлары, ял итәргә туктап, шалашлар корып кына торалар икән. Бу килеп җитү белән, абыйлары аптырашта калалар; кызлар, елаша-елаша Таңбатырны каршы алып, аңа сый-хөрмәт күрсәтәләр. Кич җитү белән, өч агай-эне өч җиргә йокларга яталар. Таңбатыр йокыга китү белән, агалары үзара киңәшләшә, сөйләшә башлыйлар, ди. Олы абыйсы әйтә: «Без моңа бик күп зыян эшләдек, ул барыбер бездән үчен алмый калмас»,— ди. Уртанчы абыйсы әйтә: «Яхшылык көтмә инде син аннан, ди, ничек кенә итеп булса да котылырга кирәк»,— ди. Сөйләшеп сүз беркетәләр дә Таңбатыр яткан шалашның ишегенә аркылыга кылыч куялар, үткен ягы белән каратып. Төн уртасы җиткәч, болар: «Харап итәләр, талыйлар!» — дип, яман тавыш белән акыра башлыйлар. Таңбатыр, йокысыннан уянып, палаткадан йөгереп чыгыйм дигәндә, үткен кылычка килеп бәрелә дә ике аягын да өздерә. Инде бу кузгала да алмый, шып итеп утыра бу шунда. Агалары әйберләрен алай-болай җыештыралар да кызларны алып кайтып

китәләр. Таңбатырның кәләше инәлеп-инәлеп сорый абыйларыннан: «Мине аның янында калдырыгыз»,— дип, тегеләр, кызның ай-ваена карамыйча, аны көчләп алып кайтып китәләр.

Ярар, тегеләр өйләренә кайта торсыннар, без Таңбатыр янында калыйк.

Таңбатыр ята тегеләрдән янып калган ут янында. Шуыша-шуыша йөреп, аннан-моннан утын-фәлән китерә бу, утны сүндерми тота, юкса эш начар бит.

Көннәрдән бер көнне моннан ерак түгел генә бер җирдә бер кеше күренә. Бу кеше киекләр артыннан куып җитә, тик тота алмый, ә үзе тегермән ташы бәйләгән. Таңбатыр моны үзе янына чакырып ала. Сорый моннан:

— Син монда нишләп йөрисең?— ди.

— Мин сукыр кеше, ди, минем йөгереклектән көнләшеп, агаларым минем ике күземне сукырайттылар да шушы җирләргә китереп калдырып киттеләр,— ди.

— Аягыңа нәрсә бәйләдең соң син?— ди Таңбатыр.

— Күрәсең ич, бәйләмәсәм, йөгерүем чамасызга китә,— ди.

Болар шулай сөйләшә-сөйләшә танышалар да икесе бергәләп көн итәргә булалар.

Ике-өч көннән соң болар янына өченче берәү килеп чыга. Бу кулсыз бер кеше икән, ди. Бу да абыйларыннан зыян күргән яшь егет икән, үзе чиксез-чамасыз көчле икән.

Яши башлыйлар болар өчәүләп, дус булып. Сукыр белән кулсыз ашарга китерә, ә Таңбатыр ашны әзерләп тора.

Көннәрдән бер көнне болар үзара сөйләшәләр: «Безгә аш пешерүче табарга кирәк»,— диләр. Китәләр болар шәһәр эзләп, аяксыз кулсызга ияpә, кулсыз Таңбатырга ияpә. Шулай итеп, бик озак вакытлар йөри торгач, бер шәһәргә барып керәләр. Бөтен шәһәр халкы боларны карарга чыга. Шул халык арасында патша кызы да бар

икән, ди. Ул арада булмый, болар шул патша кызын эләктереп алып та китәләр, ди. Куалар болар артыннан, кая ул теге йөгерек артыннан җитү, тегеләрне син күр дә мин күр.

Кайтып җитә бу өч батыр үзләре торган җиргә. Кызга әйтәләр:

— Без сине үзебезнең сеңелебез кебек кенә тотарбыз. Син безгә аш әзерләрсең, тик утны гына сүндермә, диләр. Бүтән эш юк сиңа,— диләр.

Болар һәр көнне өчесе дә җәнлек ауларга чыгып китәләр, кыз өйдә кала. Беркөнне шулай кыз, ничектер, йокыга китә дә уты сүнә. Уянып китә бу, утның сүнгәнлеген күреп куркуга төшә: «Агаларым ачуланырлар инде мине»,— ди. Йөгереп чыга да, бер биек агач башына менеп, тирә-якларны карый. Еракта-еракта, елтыр-елтыр итеп, тычкан күзе хәтле генә бер ут күренә. Шул утны эзләп китә бу кыз. Бара торгач килеп җитә бу кечкенә генә бер җир өйгә. Бәләкәй генә ишеген ачып керә. Аның эчендә бер карчык утыра икән, ди. Бу Убырлы карчык икән. Кыз килеп керү белән, Убырлы карчык сорый кыздан:

— Йә, кызым, килдеңме, ди, нәрсә эзләп йөрисең? — ди.

— И әби, ди,— утым сүнде, ут эзләргә дип чыккан идем,— ди.

— Ярар, кызым, мин сиңа ут бирермен, минем бер кешем дә юк, миңа бик күңелсез, иртәгә мин сиңа кунакка барырмын, икәү иркенләп кенә сөйләшеп утырырбыз,— ди.

— Ярар, әби,— ди кыз,— тик син ничек табарсың икән безне? — ди.

— Менә мин сиңа бер чиләк көл бирәм, ди, шул көлне үзең кайта торган юлның ике ягына сибә барырсың, мин шул юлдан, шәт, сезнең янга барып чыгармын,— ди карчык.

Кыз, карчык биргән утны өенә алып кайтып, абыйлары кайтканчы, аш-суны әзерләп куя. Тегеләр ашап-эчеп

ятып йоклыйлар да икенче көнне тагын ауга чыгып китәләр.

Абыйлары чыгып китү белән, теге карчык килеп керә бу кыз янына. Бераз утырганнан соң, карчык әйтә:

— Балакаем, ди, син минем башымны кара әле,— ди.

Кызның алдына ята, кыз моның башын караган вакытта, карчык кызның ботыннан канын суыра икән, ди. Бу карчык кызның канын суыра-суыра да торып кайтып китә. Шуннан соң бу карчык, кызның абыйлары юкта килеп, һәр көнне кызның канын суырып китә торган булган. Кыз, көннән-көн ябыга, кибә барып, тора-бара коры сөяккә генә калган, ди. Абыйлары, кызның ябыкканнан-ябыга баруын күреп:

— Сеңелем, соң син нигә болай ябыгасың, сагынасыңмы, чирлисеңме? — дип сорыйлар кыздан. Кыз әйтә:

— Сагынмыйм да, чирләмим дә, тик болай гына ябыгам,— ди, яшерә инде болардан.

Тора-бара кыз бөтенләй йөри алмый башлый, аяксыз кала. Шуннан соң гына кыз әйтә абыйларына:

— Менә шулай-шулай, ди, утым сүнгәч, мин бер карчыктан ут алып кайткан идем, ди, шул карчык миңа ияләнде, һәр көнне, килеп, минем канымны суыра,— ди.

Абыйлары, үзара сөйләшеп, бу карчыкны тотып үтерергә булдылар. Шулай сөйләштеләр дә кыз янында сукырны калдырып киттеләр. Сукыр мич башына менеп утыра. Озак та үтми, карчык килеп керә дә, мич башында утырган сукырны күреп: «Ә, бу сукыр мине сакларга калдымыни?» — дип, сукырны мич башыннан өстерәп төшерә, аның аягын-кулын чәче белән бәйләп, үзе кызның канын суыра-суыра да чыгып китә.

Икенче көнне кыз янында калдыралар кулсызны. Карчык аны да шулай чәче белән бәйләп сала да кызның, алдына ятып, канын суырып китә.

Өченче көнне кыз янында Таңбатыр үзе кала. Кызга әйтә:

— Мин сәке астына кереп ятам, карчык бүген кайсысы калды дип сораса, алар бүген гел кайтмаслар, синнән курыктылар, калмадылар дип әйт, ди. Карчык, алдыңа ятып, каныңны суыра башлагач кына, аның чәчен сәке ярыгыннан төшер,— ди.

Берзаманны карчык килеп керә, бер дә шикләнмичә, кыз алдына ятып, аның канын суыра башлый. Кыз карчыкның чәчен ярыктан сәке астына төшереп җибәрә. Таңбатыр карчыкның чәчен, тартып алып, сәке астындагы аркылы агачка бәйләп куя да, үзе сәке астыннан килеп чыгып, карчыкны ярырга тотына — кай җиреҥ кычыта! Шул арада моның иптәшләре дә кайтып керәләр. Кулсыз тотына карчыкны типкәләргә, ә сукыр кай җиренә эләксә, шунда суга, ди. Карчык бөтенләй эштән чыга, ялына башлый, ди, боларга:

— Кыйнамагыз, ди, күзсезне күзле, аяксызны аяклы, кулсызны куллы итәм,— ди. Шуннан болар карчыкны ант иттерәләр. Карчык ант итә. Иң элек йоттыралар, ди, болар кызны. Кызны йотып җибәрә дә китереп чыгара авызыннан, элеккедән дә матур, элеккедән дә чибәр кыз булып. Аннан соң сукырны йоттыралар. Сукыр да ике күзле булып чыга, ди. Аннары кулсызны йотып җибәрә, ди. Кулсыз ике куллы булып килеп чыга. Таңбатыр әйтә:

— Карагыз, сак булыгыз, ди, ул мине йотуын йотар, кире чыгармас, ди. Мине чыгармыйча җибәрмәгез сез аны,— ди. Теге Убырлы карчык Таңбатырны да йотып җибәрә. Көтәләр моны, көтәләр, килеп чыгар дип, карчык космый гына бит. Карчыкны кыйнап та карыйлар, чыгармый. Шуннан соң теге сукырдан күзле булган батыр кылычын ала да карчыкны тураклый башлый. Кискәләп бетерәләр моны, ә Таңбатыр юк. Карыйлар бу карчыкның бер баш бармагы юк. Баш бармагын эзли башлыйлар, бу баш бармак карчыкның өенә таба китеп

бара икән. Тотып алып ярып җибәрәләр — Таңбатыр килеп чыга, элеккедән дә матур, таза булып. Бу өч батыр, бик шатланышып, берничә көн бергә торалар да үз илләренә кайтырга булалар.

Таңбатыр әйтә:

— Без сеңелкәйне үз иленә илтеп куйыйк башта,— ди. Бу кызга бик күп бүләкләр бирәләр дә, саубуллашып, теге бик шәп йөгерә торган батыр, кызны үзенә атландырып, бик тиз генә илтеп куя. Кызны илтеп кую белән, өч батыр, дусларча саубуллашып, бергә-бергә торган чакларын онытмаска сүзләр куешып, һәрберсе үз илләренә кайтып китәләр.

Ярар, Таңбатыр бик күп илләр үтеп, бик күп сулар кичеп, кайтып җитә үз иленә. Патша тора торган шәһәр читендәге бер карт белән бер карчыкка килеп керә. Таңбатыр әкрен-әкрен генә сораштыра башлый:

— Патшаның батырлары кайттымы, нәрсәләр алып кайттылар, патша кызларын таба алганнармы?— ди.

— Патша кызларын табып алып кайттылар,— ди карт,— тик батырларның берсе үлеп калган бугай,— ди.

— Туйлары булдымы соң?— ди.

— Юк әле, ди, менә бер көннән булырга тиеш,— ди. Шул сүзне ишетү белән, бу тиз генә бер игълан чыгарып кадаклый: «Мин, фәлән-фәлән итекче, патша кызлары туйда киярлек читек тегеп бирә алам»,— дип яза. Патша кызлары, моны ишетеп, теге картны эзләп киләләр дә өйалдына чакыртып чыгаралар.

— Бабай, син шулай-шулай дип әйткәнсең икән, син безгә иртәгә иртә беләнгә берәр пар читек тегеп җитештер,— диләр.

— Фәлән хак бирерсез, вакытына җитештерербез,— дип ышандырып алып калалар.

Патша кызлары китү белән, теге карт эшләргә утырмакчы була. Ә егет уйлап та карамый. Карт курка, борчыла башлый.

Егет әйтә:

— Ят та йокла син, бабай, мин үзем тегеп куярмын,— ди.

Карт белән карчык ятып йоклый. Төн уртасы килеп җитү белән, егет, урамга чыгып, өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә, өчесеннән өч пар читек килә дә чыга. Егет боларны алып кайтып, өстәл өстенә кертеп куя. Иртәнчәк карт тора.

Егет әйтә:

— Менә, бабай, ди, мин читекләрне тектем, ди, алырга килсәләр, үзем тектем дип әйтерсең. Никадәр сорасалар да, мин теккәнне әйтмә,— ди.

Иртә белән тегеләр килеп җитәләр. Картны чакырып чыгаралар.

— Бабай, тектеңме?— диләр.

— Тектем,— ди.

— Йә, чыгар әле,— диләр. Карт читекләрне чыгарып бирә.

— Менә карап карагыз, ошыймы сезгә?— ди.

Кызлар читекләрне алалар, бик ошый боларга.

— Моны кем текте?— дип сорыйлар.

— Үзем тектем,— ди карт.

Картка акчаны күп кенә итеп бирәләр. Шуннан соң тагын кайтарып сорыйлар болар:

— Йә, бабай, дөресен әйт: кем текте боларны? — диләр, моны кысалар инде. Теге һаман: «Үзем тектем»,— ди. Патша кызлары картка ышанмыйлар. Картка әйтәләр:

— Ярар, бабай, без, әти белән сөйләшеп, туйны чигерәбез, син андый һөнәрле оста булгач, безнең өчебезгә җөйсез өч күлмәк тегеп бир, күлмәкләр иртәгә өлгергән булсын,— диләр. Карт тагын ышандырып алып кала инде. Алып калмас иде, Таңбатыр, ни эшләргә кушсалар да алып кал, дип өйрәткән. Карт бу күлмәкләрне ничек кенә өлгертербез икән дип чабалана. Егет әйтә:

— Син кайгырма, ят та йокла, бабай,— ди.

Төн уртасы җиту белән, шәһәр читенә чыга да теге өч күкәйне тәгәрәтеп җибәрә. Өч күкәйдән өч күлмәк килеп чыга. Алып кайтып элеп куя бу күлмәкләрне. Иртә белән тегеләр килеп җитәләр. Карт күлмәкләрне чыгарып бирә. Патша кызлары шаккатып карап торалар да:

— Бу күлмәкләрне кем текте? — дип сорыйлар, шикләнәләр инде болар.

Карт әйтә:

— Үзем тектем,— ди. Патша кызлары картка тиешле хакын бирәләр дә:

— Менә без сиңа тагын бер эш кушабыз, болай һөнәрле кеше булгач, син бу эшне дә эшләрсең,— диләр. Карт нишләсен, теләсә-теләмәсә дә:

— Ярар, әйтеп карагыз,— ди.

Патшаның олы кызы әйтә:

— Иртә белән шәһәр читендә бер бакыр сарай салынган булсын,— ди. Уртанчы кызы әйтә:

— Көмеш сарай да салынган булсын,— ди. Кече кыз әйтә:

— Ике апама ике төрле сарай салынгач, минем өчен алтын сарай салынган булсын,— ди.

Карт каушап кала да соңыннан, теге егеткә ышанып: «Ярар, тырышып карармын»,— ди.

Кызлар кайтып киту белән, карт өйгә кереп әйтә:

— Бетте баш, патша кызлары безгә шундый-шундый эшләр кушып киттеләр,— ди. Үзе калтырана, күзләреннән яшьләр килә.— Нишләрбез икән инде, безнең бетүебез шушыдыр,— ди. Егет әйтә:

— Кайгырма, бабай, ди, син ят та йокла, ди, мин үзем башкарып чыгармын,— ди.

Таңбатыр, төн уртасында чыгып, күкәйнең өчесен өч җиргә тәгәрәтеп җибәрә, өч җирдә өч сарай калкып чыга.

Иртә белән егет бабайны уята:

— Карале, бабай, ди, өч җиргә өч сарай салдырып куйдым,— ди. Бабай бик шатлана, патшаның җәзасыннан котылабыз икән, ди.

Иртә белән патша кызлары иртүк бабай янына килеп җитәләр. Берсеннән-берсе матур өч сарайны күрү белән, болар Таңбатырның кайтуын беләләр. Картны чакыртып чыгаралар да әйтәләр:

— Нихәл, бабай, без кушканны эшләдеңме? — диләр.

Бабай әйтә:

— Күрмисезмени? — ди.

— Үзең эшләдеңме, бабай? — диләр.

— Үзем булмыйча, — ди карт, һаман теге егетнең барлыгын сиздерәсе килми, әйтмәм дип сүз биргән бит.

Кызлар, ышанмыйча, көлешә-көлешә, бабайның сакалларын тарткалап карыйлар. Юк, йолкынмый. Аннары үзара сөйләшеп алалар да:

— Ярар инде, бабай, без сине гаепләмибез, син безгә бу сарайларны салдыручы егетнең үзен күрсәт инде, — диләр.

Бабай, теләсә-теләмәсә дә, егетне чакырып чыгара. Патша кызлары Таңбатыр белән елаша-елаша күрешәләр.

Таңбатырның кайту хәбәре патшага да ишетелә. Патша егетне үз янына чакыртып ала. Кызлар әйтәләр әтиләренә:

— Безне Дию кулыннан коткаручы менә шушы егет, агалары аңа бик каты зыян иттеләр, — диләр.

Шуннан соң патша, Таңбатырның көченнән куркып, кече кызын, теләсә-теләмәсә дә, аңа бирергә мәҗбүр була. «Агаларыңны теләсәң нишләт, үзең хөкем ит», — ди.

Таңбатыр агаларын үз янына чакыртып ала да әйтә:

— Сез миңа зур зыян эшләдегез, шулай да астырмыйм, кистермим мин сезне, тик бу шәһәрдән чыгып китегез, күземә күренмәгез, — ди.

Тегеләр башларын иеп чыгып китәләр. Таңбатыр, патшаның кече кызын хатынлыкка алып, кырык

көн уен итеп, кырык көн туен иткәннән соң, үзенең әти-әниләре янына кайтып тора башлый.

Хәзер дә бик шәп кенә яшиләр икән, ди, болар. Кичә бардым, бүген кайттым.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Укылган өлешне үзегез аңлаганча сөйләп бирегез.
2. «Таңбатыр» әкиятенең төзелешендә нинди үзенчәлекләрне сиздегез? Билгеләп чыгыгыз, әйтеп күрсәтегез.
3. Әкияттән тылсым элементларын, фантастик вакыйгаларны табып укып күрсәтегез. Аларның нинди әһәмияте бар?
4. Тавыш үзгәрешен, интонация-басым төсмерләрен саклап, үзегезгә ошаган аерым урыннарны табып укыгыз.
5. Әкияттәге тылсым һәм фантазияне (хыялны) ничек характерларсыз? Мисаллар китерегез.
6. Әкият сөйләүченең интонациясе, хикәяләү рәвеше турында сөйләгез. Тексттан мисаллар укып күрсәтегез.

## ҮГИ КЫЗ

Борын-борын заманда бер кешенең ике кызы, бер улы булган. Кызларның берсе үги булганга, аны бер дә яратмаганнар. Беркөн киңәш иткәннәр дә ул Үги кызны урманга илтеп адаштырмакчы булганнар. Бу Үги кызга агасы әйткән:

— Әйдә минем белән урманга. Син җиләк җыярсың, мин утын кисәрмен,— дигән.

Бу Үги кыз йомгак белән чиләген ала да агасы белән урманга китә.

Урманга барып, байтак эчкәре кергәч, бер җиргә туктыйлар. Агасы атын тугарып ашарга җибәрә дә Үги кызга әйтә:

— Бар, син җиләк җый. Минем балта тавышы ишетелми башлагач килерсең,— ди.

Үги кыз, чиләген алып, җиләк җыярга китә. Аннан соң агасы бер зур агачка утын тукмагы асып куя да, атын җигеп, өенә кайтып китә. Үги кыз урманда җиләк җыеп кала.

Бу Үги кыз бервакыт җиләк җыя да тыңлап карый. Тыңласа, агачка асып куйган әлеге тукмак, җил белән селкенеп, тук-тук агачка бәрелә, Үги кызга балта тавышы кебек ишетелә.

«Агай әле һаман утын кисә икән»,— дип, ул җиләкне җыя да җыя.

Җыя торгач, чиләге тула. Ул арада кич тә була. Җил дә басыла.

«Инде агай утын кисеп бетергән икән»,— дип килеп караса, агасы юк, аннан җилләр искән.

«Инде нишләргә?» — дип, Үги кыз, елый-елый, урман буйлап китә. Бара торгач, кырга барып чыга. Анда аңа бер юл очрый. Юлга чыгып елый-елый бара бу мескенчәк. Бераз бара да:

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?— ди.

Бу сүзне әйтә дә елый, әйтә дә елый. Шулай бара торгач, бер ат көтүенә барып җитә бу. Көтүчегә әйтә:

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, көтүче? — ди.

Көтүче әйтә:

— Күрдем йомгагыңны, миңа бер көн көтү көтсәң, сиңа бер ат бирермен,— ди. Бу кыз, ярар дип, бер көн көтү көтеп, аннан бер ат алып, көтүче өйрәткән юл белән тагын китә.

Байтак җир баргач, сыер көтүенә барып җитә бу. Сыер көтүчесенә бер көн көтү көтеп, аннан сыер ала. Бара торгач, сарык көтүенә җитә. Шул рәвешчә, аннан да бер сарык ала. Кәҗә көтүенә җитә, янә аннан бер кәҗә ала. Шулай итеп бара торгач, беркөнне кич була. Күз бәйләнә башлый. Бик курка инде бу. «Инде нишләрмен?» — дип, баягы сүзне тагын кат-кат әйтеп елый.

Менә ул ерακта кечкенә генә бер ут шәүләсе күрә.

«Монда авыл бар икән»,— дип бик сөенә, атын тагын да юырттырыбрак китә. Ул ут авылның читендә генә бер кечкенә өйдә икән, шунда барып керә. Керсә, өйдә бер карчык утыра. Ул Убырлы карчык имеш. Шунда баягы сүзләрен тагын әйтә:

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, әбекәй? — ди.

Убырлы карчык әйтә:

— Кызым, син ерактан килгәнсең икән, инде минем кызым булырсың,— ди.

Иртәгесен торгач, Убырлы карчык бу кызны мунча ягарга җибәрә.

Кыз мунча ягып булдыра да, карчык янына килеп:

— Әби, инде мунча булды. Әйдә мунчага,— ди.

Убырлы карчык әйтә:

— Ярар, кызым, ди. Мин болай гына бара алмыйм. Син минем кулымнан тот, артыма тип, мине мунчага шулай итеп алып бар,— ди.

Кыз әйтә:

— Юк, әби, алай ярамас бит. Син карчык кеше инде, рәнҗерсең,— ди. Кыз карчыкны мунчага күтәреп алып бара.

Мунчага баргач, Убырлы карчык әйтә:

— Кызым, минем чәчемнән тотып, ләүкәгә сөйрәп менгер,— ди.

Кыз әйтә:

— Юк, әби, алай ярамас, син рәнҗерсең,— дип, карчыкны ләүкәгә күтәреп менгерә. Шуннан карчык тагын әйтә:

— Кызым, син минем аркамны чап, тик себеркенең очыннан тотып, сабы белән чабарсың,— ди.

Кыз әйтә:

— Әби, алай ярамас бит,— ди. Карчыкның аркасын йомшак кына итеп чабарга тотына. Аннан соң мунчадан карчыкны күтәреп кайта да йомшак урынга яткыра. Моннан соң Убырлы карчык әйтә:

— Кызым, башым бик кычыта, азрак башымны тарасана,— ди.

Бу кыз тарак алып, карчыкның башын тарарга дип барса, ни күзе белән күрсен, карчыкның чәч бөртеге саен алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, асылташлар туп-тулы! Башын тарап бетергәч, карчык моңарга әйтә:

— Инде, кызым, бер биеп кара, синең биегәнеңне күрәсем килә,— ди. Кыз бии, әмма һич андый-мондый нәрсә коелмый. Аннан соң карчык тагын әйтә:

— Кызым, бар, мунчага барып карачы, мин кулаша[1] белән мунчага салат күтәргән идем, кипмәдеме икән?— ди.

Кыз мунчага барса, анда кулаша тулы алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, кыйммәтле ташлар. Кыз мунчадан кайткач, карчык аңардан сорый:

— Кипкәнме, кызым?— ди.

Кыз әйтә:

— Кипкән, әби,— ди.

Карчык:

— Яхшы, кызым, алайса тагын бер биеп кара әле,— дигәч, кыз тагын бии. Тик андый-мондый бернәрсә дә булмый.

Аннан соң бу Убырлы карчык, кызның турылыгын белеп, аңа әйтә:

— Инде, кызым, өеңә кайтасың килсә бар, кайт,— ди.

Кыз әйтә:

— Әби, мин юл белмим шул, бик кайтыр идем,— ди.

Карчык әйтә:

— Юл белмәсәң, мин сиңа юлны күрсәтермен. Бу яшел сандыкны алып китәрсең, ул сиңа минем бүләгем булсын. Тик син аны өеңә алып кайтып җитмичә ачып карама,— ди.

Кыз, сандыкны алып, атына атланып, сыерын җитәкләп, сарыкларын, кәҗәләрен ияртеп, әбигә рәхмәт әйтә-әйтә, юлга чыгып китә.

Көн китә бу, төн китә, бара торгач, байтак җир китә. Инде авылга да якынлашып килә. Менә агасының этләре:

---

[1] *Кулаша (колаша)* — агачтан чокып ясалган сай улак.

— Үләргә киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң,— дип өрә башлыйлар. Бу кызның агасы белән, җиңгәсе:

— Бу этләргә ни булган, болар котырганнар, ахры,— дип, этләрне таяк белән кыйныйлар. Алай да булмый, этләр аның саен:

— Үләргә киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң! — диләр.

Ул ара да булмый, Үги кыз үзе кайтып җитә. Өенә кайткач, сандыкны ачып карый. Ни күзе белән күрсен, сандык эче туп-тулы алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән, кыйммәтле ташлар. Кыз шуннан баеп китә. Моны күргәч, агасы белән җиңгәсе бик көнләшәләр. Үзләренең кызларын да шулай ук җибәреп баетып кайтармакчы булалар.

Бу кыз да, йомгагын алып, агасы белән урманга китә. Урманга барып җитә, агасы атын тугарып җибәрә. Үзе китә утын кисәргә, ә кыз, чиләген алып, җиләк җыярга китә. Ул арада агасы, бер агачка утын тукмагы асып куя да үзе өенә кайтып китә. Бу кыз, тукмак тавышы ишетелмәс булгач, агасы янына дип килсә, аннан җилләр искән. Агасы кайтып киткән була. Аннан соң бу кыз урман буйлап китә.

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар? — дип әйтә-әйтә бара торгач, бер көтүгә барып җитә.

Көтүчегә әйтә:

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар?— ди.

— Күрдем. Миңа бер көн көтү көтсәң, бер ат бирермен,— ди.

— Миңа ат кирәкмәс,— дип, кыз аннан узып китә. Сыер көтүенә җитә, сарык көтүенә барып чыга, кәҗә көтүенә килә — берсенә дә көтү көтми.

Бара торгач, Убырлы карчык өенә барып җитә.

— Тәгәри китте йомгагым, күрмәдеңме, әбекәй? — дип, карчыкның өенә керә.

— Күрдем. Инде бар, кызым, мунча як! — дип, ул кызны мунча ягарга җибәрә. Аннан соң Убырлы карчык әйтә:

— Инде, кызым, мунчага барыйк. Син минем кулымнан тот, артыма тип, мине мунчага шулай итеп алып бар,— ди.

— Ярар, әби,— дип, бу кыз, карчык әйткән рәвешчә, аны кулыннан тотып, артына тибә-тибә алып бара.

Карчык әйтә:

— Кызым, аркамны чапсана, себеркенең очыннан тот, аркама сабы белән сук,— ди.

Бу кыз себерке сабы белән карчыкның аркасына дөп-дөп итеп ора да ора. Карчык ни әйтсә дә, ул әйткәнчә эшли бирә. Аннан соң карчык моңарга:

— Кызым, минем башымны тарасана азрак,— ди.

Кыз карчыкның башын караса, чәч бөртеге саен алтын да көмеш, кыйммәтле ташлар. Бу кыз, карчыкның башыннан алып-алып, алтын-көмешне кесәсенәдә тутыра, куенына да тутыра. Шуннан соң карчык әйтә:

— Кызым, инде син биеп кара, биегәнеңне күрәсем килә,— ди.

Менә кыз бии башлый. Кыз биегән саен, аннан чылтыр-чылтыр алтын-көмеш коела икән. Карчык кызны мунчага җибәрә:

— Карачы, кызым, мунчага салат күтәргән идем, кипмәдеме икән? — ди.

Кыз, мунчага барса, ни күзе белән күрсен, монда да, баягы кебек, кулаша тулы алтын-көмеш. Кыз тагын да алтын-көмешне кесәсенә, куенына тутыра. «Түти шулай итеп баеган икән»,— дип уйлый. Карчык кызга янә биергә куша. Кыз бии башлагач, баягыча алтын-көмеш, янә чылтырап, идәнгә коела башлый.

Шулай итеп, карчык бу кызны сынап бетергәч әйтә:

— Бар, кызым, кайтып кит инде, ди. Әнә фәләнчә юлдан кайтырсың,— дип, юл да күрсәтә.— Менә, кызым,

бу кара сандыкны алып кит,— дип, бер кара сандык та биреп җибәрә.

— Өеңә кайтып җитмичә ачып карама,— дип, бик каты кисәтә. Байтак җир китеп, үзенең авылына якынлашкач, агасының этләре тагын өрә башлыйлар.

— Баерга киткән түтекәй үлеп кайта түгелме, ләңләң! — диләр.

Агалары:

— Безнең бу этләр тилергән, ахрысы,— дип, таяк белән аннан да, моннан да ыргыталар. Этләр аның саен:

— Баерга киткән түтекәй үлеп кайта түгелме? — дип, ләң-ләң итеп өрәләр. Этләрне тагын кыйныйлар.

— Баерга киткән түтекәй баеп кайта, ләң-ләң, дип әйтегез! — диләр.

Ул арада кыз үзе дә кайтып җитә. Кайтып керүгә, кара сандыкны ачып та җибәрә, сандык эченнән бер кара елан шуышып чыга да, кызның муенына чорналып, шунда ук буып та үтерә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әкиятне рольләргә бүлеп укыгыз. Үги кыз белән икенче кызның тавышында нинди үзгәрешләр бар?
2. Үги кызның уңышка ирешүенә кайсы сыйфатлары ярдәм итә?
3. Убырлы карчык образы әкияттә ни өчен бирелгән дип уйлыйсыз? Аның икенче кызга биргән җәзасы белән килешәсезме?
4. Әкияттән эндәш сүзләрне һәм кабатлауларны табыгыз. Ни өчен «Үги кыз» диалог белән язылган? Диалог нәрсә ул?
5. Әкияттә яхшылык белән явызлыкның көрәше ни рәвешле бирелә?
6. Ни өчен «Үги кыз» көнкүреш әкияте дип йөртелә?

## ГӨЛЧӘЧӘК

Борын-борын заманда зур карурман эчендә бер Убырлы карчык торган, ди. Аның бер улы белән Гөлчәчәк атлы бер килене булган, ди. Карчык бик явыз икән, ди, гомер-гомергә яхшы кешеләрне аздырып, батырларны юлдан яздырып йөргән, ди. Карчыкның улы, анасының явызлыгына түзә алмыйча, дөнья гизәргә, бәхет эзләргә чыгып киткән.

Гөлчәчәк әниләрен бик сагына икән, тик аны каенанасы — Убырлы карчык — бер җиргә дә чыгармый икән, үзе, төннәрен яхшы кешеләрне аздырырга, батырларны юлдан яздырырга чыгып киткәндә дә, киленен өендә бикләп калдыра икән, ди.

Төннәрдән бер төнне Убырлы карчык, ниндидер явызлык эшләргә чыгып киткәндә, ишеккә йозак салырга оныткан, ди. Көлгә салган күмәчләрен дә калдырып киткән, ди.

Аның чыгып китүе булган, ишекнең ачык калуын белгән Гөлчәчәк әниләренә китәргә җыена башлаган, ди.

Урман эче бик якты,
Күктә айлар калыкты.
Көлдән күмәч аламын,
Әниләргә барамын,
Әниләргә барамын,—

дип җырлый-җырлый, куенына төче күмәч кыстырган да, ди, әниләренә кунакка чыгып киткән, ди.

Төн киткән, көн киткән, бара торгач, байтак җир киткән. Ул арада Убырлы карчык кире әйләнеп кайткан да килене артыннан куа чыккан. Соры бүре төсенә кергән дә, ди, җирне исни-исни чабып киткән, ди; чаба торгач, киленен куып җиткән, ди. Гөлчәчәкнең каршысына төшкән дә, ди, калын тавыш белән улап җибәргән, ди:

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем.

Күмәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан, күмәч биреп кенә котылыр иде дә, ул вакытта инде аның күмәче калмаган. Ары каранган, ди, бире каранган, ди, якында гына тузгак башлы, куыш эчле зур бер карама күргән, ди, шул карамага ялына башлаган, ди:

Әйләнмәле карама,
Бәйләнмәле карама,
Соры бүре куып җитте,
Яшерсәнә, карама,
Яшерсәнә, карама.

Әйләнмәле карама Гөлчәчәкне бик кызганган, ди, тиеннәр чикләвек җыеп, ярканатлар көн уздырып чыга торган кечкенә куышының ишеген ачып җибәргән иде, ди, Гөлчәчәк куышка кергән дә качкан, ди.

Соры бүре карама төбен тырный-тырный улаган да, ди, Гөлчәчәкне чыгара алмагач, таң алдыннан өенә кайтып киткән, ди.

Ул арада таң аткан, кояш чыккан, көн булган. Гөлчәчәк, карамага рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән. Бара торгач, кич булган; Соры бүре, килененең эзеннән исни-исни барып, тагын куып җиткән. Гөлчәчәкнең алдына төшеп, тагын улап җибәргән, ди:

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем.
Күмәчләремне бирмәсәң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан, ди. Ары караган, ди, бире караган, ди, түгәрәк аланда бик матур бер күл бар икән, Гөлчәчәк шул күлгә ялына башлаган, ди:

Түгәрәк алан, көмеш күл,
Көмеш күлнең суы мул.

Соры бүре куып җитте,
Яшерсәнә, көмеш күл,
Яшерсәнә, көмеш күл.

Көмеш күл Гөлчәчәкне бик кызганган, ди, тирән суын айкалдырып, дулкыннарын чайкалдырып, Гөлчәчәк басып торган җирне тирән су белән урап алган, Соры бүре күл читендә бүленеп калган, ди.

Соры бүре, күл читен тырный-тырный, төн буе улаган да, Гөлчәчәк янына керә алмагач, таң алдыннан тагын өенә кайтып киткән, ди.

Ул арада таң аткан, кояш чыккан, көн булган. Гөлчәчәк, көмеш күлгә рәхмәт әйтеп, тагын үз юлына чыгып киткән. Барган, ди, барган, ди, иртә киткән, кич киткән, китә торгач, урманның кырыена ук чыгып җиткән. Инде әниләренең өй түбәләре дә күренә башлаган, ди. Тик шул урында Соры бүре тагын куып җиткән дә бу юлы бигрәк тә каты ачуланып улап җибәргән, ди:

Көлтә-көлтә койрыгым
Болгый-болгый улаем.
Күмәчеңне ашатмасаң,
Калҗа-калҗа тураем,
Калҗа-калҗа тураем.

Гөлчәчәк бик курыккан. Ары каранган, бире каранган да басу кырыенда үсеп утырган кушкаенга менеп киткән, ди. Соры бүре кушкаенның тамырларын казый башлаган, ди.

Гөлчәчәк бик курка икән, ди. «Инде монда кайтып җиткәч тә, әниләрне күрмичә үләрмен микәнни соң?» — дип әйтеп, бик елап утыра икән, шунда кушкаен башына бер сыерчык килеп кунган, ди. Гөлчәчәк сыерчыкка ялына башлаган:

Ала муен сыерчык,
Кола муен сыерчык,
Чәч бөртегем — әманәтем,
Илтеп бирче, сыерчык,
Илтеп бирче, сыерчык.

Гөлчәчәк сыерчыкка ике чәч бөртеген алып биргән, ди; сыерчык, аны алып, Гөлчәчәкнең әниләренә очып киткән дә, ди, чәч бөртеген аларның капкаларына элеп куйган, ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы капка төбенә чыккан икән, чәч бөртекләрен күргән. «Әһә, кара юргам кашынып торганда, ял бөртекләре калган икән», — дип әйтеп, чәч бөртеген, алып кереп, думбрага кыл итеп тарткан, ди.

Гөлчәчәкнең җиңгәсе думбраны аяк тибеп бии-бии уйный башлаган икән, думбра кылы Гөлчәчәк булып җырлап җибәргән:

Бии-бии уйнама,
Билгенәем авыртa,
Тибә-тибә уйнама,
Түбәләрем авырта...

Моңар җиңгәсенең исе киткән: «Әбәү, бу думбрага ни булган?» — дип әйтеп, думбраны иренә биргән. Ире чиртеп-чиртеп уйный башлаган икән, думбра тагын җырларга тотынган:

Басма-басма, абыем,
Башкынаем авырта,
Чиртмә-чиртмә, абыем,
Чәчкенәем авырта.
Урман буе кушкаен,
Кушкаенда сеңелең бар.
Кушкаенның төбендә
Каенанам Убыр бар.
Думбраңны куй, абый,
Кушкаенга кил, абый.

Шуннан соң абыйсы: «Карасана, Гөлчәчәк сеңелем харап була язган бит», — дип, чукмарын алган да, ди, бүре тибә торган атына атланып, урман буена чапкан, ди. Ул барып җиткәндә, Соры бүре кушкаенның тамырларын актарып бетерә язган иде, ди; кушкаен, менә авам, менә авам, дип кенә торадыр иде, ди.

Гөлчәчәкнең абыйсы Соры бүрене бәреп үтергән дә, ди, Гөлчәчәкне өйләренә алып кайткан, ди.

Шуннан бирле Гөлчәчәк бик әйбәт гомер итә башлаган, ди.

Бүген барып, кичә кайттым, мин дә булдым аларда. Сый-хөрмәт бик дан булды, ашатканнары май, эчергәннәре бал булды. Ике мичкә, бер чүмеч, теләсәң күпме эч. Тик авызга эләкми, мыек кына чылана.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Башка әкиятләрдән «Гөлчәчәк» кайсы ягы белән аерыла? Анда катнашкан образларны әйтегез.
2. Әкияттә шигъри сөйләм, эндәш сүзләр ничек файдаланыла? Бу алым халык авыз иҗатының кайсы төренә якын?
3. Ни өчен Гөлчәчәккә кушкаен да, көмеш күл дә, сыерчык та ярдәмгә килә?
4. Әкияттәге шигырьләрне көйгә салып әйтеп карагыз, уңышлы чыкканын магнитофон тасмасына яздырыгыз.
5. Кайсы эпизод сезгә аеруча ошады, әсәрдәге шул урынны сурәтләгез (язмача, телдән, рәсем ясап).

## АЙ БЕЛӘН КОЯШ

Ай белән Кояш элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар. Шуннан соң, бөтен кошларны җыеп, шул турыда җыелыш ясаганнар. Бөтен кошлар, боларның бер җирдә торуларына риза булып, шуңа кул куйганнар.

Болар арасында бары бер генә кош кул куймыйча калган, ди. Ул булган Ярканат. Бүтән кошлар Ярканаттан сораганнар:

— Бөтен кошлар кул куйганда, нилектән син генә кул куймадың? — дигәннәр.

— Кулны мин,— дигән Ярканат,— шул сәбәпле куймадым, дигән, Кояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, җил бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәрләр, игеннәр дә Кояш төшкән җирдә генә үсәр. Кояш төшмәгән җирдә үсмәс,— дигән.

Шуннан соң бүтән кошлар әйткәннәр:

— Дөрес әйтә шул, Кояш төшмәгән җирдә иген үсми инде ул,— дигәннәр.

Ай белән Кояшка икесенә дә бер җирдә тормаска, әйләнеп йөрергә дип карар чыгарганнар, ди.

Шуннан соң Кояш әйткән Ярканатка:

— Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәм,— дигән.

Шунлыктан Ярканат көн яктысына чыгып йөри алмый икән.

Аңа Ай сүз әйтмәгән, шуңа күрә ул Ай яктысында бик әйбәт йөри, ди.

Ай белән Кояшның болай әйләнеп йөрүен бөтен кош-кортлар, бөтен халыклар бик дөрес дип кабул иткәннәр, ди. Шуннан соң игеннәр дә яхшы була башлаган, ди.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Ярканат, Ай һәм Кояшның диалогында дөреслек бармы? Ярканат җавабы ни өчен башка кошларның җавабыннан аерылып тора?
2. «Диалог» төшенчәсен искә төшерегез. Әкияттән диалогларны табып укыгыз.
3. Күк җисемнәре Ай белән Кояш турынданиләр беләсез? Алар кайчан үз күчәрендә әйләнеп чыгалар? Бу турыда ниләр укыганыгыз бар?

## АРЫСЛАН, БҮРЕ, ТӨЛКЕ

Бервакыт Арысланга сырхау тиде. Барча ерткыч хайваннар Арысланның хәлен сорарга килделәр. Ләкин Төлке килмәгән иде. Бүре, барып, Арысланга Төлкене яманлады. Арыслан Бүрегә әйтте:

— Төлке килсә, син миңа хәбәр бир! — диде.

Ул арада Төлке килеп җитте. Бүре тиз үк Арысланга барып әйтте.

Икенче ерткыч хайваннар моны Төлкегә белдерделәр:

— Бүре сине Арысланга барып яманлады,— диделәр.

Арыслан Төлкене чакырып китерде, әйтте:

— Син кайда идең, күренмәдең?— диде.

Төлке әйтте:

— Синең авырганыңны ишетеп, сиңа дару эзләргә бардым,— диде.

Арыслан әйтте:

— Соң ничек, дару таптыңмы?— диде.

Төлке әйтте:

— Һичбер дару табып китермәдем, ләкин шуны әйттеләр: Бүренең арт аягындагы сеңерен алып, шул Бүре сеңере белән дару итсәң, шаять, терелер идең,— диде.

Арыслан Бүрене тотты, арт аягын ярды да сеңерен өзеп алды. Бүренең аягы канап китте. Төлке кычкырды:

— Кая барасың, кызыл ыштан?! — диде.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Интонациягә әһәмият биреп (тиешле тавыш белән), әкиятне рольләргә бүлеп укыгыз.
2. Әкиятнең эчтәлеге сездә нинди фикерләр уята? Бүрегә бирелгән җәза белән килешәсезме?
3. Төлкегә тагын нинди сыйфатлар хас? Ни өчен халык арасында «төлке» сүзе кешенең кайсыдыр сыйфатын характерлау өчен кулланыла? Мисаллар китереп сөйләгез.

## ӘКИЯТЛӘР ТУРЫНДА

Безнең халык әкиятләр сөйләргә бик һәвәс. Ул әкиятләрне күңел кузгатырлык итеп, тәмләп, яратып сөйли белә. Иҗат талантының җимеше булган әкияттә берсеннән-берсе кызыклы, маҗаралы вакыйгалар үрелеп кенә бара. Шунлыктан әкият тыңлаучыны тиз җәлеп итә, аны бай хыял дөньясына алып керә, бигрәк тә балаларны әсәрләндерә. Анда халкыбызның уйтеләкләре, якты омтылышы, гаделлек һәм тәвәккәллек сыйфатлары калку сурәтләнә.

**Әкият** — халык авыз иҗатының бик борынгы төрләреннән берсе. Аның килеп чыгуын еллар саны белән

генә билгеләп булмый. Ул — сәнгатьчә фикер үсешенең гасырлар дәвамында формалашып килүен күрсәтә торган якты үрнәк. Әкиятләр башта талантлы кешеләр тарафыннан иҗат ителә, соңыннан авыздан-авызга, телдән-телгә күчеп тарала. Күчеш процессында ул фикри байый, заман үзгәрешләрен ала, матурлана һәм төзекләнә бара.

Әкияттә вакыйгалар тиз алмашынып тора, күз ачып йомганчы әкият герое колак ишетмәгән җирләргә барып җитә. Ул халык баласы, ярлы егет, карт белән карчыкның төпчек улы була, туган халкының бәхете өчен көрәшеп йөри, явыз көчләрне җиңеп, һәрчак азатлык яулап ала.

Татар халык әкиятләрендә очрый торган ярлы егетләрнең барысына да диярлек бер үк төрле уңай сыйфатлар хас: алар тапкыр сүзле, бик акыллы, күркәм холыклы һәм гаять булдыклы итеп тасвирлана.

Әкият герое үз язмышы турында күп уйлап тормый, ул бары хәрәкәт итә, патша сараена килгәч тә көтеп тормый, керергә рөхсәт тә сорамый, бара да керә. Бу яктан ул язма әдәбият образларыннан аерылып тора.

Әкиятләр, эчтәлегенә карап, төрләргә бүлеп өйрәнелә. Аларның бер төре ф а н т а с т и к яки т ы л с ы м л ы әкиятләр дип йөртелә. Чөнки алар хыялга (фантазиягә) гаять бай: иксез-чиксез диңгезләр, кеше үтә алмаслык кара урманнар, башын күккә чөйгән биек таулар, бер төн эчендә ясалган гүзәл сарайлар, ерактан күрсәтә торган сихри көзгеләр һәм тагын җир астындагы гаҗәеп дөнья турында сөйләнелә. Фантастик әкиятләр башка төр әкиятләргә караганда күләмнәре ягыннан зуррак, катлаулырак вакыйгаларны чагылдыра. Аларда хәрәкәт бик кызу, вакыйгалар әле чиксез зурайтылып (гипербола), әле бик кечерәйтелеп (литота) бирелә: Таңбатыр («Таңбатыр») җиде чуен капканы чукмары белән бер сугуда коеп төшерә, шулай ук җиде, тугыз, унике башлы диюләрне җиңә. Кешене

йотып җибәрә торган Убырлы карчык гаҗәпләнү, сискәнү хисләрен тудыра. Алтын, көмеш, бакыр сарайларның күкәй хәтле генә калуы, киселгән баш бармакка сыеп бетә алган егет күренеш һәм вакыйгаларны гаять кечерәйтеп күз алдына бастыра.

Тылсымлы әкиятләрнең геройлары — мифлардагы[1] Дию пәрие, Убырлы карчык, Су анасы, Йорт иясе һ. б. Алар бик борынгы заманнарда ук уйлап чыгарылганнар һәм ерак бабаларыбызның тышкы дөнья күренешләрен ничек күзаллавын чагылдыралар.

Әкиятләрнең икенче төре — хайваннар турындагы әкиятләр. Башкаларга караганда бу төр — иң борынгысы, ахры. Чөнки ерак бабаларыбызга иң элек дүрт аяклы хайваннардан сакланырга кирәк булгандыр. Моның өчен алар төрле ырымнар уйлап чыгарганнар, тора-бара хайваннар дөньясын өйрәнеп аучылык кылганнар.

Бу төр әкиятләрдә катнашучылар да — хайваннар. Аларның һәркайсы билгеле бер сыйфатка ия булган: бүре — комсыз, усал; куян — куркак; аю — авыр табигатьле; төлке — мәкерле, хәйләкәр, ялагай, куштан һәм алдакчы; ат — турылыклы; сарык — аңгыра; кәҗә тапкыр һәм хәйләкәр итеп сурәтләнә. Әкиятләрдәге хайван образлары аша кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр чагыла, аларның аерым сыйфатларына ишарә ителә.

Өченче төр — тормыш-көнкүреш әкиятләре. Алар, күләм ягыннан кыска булып, чынбарлык вакыйгаларын чагылдыралар. Мондый әкиятләрнең геройлары да тормыштан алына: көтүче егет, таз, акыллы килен, усал каенана, куркак солдат, тапкыр кыз һ. б. Тормыш-көнкүреш әкиятләрендә саранлык, ялагайлык, ялкаулык кебек тискәре сыйфатлар тәнкыйтьләнә, андыйлардан халык ачы итеп көлә.

---

[1] *Миф* (грекча) — «уйдырма, уйлап чыгарылган» дигән сүз.

Әкиятләрнең теле бик образлы, төрле бизәкләргә, сурәтләү чараларына гаять бай (мәсәлән: алтмыш колачлы ала айгыр; ат килсә, тоягы көя, кош килсә, канаты көя торган җир). Әкиятләрдә чеметтереп ала торган усал көлү белән бергә шаян тон, үткен юмор, җиңелчә көлүне дә очратырга мөмкин.

Әкиятне җанлы, кызыклы итеп сөйләүче кеше образы аеруча әһәмиятле, аның телендә бөтен нәрсә җанлана, әллә нинди төсләргә кереп балкый. Әкият сөйләүче телендә интонация төсмерләре алмашынып тора: гаҗәпләнү, сөенү, сагышлану, нәфрәтләнү, соклану һәм башка хисләрне тудыра.

Әкиятләр сөйләм телен үстерүгә ярдәм итәләр, алардагы чикләнмәгән хыял байлыгы яшь кешенең акыл зирәклеген арттыра, тормыштагы төрле хәлләрне бәяли белергә өйрәтә.

* * *

**Гипербола** («арттыру» дигән грек сүзеннән) — вакыйга һәм күренешләрне артык зурайтып сурәтләү.

**Литота** (грекча «кечкенәлек» дигән мәгънәдә) — вакыйгаларны бик кечерәйтеп тасвир итү.

**Фантастика** (грекча «хыял», «уйлап чыгару» дигән мәгънәдә) — чынбарлыкны сәнгатьчә тасвирлауның үзенчәлекле ысулы. Әкиятләрдә чынбарлык элементлары белән табигый булмаган күренешләр үзара ярашып киләләр. Тылсымлы әкиятләр фантастик вакыйгаларга аеруча бай.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Үзегез белгән, ишеткән әкиятләр турында фикер алышыгыз.
2. Дәрестә танышкан һәм укыган әкиятләрнең төрен билгеләгез. Алар арасындагы охшашлык һәм аерма нидән гыйбарәт?
3. Әкият ничек туа? Үз хыялыгызга нигезләнеп, әкият уйлагыз.

## МӘЗӘКЛӘР ТУРЫНДА

**Мәзәк** — халык авыз иҗаты әсәрләренең үзенчәлекле кечкенә жанры. Ул — кыска күләмле, көтелмәгән чишелешле, юмор һәм сатирага (ачы көлүгә) нигезләнгән чәчмә әсәр. Үзенең тапкырлыгы һәм көтелмәгәнчә тәмамлануы белән мәзәк тыңлаучының хисләрен кузгата, гаҗәеп акыл зирәклеге белән шаккатыра. «Замана килене» дигән мәзәкне карыйк. Анда картлар белән яшьләр арасындагы ямьсез мөнәсәбәтләр моңсу көлү тудыра:

Өйдә чәй куярга су беткән. Әби белән бабай, чиләк тотып, ишегалдына чыкканнар. Бабай:

— Мин барам,— дип әйтә, ди.

Әби аңа каршы:

— Юк, мин барам, тау менгәндә, синең тының бетәр, үзем барам,— дип әйтә, имеш, ди.

Килен көзге алдында бизәнеп маташа икән. Тәрәзәдән башын тыккан да:

— Нигә сез бала-чага шикелле юкка тавышланасыз? Алдан берегез алып кайтсын да, аннары икенчегез барыр,— дигән.

Бу мәзәктә киленнең мәгънәсезлеге һәм шактый оятсызлыгы җанга тия.

Мәзәк тормышның бөтен якларын иңли. Кешеләрдәге кимчелекне, мөнәсәбәтләрдәге тупаслыкны ул оста тотып ала. Мәсәлән, мактанчыклык кешене түбәнәйтүен, кыен хәлдә калдырганын «Җырчы» мәзәгендә күреп була:

Җырчы иптәшеннән сораган, ди:

— Кичә минем җырлаганымны тыңлагансың инде. Ишеттеңме? Тавышым залга сыймады!

— Юк, ишетмәдем, күрдем. Синең тавышыңа урын булсын өчен, кешеләр, залны буш калдырып, өйләренә кайтып баралар иде.

Мәзәктә күбрәк диалог өстенлек итә. Чөнки анда ике яки өч кешенең генә сөйләме бирелә. Берсе тапкырлыгы белән, икенчесе наданлыгы белән фикерләр бәрелешен китереп чыгара, моннан тыңлаучы рәхәтләнеп көлә. «Ашауны гына белгәч» мәзәген искә төшерик:

Шәһәрдән авылга бер егет кунакка кайткан. Алар авыл егете белән яшелчә бакчасы буеннан үтеп ба-

ралар икән. Шәһәр егете, бакчада үсеп утыра торган кәбестәләрне күреп:

— Бу нәрсә? — дип сораган.

Авыл егете:

— Кәбестә, — дип җавап биргән.

— Нинди кәбестә: тозлаганымы, әллә тозламаганымы? — дип сораган шәһәр егете.

Мәзәк һәрчак заман белән бергә атлый. Шул ягы белән ул фольклорның башка жанрларына караганда өлгерлек һәм җитезлек күрсәтеп килә. Хәзерге вакытта балалар мәзәкләре күбәеп бара. Аларда самимилек, риясызлык һәм дөреслек ачык бирелә. Бала тапкырлыгы кайчак өлкәннәрне дә хәйран итә, мәсәлән, «Наилнең шатлыгы» мәзәгендә:

Кечкенә Наил бик начар укыган. Ул һаман «2»ле алып кайта икән.

Әнисе, улын оялтмакчы булып:

— Рәүфә әнә гел «5»легә генә укый. Рәүфәдән үрнәк алыр идең, — дигән.

Беркөнне Наил мәктәптән бик шатланып кайтып кергән.

— Улым, әллә «5»ле алдыңмы? — дип сораган әнисе.

— Юк, әни, Рәүфә «2»ле алды! — дип җавап биргән Наил.

«Фамилияне корбан итеп» мәзәгендә малай үзенең эчкерсез, балаларча беркатлылыгы белән этисенең хәйләле ялганын ачып ташлый:

Мәгариф инспекторы белән мәктәп директоры урамнан барганда, бер малай агач сындырып ята икән.

— Бу нинди тәртипсезлек?! — дигән инспектор.

Директор кызарынган да малайга:

— Сабитов, нишләвең бу? — дип кычкырган.

— Әти, безнең фамилия алай түгел бит! — дигән малай.

Безнең халык арасында Хуҗа Насретдин исеме белән бәйле мәзәкләр яшәп килә. Аларга һәр заманның үзгәреше килеп керә. Хуҗа турындагы мәзәкләр аеруча яратып сөйләнә. Хуҗа бик тапкыр, кем булуына карамастан, ул дөресен ярып әйтә. Менә бер мәзәк:

Хуҗа өйдә юк чакта, аңа мулла килеп чыккан. Хуҗаның өйдә булмавына бик ачуы килеп, ишегенә «Ишәк» дип язып киткән.

Хуҗа, аны урамда очратып:

— Миңа килгәнсең икән,— дигән.

Мулла, гаҗәпләнеп:

— Каян белдең?— дип сораган.

Хуҗа аңа:

— Ишеккә исемеңне язып киткәнсең ич,— дигән.

Мәзәкләр һаман иҗат ителеп тора. Үз чорында мәзәкләрне Каюм Насыйри да җыеп бастырган. Хәзерге вакытта да мәзәкләрне җыю, туплап бастыру эше дәвам итә. Бу эшкә язучылар, галимнәр һәм халык үзе дә актив катнаша. «Мең дә бер мәзәк» җыентыгы (җыючысы — Г. Бәширов) , «Татар халык иҗаты. Мәзәкләр» китабы (Татарстан китап нәшрияты, 1979) басылып чыкты. Нәкый Исәнбәтнең «Балалар фольклоры» китабына (Татарстан китап нәшрияты, 1984) кергән әсәрләрне автор халыктан үзе җыеп бастыра. Анда балалар мәзәкләре дә байтак.

## МӘЗӘКЛӘР

### ИШӘК ӨСТЕНДӘ

Хуҗа, ишәгенә атланып, базарга китеп барганда, аның артыннан атка атланган бер бай килеп җиткән. Ул, Хуҗаны хурламакчы булып:

— Йә, ишәк өстендә бару ничек, әйбәтме? — дип сораган.

— Атка атланган ишәккә караганда, акыллы баш булып, ишәккә атланып йөрү күңеллерәк,— дип җавап кайтарган Хуҗа.

### ШАЙТАН НИ ТӨСЛЕ?

Бик тәкъва бер мулла тинтәккә санап йөртелгән бер кешедән сораган:

— Әй, сине шайтан белән сөйләшә, диләр. Шайтан ни төслерәк була ул?— дигән.

Тинтәк әйткән:

— Көзгедән кара әле, шул көзгедә күргәнең шайтанның нәкъ үзе булыр,— дигән.

## АЯГЫН КҮТӘРӘ ТОРГАН АТ

Бер колхозга шәһәрдән яңа председатель җибәргәннәр. Шәһәрдә туып үскәнлектән, моның үз гомерендә ат җиккәне юк икән. Көннәрдән бер көнне бу бер атны «киендереп» бирергә кушкан.

Бу атның тибә торган гадәте бар икән. Басудан кайткач, председатель ат карауч бабайга әйткән:

— Бар, чишендер, ләкин миңа бүтән аягын күтәрә торган ат бирмә! — дигән.

## УКЫТУЧЫ БЕЛӘН УКУЧЫ БАЛА

Укытучы балага сорау биргән:

— Ни сәбәпле кыш көне су бозга әйләнә?

Укучы бала әйтте, ди:

— Тимераякта шуарга яраклык булсын өчен.

## ТАРТЫЛМЫЙ ДА, СУЗЫЛМЫЙ ДА

Укытучы дәрестә бер малайга авазларның бүленешен сөйләргә кушкан. Малай:

— Тартыклар: б, в, г, д, ж. Сузыклар: а, ә, у, ү, я, ни...— дип туктап калган.

— Ә калганнар?

— Калган авазлар, апа, тартылмый да, сузылмый да,— дигән малай.

## ӨМЕТСЕЗ

Ике куян, икесе ике якка киткәндә, урман авызында саубуллашканнар. Берсе:

— Тагын кайчан күрешербез икән? — дип сораган.

Икенчесе моңа җавабында әйткән:

— Кайда булсын, безнеке билгеле инде, киләсе атнада тире-яры базарында,— дигән.

## ТӨБЕНДӘ ЮКМЫ?

Хуҗа Насретдин бик саран байга хезмәтче булып кергән. Бай көндезге ашка бурда сыман бернәрсә биргән. Анда берничә кишер сыман нәрсәдән башка берни дә юк икән. Хуҗа Насретдин урыныннан торган да чишенә башлаган.

— Нәрсә эшләргә җыенасың син, дус кеше? — дип гаҗәпләнгән бай.

— Комачаулама әле. Мин табакка чумып карамакчы булам. Аның төбендә берәр кисәк ит юк микән? — дигән Хуҗа.

## БЫЛТЫРГЫ «А»

Бер ялкау малай, начар уку сәбәпле, үзе укыган беренче сыйныфта икенче елга утырып калган. Менә икенче уку елы башланган. Укытучы апалары кара тактага зур итеп «А» хәрефен язып күрсәткән. Бу малай бик гаҗәпләнеп карап торган-торган да:

— Апа, былтыргы «А» бит бу! — дип кычкырып җибәргән.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Бирелгән мәзәкләрне дөрес интонация белән укыгыз, аларның мәгънәләрен һәм төзелешен ачыклагыз.
2. Мәзәкнең үзенчәлекле сыйфатларын билгеләгез, алар ничек туа? Шуңа мисаллар китерегез.
3. Мәктәп тормышын чагылдырган нинди мәзәкләр беләсез?
4. Балалар мәзәкләрен җыегыз. Алар турында үзара фикер алышыгыз.
5. Ни өчен мәзәкләр озак яшәүчән? Сез ничек уйлыйсыз?
6. Ялкаулык, наданлык һәм аңгыралык кебек тискәре сыйфатлардан көлгән нинди мәзәкләр беләсез? Аерым төркемнәргә бүленеп, үзара ярыш оештырыгыз.

**Мөстәкыйль эш.**

1. Мәзәкләргә багышланган стенд төзегез. «Яңа мәзәкләр» бүлеген тулыландырып торыгыз.
2. Үзегез тапкан берәр мәзәкнең эчтәлеген рәсем итеп ясагыз.

# *Абдулла Алиш*

## *(1908—1944)*

Абдулла Алиш — Муса Җәлилнең көрәштәш дусты, батыр йөрәкле солдат — әсирлектә дә үзенең кешелекле табигате белән мәгълүм шәхес. Ул — татар әдәбиятында балалар дөньясын киң сурәтли алган, нәни дусларының күңеленә кирәклек әсәрләр калдырган язучы. Балалар белән бик тиз уртак тел тапкан Абдулла Алиш, аларны очраткан саен, серле әкиятләр сөйләп, тәэсирләнүчән яшь күңелләрне матурлык дөньясына алып керә, белемгә, китап укырга дәртләндерә. Атаклы рәссамнар Лотфулла Фәттахов, Харис Якупов, язучы Җәвад Тәрҗеманов, үзләренең сөекле укытучылары итеп, Алишны сагынып искә алалар иде.

Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның сентябрендә элекке Казан губернасы Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Спас районы) Көек авылында туган. Аның туган ягы матур табигать кочагы, үзенең иркен болыннары, көзгедәй ялтырап яткан күлләре, шаулы урманнары белән әдипнең зәвыгы һәм нечкә хисләре формалашуда эзсез калмаган, билгеле. Нәни Абдулла китап дөньясына бик кечкенәдән тартыла. Гаилә дә шуңа этәргән булса кирәк: әтисе Габделбари агай улына беренче хәреф танырга өйрәтсә, укымышлы, сәләтле ана Газизә апа, үзе бәетләр, шигырьләр язып, иҗатка рухландыра. Абдулла Янбакты мәдрәсәсендә генә укып калмый, 1923—1927 елларда Спастагы рус

мәктәбендә белем ала, аның беренче шигырьләре шунда языла.

1927 елда Казанга килеп, җир төзелеше техникумын тәмамласа да, Абдулла әдәбиятка, язу эшенә тартыла, балалар журналында аның әкиятләре, очерклары дөньяга чыга. Чыннан да, А. Алиш әкият остасы булып танылып китә (егерме бишләп әкиятнең авторы ул): «Сертотмас Үрдәк», «Нечкәбил», «Куян кызы», «Койрыклар», «Мактанчык Чыпчык белән тыйнак Сыерчык» һәм тагын башка күп кенә әкиятләр иҗат итә. Бу әкиятләр бала күңелен нечкә сиземләп, аларны сөендерерлек һәм урыны белән көендерерлек итеп язылулары белән күркәм. Язучының балалар тормышын матур чагылдырган җыйнак хикәяләре дә («Бозлар акканда», «Тургайлар очканда», «Отряд умартасы», «Кадерле бүләк», «Беренче дәрес» һ. б.) яратып укыла, нәни укучылар арасында бик тиз популярлык казана.

1941 елда фашистик Германия белән сугыш башлангач, А. Алиш фронтка китә. Каты сугышларда чолганышта калып, әсирлеккә төшә. Седльце лагеренда күмәк качу оештыру турында уйлый башлый. Концлагерьларның берсендә Муса Җәлил белән очрашкач, аның планнары үзгәрә. Ул Җәлил җитәкләгән яшерен оешмага керә һәм фашистларга каршы көрәш башлап җибәрә. Әмма бу дәһшәтле көрәш — зур батырлык һәм гомереңне сораучы соңгы көрәш. «Ничек килер үлем?» шигыре солдат йөрәгенең пакьлеген, килер фаҗиганең ачыклыгын бер дә шөбһәсез күз алдына китерә:

Күпме кәгазь языла безнең хакта,
Бәлки, кабат аны укырлар,
Иптәше өчен кеше корбан була, —
Шундый инде безнең гасырлар.
Көрәш белән тудык, көрәш белән
Керәбез дә, ахры, кабергә.
Язган икән соңгы сулышыбызны
Илебез бәхете өчен бирергә.

«Без Берлин төрмәсендә ярты ел утырдык,— дип яза ул үзенең бер хатында.— Килдем, көрәштем, киттем. Күрәсең, безнең язмышлар шулайдыр инде. Без соңгы сулышыбызга кадәр үз халкыбызга тугрылыклы булып

калабыз...»[1] Мәгълүм ки, А. Алиш туган илгә әйләнеп кайта алмады. 1944 елның августында аны фашистлар Җәлил белән бергә җәзалап үтерәләр. Тоткыннар янына кереп йөргән Юрытко атакай аларның, үлемгә хөкем ителгәч тә, үзләрен тыныч тотуын сокланып искә ала[2].

Әсирлектә фашизмга каршы алып барган тиңсез батырлыгы өчен Абдулла Алиш вафатыннан соң I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

**Сорау һәм биремнәр.**

1. Абдулла Алиш турында нинди китаплар укыганыгыз бар? Шуларны исегезгә төшерегез һәм фикер алышыгыз.
2. Ватан сугышына багышланган берәр фильм карап яки берәр китап укып алган тәэсирләрегезне хикәя итеп языгыз. Дәрестән тыш шул хакта фикер алышып, уйланып карагыз.

## СЕРТОТМАС ҮРДӘК

Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер Үрдәк булган. Ул үзе, сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлыйтыңлый арып бетәләр йә бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. «Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим»,— дип башлап китә торган булган ул сүзен.

Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен иярткән, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!» — дигән.

[1] Муса Җәлил турында истәлекләр / Төз. Мостафин Р. Ә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 233 б.

[2] Шунда ук.— 249 б.

«Нигә белдермәскә кушты икән?» — дип, Үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.

Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу», — дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәргә булганнар. «Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!» — дигәннәр алар Үрдәккә. «Ләкин, берүк, нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» — дигәннәр. Үрдәк күнгән: «Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде», — дигән.

Иртә торгач та, Үрдәк уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча, бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре — тәпиләре — үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып, тәпи-тәпи дә йөгергән...

Бара-бара, куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән.

Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер Керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан:

— Кая барасың болай? — дигән.

Үрдәккә инде шул гына кирәк тә. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә оныткан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган:

— Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр, — дигән.

— Синең өең еракмы соң? — дигән Керпе. — Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? — дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик нык ашыйсы килә икән.

— Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара! — дигән Үрдәк.

Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын, тычканнарга көн бирмәүче мәченең шуклыгын да сөйләп биргән.

— Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр,— дигән. Керпенең бу акыллы киңәшенә Үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга, урман эченәрәк атлаган.

Бара-бара, Үрдәккә озын колаклы бер Куян очраган, һәм ул да аңардан сораган:

— Әй бүрекле Үрдәк, күзге төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?

— Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды,— дигән Үрдәк, Керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән. Куян эченнән генә: «Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән»,— дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге юләр моңа да серен ачкан.

— Хуҗаңны күргәнем юк,— дигән дә Куян, куаклык эченә кереп югалган.

Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара, бер аланлыкка барып җиткән. Анда бер зур соры Аю мышный-мышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан. Керпе белән Куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында Аюдан сораган:

— Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?

Аю:

— Күрмәдем,— дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган:— Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез, табарсың,— дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: «Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән»,— дип, ашыга-ашыга китеп тә барган.

Үрдәк һаман хуҗаны эзләвен дәвам иттергән. Аның саен урманның эченәрәк керә барган. Бара торгач, аның каршына Бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

— Әй бүрекле баш, шушындый куе урманда, япа-ялгызың гына курыкмыйча, батырланып, ничек йөрисең?— дигән. Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән. Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен Бүрегә дә әйткән. Усал Бүре тешләрен шыгырдаткан, үз-үзенә: «Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән»,— дигән, ә Үрдәккә: «Андый кешене күргәнем юк!»— дигән дә үзе куаклар арасына кереп югалган.

Үрдәк һаман туктамаган. Хуҗасын эзләүне һаман дәвам иткән. Күргән бер коштан, төрле ерткычтан, хәтта нәни бөҗәкләрдән дә бу турыда сорашып бара икән.

Бара-бара, аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер Төлке килеп чыккан. Теге дә ахмак бит, моңа да сүз кушкан:

— Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмәдеңме?— дигән.— Янында эте, кулында балтасы бар иде,— дип өстәгән. Хуҗасыз һәм этсез өйдәге хайваннарның тынычсызлануларын, алардан башка куркуларын да сөйләп биргән.

— Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны!— дигән Төлке.— Янында кәкре койрыклы эте дә, билендә корыч балтасы да бар иде,— дип өстәгән. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән. Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар. Шунда Төлкенең оясы буенда балалары уйнап йөриләр икән.

Алар:

— Әни, безгә азык алып кайттыңмы?— дип, аның тирә-юнен сырып алганнар, ә ул, авызын ерган килеш, Үрдәккә күрсәткән...

— Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите,— дигән һәм шул минут Үрдәкне буып, балаларына бүлеп тә

биргән. «Үрдәк ите бигрәк тәмле була икән!» — дип, алар, авызларын ялый-ялый, аны ашап та ташлаганнар, ләкин туймаганнар, аналарыннан тагын да сораганнар.

— Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам,— дигән Төлке. Балаларын калдырып, авылга киткән.

Бер сертотмас Үрдәк аркасында бу хуҗалык тәмам туздырылган булыр иде, ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган. Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән. Бүрегә дә сарыклар эләкмәгән, хуҗалык абзарына ул бөтенләй керә алмаган. Төлке хәйләкәр булса да сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа, кайткач инде, аның кирәген биргән... «Тагын берничәне тоткач, толып тектерермен»,— дигән һәм тиресен киптерергә амбарга элгән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр, сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар да бик нык үкенгәннәр.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әкияттә сурәтләнгән вакыйгалар сездә нинди фикерләр уятты? Моннан сабак алырга[1] мөмкинме?
2. Сертотмас нинди хайваннар белән очраша, һәм аларга нинди сыйфатлар хас?
3. Ни өчен йорт хайваннары хуҗаны эзләргә нәкъ менә Үрдәкне җибәрәләр?
4. Хайваннарның кайсысы Үрдәкне тиз генә алдауга ирешә? Ни өчен? Халык әкиятләре белән дә чагыштырып сөйләгез.
5. Хуҗа кешенең тапкырлыгы сезгә ошадымы? Аның Төлкегә биргән җәзасы белән килешәсезме?
6. Текстан сценарий төзеп, үзара уку оештырыгыз. Анда күбрәк нинди җөмләләр кулланыла? Аларны тиешле интонация белән укыгыз, тавышка, басымнарга әһәмият бирегез.

---

[1] *Сабак алу* — гыйбрәтле эш-хәлдән, вакыйгадан киләчәк өчен файдалы нәтиҗә ясау.

## НЕЧКӘБИЛ

(*Кыскартып алынды*)

1

Каршыгызда, менә күрәсезме, нәрсә соң ул, беләсезме?

Шашка шакмаклары төсле тезелеп киткән йортлар. Ул йортларда яшиләр кортлар.

Кортлар? Нинди кортлар?

Татлыдан-татлы бал җыялар, шәмгә яраклы балавыз коялар. Ерак-ерак җирләргә очып китәләр. Укларын кадасалар, еларга итәләр.

Аларның йортларын мәк чәчәге кебек кызылга, үлән төсле яшелгә, ком сыман сарыга, күк төсле зәңгәргә, төрле-төрле матур төсләргә буяганнар.

Әнә зәп-зәңгәр офык читеннән, көлә-көлә, алтын кояш та күтәрелә. Аның шаян нурлары, җиз уклары умарта өйләренең стеналарына тияләр дә:

— Торыгыз, торыгыз, эшкә тотыныгыз,— дияләр.

Башта сирәк-мирәк кенә, берәмләп кенә, бал кортлары ояларыннан чыгалар. Кояш югары менеп киткәч, һава җылынып җиткәч, көтүләре белән бергәләшеп, җиң сызганып, күмәкләшеп эшкә ашыгалар.

Зың-зың... Еракка-еракка, бакчаларга, кырларга, урманнарга, болыннарга...

2

Менә бу зәңгәр ояның хуҗалары бик күп аның. Кулыңдагы бармакларыңны мең тапкыр санасаң яки күктәге йолдызларның санын исәпләп карасаң, бәлки, аларның очына чыгарсың.

Барысыннан да алдан торып, «соңга калам, ахры» дип, бар көченә йөгереп, менә шушы зәңгәр йортның ишегеннән, сөйгән өе эченнән Нечкәбил тышкы якка чыкты.

Алмагач биеклеге күтәрелгәч тә, зәңгәр өйнең кайдалыгын билгеләде Нечкәбил: «Усаллар, килеп, өйне алмаштырмасыннар, Нечкәбилне саташтырмасыннар». Шуңа күрә ул өйнең төсен җентекләп карады. Өйнең төсе күк төсле зәңгәр. «Сау бул, өйкәем, матур гөлкәем»,— диде Нечкәбил, өе өстендә бер-ике мәртәбә әйләнде дә ук шикелле туп-туры очты да китте.

3

Озак, бик озак очты Нечкәбил.

Өлгергән арыш, үзенең башакларын селкеп, аны сәламләп калды, чәчәкләргә төренгән кыр алкышлап каршы алды.

Нечкәбил, кечкенә очкыч моделе төсле әйләнә-әйләнә, чәчәккә килеп төште... Тирә-ягы тулы чәчәкләр: ап-аклар, сап-сарылар, зәп-зәңгәрләр, кып-кызыллар. Йомшак кына искән җил белән селкенәләр, йөрәкне җилкендерәләр. Тирә-якка хуш ис чәчәләр, әйтерсең ислемай сөрткәннәр.

Бер чәчәктән икенчесенә, икенчесеннән өченчесенә күчә Нечкәбил.

Бер чәчәктән икенчесенә куна-куна, чәчәк тузанына буялып бетә. Ул тузанны, бер чәчәктән алып, икенчесенә калдырып китә. Шулай итеп, уңышны күтәрүдә ярдәм итә.

4

Чәчәктән чәчәккә күчкәндә, аларның татлы суларын эчкәндә, Нечкәбилгә бер Саранча очрый.

Җитмәсә:

— Әй йонтач! — дип, Нечкәбилгә эндәшә.

— Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса, якын кил,— ди Нечкәбил.

Саранча якынрак килә дә Нечкәбилнең ни эшләп йөрүен сораша, аннан үзе турында да сүз ача: «Минем бабаларым бу илгә ачлык елны Иран якларыннан очып килгәннәр. Күрәсең, монда тормыш шәбрәк дип

белгәннәр. Ләкин кешеләр аларны агулап үтергәннәр, канаулар казып күмеп бетергәннәр. Шомырт түшле сыерчыкларга кадәр безне берәмләп чүпләгәннәр».

Нечкәбил каршы җавап кайтара. Җавапны тыңлаган Саранчаның күзләре акая.

— Үзләренә файда китерсәң, кешеләр агулап та үтермиләр, күмеп тә бетермиләр. Җылы өй ясап үрчетәләр, тәмле ширбәт эчертеп үстерәләр. Игеннәрнең башларын коеп йөргәч, нигә үтермәсеннәр?— дип, Нечкәбил сүзен бетерә. Нәкъ шулвакыт һавада сыерчыклар көтүе күренә. Арадан берсе, артык тересе, чем-кара түшлесе, теге Саранчаны тота да йота.

Саранча турында сүз дә шуның белән бетә.

Ә безнең Нечкәбил алга таба очып китә.

5

Чәчәктән чәчәккә күчкәндә, баллы сулар эчкәндә, Нечкәбилгә тагын кемдер эндәшә, үзе янына дәшә:

— Чага торган кортчык, минем яныма килеп чык,— ди.

Нечкәбилнең исе китми, аның янына бармыйнитми:

— Минем исемем Нечкәбил, булса сүзең, үзең кил,— ди.

Бусы да кешеләрдән, хайваннардан зарлана: «Кайсы кулы белән бәреп үтерә, кайсы койрыгы белән сыпырып бетерә, ди. Кояш нурларыннан куркам, шуңа күрә яфрак астында посып утырам, аугa да көндезен сирәк чыгам»,— ди.

Нечкәбил Саранчага биргән сабакны, аңа әйткән туры җавапны моңа да әйтә:

— Кан эчәбез дип, кеше борчыйсыз, бизгәк авыруы таратып йөрисез!

Кичтән ач калган Озынборын, Нечкәбилнең үткен сүзләрен тыңламый-нитми, чүп утаучыга таба: «Җизни, җизни, күңелем синнән бизми!» — дип безелди-безелди,

кан эчәргә оча. Утаучы да аның кунганын гына көтә, Озынборынны шунда ук юк итә.

Аның турында да сүз шуның белән бетә.

Ә безнең Нечкәбил башка чәчәккә күчә.

6

Чәчәктән чәчәккә очканда, мәк чәчәгендә бал суырып ятканда, калын тавыш белән тагын кемдер эндәшә:

— Бал корты, бал корты! — ди.

— Минем исемем Нечкәбил, сүзең булса, монда кил!

Үлән арасыннан выжылдау ишетелә, ике канатлы, алты аяклы, яшел башлы, күгелҗем кашлы Кигәвен килә. Кигәвен Нечкәбил янына килеп җитә. Аннан үзара исәнлек-саулык сорашу башланып китә.

Кигәвен Нечкәбил янына чәчәк урындыкка утыра да елларның «авырлыгыннан» зарланырга тотына:

— Печән чабу вакытын без өзелеп көтәбез, хәер, аннан соң үзебез дә үлеп бетәбез. Шулвакыт безнең өчен азык күп була. Атлар, тайлар, кешеләр белән бөтен болын тула. Ә бу елларда атлар, печән чабучылар урынына ниндидер машина килә. Үзенә тагылган машинасы-чалгысы белән бер-ике көндә бөтен болынны чабып та китә. Ул машина үзе һаман пошкыра, тирәюньне бик тәмсез ис белән тутыра. Шул машинаның сыртына да кунасың, үзеңчә татлы итеп тешләгән дә буласың, һич тә рәт чыкмый.

Нечкәбил авызын ерып көлә дә бер-бер артлы тезеп сөйләп тә китә:

— Ул болыннар элек алпавыт болыны иде. Хәзер аны совхоз болыны диләр. Тәмсез ис чыгара торган машинаны трактор дип атыйлар. Аңа керочин ягалар, ә артына чабу машинасы тагалар.

Нечкәбил аңа үзенчә аңлаткан була, җиренә җиткереп сөйләп тора, ә ул, явыз, тир исен сизә дә сыза, Нечкәбилнең кәефен боза.

Нечкәбил артына әйләнеп караса — такыр гына юлдан, атын куа-куа, юлчы бара.

Нечкәбил аның дугасына күзен сала, теге, хәерсез Кигәвен, шул дугага кунып бара, аннан ат ботына куна, һәм ат аны койрыгы белән җиргә бәреп төшерә.

Кигәвен турында да сүз шуның белән бетә.

Ә безнең Нечкәбил исән-сау очып китә.

## 8

Оча-оча, шактый кителгән, ун километр ераклыктагы урман артына барып җителгән. Өенә кайтырга чыккач, Нечкәбилне дулап искән җил каршы ала. Җитмәсә, көньяктан күк күкрәп, болыт та кузгала. Җил котырып исә, очучы чыпчыкларны да, кечкенә кошчыкларны да үзе белән ияртеп алып китә. Җил бит ул менә нинди тиле, Нечкәбилне дә әллә кая алып китәргә тели. Нечкәбил карыша, җил белән тартыша.

Мескен Нечкәбил бик арыган була, җитмәсә, кайтып җитәм дигәндә генә, яңгыр астында кала.

— Инде нишләргә?

Нечкәбил аптырамый, ул шунда ук таба яхшы юл — әрекмән яфрагы астына керә, шулай итеп, яңгырдан яшеренә.

Үкереп искән җил болытларны куа... Бераздан яңгыр да тына, ялтырап, кояш та чыга. Аннан Нечкәбил дә кайтырга чыга.

## 9

Алып кайткан балын, ашый торган азыгын кәрәз күзәнәгенә салыйм дисә, ни күрсен Нечкәбил: ятьмәдән эшләнгән битлек кигән бабай, шундый ук битлекле бер малай Нечкәбилләр өенә төтен өрдерәләр, ә умарта кортлары, төтеннән куркып, тышка йөгерәләр. Карышучыларны һәм рамда калучыларны йомшак канат белән себерәләр. Бал тулы рамнарны бал суыртучыларга илтеп бирәләр.

Әнә анда ак калайдан эшләнгән бал суырту машинасы әйләнә. Күзәнәкләрдәге сыек бал, суырту көченә каршы тора алмыйча, машина стенасына сибәли.

Аннан соң татлы бал такта чиләккә су кебек агып төшә. Тирә-якка бал исе бөркелә, сизгер бал кортына гына түгел, бу ис безгә дә сизелә.

Ә нигә соң бал кортлары килмиләр, савыт тирәли выжылдап очып, йөдәтеп йөрмиләр? Чөнки моннан башка чәчәкләрдә дә бал күп, барлык умарта кортлары да тук. Ә менә син, табыш беткәч, бал исе чыгарып кара, ничек чыдарсың, бичара?! Умарта кортлары савытыңны сырып алырлар, кайсылары балга батып чыга алмый да калырлар. Булышырга шөпшәләр дә килеп җитәр, чиләк эчендәге балың минут эчендә бетәр.

Әлегә җан тыныч, һич юк куркыныч. Агач чиләккә бал ага, кәрәз күзәнәкләре бушап кала.

## 10

Ә аннан соң тагын кызу эш башлана. Күмәк хезмәтчеләр барысы да кәрәзгә ташлана. Кәрәзнең күзәнәкләрен төзәтергә, яшь балаларны тәрбияләп күзәтергә, күзәнәктә төренеп яткан бал кортларын җылытырга, өй эчен чиста тотарга...

Балавыз төсле соры, озынча гәүдәле, кыска канатлы, бөтен ояда бердәнбер булган ана корт кәрәз күзәнәге саен йомырка салып йөри.

Юан сорыкортлар симереп, эшче кортлар ташыган балны ашап, кикереп яталар.

Бөтен эш эшче кортлар җилкәсендә: алар бал җыялар, балавыз сузалар, бала тәрбиялиләр, йорт эшен дә эшлиләр. Үзләре бик көчле булалар, дошманга каршы да торалар.

Безнең Нечкәбил дә — эшче корт, аның да җилкәсендә зәңгәр йорт.

11

Көннәрнең берендә, калынаеп кына, авыраеп кына, Нечкәбил эштән кайтса хәйранга кала: зәп-зәңгәр өйләренең ишегеннән бал кортлары бертуктаусыз атылып чыгып торалар, көтүләре белән очалар, сорыкортлар выжылдыйлар.

Очалар да очалар кортлар, ояларына кире кайтмыйлар, кояшны кечкенә генә болыт кебек каплыйлар.

— Ни булган?

— Кем тия?

— Нигә болай бал кортлары тузгыйлар?

Бал суырткан бабай белән әлеге малай шатланып йөриләр:

— Умарта аера,— диләр.

Алмагач ботагына, беренче булып, ана корт куна. Шул урынга ук эшче кортлар да куналар, бары да бергә җыйналалар, күп булалар. Йон йомгагы төсле булып, корт иле алмагач ботагына сара.

Әлеге бабай белән шаян малай илнең сарып бетүен генә көтәләр, кабыктан эшләнгән тубал алып киләләр. Әйбәтләп аңа лимон мае сөртәләр. Бабай туз кашык белән, җайлап кына, кортларны тубалга соса башлый. Бик күп сандагы башка кортлар белән бергә, таныш булган Нечкәбилне дә тубал эченә ташлый.

Тубал эчендә жулау башлангач, яртысыннан артык ил тубалга туплангач, бал кортлары үзләре үк тубалга керә башлыйлар.

Бал кортлары кереп беткәч, бабай тубалның авызын бәйләп куя. «Тубалны, улым, син салкынча урынга куй»,— дип, аны малайга тапшыра, үзе яңа гаилә өчен яңа йорт әзерләргә керешә.

12

Эш шулай булган да булыр иде. Ләкин бабай белән теге шаян малай аны көтеп тормадылар, хәйләлерәк юлны сайладылар. (Мин генә сезгә шулай язып үттем,

сезне дә әз генә алдалап киттем.) Зәңгәр өй урынына шуның төсле үк өйне китереп куйдылар, ә тегесен күздән җуйдылар. Умарталыкның теге башына илттеләр дә үзләре тыныч кына кайтып киттеләр.

Берни булмаган төсле, эшче кортлар бал эчәргә ашыгып очтылар, тик инде төп йортка кайтмадылар, шикләнсәләр дә, яңа куелган өйгә кереп тулдылар. Төп йорт зәгыйфьләнебрәк калды, яңа йорт үсә башлады. Ятим иделәр, ана чакырдылар, менә дигән итеп тора башладылар.

13

Ләкин яңа өйдә әле ярлылык.

Рамнарның әле тирән күзәнәкле кәрәзләре юк. Яңа өйдә әле бер тамчы да бал юк. Ясалма кәрәзләрне бал салырга яраклы итеп, тартып-сузып эшлисе бар.

Һичнигә карамый яңа хуҗалар үзләренчә җанфәрман тырышкан булалар: бал ташыйлар, кәрәз ясыйлар.

Зур дәрт белән эшләгәч, көчеңне кызганмагач, яңа йорт та аякка баса.

Ләкин...

Кышка бал әзерләнеп җитте, инде баштан кайгы китте дигәндә генә, әлеге бабай белән теге шаян малай, килеп, баллы кәрәзләрне кистеләр дә алып киттеләр. Суыртылган балны кешеләргә — колхозчыларга бирделәр.

14

Менә кортлар өчен күңелсез көз дә җитте. Кырда, болыннарда чәчәкләр күптән бетте. Суык җилләр исә башлады. Нечкәбил дә хәзер бал алып кайтмады.

Көннәрнең дә яме китте, кышка җыенырга вакыт җитте.

Сорыкортлар үзләре бал җыймыйлар, бик юашлар, чага да белмиләр, ә бит менә кышка дигән азыкны ашап йөриләр. Гаиләдәге шулкадәр сорыкортны

кышлатсаң, азык күп китә, эшчеләрнең азыклары үзләренә генә җитә, шуңа күрә сорыкортларны бүгеннән үк үлем көтә.

Сорыкортларга — әрәмтамакларга каршы сугыш башлана. Нечкәбил бер симез сорыкортның җилкәсенә менеп атлана. Сугыша-сугыша очып барышлый, әрәмтамакның билен кыеп ташлый.

## 15

Нечкәбил бүген ишек янында, бернинди корал юк кулында, ләкин үзе сакта тора. Җәй көне бер корт та сакламады ишекне, өй эченә кертә торган тишекне, ә көз булгач, саклау нигә кирәк? Кайсыгыз зирәк? Әйтегез әле тизрәк.

— Әнә күрәсезме, кара гына, шома гына бер эшче корт өй тирәсендә әйләнә: өйгә керергә исәбе, белә ул кая яшерелгән бал кисмәге. Балны урлап ашарга да җәһәт кенә качарга...

Умартачы бабай зәңгәр йортның ишеген кыса төшкән, моның белән Нечкәбилгә бик зур ярдәм иткән. Саклау өчен, эш җиңелләшкән. Шуңа күрә ул постында нык тора, килгән каракларның барысын да кире бора.

## 16

Беркөнне умартачы бабай белән әлеге малай умарталарны кышлыкка әзерләп йөриләр иде.

Яңа гаилә йортының эчке катын бөтенләй алып ташладылар. Җылырак булсын өчен, аскы катны да кыса башладылар.

Болай актарынуга Нечкәбил иптәшенең бик ачуы килде. «Ахры, соңгы балыбызны да алырга килгәннәр»,— диде дә әлеге шаян малайның борын очына гына үзенең угын кадады.

Малай үрле-кырлы сикерде, түзә алмагач елап ук җибәрде.

Ак сакаллы бабай, җитди төс алып:

— Әйттем бит мин сиңа, көз көне бал кортлары ачулы булалар, дидем, ә син битлек кимәдең, карыштың,— дип, малайны орышты.

Бал кортының агулы угы малайның борынында утырып калган иде. Угы белән бергә, аның эчәгеләре дә чыкты. Ул башта очып киткән булды, ләкин озак оча алмады, үлде.

17

Яфраклар коелып беткәч, кошлар җылы якка киткәч, бал кортларының ояларын җылы урынга кышларга күчерделәр.

Нечкәбилнең зәп-зәңгәр өен башка бик күп өйләр белән кышларга керттеләр.

Әкият тә шуның белән бетте.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әкиятнең эчтәлеген үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аңа нинди бәя бирер идегез?
2. Әкияттә катнашучыларны характерлагыз. Шулар арасында Нечкәбил нинди урын алып тора?
3. Әсәрдә бал кортларының файдасы һәм кешенең аларга ярдәме ничек чагылыш тапкан?
4. Алиш әкиятләре халык әкиятләреннән кайсы ягы белән аерыла?

## КОЙРЫКЛАР

(*Африка халыклары әкияте*)

Борын-борын заманда юаш хайваннарның, ерткыч җанварларның койрыклары бөтенләй булмаган. Кешнәүче ат та, мөгрәүче сыер да койрыгы белән чебен кумаган. Шаян тиен дә, чикләвекләр ашап, ботактан ботакка сикереп уйнамаган.

Хәйләкәррәк ерткычлар җыелганнар барысы да бергә, койрык алып калу турында киңәшергә. Ак түшле саесканнарны чакырганнар, аларга да зур йомыш тапшырганнар.

— Сез, ак түшле саесканнар, туры юлдан адашканнар, очыгыз да китегез, еракларга җитегез: биек-биек тауларга, шаулап торган урманнарга, ямь-яшел болыннарга, җырлап аккан суларга безнең сүзне илтегез, дигәннәр. Юаш хайваннарны, ерткыч җанварларны чакырыгыз: үткәргәч караңгы төнне, менә фәлән көнне, томан беткәч тә, кояш күтәрелгәч тә, карт имән янында өләшәчәкләр диегез койрык, менә сезгә шул безнең боерык,— дигәннәр.

Саесканнар төрлесе-төрле якка карап очканнар, үзләре белән зур-зур быргыларны кычкыртып барганнар:

— Әй сез, куе урманнарда, киң кырларда, яшел болыннарда, диңгез-океаннарда яшәүче ерткычлар,— дигәннәр алар.— Томан беткәч тә, кояш күтәрелгәч тә, бөтенегез дә карт имән янына барыгыз, койрык өләшәчәкләр, килеп алыгыз,— дигәннәр.

Усал ерткычлар, бишәү-унау, яудырганнар берьюлы сорау:

— Бу нинди боерык?Нәрсә соң ул койрык?Ул нигә кирәк?Әйтегез әле тизрәк,— дигәннәр.

Хәйләкәр Төлке (серне белгәч, аңа көлке):

— Өләшәләр икән — барып алыйк, яраклылармы икән — үлчәп карыйк, нәрсәгә кирәк икәнен соңыннан белербез, бәлки, күбебез сөенербез,— дигән.

Үткәргәч караңгы төнне, шул билгеләнгән бер көнне ерткычлар койрык алырга карт имән янына барырга юлга чыкканнар, кайсы үрмәләгән, кайсы йөгергән, кайсы чапкан.

Кыр Куяны үзенең тунын чистарткан, тәпиләре белән битен юган, ул да карт имән янына барырга җыенган. Чыгам дип, оясының ишеген ачкан, ләкин көчле яуган яңгырга чыдамаган, кире оясына кереп качкан.

Оясында озак утырмаган зур колак Куян, дөп тә дөп басып килгән аяк тавышын ишеткән, карамыйча яңгырга, йөгереп, тышка чыккан. Агач куышына кереп утырган да ерактан килүчене карарга тотынган.

Агачлар куркышып чатнаганнар. Үләннәр үкерешеп шаулаганнар. «Кулына тотып таяк, киләдер теге кәкре аяк»,— дип уйлаган Куян, чыннан да шулай булып чыккан.

Куян килүчегә сүз кушкан:

— Аю бабай, башкалардан артка калмыйсыңдыр, үзеңә койрык сайлыйсыңдыр, шунда миңа да нинди генә булса да бер койрык алып кайта алмассыңмы икән?— дигән.

— Әгәр дә онытмасам алып кайтырмын, авыр эшмени ул,— дигән Аю.

— Ярарын ярар, шулай да аңа ышанып булмый,— дигән Куян.— Аю бабай инде картайган, зиһене дә таралган. Онытыр вәгъдәсен, аннан табар хәйләсен, тагы кемнән дә булса башка берәүдән үтенергә кирәк,— дигән Куян.

Тагы тып-тып бер тавыш килә, вак чыбыкларны чыжылдатып, кем соң ул йөгерә?Ә, Бүре килә.

— Бүре абый, карт имән янына барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр, шунда миңа да нинди дә булса берәр койрык алып кайта алмассыңмы икән? — ди Куян.

— Барысына да җитәрлек булса, берәрсе артып та калса алып кайтырмын,— дип, Бүре үтеп китә.

— Юкка әрәм иттем моңа сүз, Бүре бит ул туймас күз, сайлап бетерерләр, берәү дә калмас, артып калса да, ул алмас, миңа бирмәс, бозар вәгъдәсен, табар хәйләсен. Кемне дә булса тугрыракны, бу эш өчен хубракны табарга кирәк,— ди Куян.

Тагы кемдер дөп тә дөп итеп басып килә. Үлән әз генә селкенә, Төлке йөгереп килә.

— Бу эш түгел көлке, апакаем Төлке, үзем бара алмадым, ахры, инде койрыксыз калдым. Карт имәнгә барасыңдыр, үзеңә койрык аласыңдыр. Сиңа бу зур

үтенечем, боерык дип уйлама, алып кайтмассыңмы икән миңа бер койрык?

— Ярый, ярый, һич хафаланма, бирәүгә дә зарланма. Куян дустым сорады диярмен, койрыкның менә дигәнен алып кайтып бүләк итәрмен. Туның белән бертөсле булыр, әллә кайдан ук күренеп торыр.

Төлке, барысыннан да соң юлга чыкса да, Куян янында шактый тукталып торса да, иң туры юллар табып, бар көченә чабып, карт имән янына иң алдан барып җитә.

Койрыклар белән карт имәннең ботаклары тулган, һәр ботак саен бер койрык асылынган: йонлач озыннары да, йонсыз ялангачлары да, җеп шикеллеләре дә, алтын йон белән капланганнары да, кара һәм аклары да, кәкреләре дә, турылары да — бар да бар. Җыелган ерткычлар аларны күреп хәйран калалар, башларын кыңгыр салалар, көтмичә бернинди боерыкны, беренче булып Төлке сайлый койрыкны:

— Миңа менә шушысын, мамыклысын, йонлысын,— ди.

Башкалар йоклап кала, ә ул үзенә менә дигән бер койрыкны сайлап ала. Төлке әйләнә дә тулгана, койрыгы да бергә болгана.

Стакан тояклары белән тыпыр-тыпыр басып, үзен үзе белештерми ярсып, Ат килеп тә җитә, себерке шикелле кыл койрыкны алып та китә. Үзе айкала да чайкала, кыл койрыгы белән мактана:

— Борыныма кадәр барып җитә, димәк, чебеннәргә моннан соң көн бетә,— ди.

Сыерның да койрыгы яхшы, Бүренең дә начар түгел. Тиен дә койрыктан уңган, сикерсә, пружинадай булган, йокласа — юрган. Фил һаман бер урында таптанып йөргән, күпләрнең тәпиләрен изгән. Ул селкенгәнче, килеп җиткәнче, иң кыска койрыклар гына калган булган. Фил үз язмышына үзе үпкәләгән, борынын түбән салган. Шуннан бирле аның борыны салынкы булып калган.

Аю юлда умарталыкка очраган, туйганчы бал ашаган, шуңа күрә койрык алырга да соңга калган, шулай да бернәрсә тапкан, тире кисәген койрык итеп таккан.

Койрык өләшеп бетергәч, таралырга вакыт җиткәч:

— Барыгыз да койрыклымы инде? — дип, бер-берсеннән сорашалар ерткычлар.

— Юк әле, юк, туктап торыгыз, мин алмый калдым,— дип мыгырдый Дуңгыз.

Сазда аунаганнар, кояшта кызынганнар, пычрак ерганнар, шуңа күрә койрык алырга да соңга калганнар.

Барып җиткәч сорасалар, күз төшереп карасалар, бары тик бармак буйлыгы койрыклар гына калган булган. Дуңгызның балалары уникесе унике яктан чинарга тотынганнар:

— Кирәкми, андый койрыкны алмыйбыз, хурланмыйча, аны койрык итеп тагып та йөрмибез,— дигәннәр. Ләкин сайларлык башка койрык булмаган, ана Дуңгыз бик аптыраган, шул койрыкны тагып алган да кәкрәйтеп салган. Шул көннән алып, барлык дуңгызларның да койрыклары ыргакланып калган.

Кыр куяны койрык алып кайтучыларны көткән, оясында ятып та аптырап беткән, ахыр чиктә түзмәгән, кайсын булса да берсен очратырмын диеп, юлга чыгып киткән.

Әнә еракта алпан-тилпән кайтучы Аю күренгән. Куян, шатланып, әйтерсең канатланып, Аюга каршы йөгергән.

— Аю бабай, онытмадыңмы? Менә дигәнен алып кайттыңмы? — дигән.

— Кит әле моннан, ялкау Куян! Үзең бармагач, армагач-талмагач, кыршылмагач, сугышмагач, тик утырып кына койрыклы булып буламы соң, юләр, мин йөгерә-йөгерә барып та, үлә язганчы арып та, менә шушындый кыска койрык кына эләктерә алдым,— дигән Аю Куянга.

Аю мескен Куянны тиргәгән дә киткән, ә Куян башкаларны көткән.

Күп тә үтмәгән, Бүре күренгән, Куян аңа каршы йөгергән.

— Бүре абый, Бүре абый, миңа диган, менә диган койрыкны бир, абый,— дигән.

— Кая әле сиңа дигән койрык, үземә дә көчкә генә берне эләктердем,— дигән Бүре.

Бүре шулай дигән дә киткән, ә Куян Төлкене өзелеп көткән. «Төлке апакай, багалмакай, ул гына алдамаса алдамас, әгәр койрык алып кайтса, китереп алдыма салса бүләк итәм бер каз»,— дип уйлаган Куян. Тау битенә ныклабрак күз салса, Төлке килә ләбаса. Куян чакырганны көтмәгән-нитмәгән, аның каршысына барып баскан:

— Апакаем, багалмакаем, миңа дигән койрыкны биреп калдыр, мине шатландыр,— дигән.

— Син генә идең минем башымда, әллә нинди җайсызлыклар чыкты каршыма. Син менә күз сал әле, кызыгып кал әле: йомшак кына, мамык кына, үземә менә дигәнне эләктердем, хәер, шуның аркасында күп мал бетердем,— дигән Төлке.

Шул сүзләрне әйтеп, күз уйнатып, Куян борыны янында койрыгын болгап, Төлке көлеп торган.

Куян койрык көтеп бик зарыккан булган. Мескеннең күңеле тулган. «Менә кирәк булса, туганнар барысы да мине онытканнар»,— дип елап ук җибәргән.

Күңелсезләнеп утырганда, тирә-ягын күз яше белән тутырганда ишеткән Куян: «Вау да вау, мырау да мырау». Борылып карый, карый да: «Менә монысы ярый». Эт белән Мәче ду килеп сугышалар икән.

Эт: «Минем койрык иң яхшы!»— дигән. Мәче аркылы төшкән: «Минеке ише дөньяда да юк!» — дигән. Тартышканнар да тартышканнар. Әүмәкләнә торгач, сугышның очы чыга... Мәченең койрык очы өзелеп чыга. Мескенем куркуыннан агач башына ук

менеп китә. Өзелгән койрыкны җил, тәгәрәтеп, Куян оясына илтә. Куян аны үзенә койрык итә. Шул көннән башлап, Мәче белән Эт арасындагы бу ызгыш мәңгелеккә китә.

Әкият тә шуның белән бетә.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. «Койрыклар» әкиятендәге хикәяләү стиле хайваннар турындагы халык әкиятләреннән кайсы ягы белән аерыла? Аерым урыннарны укып күрсәтегез.
2. Әкияттәге хайваннар образын характерлагыз. Куян вакыйгалар үсешендә нинди урын тота? Ни өчен ул койрык алырга үзе бармый?
3. Эт белән Мәченең дошманлыгы нидән башлана?
4. Хайваннарга койрык ни өчен кирәк? Үзегез белгәнчә сөйләп карагыз.
5. Хайваннар турында нинди китаплар укыганыгыз бар? Шулар буенча әңгәмә оештырыгыз.

# *Габдулла Тукай*

***(1886—1913)***

## ИСЕМДӘ КАЛГАННАР

### 1

Минем атам Мөхәммәтгариф, Кушлавыч авылында Мөхәммәтгалим исемле мулланың угылы булып, карт атасы тере вакытта ук авылыбыз Кушлавычка мулла булмыштыр.

Минем туганыма биш ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып үлгән.

Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам, мине авылыбыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрь карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна исемле авылның мулласына кияүгә чыккан...

Мин бу карчык өендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән — тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-ике ярым яшемдә генә булганмын дип уйлыйм.

Хәзер авылда минем балалык вакытымны күргән карчык вә[1] хатыннар тәрбияче карчыгымның минем белән бик начар мөгамәләдә булганлыгын үземә хикәя итәләр.

Җөмләдән берсе[2]:

Мин кыш көннәрендә төнлә, яланаяк, күлмәкчән көенчә, тышка чыгам икән дә бераздан, өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканчы көтеп торам икән.

Карчык исә үзенең «Кадалмас әле килмешәк!» дигән «шәфкатьле» фикере илә[3] мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән.

---

[1] *Вә* — һәм.

[2] *Җөмләдән берсе* — шулардан берсе.

[3] *Илә* — белән.

Мин бу карчыкта торган вакытта, анам да теге муллага үзләшеп җиткән булырга кирәк, ул бервакыт мине үз янына Саснага алдырырга атлар җибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән минутларда мин, бала булсам да, хәзер дә, атта утырып, Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә[1] хис иткәнемне, юлда барганда, күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвешле бардым, мине кемнәр каршылады — анысын белмим; ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт озакка бармаган. Минем анам бу муллада бер ел кадәрме, күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

Мин монда, әнкәмнең җеназасын[2] күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан үкереп елый-елый йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!»— дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә хәтерләвемне язамын.

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле авылындагы анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән.

Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чакта ук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны аңа ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

---

[1] *Галәмдә* — дөньяда.

[2] *Җеназа* — мәет («үлгән кеше» мәгънәсендә).

Өчиле авылы (исеменнән дә мәгълүм) бик кечкенә вә бик ярлы бер авыл булганга, шуның өстенә мин ятим калган елларда ул тарафларда каты ачлык булганга, бабайның көнкүреше гаять начар булган.

Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.

Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине еласам — юатучы, иркәләним дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.

Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.

Шул рәвешчә, көннәр үткән, мин, монда торганда, чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр[1] дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.

Бу семьяда һәммәсе (бер җитеп килә торган Саҗидә исемле кыздан башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде»,— дип кенә караганнар.

Мин әле хәзер аерым әйттекем[2] Саҗидә апайның, үги әбидән яшереп кенә, мине юатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Ни күрсәм дә — күргәнмен, ни булса да — булган, һәрничек мин бу семьяга сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылыбыздан Казанга бара торган бер ямщикка мине утыртып, Казанга озаткан.

Ямщик, Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан алтмыш кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?» — дип кычкырып йөргәндә,

---

[1] *Хәстәлек* — авыру.

[2] *Әйттекем* — әйткәнем.

халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктан алган. Ул мине, асрау бала итеп, өенә алып кайткан.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдырмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәлен дә бераз язып китим әле.

Миңа эти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа Бистәдә иде.

Эти талчокта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда — анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.

Әни, Печән базарына кәләпүш чыгарганда яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә иртеп баргалый иде.

Мин, байлар йорт эченең матурлыгын, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби[1] суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур орга́ннарын[2] күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

Бервакыт шулай байларга барганда, ишегалдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависны[3] күреп, бигрәк тә сокландым.

Бу ата-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда миңа ач торырга туры килми иде.

Кайчакта әни белән ташаяк базарына барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда, шатланып-шатланып, агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

---

[1] *Кеби* — кебек, шикелле.
[2] *Орга́н* — уен коралы.
[3] *Тавис* — кош (павлин).

Мин дә атланыр идем — акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.

Аннан соң җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз йоннары куып йөргәнемне, арыгач, Хан мәчетенә юнәлеп ятып, чирәмдә ял иткәнемне бер дә онытмыйм.

Мин бу ата-анамда ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә — икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк»,— дип, теге мине Казанга китергән ямщикны табып, мине, янәдән аңарга утыртып, Өчиле авылына җибәргәннәр.

Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу семьяның мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.

Мин кайтып бераз торгач та, әби белән бабай, инде мине шәһәргә җибәрүдән өмет кисеп, кая булса да бер чит авылга асрарга бирергә уйлашканнар.

Болар Өчилегә килгән һәрбер чит авыл кешесенә үзләрендә асрарга бирергә бер ятим бала барлыгын сөйләгәннәр.

Шулай мәшәкатьләнә торгач, бездән җиде генә чакрым Кырлай исемле авылдан ир баласыз Сәгъди исемле бер кеше килеп, мине үзенә алып киткән...

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Укыган бүлекнең эчтәлеген сөйләгез.
2. Кайсы вакыйга сезгә нык тәэсир итте? Ни өчен? Сыйныфта шул хакта әңгәмә оештырыгыз.
3. Түбәндәге җөмләләрне ничек аңлыйсыз? Аларны үзегезчә сурәтләп карагыз:

   — ...Үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

— Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине еласам — юатучы, иркәләнім дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.

4. Түбәндә бирелгән өзекне үзегез аңлаганча сөйләп карагыз. Сурәтләү чарасы булып килгән чагыштыруларны әйтегез. Тукай тормышына өзекнең нинди бәйләнеше бар?

— Мин, байлар йорт эченең матурлыгын, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур оргáннарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

2

Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби (Сәгъди абзыйдан яхшысынмый гына булырга кирәк) мине озатырга чыктылар. Тагын да минем китүемне кызык күргән яланаяклы малайлар да арба тирәсендә йөгергәләп йөриләр иде.

Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Алла боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың»,— дип, миңа барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине юатып бара иде.

Мин дә, ачык йөзләрне бик күптән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.

Бу вакыт җәйнең матур чаклары булганга, тирәяктагы яшел чирәмнәр вә урманнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш, икенче яктан, тагын рәхәтләндерәләр иде.

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты, басу капкасыннан кергәч, күп ерак түгел икән, аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган[1], минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты, мине ачык

[1] *Вакыйган* — чыннан да.

йөз илә каршы алып, арбадан күтәреп төшереп, өйгә дә алып керде.

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, әти дә өйгә керде. Кергәч тә, энигә эндәшеп: «Хатын, бар, балага катык белән ипи китереп бир»,— дип әмер итте.

Әни дә, шунда ук баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле юньләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин, анда чыгып адашудан куркып, артыма карый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар, һәр көн авылның бер башыннан бер башына йөгереп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситсы күлмәк, башымда да, мине Өчилегә кире җибәрер алдыннан, әнинең миңа сагынмаклык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар, мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда ике җиткән кыз күрдем.

Боларның берсе таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе арык кына, сары йөзле генә, култыгында агач таяклары бар, аксак бер кыз иде.

Әни миңа: «Менә болар — апайларың: берсе — Саҗидә апаең, берсе — Сабира апаең, күреш!» — дигәч, мин, әкрен генә барып, кулымны суздым.

Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Саҗидә атлы икән. Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым. Авыл малайлары белән дә таныштым.

Сәгъди абзыйның юлда әйткәненчә, вакыйган, монда катык, сөт күп, шулай ук бәрәңгегә дә ихтыяж[1] юк иде.

Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар.

Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар белән авыл буенча йөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем.

Алар, әбәттән (көндезге аштан) соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, ян тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше калмаганлыктан, без бакчадагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек. Әгәр өй саклаучы карчыклар күрсә, без дәрхәл[2] киртәдән сикереп качадыр идек. Карчык мескеннең орышып, тешен кысып калудан башка кулыннан бер эш тә килмидер иде.

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үзебезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар белән вак балыклар сөзеп ята идек. Күңелле чаклар!

Бервакыт шулай уйнап йөргәннән соңра, кич белән өйгә кайтсам, өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем. Бу нидән икән дип уйлап торгач, Сабира апаның идәннән сәкегә котырган шикелле йөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның урактан «җенләнеп», авырып кайтканын белдем.

Ул төнне өйдәгеләр берсе дә йокламый үткәрделәр. Мин генә, бик йокым килгәч, тыштагы арбага чыгып йокладым.

---

[1] *Ихтыяж* — «аптырау», «җитмәүчелек» мәгънәсендә.
[2] *Дәрхәл* — шунда ук.

Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма:

— Сабира апаң вафат булды, син йоклап ятасың, тор, тор! — дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам, каршымда әни тора иде.

Бу, билгеле, миңа да гади хәбәр түгел — йокы тәмле булса да сикереп тордым.

Шул көнне Сабира апаны җирләделәр. Аны җирләп берничә көн үткәч, әнинең этигә:

— Менә «Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул, мөгаен, шуның шомлыгыннан булды инде бу! — дип сөйләгәнен ишеткәли башладым.

Аннан соң кайчакларда әнинең йә кушкан йомышын тыңламасам, йә җиренә җиткерми эшләсәм, шул сүзне әйткәли торган иде.

Әти белән без бик-бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде.

Мәсәлән, бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, казакиларым тузгач, әти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән улының күк киндер күлмәге белән бишмәтен миңа бирмәкче булды.

Шунда әни: «Мин үз улымның төсе итеп саклаган киемнәрне кешегә бирер хәлем юк»,— дип, бик озак тарткалашты.

Ахырда әти: «Я, хатынланма әле юкка, үзеңнән тумаган бала дип, әллә аны шыр ялангач йөртерсеңме?» — дип, киемнәрне, көчләп диярлек, миңа алып киертте.

3

Шулай итеп, урак бетте, көз җитте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәңге казыр вакыт җитте.

Бу бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә туры килмәде: миңа казып чыгарылган бәрәңгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт, көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым туңганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем.

Бервакыт шулай, аякны балчыкка күмеп, бәрәңге чүпләгән чагында, теге бәрәңге казучы аксак Саҗидә апай ялгыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин дә урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып елгадым да, соңра җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемдә дәвам иттем, ләкин бу юлы аякларны, никадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

— Моны ни өчен яздың? — диярләр.

Ни өчен яздым? Шулвакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга тоттым да яздым.

Бара торгач, бакча эшләре дә бетте.

Беркөнне кич әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга[1] укырга илтәчәкләрен миңа мәгълүм иттеләр.

Таң атты, кояш чыкмас борын ук торып, чәй эчтек. Чәйне җыештыргач, әни мине кулымнан җитәкләде дә үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек, мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында, минем яшемдәге кечкенә кыз балалар булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богдай арасындагы берничә борчак кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни иң элек ике бөтен икмәк белән бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык.

Әни мине тапшырып үзе киткәч, мин, кызлар белән бергә, «әлеп, би, ти, си, җом, хи»ны бер дә тартынмыйча кычкырып укый башладым.

Шул рәвешчә, «әлеп, би, ти, си»не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарты»[2] да тоттырдылар.

---

[1] *Абыстай* — бу урында: мулла хатыны.

[2] *«Иман шарты»* — дини китап.

Бу «Иман шарты»ның иҗеге белән сүрәсе миңа кыш буена җитте бугай. Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарты» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым.

Фәкать «Иман шарты» бетерүгә гыйлавә[1] буларак, бервакыт, абыстай өйдә юк вакытта, бәгъзе[2] шаян кызларның: «Кәлимәтен, тайибәтен, безнең әни бай хатын, изүе тулы тәңкә...» — дигән сүзләрен ишеттем.

Ишетелмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә — һәрберсе гыйлем[3] булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым. Һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкрарлап[4], аларны көлдереп йөрер булдым.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Кырлай тормышы нәни Габдуллада нинди истәлекләр калдыра?
2. Малайда Сәгъди абзыйга җылы караш ничек туа? Шуңа нигезләнеп, Сәгъди абзыйны характерлагыз.
3. «Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» мәкаленең әсәрдә кулланылган мәгънәсен аңлатып бирегез. Ананың бу сүзләре ятим Габдуллага ничек тәэсир иткән дип уйлыйсыз? Үзара фикер алышыгыз.
4. Кырлай мәдрәсәсе Габдуллада нинди хатирәләр[5] калдыра?
5. Байназар Әлменов рәсеме («Исемдә калганнар» буенча) сездә нинди фикерләр тудыра? Малайларның йөзенә игътибар итегез.

## 4

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр тәмам кардан ялангач калып карала башладылар.

---

[1] *Гыйлавә* — өстәмә.
[2] *Бәгъзе* — кайбер.
[3] *Гыйлем* — белем.
[4] *Тәкрарлап* — кабатлап.
[5] *Хатирә* — истәлек.

Менә бераздан Сабан туе җитте. Мине Сабан туе көнне иртә үк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем.

Авыл халкы, тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген Сабан туе бәйрәме булганга, бигрәк тә иртә торган, вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, ятим калган мулла баласы икәнемне искә алгач, миңа, башка малайларга биргән кеби конфет, бер-ике перәнник кенә бирмичә, һәр йортта буялган күкәй дә бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буялган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыгым болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр дә, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы — анысын белмим, капчыкны әнигә бирдем дә үзем кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл егетләре, авыл кызлары, ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан Сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситсы кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без, яланаяклы малайлар исә, аның артыннан бер дә калмыйча йөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы — хатын-кызы, баласы-чагасы — болынлыкка төште. Көрәшләр, узышлар башланды.

Болынлыкта йөк-йөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак перәнникләр хисапсыз иде...

Атлар да чабышты. Малайлар да йөгереште, яулыклар да алынды, шулай итеп, Сабан туе да бетте.

Исемдә юк инде — бу Сабан туе бәйрәме ничә көн булгандыр, мин бер көнен генә яздым. Бәлки, өч-дүрт көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

Шуны да әйтергә кирәк: мин бу җәйне үткән җәй кеби йөгереп, уйнап үткәрә алмадым, чөнки, шушы язга чыгар алдыннан гына, Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы юатып, тирбәтеп утыра идем.

Менә тагы урак вакыты да җитте, үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мине — бер малайны — быел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә уракка да алып чыктылар. Шунлыктан бу җәем эш белән үтте.

Бу бала тугач, әтинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды. Шөйлә ки[1], мин үз өлешемә төшкән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым.

Җитмәсә, тагы теге аксак кыз да: «Үз энем! Җан энем!» — дип, Садрины юри мине кәефсезләндерер өчен сөйгән була иде.

**Сораулар һәм бирем.**

1. Габдулла Сабан туен ничек сурәтли? Хәзер үзегез күргән Сабан туе белән аның уртаклыгы бармы? Шул хакта сөйләп карагыз.
2. Садри тугач, Габдуллага мөнәсәбәт ни өчен үзгәрә, һәм бу үзгәреш аңа ничек тәэсир итә?

5

Көз җитте. Гадәттәге бәрәңге хезмәтемне иткәч, мине бу юлы (кызлар белән бергә абыстайга түгел) мәдрәсәгә бирделәр.

Мин, мәдрәсәдә «Һәфтияк» иҗеген һәм сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга[2] кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга

---

[1] *Шөйлә ки* — шул рәвешчә.

[2] *«Һәфтияк», «Бәдәвам», «Кисекбаш»* — элек мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек итеп укытылган китаплар.

туры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар.

Шул балалар арасында авылыбызның бер бай баласы да булып, ул мине, хәлфәсе кебек итеп, чәйгә вә эченә борай ярмасы салган бәлеш ашарга чакыргалый иде.

Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да йорт хезмәтләренә дә ярый башладым.

Мәсәлән, иртә белән, менеп, морҗа ачу, аннан соң морҗа ябу, мичкә ягар өчен, салам көлтәләр бәйләү, сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кебек эшләр — һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.

Кайвакыт җәй көне әти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем.

Авылыбызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, берзаман әтинең шәриге[1] йә дусты булганмы, нидәндер, миңа атна саен биш тиен акча бирә иде.

Мин, бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем.

Әти мәрхүм, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәчеңне әниеңә дә калдыр»,— дип куя иде. Мин дә, әлбәттә, «ярар» дия торган идем. Ләкин ул күмәч, авылга кайтып җиткәнче, вак-вак кына капкаласам да, әнигә кала идеме, юкмы — хәтерләмим.

Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга, андагы хатирәләргә озаграк туктарга туры килде.

Сәҗидә апай, чахотка белән бик озак авырып, хәтта мунчага-фәләнгә барганда, аны әти үзенең аркасында күтәреп йөри торгач, ниһаять, үлде. Әтине дә, кич белән әллә кайсы авылдан кайтып ат туарган чакта, кисәктән

---

[1] *Шәриге* — мәдрәсәдә бергә, бер сыйныфта укыган иптәше — сабакташы.

килгән бер авыру эләктерде. Аның шунда ук аңсыздан бер аягы аксады. Бу авыру хакында «ат җене сукты», «йолдыз атты», фәлән кеби төрле хөкемнәр йөрттеләр. Әти бу авыру сәбәпле эштән калмады, тик бер аягы гына чатанлап йөрүчән булып калды.

Бервакыт көз көне өйләдән соң әти белән әни ындырда иде, мин ян тәрәз төбендә «Рисаләи Газизә»[1] укып утыра идем, безнең капкага арбалы бер кеше килеп туктады.

Бу кеше, атын куеп, өйгә керде дә миңа: «Әти-әниең кайда?» — диде.

Мин: «Ындырда»,— дидем. Бу кеше: «Бар, чакырып кайт»,— дигәч, мин, тиз генә ындырга йөгереп барып: «Өйгә әллә нинди бер кеше килгән, сезне чакыра»,— дигәч, алар хәзер кайтырга булдылар.

Бераздан ишектән әти белән әни килеп керделәр, мосафир[2] белән күрештеләр.

Чәй куелды. Бу юлы, кунак булса да, чәй янына, нидәндер, мине дә утырттылар вә, гадәткә каршы буларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар.

Әтинең: «Ни хезмәт илә килдегез?» — дигән сөаленә[3] каршы мосафир: «Менә бу баланы алырга килдем»,— диде.

Бу сүздән әти, бик гаҗәпкә калып: «Ничек ул?Ник син алырга килдең?» — дип, сөальләр бирә башлагач, мосафир бу рәвешчә сүзгә башлады: «Мин — Кушлавыч кешесе. Бу бала — авылыбызның имамы баласы. Без, аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән хәбәрсез идек, менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек[4] каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе бар. Менә шул җизнәсе, каенесенең болай кара кешеләр арасында йөрүен ишетеп,

---

[1] *«Рисаләи Газизә»* — «Газизә китабы» (китап исеме).
[2] *Мосафир* — юлчы.
[3] *Сөаль* — сорау.
[4] *Җаек* — Уральск.

аны Җаекка үз янына чакыртмакчы була. Менә мин быел Җаектан, аның кушуы буенча, бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм»,— диде.

Мосафирның бу сүзләренә этинең дә, энинең дә бик кәефләре китте: «Ярар менә, без, икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта, аны өч-дүрт ел ашатып торыйк та, хәзер эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп җибәрик, имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән?» — кеби сүзләр илә нык тартыштылар.

Ара-тирә эни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!» — дип куйгалый иде.

Мосафир Бәдретдин абый:

«Юк, сез не имеешь право кеше баласын тотып торырга, мин хәзер урядникка әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне подсуд җибәрермен»,— дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара эти-эни йомшардылар.

Бераздан минем тату тормаган энием: «Я, атасы, бирик инде, ахры, кеше баласы безгә булмас, Алла сакласын, әллә ниләр күрербез»,— дип, үкереп елап та җибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соңра бераз дулкынланып торган диңгез кеби, актык вә йомшак тартышу белән генә тартышкач, эти дә риза булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми, мине арбага чыгарып утырттылар.

Эти-эни, бичаралар, һәр икесе еглаганнары хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда эни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве[1] булырсың»,— дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек. Минем китү мәсьәләм бөтенләе ярты сәгать диярлек аз вакытта хәл ителгәнгә,

---

[1] *Тәмуг кисәве* — «тәмугта янарсың» мәгънәсендә.

авылдагы иптәшләр вә таныш-белешләр илә күрешә алмадым. Алар белми калдылар.

Без юлга чыккач, күп тә үтми, кич булып, караңгы төшә башлады.

Юлда Өчиле авылына — бабайларга төштек. Анда чәй эчтек. Бу гаиләнең һәммәсе мин күргәндәгечә бергә торалар, фәкать Саҗидә апай гына кияүгә киткән иде.

Чәй эчкәч, әллә нинди Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты авылларын үтеп, төн урталарында үземнең туган авылым Кушлавычка барып кердек.

Юлда килә-килә, мин арбада шактый ватылган булырга кирәк, Бәдри абзыйның өенә кергәч тә эреп йокладым.

Иртә белән торгач, үземне бер кара өй эчендә күрдем. Бу өйнең эчендә, табак-савыт, кашык-чүмеч, камытшлея кеби нәрсәләр генә булып, җиһаз-фәлән кеби нәрсәләр бер дә юк иде.

Чәй эчтек. Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14—15 яшьлек бер угылы[1] вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы, вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде.

Чәйдән соң өйдән чыгып, аңа каршырак салынган ак өйгә кердек.

Бу инде мин кунган кара өйгә охшамый. Стеналары сап-сары нараттан, җиһазлары вә язу өстәлләре авыл кешесе өчен җитәрлек иде.

Бәдри абзыйның амбарлары тулы ит, богдай, арышларны күргәч, мин аның бу авылның иң бай кешеләреннән берсе икәненә хөкем иттем.

Тагы Камалетдин миңа, күз җиту сәбәпле яме киткән булса да, умарта оялары белән тулган шактый зур бакчаларын да күрсәтеп йөрде.

---

[1] *Угылы* — улы.

Мин инде, бер кергәч, бу ак өйдән чыкмас булдым вә шунда куна да башладым.

Бәдри абзый, мине өенә алып кайткач та, үзе бер эш белән Казанга китте.

Ул анда бер ай торган вакытта, мин дә буш ятмадым. Камалетдин илә бергә, авылыбызның мәдрәсә шикелле бернәрсәсенә барып, сабак укыдым. Күп вакыт кунып укырга да туры килә иде.

Хәзрәтләре, ахры, бик «кысып» укыта торган вә кешене «гыйлем» итә торган кеше булырга кирәк ки, шул аз вакыт эчендә дә мин аның көн саен әллә ничәшәр баланы эт урынына кыйнаганын күреп, калтырап торганым бар.

Кайчан да булса бервакыт бу хәзрәт таягының миңа да эләгү ихтималы мине куркытканга вә таң белән, шәкертләр белән бергә куылып, иртә намазына бару бик авыр булганга, эчемнән: «Ай, Бәдри абзый кайтса, тизрәк Җаекка китәр идем»,— дип көтә идем.

Берзаман Бәдри абзый кайтты. Миңа яңа бүрек, яңа киез ката, яңа бишмәт алып кайткан.

Мин бу яңалыкларны бик зур куанычлар илә кидем дә үземнең иске киемнәремнән бүрегемне, «бервакыт кайтып карармын» дип, чормага яшереп, саклап куйдым. Бу да гаҗәп эшләремнән берсе иде.

Шуннан соң Кушлавычта берничә көн генә тордык та Бәдри абзый белән Җаекка таба юнәлеп чыгып киттек.

Бер тәүлек кадәр баргач, Казанга килеп кереп (Печән базары тирәсе булырга кирәк), бер урынга туктадык.

Шулвакыт күрдек ки, безгә таба күзләре яшәргән, куллары җәелгән, сакалы агарып бетә язган бер кеше йөгереп килә.

Бу, минем яныма килгәч тә: «Әле син теремени?! Анаң әле кичә генә сине төшендә күргән иде, әйдә, өйгә алып барыйм, чәй эчәрсең, бездә кунарсың»,— дип, мине алып китте.

Өйгә барып кердем. Анда әни каршы алды. Бичара, сагынган икән, ул да еглады.

Минем өчен хәзер чәй куелды. Әти харчевнядан пилмән алып чыкты: сыйландык. Миннән моңа кадәр ниләр күргәнемне сораштылар. Мин дә онытмаган кадәрене сөйләдем...

Бу ата-анамның, мин аерылып торган вакытта, әтинең сакалы агаруы вә, Яңа Бистәдә булып, хәзер Иске Бистәгә күчүләреннән бүтән үзгәреш күренми иде.

Ул кичне шунда кундым. Иртәнге чәйне эчкәч, әни мине ләгәнгә утыртып юындырды. Яхшы кәләпүш һәм кыш көне барачак минем озын сәфәрем[1] өчен кирәкле булган бер тире чалбар кидерде...

Без торган номер бик начар да, бик яхшы да түгел, уртача гына бер номер иде.

Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән иде. Шул сәбәпле Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык.

Ниһаять, безнең көткән Алты-биш Сапыебыз, килеп, без торган номер күршесенә төште.

Ул, килеп, берничә көн торгач, Бәдри абзый мине аның номерына күчерде дә, үзе, миңа алты данә икешәр тиенлек унике тиен акча биреп, авылга кайтып китте.

Ул киткәч, мин Алты-биш Сапый вә хатыны янында калдым.

Бу шәһәрдән килгән кешенең киемнәре вә сөйләшүләре миңа ят тоела иде.

Мәсәлән, ул сүз арасында «мин өлкән кеше» дип ычкындырса, мин бу «өлкән» дигән сүзне һич аңлый алмый идем.

Алты-биш Сапыйның өстендә якасы вә җиңе камалы төлке тун булганга, «өлкән» кеше дип әллә шундый тун кигән кешегә әйтәләрме дип тә уйлый идем.

---

[1] *Сәфәр* — «юлга чыгу» мәгънәсендә.

Соңыннан Җаекка килгәч белдем ки, «өлкән» «олуг» дигән сүз икән.

Бәдри абзыйдан калган унике тиенгә тозлы балык — вобла һәм симәнке алып ашадым.

Берничә көн торгач, Җаекка юнәлдек.

Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һичбер яктан сулыш алырга бирмәделәр.

Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә, иркенгә чыгаралар иде.

Мин никадәрле: «Җәяү барсам да, тышта, иркендә барам»,— дип гозерләнсәм дә, «Туңарсың, җизнәң туңдырмаска кушты»,— дип, мине чыгармыйлар иде.

Җизни бу Алты-биш Сапыйга Казаннан әллә нинди бер яхшы чана алып кайтырга кушкан икән, шул чана безнең артка тагылган, һәм, безнең алдан бара торган тагы төрле-төрле йөкләр төялгән Җаек кешеләре булганга, без «обоз» йөрүе белән бардык.

Шул сәбәпле ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә, тәмам унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып кердек.

Җаекта иң элек Сапый абзыйның өенә төштек. «Монда чәй эчик тә җизнәңнәргә кичкә илтербез»,— диделәр.

Кичкә таба, икенде-ахшам арасында, Сапый абзыйның җитәгендә җизниләргә киттем.

Юлда яшел чапан бөркәнгән яшь кенә бер хатын очрады. Алты-биш Сапый: «Бу — апаең, күреш»,— дигәч, моның илә күрештем.

Җизниләрнең өе бер ун сажин гына булыр ераклыкта икән, капкадан кереп, биек-биек баскычлардан менеп, өйнең икенче катына кердем.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Бүлеккә исем уйлагыз.
2. Бәдри абзый өендә үткән көннәрен шагыйрь ничек искә ала?

3. Нәни Габдулланы Казан икенче тапкыр ничек каршылый? Мөхәммәтвәли абзыйның кичерешләре турында әсәрдән өзекләр китерегез.
4. Кешеләрнең Тукайга җылы карашы кайсы вакыйгалардан күренә? Шул урыннарны табып укып күрсәтегез.
5. «Габдулланың Кырлай белән саубуллашуы» дигән темага рәсем ясагыз. Уңышлы табылганын сыйныф почмагына куегыз.

**Биремнәр.**

1. Тукайның тормыш юлына багышланган диафильмны карагыз.
2. Әсәрдән туры сөйләмгә мисаллар китерегез. Туры сөйләм нәрсә ул?
3. Тукай шигырьләренә язылган нинди җырлар беләсез?
4. «Габдулла Тукай» (Казан, 1986) альбомындагы рәсемнәрнең «Исемдә калганнар» әсәре белән уртак яклары бармы? Альбомдагы рәсемнәргә карап, фикер алышыгыз.

**Мөстәкыйль эш.**

1. «Асрарга бала бирәм, кем ала?» (Инша.)
2. «Кырлай авылы — минем дөньяга иң элек күзем ачылган урын» дигән темага бергәләп план төзегез.
3. «Исемдә калганнар» әсәре сездә нинди хисләр уятты? Әсәр турында фикер алышыгыз һәм телдән хикәя төзегез.
4. М. Казаковның «Үксез бала» рәсемендә Габдулланың күз карашын характерлап сөйләгез. Сабыйның күзләрендә ниләр күрәсез? Рәсем сездә нинди тәэсир калдырды?

## «ИСЕМДӘ КАЛГАННАР» ӘСӘРЕ ТУРЫНДА

«Исемдә калганнар» — автобиографик әсәрнең матур үрнәге. Шагыйрь аңа әйбәт исем тапкан. Ул үз башыннан кичергән хәлләрне, исендә калганча язып, укучы белән уртаклаша, ятим бала өстенә төшкән авырлыкларны, бер дә сыкранмыйча (ярым шаярып та, әмма булганча), оста хикәяләп бирә.

Габдулланың үзен белә башлавы ятимлек һәм усал карашлар белән исендә калган. Шуңадыр да аның зур кара күзләрендә өлкәннәрнең кырыс карашы мәңгегә язылып кала. «Асрарга бала бирәм, кем ала?» — дип, базарда сатылуын бала күңеле оныта алмый, билгеле. Шагыйрь булгач та, ул сабый чак ярасына әйләнеп кайта:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңгаемнан милләтем.

(*«Дошманнар», 1912*)

«Әнине кайтарыгыз!» — дип, җеназа артыннан үксеп йөгергән нәнинең аяныч хәле укучы күңелен әрнетә, аның эчке дөньясын айкап үтә. Әсәрдәге мондый урыннарны тыныч кына укый алмыйсың. Әле дә баланың әрнүле шушы авазы ишетелгән сыман тоела. Шуңа карамастан «Исемдә калганнар» оптимистик рухы, яшәүгә мәхәббәте белән сокландыра. Бала дөньясы үзенең шуклыклары, наянлыклары белән матур. Бу әсәрдә кыска-кыска мизгелдә Габдулла тормышындагы сөенечләр дә бирелә. Сабан туе шатлыгы, Кырлайда үткәргән җәйге уеннары — аның онытылмас хатирәләре.

Кырлай Тукай тормышында зур урын алып тора. Монда ул яхшылык белән яманлыкның, изгелек белән рәхимсезлекнең ни икәнен сизгер күңеленә салып куя. Сәгъди абзыйның шәфкатьле карашын тойса, әнкәсенең төкселегеген, үги бала итеп кимсетүен рәнҗү катнаш газап белән кичерә. Китек күңел тиз сизенә ич, һәрчак үзенә булган мөнәсәбәтнең үзгәреп торуын ул сагаеп кабул итә. Болар барысы да нәни кешенең йөрәгенә онытылмас эз салган һәм күңелендә калган истәлекләрнең җанлы күренешен язарга этәргән. Тукай — бала чагыннан ук халкы белән бергә яшәгән, аның авыр тормышын гына түгел, күңел байлыгын да җырлаган әдип. Шагыйрьнең яшьли үлеме халык йөрәгендә тирән яра, олы фаҗига булып кала.

## АВТОБИОГРАФИЯ ҺӘМ БИОГРАФИЯ

**Автобиография** — үз тормыш юлың турында язу. Аерым кешенең башыннан кичергән хәлләре, булган тормыш фактлары автобиографиядә бик эзлекле бирелә. Танылган язучының автобиографиясендә, тормыш вакыйгаларыннан тыш, ул яшәгән чорның характерлы яклары да чагылыш таба. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрендә, балачак истәлекләре белән бергә, халыкның нәни Габдуллага тирән мәхәббәте ул яшәгән иҗтимагый җирлектә нык сиземләнә.

**Биография** — кемнең дә булса тормыш юлы турында язу. Гадәттә, язучылар, фән эшлеклеләре һәм атаклы шәхесләр тормышы турында биографияләр языла. Аларның кайсы чорда, нинди шартларда яшәве, рухи дөньясы һәм иҗат юлы белән биографиядә танышырга мөмкин. Мәсәлән, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлын өйрәнеп, аның фашистларга каршы ничек көрәшүен, ниләр уйлануларын, нинди хәлләрдә яшәвен беләбез.

**Бирем.**

Автобиографиягезне языгыз.

## ШҮРӘЛЕ

1

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл — Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.
Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап чәчкән идем, урган идем.
Ул авылның,— һич онытмыйм,— һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы? — дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә — инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.
Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Түбәләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.
Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр[1].
Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.
Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп,
киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.
Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.
Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.
Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен сауләтләре[2].
Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? без дә Хакның бәндәсе.

2

Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.
Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым...
Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле;
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит — «Шүрәле».
Аз гына сабрит[3] әле, и кариэм[4]! хәзер язам;
Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.

3

Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар,
Юк түгел аю, бүре; төлке — җиһан корткыч та бар.

---

[1] *Гонҗә* — ачылып җитмәгән чәчәк.
[2] *Сауләтләре* — батырлыклары.
[3] *Сабрит* — сабыр ит.
[4] *Кариэм* — укучым.

Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, пошн —
Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.
Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр,
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр.
Һич гаҗәп юк, булса булыр,— бик калын, бик күп бит ул;
Күктә ни булмас дисең,— очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

4

Шул турыдан аз гына — биш-алты сүз сөйлим әле,
Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.
Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга ялгызы, бер ат җигеп.
Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны балта берлән тук та тук!
Җәйге төннең гадәтенчә төн бераз салкын икән;
Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.
Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,
Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.
Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора;
Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.
Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә,
Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.
Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!
Борыны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да — ботак-тармак кеби.
Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр, төнлә түгел — көндезләре.
Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.
Кәкре түгелдер моның бармаклары — бик төз төзен,
Тик килешсез — һәрбере дә ярты аршыннан озын.

5

Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»

— Бер дә шикләнмә, Җегет, син; мин карак-угъры түгел;
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел.
Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле, күргәч сине, шатлыгымнан үкерәм.
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым —
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.
Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети.
— Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, мин карышмый
уйныймын;
Тик сине шартымга күнмәссең диеп, мин уйлыймын.
— Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?
Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.
— Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.
Мин дә көч-ярдәм бирермен: әйдә, иптәш, кузгалыйк,
Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы —
Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире,
Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире;
Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын,—
Кариәм, күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын!
Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу,
Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.
Шүрәле тыккан кулын — селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан[1] хәйләсен — һич балтага күз салмыйдыр.
Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.
Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра.
Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына,
Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына:
— Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәм генәм;
Мондин ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм.

[1] *Инсан* — кеше.

Башкалардан да тидермәм, ул минем дустым диеп,
Аңгар урманда йөрергә мин үзем куштым диеп.
Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр;
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар? —
Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша;
Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.
Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;
Ул моның фөрьядларын[1] асла[2] колакка элми дә.
— И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең?
Иртәгә килгәнче дустлар, тәндә җаным торса гәр,
Шул фәлән атлы кеше кысты диермен, сорасалар.
— Әйтсәм әйтим, син белеп кал: чын атым «Былтыр» минем.
Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!—
Шүрәле фөрьяд итәдер, аудан ычкынмак була
Һәм дә, ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була.
Кычкыра: «Кысты, харап итте явыз Былтыр мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»
Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
— Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең,— диләр.
Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!
И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел!»

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. «Шүрәле» поэмасын укыгач, сездә нинди хисләр туды? Нинди күренешләр күз алдына килде?
2. Поэманың кайсы урыннары аеруча тәэсирле булды? Үз сүзләрегез белән сөйләгез. Халык тагын нинди фантастик образларга ышанган, алар турында фикер алышыгыз.
3. Күренеш һәм вакыйгалар тәфсилле, мавыктыргыч булсын өчен, шагыйрь нинди сүзләр сайлый? Шул юлларны әсәрдән табып укып күрсәтегез.
4. Поэмадагы персонажларның үзара мөнәсәбәте, хәрәкәт-омтылышлары сездә нинди кичерешләр уятты? Текстка таянып, сурәтләп сөйләгез.

---

[1] *Фөрьядларын* — зарланып елауларын.
[2] *Асла* — һич тә.

5. Кырлай табигате ничек тасвирлана? Сезнең хәтерегездә табигатьнең кайсы вакыты күбрәк саклана? Ни өчен?
6. Поэманың бишенче бүлеген рольләргә бүлеп укыгыз. Сорау һәм өндәү җөмләләрне табып, интонация төрлелеген билгеләгез. Тавышта нинди үзгәрешләр ясала?
7. Поэмада утынчы егет һәм Шүрәле образлары ничек сурәтләнә? Шүрәленең тышкы кыяфәтен тасвирлаган юлларны текстан табып укыгыз.
8. «Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә», «урман сарыгы», «тавыклары җырлай» дигән төшенчәләрне аңлатыгыз. Бу сүзләрне кертеп, җөмләләр уйлагыз.

**Мөстәкыйль эш.**

1. Поэманың үзегезгә ошаган урынын рәсем итеп ясагыз.
2. Беренче бүлекне, сәнгатьле итеп, яттан сөйләргә өйрәнегез.
3. «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп, нинди сәнгать әсәрләре иҗат ителгән? Фикер алышыгыз. Берәр музыкаль әсәрне сыйныфта тыңлап карагыз. Әсәрнең эчтәлеген аңлатуга көй ничек ярдәм итә?

## «ШҮРӘЛЕ» ПОЭМАСЫ ТУРЫНДА

Шүрәле — татар халкының борынгыдан бирле сөйләнеп килә торган мифик образы. Халык әкиятендә ул — урман хуҗасы, кешеләрне кытыклап үтерә дип уйланыла. Кеше, табигать баласы булып яшәгәндә, үзен чолгап алган тирә-юньне серле итеп тойган, бөтен нәрсәнең җанлы булуына ышанып, үзенең күзәтүләрен, омтылышларын хыял образлары аша сурәтләп, һәр нәрсәнең иясен, хуҗасын уйлап чыгарган. Хыял нигезендә туган образларны Җир шарында яшәүче барлык халыкларда да очратырга мөмкин. Прометей — кешенең азатлыгы өчен көрәшүче мифик герой, аны грек халкы иҗат иткән.

Габдулла Тукай халык тормышына аның гореф-гадәтләре, ерак тарихыннан килгән мифик образлары аша карый. Болар барысы да безгә туган җирнең газизлеген тоярга, урман-сулары, сайрар кошлары, кояшлы иртәләре белән күз алдына китерергә ярдәм

итә. Шүрәле — шагыйрьгә туган җир моңын, туган җир сагышын яңарткан, сабый чак истәлекләрен хәтерләткән, халыкның кабатланмас хыялында туган образ. «Шүрәле» әкиятенә таянып, ул «Шүрәле» поэмасын иҗат иткән. Әмма Тукайда «Шүрәле» — шигъри әсәр: ул халык моңнары, биюләре, табигать кочагындагы тормышы, чәчәкле болыннары белән күңелләрне кузгата, туган як истәлекләренә күмеп ташлый. Шүрәле белән очрашкач, Былтырның зирәклеген, тапкыр акылын сурәтләп, язучы бала күңеленә шатлык өсти. Вакыйганың киеренкелеге ахырга кадәр дәвам итә. Егет язмышы өчен борчылу әле курку, әле куанычлы хисләр агышын тудыра.

Шагыйрьнең уйлап табуы, хыял дөньясын тасвирлавы бик матур, аның вакыйгаларны көтелмәгәнчә төгәлләп куюы күңелләрне бушатып җибәрә: «Әй җүләр, кысканга былтыр, кычкыралармы быел!»

Поэманың һәр юлы җырлап тора; халык көйләренең дәртле яңгырашын, интонация байлыгын, шигъри төгәллекне укучы сизеп кенә калмый, матурлык дөньясын күрә, сәнгатьчә сурәтләүдән туган ләззәтне үзе кичерә.

«Шүрәле» поэмасы — татар сәнгатенең башка тармаклары үсешенә дә этәргеч биргән үлмәс әсәр. «Шүрәле» балеты (Фәрит Яруллин музыкасы) халыкның музыкаль сәләтенә, акыл тапкырлыгына, җиңелмәс рухына һәйкәл булып тора.

## ЧАГЫШТЫРУ

Г. Тукай — сүз остасы. Шигырьне ул күңелне тибрәтерлек итеп сурәтләп бирә. Язучы теленең байлыгы, матурлыгы үзенә генә хас сурәтләү чараларын табуда, аларны белеп куллануда. Чагыштыру һәм эпитетны ул, «Шүрәле» поэмасын язганда кулланып, күренешне һәм андагы персонажларны укучыга җанлырак, тәэсирлерәк итеп җиткерә:

Борыны кәп-кәкре — бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да — ботак-тармак кеби.

Шүрәле әнә шундый куркыныч зат булып күз алдына килә.

Димәк, **чагыштыру** бер предмет яки күренешне икенче предмет һәм күренешкә охшатып әйтүне белдерә.

**Эпитет** («ачыклагыч», «өстәмә» дигән мәгънәдәге грек сүзеннән) — ачыклагыч сүз. Эпитетлар җөмләне аеруча бизәп торалар, һәм аларны табарга да җайлы. Мәсәлән,

Ал, кызыл, ак, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Ал, кызыл, ак, сап-сары, зәңгәр, яшелдән сыйфатлары, эпитет булып, чәчкәләрнең билгеләрен гаять матур характерлый.

**Бирем.**

Үзегез укыган берәр китаптан чагыштыру һәм эпитетка мисаллар табып, дәфтәрегезгә языгыз һәм аны үзара тикшереп карагыз.

## ПАР АТ

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.

Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән, һәм тәмам баскан йокы.

Берзаман ачсам күзем, бер төрле ял-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә бер тапкыр күрәм.

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.

Хуш, гомер иткән шәһәр! Инде еракта калдыгыз;
Аһ! Таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.

Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;
Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

Әллә нәрсәм юк кеби, бер нәрсә юк, бер нәрсә ким;
Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.

Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?
Бикмөхәммәт, Биктимер — берсен дә белмим, әллә кем!

Сездән айрылып, туганнар! — җайсыз, уңгайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.

Шундый уйлар берлә таштай катты китте башларым;
Чишмә төсле, ихтыярсыз акты китте яшьләрем.

Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан».

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә, чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан[1],
монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

[1] *Гыйрфан* — аң-белем, культура.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шигырьне дөрес интонация белән укыгыз.
2. Шагыйрьнең эчке дөньясын тасвирлаган, хисләр үзгәрешен, хисләр агышын чагылдырган урыннарны табыгыз.
3. Ни өчен шигырь «Пар ат» дип исемләнә? Бу исемнең герой уй-кичерешләренә бәйләнеше бармы?
4. Тексттан сурәтләү чараларын табыгыз, аңа ияреп, үзегез дә мисаллар уйлагыз.
5. Лирик геройның кичерешләрен ничек бәялисез? Нигә шагыйрь: «Тик икәү без: уй да мин»,— дип моңая?
6. Тукайның ерак бабаларыбызга, туган халкының тарихына, мәгърифәтенә мөнәсәбәтен, җылы карашын сөйләгез, мисаллар укып күрсәтегез.
7. Сезнең халкыбыз тарихы турында нилəр укыганыгыз бар?

## «ПАР АТ» ШИГЫРЕ ТУРЫНДА

«Пар ат» — лирик геройның кичерешләрен, эчке дулкынлануларын сурәтли торган нәфис шигырь. Шагыйрьнең тасвирлавында торган җирдән аерылу сагышлары, борчулы күңелнең әзләнүләре гәүдәләнә:

Сездән айрылып, туганнар! — җайсыз, уңгайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.

Әмма лирик геройның хисләре үзгәрүчән: алда аны ашкындыра торган сөенечләр, якты өметләр көтә. Аның туган җиренә кайту куанычы бөтен күңелен биләп алган, эчке дөньясын шатлык хисләре күмеп киткән. Казан белән очрашу сөенечләре бик табигый:

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Геройның кичерешләре туган җир күренешләре, тирә-юнь киңлекләре белән бәйләнгән. Бу аның хисенә юнәлеш бирә, хисләр ташкынын ясый. Тукай, күрәсең, эчке дөньяны сурәтләү аша тышкы күренешләргә килә. Аңа кешенең уйларын, яну-шатлыкларын тасвирлау хас.

## ШИГЪРИ СӨЙЛӘМ

**Шигырь** (гарәп сүзе) «тәртип», «рәт» дигән мәгънәне аңлата. Ул — басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең билгеле бер тәртиптә чиратлашып килүенә нигезләнә. Аның һәр юлы төгәл үлчәмгә буйсына. Димәк, шигырь — хис һәм фикер берлеген белдерүче көйле сөйләм. Аңа музыкальлекне шигъри ритм бирә. Шигъри ритм гадәти ритмнан аерылып тора. Ул басымлы һәм басымсыз иҗекләрнең билгеле бер үлчәмдә килүен таләп итә. Бер мисал алыйк:

Боз һәм кар эрде,
Сулар йөгерде,
Егълап елгалар,
Яшьләр түгелде.

(*Г. Тукай*)

Шигырьнең дүрт юлы да бишәр иҗекле; бер үк сандагы иҗекләр, кабатланып килеп, ритмик сөйләм тудыралар. Поэзия — язма сәнгатьнең нечкәрәк, тәэсирлерәк төре. Чынбарлыктагы күренешләрне, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен хис һәм кичереш ярдәмендә сурәтләп бирү аеруча поэзиягә хас.

# *Фатих Әмирхан*

## *(1886—1926)*

Фатих Әмирхан — шәһәр халкын, аның гореф-гадәтен яхшы белгән чын зыялы Казан кешесе. Җыелышларда, мәҗлес-туйларда күркәм кешеләр белән очрашу, кешеләрдә булган рухи матурлыкны, күңел киңлеген, яшәү ямен күрү, алар белән аралашу, әңгәмә кору әдипнең яраткан шөгыле була. Төрки телләрдә, гарәпчә, фарсыча, русча иркен укуы һәм сөйләшүе өстенә, аның француз теленнән дә хәбәрдарлыгы мәгълүм. Ул Казанда татар театрын җанландырып җибәрүчеләрнең дә күренеклесе була.

«Фатих Әмирхан — татар әдәбияты тарихында гына түгел, бөтен татар иҗтимагый тарихында иң күренекле урын тоткан, вакыты буенча кечкенә, ләкин әһәмияте буенча чиксез зур булган бер буынның үзәгендә торган кеше»[1].

Фатих Әмирхан 1886 елның 1 гыйнварында Казанда мулла гаиләсендә туа. Зиһенлелеген, укуга сәләтен яшьтән күреп, аны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Югары сыйныфларга җиткәч, ул үзлегеннән русчага өйрәнә, университетка керергә әзерләнә.

Фатих мәдрәсә чорында ук яза башлый, иҗтимагый эшләрдә актив катнаша. Җитдилеге, үткерлеге,

---

[1] Фатих Әмирхан турында истәлекләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.— 39 б.

уй-фикерләрендә мөстәкыйльлеге белән ул башкалардан аерылып тора. 1903—1905 елларда мәдрәсәдә шәкертләр хәрәкәтенең башында тора, аның җитәкчелегендә әдәбият түгәрәге эшли, кичәләр үткәрелә. Шул дәвердә үк ул Көнчыгыш һәм Көнбатыш галимнәренең фәлсәфи хезмәтләрен, рус һәм Европа әдәбиятын кызыксынып укый.

1906—1907 елларда ул «Тәрбиятел-этфаль» («Балалар тәрбиясе») журналында секретарь булып эшли, җитди мәкаләләр яза, тәрҗемә эше белән дә шөгыльләнә. Дания язучысы Г.-Х. Андерсенның «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» исемле әсәрен тәрҗемә итеп, аны журналда бастыра.

1907 елда Казанга кайткач, көтелмәгән бәхетсезлеккә дучар була: аның ике аягын һәм уң кулы белән битенең уң ягын паралич суга. Егерме бер яшьлек егет хәрәкәтсез кала. Әдип, гомере буе аягына баса алмыйча, кеше ярдәме белән коляскада йөрергә мәҗбүр була. Шундый хәлендә дә төшенкелеккә бирелмичә иҗат эшен дәвам итә, замандашлары Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Шәриф Камал белән бер сафта атлый. «Сәмигулла абзый», «Танс кичәсе», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Танымаганлыктан танышлык», «Фәтхулла хәзрәт» кебек юмор белән сугарылган күп санлы хикәяләр белән бергә, җитди повесть һәм драма әсәрләре иҗат итә. Аның «Яшьләр», «Тигезсезләр» исемле сәхнә әсәрләрендә үз заманының иң әһәмиятле вакыйгалары тасвирлана.

Фатих Әмирхан янына артистлар, язучылар, матбугат хезмәткәрләре, сәнгать әһелләре даими йөргәннәр, аннан киңәшләр алганнар, чөнки әдип кешенең шатлыгын да, кайгысын да ихлас уртаклаша белгән.

Шулай ук күзәтүчән, тәэсирләнүчән, киң колачлы язучы табигатьне ярата, аннан үзенчә ямь таба...

«Табигать матур, шулай да кеше кызыклырак»,— дип әйтергә яраткан ул. Әнә шулай берсе икенчесен кабатламаучы кызыклы образларны үзенең төрле жанрдагы әсәрләрендә оста итеп сурәтли алган.

Кыска һәм фаҗигале гомерендә Фатих Әмирхан зур әдәби мирас калдыра. 1926 елның 9 март иртәсендә язучы каты авырудан вафат була. Аның кабере — Казанда, Яңа Бистәдәге татар зиратында.

## НӘҖИП

### 1

Минем абыемны бөтен күрше-күрпе мактап сөйлиләр иде:

— Булдыклы бала, матур бала, акыллы бала...— диләр иде. Безгә керә торган карчыклар гына түгел, кызлар да, ул өйдә булмаса, ападан:

— Гомәр кайда соң? Күренми лә, ишегалдында да күренмәде,— дип сорыйлар.

Әгәр инде ул өйдә булса, карчыклар аны чакырып сөяләр, сөйләштерәләр, кызлар аны үзләренең уеннарына катыштыралар, аны кыстап, курай уйнаталар иде. Кайдан өйрәнептер, ул курайны бик матур итеп, моңлы итеп уйный иде.

Башка кешеләрнең аны болай сөюләре, мактаулары мине бик үк көнләштермәсә дә, Мәрфуга апаның аны миннән артык сөюе мине борчый һәм бик кәефсезләндерә иде.

Мәрфуга апа дип, без үзебезнең күрше Габдрахман абзыйның олы кызын йөртәбез. Миңа караганда сигез-тугыз яшь, абыема караганда алты-җиде яшь олырак булган бу кыз, инде җиткән кыз булса да, безнең ундүрт-унбиш яшьлек апабыз янына сөйләшеп утырырга гына түгел, курчак уйнашырга да керә иде. Абый да, мин дә аны бик сөя идек. Мин аны күзләре зур булганга, тешләре бик тигез, ап-ак булганга һәм авызын матур итеп көлгәнгә күрә сөя идем: абый ник сөйгәндер — мин анысын белмим, бәлки ул аны тавышы матурга күрә сөя торган булгандыр. Мәрфуга апа бер дә җырлый белмәсә дә, бик матур тавыш белән сөйләшә. Аның күкрәгеннәнрәк алып чыгарып сөйли торган тавышы абый уйный торган курай тавышына охшап-охшап китә.

Көннәрдән бер көнне без абый белән уйнарга тотындык: иске тарантасыбыз — пролётка урынында, аның югары күтәреп бәйләнгән тәртәләре — ат урынында,

абый — бай, мин кучер булдык. Абый: «Киттек!» — дип кычкыргач, мин, тарантасның кучер аягы басар өчен куелган тактасына аякларым белән тибеп, ат барган кебек тавыш чыгарырга тотындым. Ат кузгалды, без киттек, имеш!

Берничә минутлар шулай баргач, абый миңа:

— Атны чаптыра төш! — диде. Мин дә аякларымны бөтен көчләрем белән тыпырчындырырга башладым. Очабыз гына, имеш!

Бу арада апа, тәрәзәне ачып:

— Гомәр, кер әле монда. Безгә курай уйнарсың! — дип кычкырды.

Мин, абыйның җавап биргәнен көтмичә, аның өчен үзем җавап бирергә ашыктым:

— Уйныйбыз әле без. Курай, курай, имеш, тапканнар бер курай. Кермибез без, йөдәтмәгез безне! Шулай бит, абый. Анда кызлар арасында ир малайларга нәрсә бар соң.

Апа янында бу көн кызлар вә алар арасында Мәрфуга апа да барлыгын без белә идек. Минем абыйны чакырып та, үземне чакырмый калдыруларына ачуым килгән иде. Абыйны кертмәс өчен, мин, аякларымны тагын да ныграк тыпырчындырып, атның бик шәп һәм бик дәртле барганлыгын күрсәтергә тырыштым.

Абый апага:

— Кермим! — дип, үзе җавап бирмәсә дә, минем җавабыма каршы килмәде. Әмма апа, минем ачуымны тагын да китерә төшәр өчен дигән шикелле итеп:

— Сине дәшмибез дә без, синең кирәгең юк. Гомәрне дәшәм бит мин. Гомәр, кер, акыллым! — дип кычкырды.

Мин, апаның бу сүзләрен абыйга ишеттермәс өчен, аякларымны шулкадәр каты тыпырчындырдым ки, аякларымның сөякләре яңгырадылар, тарантас тактасы кубарган тавыштан үземнең колакларым җәфаландылар. Ләкин файдасыз: абыйның апа сүзләрен ишеткән икәнен мин йөзеннән карап аңладым. Апаның ул

сүзләренә каршы миңа нәрсә дә булса эшләргә кирәк иде. Нишлисең. Мин тоттым да апаны үчекләргә керештем. Иренемне бераз былчайттым, күзләремне акайттым да:

— Вә-вә-вә, Гомәр, кер-кер-кер, вә-вә-вә, курай-райрай, вә-вә-вә... — дип кычкырдым.

Ачуымнан минем бөтен кәефем бозылып өлгергән иде инде. Әле ярый абый тарантастан төшмәде, апалар янына кереп китмәде. Булмаса, Ходай белә, миңа елап җибәрергә дә тугры килгән булыр иде.

Апа тәрәзәдән китте. Мин дә бераз тынычландым, тәртәләргә чыбыркы белән бер-икене сыдырдым:

— На-а-а, ник ялкауландың, хайван!

Шулай итеп, менә инде уеныбыз яңадан әүвәлге дәртле хәленә кайта дип торганда гына, тәрәзәдән тагын:

— Гомәр! — дигән тавыш ишетелде. Бу юлы инде апа тавышы түгел, Мәрфуга апаның матур тавышы иде. Минем аяклар ихтыярсыз тыпырчынудан туктадылар.

— Гомәр, кер әле, нәнәм, безгә курай уйна!

Мәрфуга апаның матур тавышы миңа бу юлы шундый ямьсез, шундый начар булып ишетелде ки, мин эчемнән генә аны да үчекләдем:

— Вә-вә-вә, Г-г-г-омәр, вә-вә-вә...

Минем атны бик чаптыруыма да карамыйча, абый тарантастан төшеп китте һәм, минем: «Ат чабып барганда төшмиләр инде аны!» — дигән сүземә җавап та бирмичә, өйгә дә кереп китте. Бу эшләрнең барысы мине шулкадәр хурландырды ки, минем күзләремә яшь тә килеп өлгерде: «Кешене мыскыл итәләр, кешене җәберлиләр, аны дәшәләр, мине дәшмиләр дә. Мине һәр кеше җәберли генә, мыскыл итеп йөртә генә, әллә, бәлки, мин эти-әнинең дә үги балаларымындыр да, минем үземә генә әйтми торганнардыр... Менә барысы да кыямәт көнендә җәһәннәм утында янарлар әле...» — ди-ди уйланып, мин шактый вакытлар кучер

урынында утырып тордым; күз яшьләре инде акрын-акрын гына йөземне чылата башлады.

«Менә кыямәт көнендә үзләре дә күрерләр әле... Сабый баланы елаткан өчен, җәһәннәм утында янарлар әле...» дип, тагын-тагын уйландым. Бу «үзләре» дә дигән кешеләрем кемнәр булгандыр — анысын Хода белә. Биш-ун минут шулай утырганнан соң, мин күз яшьләремне сөрттем дә ачу алу кайгысына төштем. Әмма кемнән ачу алырга? Абыйданмы? Ападанмы? Мәрфуга ападанмы? Әллә барысыннандамы?

«Анысы ничек тугры килер әле. Җае ничек тугры килсә, шулай эшләрмен!» — дип уйлап, мин кызлар җыелып утыра торган апа бүлмәсенә чаптым. Ул бүлмәдә, апа һәм Мәрфуга ападан башка, берсе җиткән, берсе минем кордаш ике кыз утыралар иде. Үзем танымый торган бу кызларның Мәрфуга апаларга икенче шәһәрдән кунакка килгән кызлар икәнен мин актыктан гына белдем. Мин барып кергәндә, абый курай уйнап утыра, Мәрфуга апа да, теге кунак кызлар да бик күңел биреп тыңлап утыралар иде. Барып кергәч тә, мин ачы чырылдык тавыш белән абыйның курай уйнап утыруын үчекләргә ябыштым. Берәр минутка бүлмәдәгеләр аптырашып калган шикелле булып тордылар да, аннан соң апа, минем авызны кулы белән каплап:

— Шаярма, тукта, булмаса, хәзер чыгып, әнигә әйтәм! — дияргә тотынды.

Мәрфуга апа, зур күзләренә гаҗәпсенү кыяфәте чыгарып:

— Әбәү, нәнәм, бу ни эшең бу? Син бер дә болай түгел идең бит. Менә бу кунак кызлары үзеңне акылсыз малай икән бу дип китәрләр,— диде.

Мин Мәрфуга апаның бу сүзләреннән соң дәрәҗәдә кәефсезләндем, кунак кызларының үземә туп-тугры карап торуларыннан хурландым да ачудан һаман әле уйнап утыра торган абыйның авызыннан载раен тартып алдым. Бу эш, минем үземчә, бер батырлык, бер егетлек

шикелле булып, кунак кызларының, бигрәк тә Мәрфуга апаның исен китерер һәм аларга мине бер батыр егет итеп күрсәтер шикелле тоела иде. Ләкин эшнең ахыры алай булып чыкмады: абый кураен минем кулдан тартып алды да үземне этеп җибәрде, Мәрфуга апа һәм кунак кызлары миңа:

— Әбәү, акылсыз! — диештеләр.

Апа, минем абый белән сугышырга торганымны күреп, ике кулымнан тотып, бүлмәсеннән чыгарып җибәрде дә ишеген бикләп алды. Мин, күзләремнән ага торган яшьләр белән тотлыга-тотлыга:

— Ачмасагыз, ишегегезне ватам! — ди-ди кычкырынып, бүлмә ишеген кагарга тотындым. Тавышка килгән әнине күргәч, мин инде җылап ук җибәрдем: — Абыйны үзләре чакырып алалар. Мине, үзем килгәч тә, бүлмәләреннән куып чыгаралар...

— Абыеңныкы шикелле берәр һөнәрең булса, сине дә үзләре чакырып алырлар иде. Кит аннан, тавыш чыгарып йөрмә! — дип, әни мине бүлмә тирәсеннән куып җибәрде.

Бу хурлыктан соң мин, бакчага чыгып, бик озак җылап утырдым.

«Мине барысы да җәберлиләр генә. Әнием дә минем үги ана булырга кирәк... Менә кыямәт көнендә һәммәсе дә җәзаларын күрерләр әле. Барысы да җәһәннәм утында янарлар... һөнәрең булса дигән булалар. Абый миңа караганда олы бит ул, аның яшенә җиткәч, минем дә һөнәрем булыр әле...» — дип уйлый-уйлый җылап утырдым.

2

Ул көн кич йокларга яткач, мин үземнең шул дулавым хакында бик озак уйландым. Бер караганда, апа, Мәрфуга апа, әни, абый, хәтта теге кунак кызлары да мине җәбер иткәннәр шикелле тоелалар, икенче караганда, мин үзем, болай сугыша башлап, начар эшләгәнмен шикелле тоела. Бер уйлаганда, тегеләргә

ачуым кабара, икенче төрле уйлаганда, алардан оялган сымак булам. Башкалары тагын бер хәл иде, Мәрфуга апа алдында мин үземне оятлы итеп сизәм.

Ул мине акылсыз малай икән бу дип уйлагандыр инде. Абый, минем кулымнан кураен тартып алып, үземне этеп җибәрде. Мәрфуга апа мине бигрәк көчсез икән бу дип уйлагандыр инде. Мине апа кулымнан тотып чыгарып җибәрде. Мәрфуга апа мине кызлар хәтле дә көче юк икән аның дип уйлагандыр инде. Әнигә әйткәндә дә, мин җылап җибәрдем. Мәрфуга апа аны ишеткәндер дә, бигрәк җылак малай икән бу, кыз балалар шикелле икән, дип уйлагандыр... Абыйны алар һөнәре өчен чакырып алалар икән, Мәрфуга апа мине бигрәк һөнәрсез малай бит бу дип уйлый торгандыр...

Бу уйлар мине шулкадәр ваттылар ки, мин таң атмыйча йокыга китә алмадым. Икенче көн иртә белән минем башым үземне Мәрфуга апага ничек итеп батыр, һөнәрле, җылак түгел итеп күрсәтү юлларын уйлау белән мәшгуль булды. Уйлый-уйлый торгач, бер юл табылган шикелле булды. Мәрфуга апаның һәркөнне безгә керә торган вакытын мин белә идем. Шул вакытны саклап торып, мин өебез түбәсенә мендем дә, аның иң очланып килгән җиренә барып, бер генә кулым белән морҗага ябышып басып тора башладым. Миңа, Мәрфуга апаның керүен көтеп, шул хәлдә унбиш-егерме минутлар торырга туры килсә дә, мин чыдадым: менгән урынымнан төшмәдем. Менә бервакыт капкадан Мәрфуга апа күренде... Аның безгә кереше. Ул инде ишегалдының уртасына ук җитте... Ләкин түбәгә бер генә мәртәбә яңлыш кына да күз дә төшермәде. Ул килә дә килә. Мин аның үземне күрүен көтәм дә көтәм, әмма ул... ул үч иткән шикелле күрми дә күрми. Ахыры, мин чыдамадым:

— Мәрфуга апа! — дип кычкырып җибәрдем. Ул як-ягына каранды, мин яңадан кычкырдым. Шуннан соң ул мине күрде, ләкин:

— Исәнме, Нәҗип! — диюдән башка бер сүз дә әйтмәде. Минем шушындый биек һәм куркыныч урында басып торуыма бер дә исе китмәгән шикелле генә итеп йөри бирде. Аның болай исе китмәвенә кәефсезләнебрәк, мин яңадан:

— Мәрфуга апа! Мин монда әллә кайчаннан, бик озактан бирле басып торам бит! — дип кычкырдым.

Ул тагын бер кат миңа күтәрелеп карады да:

— Аягың ычкынып егылып китсәң, булыр эш. Төш, нәнәм, аннан. Өй түбәсендә каргалар гына йөриләр. Зур егетләр анда менмиләр, әнә абыең зур булгач, анда бер дә менми! — диде. Бу сүз минем бөтен кәефемне бозды, моннан соң түбәдә басып торуның бер тиенлек тә кызыгы калмады. Мәрфуга апа, бу сүзне әйткәнче, мине борып чеметеп алган булса, бусы миңа җиңелрәк булган булыр иде. Кәефсез генә, азапланып кына, йөземне чытып кына, мин түбәдән төштем дә бакчага барып утырдым һәм: «Минем бернәрсәм дә күренми, абый менеп шулай басып торса, барысы да аны мактарлар иде, барысының да аңар исләре китәр иде. Ул курка, ул менә алмый шул, ә аны берсе дә куркак дими... Барысы да миңа үч итәләр...» — дип уйлап, үз-үземне бик җәберләнгән кеше шикелле итеп тоя башладым. Мәрфуга апага һәм үзем белеп җиткерә алмый торган әллә кемнәргә ачуым килде. Ачуым килде, әмма... Ләкин ничек тә булса, Мәрфуга апага үземнең батыр икәнемне күрсәтү уеннан мин кайта алмадым. Моның өчен мин аның өенә кайтырга чыкканын саклап тордым да, безнең өй ишегеннән аның чыкканын күргәч тә, җәһәт кенә, батыр гына койма өстенә менеп киттем. Һәм койма өстенә куелган бер кул яссылыгы гына такта өстендә арлыбирле йөрергә тотындым. Мин йөрим дә йөрим, әмма ул алдына караган да, мине күрмичә, әллә нәрсә уйланып килә дә килә. Инде ул коймага якыная дигәндә, мин тамак кырып бактым, ләкин файдасы булмады, кычкырып әйтеп, үз-үземне күрсәтсәм, баягы шикелле булу-

ыннан курыктым, шунлыктан ике кулымны кушлап тотып, баш бармакларымны авызыма кабып, пароход тавышы белән кычкыртып җибәрдем. Бер кычкырттым, ике кычкырттым, өченче кычкыртуымда инде Мәрфуга апа, йөзен күтәреп, миңа карады. Мин моны күргәч тә, бер аягымны коймадан күтәреп, бер генә аягым белән аның өстендә калдым: тар гына урында да мин, бер аяк өстендә генә дә басып тора алганлыгымны Мәрфуга апага күрсәтеп, аны хәйран калдырырга тели идем. Ләкин аның минем бу һөнәремә дә бик исе киткәнлеге күренмәде. Бары ул:

— Нәҗип акыллым, төш аннан, төш! Шундый урыннан егылып, берәр җиреңне имгәтмәсәң ярар иде. Зур егетләр койма өстенә менеп йөрмиләр. Койма өстендә мәчеләр генә йөриләр. Әнә абыең, акыллы булгач, бер дә андый җиргә менми! — диде.

Бу сүз мине тагы үтерде дә салды.

— Әйе, абый менеп йөри алса, сез барыгыз да аны мактар идегез әле. Ул курка шул, ул менеп йөри алмый шул. Менә ул монда бер аягы белән генә басып торып карасын әле!..— дип, мин юаш кына мыгырдандым. Мәрфуга апа:

— Нәҗип, төш, акыллым, аннан, төш! Сине дә мактыйбыз без. Синең басып торганыңны күрдем мин, артык кирәкми инде, төш, акыллым! — дип узып китте.

Бу сүз миңа әүвәлгесеннән дә яманрак тоелды. «Мәрфуга апа минем үземне күрсәтергә йөргәнемне сизде. Мине бер дә батыр дип тә, егет дип тә уйламады. Бер аяк белән генә басып торганымны рәтләп күрмәсә дә, юри генә күрдем дигән булды. Мине кечкенә балаларны алдаган шикелле итеп алдар өчен генә: «Сине дә мактыйбыз без»,— дигән булды...» — дип уйланып-уйланып, мин Мәрфуга апага ачуландым, үпкәләдем һәм эчемнән генә аны үчекләп алдым:

— Төш, төш, таш, таш, вә-вә-вә, басып торганыңны күрдем.

Болай үчеклəп кенə ачуым басылмагач: «Аның күзлəре дə зур түгел, кеп-кечкенəлəр, тешлəре дə матур түгел, кап-кара гына, бик ямьсез генəлəр, көлүе дə бер дə матур түгел, əбилəр көлүе шикелле генə...» — дип уйлап, аның əүвəлдə үземə матур күренгəн һəммə җирен ямьсезгə чыгардым һəм, шулай итеп, үз-үземне беркадəр юаттым. Лəкин, ачуым басыла төшкəч, болай дип уйлавымның дөрес түгел икəнен үзем дə бик яхшы аңладым: аның күзлəре зур, тешлəре ап-ак, көлүе дə əбилəрнеке шикелле түгел, матур бит...

Лəкин ачуым ачу, бу соңгы уемны ничек булса да какшатып, Мəрфуга ападан үч алмый калырга ярамый.

«Күзлəре зур булса ни, алар əле генə зур бит. Менə икесенə дə арпа чыгар да кеп-кечкенə булып калырлар. Тешлəре дə авырырлар да, менə кайсылары төшеп бетəрлəр, кайсылары кап-кара булып калырлар. Көлүе дə ямьсезлəнер əле... Сабый баланы күп рəнҗетеп йөрсə...» — дип уйлап, мин кəефемне төзəтергə тырыштым.

Ул көн көне буе гына түгел, хəтта кич буе да əле минем күңелемдə Мəрфуга апага үч сакланды, лəкин икенче көн инде ачу онытылган, бары җиңелчə бер үпкəлəү генə калган иде.

Икенче көн иртə җилле, давыллы булды. Урамда күз ачып булмаслык тузан күтəрелгəн, бакчабыз агачлардан сынып төшкəн вак ботаклардан пəри оясы шикелле булган иде. Күк йөзе зəңгəрсу, кара куе вə калын болыт кисəклəре белəн капланган, дөнья шул болытлардан аңкыган салкынчалыктан җыйналган иде. Менə бервакыт давыл бераз акрынлаган шикелле булды. Бераздан тагын куəтлəнде, тагын бераз акрынлады, тагын куəтлəнде дə тагын бераз тынды. Бу вакытта бер куе болыт нəкъ безнең өскə килеп җиткəн иде. Дөнья җимерелгəн шикелле итеп, күк күкрəде, берəр мəртəбə яшен уты күренеп китте. Күк күкрəве тагын да куəтлəнде дə чалтыратып суккан яшен тавышы бөтен дөньяны яңгыратты. Тагын күк гөрелдəде, тагын яшен

чалтыратты да, чиләктән койган шикелле итеп, яңгыр яварга тотынды... Эре тамчылар белән дөньяны дер селкетеп яуган бу яңгыр ярты сәгать эчендә безнең бөтен ишегалдын суга батырды. Ярты сәгатьтән соң яңгыр инде әкренли башлады: тамчылар сирәгәйделәр, тигезләнеп исә башлаган җил болытны куды, аның астында капланып торган кояш, үзенең нурлы йөзен безгә таба юнәлдереп, юеш җирне җылыта, гөрләп ага торган яңгыр суын бриллиант тамчылары шикелле итеп ялтырата башлады. Дөнья яктырды, шатланды, көлеп җибәрде.

Мин, балакларымны сызганып, суда, былчыракта йөрергә чыгып киттем. Яңгырның салкынча суы аякларны кәефле кытыклый. Су белән изелгән кызыл балчык аякларга сыланып, аларны рәхәтләндерә. Шактый вакытлар бу кәефле эш белән маташканнан соң, мин кызыл балчыктан төрле нәрсәләр әвәләргә тотындым: күмәч булды, башлы шикәр булды, ат булды. Хәер, бу соңгы нәрсәмне ат дип тә, мөгезсез сыер дип тә, хәтта сарык дип тә уйларга мөмкин иде. Караган кешегә танырга уңгай булсын дип, мин бу «хайван»ның аркасына шырпы белән «ат» дип язып куйдым. Бу нәрсәләрнең бик килешле чыгуы мине үсендереп җибәргәч:

«Тукта, Мәрфуга апа сурәтен ясыйм. Үзенә күрсәтеп исен китерермен. Әгәр инде бик кызыгып куйса, аны үзенә үк бирермен»,— дип уйлап, адәм гәүдәсе әвәләргә тотындым. Монысы булды. Әүвәл корсагы бераз чыгынкырак булган иде дә: «Мәрфуга апаның корсагы болай түгел»,— дип уйлап, аны тигезләдем. Гәүдәгә аяклар кирәк. Шактый азаплана торгач, алар да бертөрле ясалдылар. Дөрест, бу аяклар бик нәфис түгелләр, аяктан да бигрәк кәкре башлы бүкәннәргә охшыйрак төшәләр иде. Ләкин нишләмәк кирәк? Яхшырак, нәфисрәк итеп эшли башласаң, кызыл балчык чыдамый, әле бер җире кителеп төшә, әле икенче җире сынып китә. Кулларны ясау аякларны ясауга караганда да мәшәкатьлерәк булды. Шулай да, азаплана торгач, алар да ясалып тәмам

булдылар. Дөрест, куллар бармаксыз һәм берсе берсеннән озынрак булып чыктылар. Ләкин аннан гына әллә никадәр зарар килми бит. Болар тәмам булгач, шар кыяфәтле итеп баш ясадым да шырпы белән авыз сыздым. Бик азапланып, тукмакка охшашлы борын ясап куйдым. Күзләр урынына, мәкәрҗә бүләгенә өләшенә торган кашлы йөзекләрдән алып, ике ялтыравыклы пыяла утыртып куйдым да алар өстеннән каш сыздым. Күзләр урынына утыртып куйган ялтыравыклы пыялаларымның түгәрәгрәк булып, зураеп, ялтырап торулары минем үземә бик килешле шикелле тоелды. Дөрест, бу ялтыравыклы пыялаларның берсе Мәрфуга апаның күзе шикелле зәңгәр булса да, икенчесе, кып-кызыл булып, аның күзенә охшамый торган булып тора иде. Ләкин нишләмәк кирәк? Хәзинәмдә бары шулкадәр генә иде шул. Колакларны шырпы белән сызып, мунчаладан чәч тә куйгач, «Мәрфуга апа» ясалып тәмам да булды. Караган кеше танымый тормасын өчен, моның да аркасына «Мәрфуга апа» дип язып куйдым.

Моны эшләп бетергәч, мин инде шактый вакытлар тик кенә утырып ял итүдән үз-үземне тыя алмадым. Яңа ясалып беткән «Мәрфуга апай»га карап тору минем үземә дә кәефле иде:

— Менә абый ясап карасын әле шушылай итеп!— дидем.

Хәзер инде Мәрфуга апаның үзебезгә керүен генә көтеп утырырга калды. Үзем ясаган «Мәрфуга апа»ны киптерергә кояшка куеп, чын Мәрфуга апаның кергәнен көтәргә тотындым. Көткән нәрсә озак тоела, миңа да көтә-көтә зарыгып бетәргә туры килде. Шулай да чыдадым.

Менә бервакыт Мәрфуга апаның капкадан кергәне күренде. Аны күргәч, минем йөрәгем әллә ничек кызурак тибәргә тотынды. Минем турыгарак җиткәч, Мәрфуга апа, матур тешләрен күрсәтеп, матур итеп елмайды да:

— Исәнме, Нәҗип! Нишләп болай былчыранып беттең, җаным?— диде.

Гадәттә, «җаным» дип сөйләшми торган Мәрфуга апаның бу юлда миңа «җаным» дип эндәшүе бик күңелле вә бик мәхәббәтле тоелды. Кичәге ачу урынына калган үпкәмне онытып, мин: «Ул мине дә сөя, абыйны гына түгел!» — дип уйлап алдым да:

— Мәрфуга апа, кил әле монда. Синең үзеңә генә бер нәрсә күрсәтәм! — дидем. Ул минем яныма килгәч, кип-тererгә куйган «Мәрфуга апа»ны аның алдына китереп куйдым. Мәрфуга апа аңар күзен генә төшереп алды да:

— Ник, җаным, болай былчыранасың? — диде.

Мин, тизрәк моның нәрсә икәнен аңлатып, аны яхшылап карарга мәҗбүр итмәкче булдым:

— Бу син бит, Мәрфуга апа. Әнә аның күзе нинди зур, үзе зәңгәр. Мин аның икенче күзенә дә иртәгә зәңгәр пыяла табып куярмын... — дидем.

Болай дигәч, Мәрфуга апа, чынлап та, өстән генә карап китә алмады, сурәткә якынрак килеп карады һәм, көлеп җибәреп:

— Әбәү, җаным, бу бик ямьсез бит! Мин шулай ук ямьсезмени соң? — диде.

Мин, уңгайсызланып кына, моның ямьсез түгел икәнлеген, менә иртәгә икенче күзенә дә зәңгәр пыяла куйгач, бик матур булачак икәнен сөйләргә керештем һәм ахырдан гына:

— Менә аның чәче дә синеке шикелле сары, корсагы да синеке шикелле тигез! — дидем.

Ул, минем исемне җибәреп:

— Мин бик үпкәлим инде, Нәҗип, сиңа, мине шундый ямьсез итеп ясагансың. Кирәкмәс, акыллым, андый нәрсәләр ясама, былчыранып йөрмә. Менә абыең акыллы булгач, бер дә былчыранып йөрми... — диде дә үзе китеп тә барды.

Көтелмәгән бу сүзләрдән мин нишләргә дә белмәдем. Хурлануымнан, ачуымнан җылыйсыларым килде. Башта ни дип җавап бирергә дә белмәдем, бераздан гына өй ишегеннән кереп бара торган Мәрфуга апаның аркасына карап:

— Әйе, абый ясаган булса, барыгыз да матур дияр идегез әле. Мин ясаганга күрә генә син шулай дисең. Менә абый ясап карасын әле шушылай итеп. Ул ясый алмый шул!..— дип кычкырып кала алдым. Бу хурлыкка җыламый түзү минем өчен бик җиңел булмады: күземә килгән яшьләремне мин керфекләремне еш-еш йомгалап кына кире кайтарып җибәрә алдым.

Биш минуттан соң инде мин үзем ясаган «Мәрфуга апа»ның кызыл вә зәңгәр күзләрен чукып алдым, авызын шырпы белән колакларына кадәр ердым, бер кулын бөтенләй алып ташладым да, аны шул килеше белән күтәреп, өйгә, апа бүлмәсенә алып кердем һәм, өстәл өстенә бастырып куеп:

— Ырр-рый, Мәрфуга апа нинди ямьсез! Аның күзләре дә зур түгел, чукып алынган күзләр, авызы да матур түгел, әбиләр авызы шикелле, ике колагына кадәр җиткән. Кулы да бер генә, ырр-рый, Мәрфуга апа нинди ямьсез!..— дип, ачу һәм хурлану катыш тавыш белән кычкырып җибәрдем. Аннан соң, апаның мине әнигә әләкләргә чыгып киткәнен күреп, сурәтне алып, тизрәк бүлмәдән сыздым да, ишегалдына чыккач, сурәтне җиргә салып таптап, изеп бетердем.

— Менә сиңа Мәрфуга апа, менә сиңа Мәрфуга апа... Апа менә, апа да түгел, Мәрфуга да түгел, юньсез кыз шунда...

Сурәтне таптагач, җылыйсы килүем бөтенләй бетеп, ачуым бераз басылса да, бу вакыйгадан соң бик озак вакытлар мин Мәрфуга апаны дуст күрә алмыйча йөрдем.

## 3

Бу елның кышында мин үзем укый торган хосусый мөгаллимнән рәсем төшерү дәресләре дә ала башладым. Мин, башка дәресләремне тырышып укыган шикелле, рәсем дәресләрен дә тырышып өйрәнә идем. Кыш урталарына таба мин рәсемнәрне инде бик яратып ясый

башладым. Һәм яз башында инде мин, шактый авыр ясала торган чәчәкләрне дә күчереп, яхшы ук матур итеп ясый ала торган булдым.

Язгы көннәрнең берсе иде. Мин, дәресләремне укып бетереп, уйнар өчен ишегалдына чыктым. Без абый белән кар суында көймә йөртергә тотындык. Ак карның саф суы уйнаклап ага; безнең көймә итеп йөртә торган, ике башын очландырып, уртасына кәгазь әләм эләр өчен чыра кадап ясалган тактабыз, бозларга бәрелә-бәрелә, су аккан уңайга бара иде. Бервакыт өй ишегеннән апа күренде дә:

— Нәҗип, монда кер әле, акыллым! — дип кычкырды.

— Тукта әле, мин уйныйм әле, апа! — дидем мин.

Апа кереп китте. Бераздан соң аның урынына ишек төбенә Мәрфуга апа чыкты да:

— Нәҗип, бер генә минутка өйгә кереп чык әле, җаным! — диде.

Мәрфуга апа белән мин хәзер әле бик артык дуст булмасам да, ул әйткәч, зур күзләрен миңа каратып әйткәч, мин керми кала алмадым.

Мин кергәндә, алар өйдә минем рәсемнәр төшерә торган альбомымны актарып утыралар иде. Мин аларның янына да барып җитмәдем, Мәрфуга апа:

— Нәҗип, кил әле, җаным, монда, менә шушы зур итеп төшергән чәчәгеңне син миңа кечерәйтеп төшереп бирмәссең микән? — дип, миңа альбомымдагы бер зур чәчәкне күрсәтте. Мин чәчәкне карадым да:

— Сиңа кайчан кирәк соң ул? — дип сорадым.

— Хәзер булса, бигрәк яхшы булыр иде, җаным, ярыймы? — диде.

Мәрфуга апаның матур елмаеп әйткән бу «ярыймы» дигән сүзенә каршы мин «ярамый» дия алмадым, альбомны алдыма куеп, икенче бер кәгазьгә зур чәчәкне кечерәйтеп төшерә башладым. Мәрфуга апа минем төшергәнемне карап тора, кайсыбер сызыклар бигрәк матур чыгып куйса, ул зур күзләре белән миңа

көлемсерәп, иркәләгән шикелле карап ала иде. Чәчәк ясалып тәмам булды, ләкин минем бу күңелле эшемнән тиз генә аерыласым килмәде:

— Мәрфуга апа, бу чәчәк ни өчен кирәк булды сиңа?

— Калфакка чигәргә. Инде ясалып бетте бит ул. Бик рәхмәт сиңа!

— Ачылып җиткән бу чәчәкнең янына ачылып килә торган бер чәчәк тә ясап бирсәм ничек булыр?— дидем мин Мәрфуга апага.

— Алай ясап буламы соң? Аны ясап булса, бигрәк тә матур, бигрәк тә тулы булыр иде,— диде ул. Мин яфраклар арасына тел-көйләрен яңа ачып җибәрә торган бер кечкенә чәчәк тә ясап куйдым. Болай иткәч, рәсем, чынлап та, тулырак булып китте, тагы да матур иде.

— Кечкәнтәй генә куллары белән нинди матур чәчәкләрне нинди оста итеп ясый белә бит! — дип, Мәрфуга апа, елмаеп, иркәләү карашы белән минем күзләремә туп-туры карады. Минем күзләрем аның елмайган күзләреннән оялдылар. Мин үзем җиңелчә кәефле кызарындым. Урынымнан сикереп тордым да ялт кына йөгереп чыгып китмәкче булдым. Ләкин Мәрфуга апа мине эләктереп алды. Эләктереп алды да шаян гына үпмәкче булды. Ләкин мин аның кулларыннан ычкынып качтым.

— Нәҗип, бик рәхмәт, җаным! — дип, ул минем артымнан кычкырды. Минем аңар каршы ни дип җавап бирергә дә тапкырлыгым җитмәде, эчемнән генә мин: «Аллага шөкер, хәзер минем дә инде бер һөнәрем була башлады бит!» — дип уйладым.

* * *

**Хикәя** — тормышта булган һәм булуы ихтимал берәр вакыйганы сурәтләгән кечкенә күләмле чәчмә әсәр.

«Нәҗип» — хикәянең матур үрнәге. Анда вакыйга Нәҗип исеменнән бәян ителә.

**Бирем.**

Хикәягә мисаллар уйлагыз. Ни өчен аларны хикәя төренә кертәсез?

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. «Нәҗип» хикәясендә табигать күренешләре ничек сурәтләнә? Әчтәлекне ачуда аның нинди әһәмияте бар?
2. Ф. Әмирхан әсәрдә нинди вакыйганы сурәтли? «Нәҗип» ни өчен хикәя дип атала?
3. Нәҗип кичерешләре сезгә ничек тәэсир итә? Аның борчулы, каршылыклы хисләрен сурәтләп сөйләгез.
4. Мәрфуганы ничек күзаллыйсыз? Кызның бик нәфис, ягымлы булуын текстта бирелгәнчә хикәяләгез.
5. Ни өчен һөнәргә өйрәнү кирәк? Сез ниләр эшли беләсез?
6. Хикәядән сурәтләү чараларын һәм эндәш сүзләрне табып, үзара тикшереп карагыз.
7. Түбәндәге өзекне, тыныш билгеләренә туктап, рольләргә бүлеп укыгыз. Өндәү һәм сорау җөмләләрне табыгыз:

   — Шаярма, тукта, булмаса, хәзер чыгып, әнигә әйтәм! — дияргә тотынды.

   Мәрфуга апа, зур күзләренә гаҗәпсенү кыяфәте чыгарып:

   — Әбәү, нәнәм, бу ни эшең бу? Син бер дә болай түгел идең бит. Менә бу кунак кызлары үзеңне акылсыз малай икән бу дип китәрләр,— диде.

   Мин Мәрфуга апаның бу сүзләреннән соң дәрәҗәдә кәефсезләндем, кунак кызларының үземә туп-туры карап торуларыннан хурландым да ачудан һаман әле уйнап утыра торган абыйның авызыннан кураен тартып алдым... Күрше кызлары миңа:

   — Әбәү, акылсыз! — диештеләр.

**Язма эш (сайлап алу өчен).**

1. Нәҗип образын характерлау өчен, киңәйтелгән план төзегез.
2. «Минем яраткан эшем» темасына инша языгыз.



## *Галимҗан Ибраһимов*

## *(1887—1938)*

Галимҗан Ибраһимов — бай әдәби мирас калдырган язучы. Аның егермеләп хикәясе, повесть һәм романнары, тел, әдәбият буенча унлап дәреслеге бар.

Галимҗан Ибраһимов 1887 елның 12 мартында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) Солтанморат авылында мулла гаиләсендә туган.

Галимҗан — авыл баласы, аның балачак хатирәләре матур.

«Атлар ярату миңа әтидән күчкән булса кирәк...— дип яза ул.— «Алмачуар» дигән хикәям дә үз тормышымнан алып язылган дисәм дә була. Әти безне иркәли дип әйтә алмыйм. Андый кеше түгел иде. Шулай да ул безне кеше итәргә бик тырышты. Заманы өчен үз даирәсендә алдынгы кеше иде... Башта ул минем язучы булып китүемә шактый кырын карады... Минем беренче әдәби адымнарыма кырын каравы аның язучылык эшенә ихтирамы булмаганлыктан түгел, ә минем, үз эшемне тиешенчә булдыра алмыйча, тормышта үзенең урынын, сәләтен таба алмаган кеше булып калуымнан куркуы булгандыр дип уйлыйм. Ул исән чакта минем кайбер хикәяләрем, хәтта «Яшь йөрәкләр» романы да басылып чыкты. Боларны күреп шатланды гына»[1].

---

[1] Галимҗан Ибраһимов : мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2007.— 388 б.

Әти-әнисеннән укырга-язарга өйрәнгән Галимҗан башта авылларыннан биш чакрым ераклыктагы Кешәкне авылы мәдрәсәсенә укырга йөри. Шул ук вакытта үз авылларындагы башлангыч мәктәптә русча да укый.

1898 елның көзендә әтиләре ике улын — Шакирҗан белән Галимҗанны — Оренбург шәһәрендәге мәдрәсәгә укырга илтә. Бу вакытта Галимҗанга унбер генә яшь, шулай да күп белергә омтылган шәкерт мәдрәсәдә бирелгән сабаклар белән генә канәгатьләнми, шәһәр китапханәсенә йөреп укый, вакытлы матбугат хәбәрләре белән дә кызыксына.

1905 елгы революция чорында мәдрәсә тәртипләреннән ризасызлык белдереп баш күтәргән шәкертләр арасында Галимҗан да була. Шуның өчен аны мәдрәсәдән куалар. Беркадәр вакыт үткәннән соң гына, Галимҗан Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укуын дәвам итә. Әдәби иҗат эшчәнлеге аның шул чорда башлана. Белемгә омтылган яшь егет университетка керү хыялы белән 1909 елда Казанга килә, тик хыял тормышка ашмый. Галимҗан үзлегеннән белемен күтәрү өстендә туктаусыз эшли. Дөнья әдәбияты классикларын, рус язучыларының әсәрләрен өйрәнә, фикердәшләр таба. Казанда аның әдәби иҗаты җанланып китә: «Яз башы», «Диңгездә», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карт ялчы», «Сөю — сәгадәт» кебек хикәяләре басылып чыга. Шул ук чорда публицистик һәм әдәби тәнкыйть эшчәнлеге дә башлана. 1912 елда «Яшь йөрәкләр» романын тәмамлый.

Г. Ибраһимов 1915—1917 елларда Уфада «Галия» мәдрәсәсендә укытучы була.

1918 елда Петроградта Үзәк мөселман комитеты рәисе Мулланур Вахитовның урынбасары булып эшли. Шул ук вакытта комиссариат каршында чыга торган «Чулпан» газетасына җитәкчелек итә, шунда мәкаләләр бастыра.

Гражданнар сугышыннан соң Галимҗан Ибраһимов Казанда яши, иҗат эше белән шөгыльләнә, дәүләт һәм җәмәгать эшләрендә актив катнаша.

1928 елда язучының 20 еллык иҗат бәйрәме зурлап үткәрелә. Илнең төрле почмакларыннан аңа мәңләгән котлау телеграммалары килә, күп телләрдә басылган газеталар, аның иҗатын хөрмәтләп, мәкаләләр урнаш-

тыралар. 1932 елда Галимҗан Ибраһимовка Хезмәт батыры дигән мактаулы исем бирелә.

Галимҗан Ибраһимов, каты авыру сәбәпле, гомеренең соңгы ун елын Кырымда — Ялтада уздыра, иҗат эшен дәвам итә. Әмма авыру булуына карамастан, «халык дошманы» дип гаепләп, аны кулга алалар һәм Казан төрмәсенә китерәләр; каты җәзалау нәтиҗәсендә, ул 1938 елда төрмә хастаханәсендә җан бирә.

Хәзер Казанда Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Галимҗан Ибраһимов исемен йөртә. Шулай ук Казанда аның исемендә зур урам — Галимҗан Ибраһимов проспекты бар.

Галимҗан Ибраһимовның үлем алдыннан язган сүзләре хак булды. «Партия каршында, халык каршында һичбер гаебем юк,— дип язган ул.— Хакыйкать ачылыр, тарих үз сүзен әйтер». Чыннан да, талантлы әдипнең исеме, акланып, татар әдәбияты балкышында үз урынын алды.

## АЛМАЧУАР

(Бер мәхәббәтнең тарихы)

(*Кыскартып алынды*)

1

Миңа, күп куйганда, җиде-сигез яшь булгандыр, әллә нинди коточкыч кара йөзле, усал елтыр күзле бер башкорт һич көтелмәгән җирдән үзенең кара бурлы, матур, зур симез биясен безгә бүләк итте, алай-болай гына түгел, үз кулы белән йортыбызга китерә, капка төбендәге зур ташка утыра да кешеләр алдында дога кылдырып бирә.

Авыл халкы бу эшкә башта аптырап калалар: ни сәбәптән, бу тирә-якка усаллыгы, саранлыгы белән даны чыккан явыз көрәшче Әлемгол, тик торганда, үзенең гомерлек дошманы Хафизга (безнең әткәйгә) бер бия китереп, фатиха кылдыра?!

Эштән чыккан бер мал булса, тагы бер хәл иде! Биясе нәрсә бит: бөтен тирә-якта дан тоткан ике алмачуар

чабышкының анасы! Җитмәсә тагы, карынында бер колын бар!

Мондый бер хәл һичкемнең башына сыя алмый. Безнең күрше карчык Фатиха әби башкорт баһадирының үз күзе алдында ук:

— Балалар, бу эш хәерлегә булмас! Моның астында берәр хәйлә бардыр,— ди.

Безнең кардәш Сафа карт та, ак сакалын сыйпап, бу сүзне куәтләп куя:

— Китапча итеп әйтсәң инде, ди, мин әйтәм, ди, таштан су чыгар, усак агачы алма бирер, ди. Әбүҗәһел иманга килер. Әмма, ди, Әлемгол бай, ди, бу данлыклы бияне карынындагы колыны белән тиктән-тик Хафизга китереп бирмәс, монда берәр этлек юкмы икән, балалар,— ди.

Башкорт боларның һәммәсен тыныч кына тыңлап тора да, бераз җылмаеп, кара күзләрен тагы ныграк елтыратып, үзенең хәлен сөйләп бирә.

Ул сөйләгәч, халыкның аптыравы шатлыкка, хәердогага әйләнә.

## 2

Безнең әткәй Мөхәммәтхафиз исемле булса кирәк. Буйга зурлыгы өчен аны Озын Хафиз дип йөртәләр.

Ул яшь чакта имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле булган дип сөйлиләр. Тирә-якта теләсә сугышка булсын, теләсә көрәшкә булсын, аңа тиңдәш, охшаш чыкмаган. Иң зур Сабан туйларында да ул әллә кайлардан килгән данлыклы көрәшчеләрне шаяртып кына чөеп ташлый торган булган...

Менә бервакыт Чишмәдә зур Сабан туе ясала.

Асыл сөяк чабышкы атлар, үз тирәсендә исем казанган көрәшчеләр, шәп йөгерүче җегетләр бу җыенга йөзәр чакрымнан киләләр — көч сынамакчылар, үзләрен күрсәтмәкче, дан алмакчылар.

Көрәш башлана.

Ни күрәсең? Хафизга кем чыдасын!

Безнең әткәй чыккан бер баһадирны аз-маз шаярта да чөеп үк ташлый.

Ахырдан килеп чыгаябык, чандыр бер кара башкорт.

Ике баһадир, билләрен берәр тартып сыныйлар да, бер-берсенең сыртларына кулларын салган хәлдә, бөтен халыкның күзе астында, түгәрәк мәйданда әйләнәләр.

Йа Ходаі Бу ни эш?!

Кинәт данлыклы Хафиз тәгәрәп-тәгәрәп китә дә чалкан барып төшә!

Мәйдан гөж килә. Әткәйнең дуслары бу хурлыкка чыдый алмыйлар.

— Башкорт хәрәмләде, аяк чалды! — дип, шау-шу күтәрәләр, яңадан көрәшергә чыгуны сорыйлар.

Ике як та риза була. Баһадирлар тагы түгәрәк мәйданда. Бөтен халык тагын, тыннарын да алмыйча, бу зур көрәшкә карап катканнар!

Ал аякларын бер-берсенең сыртларына салган арыслан белән юлбарыс кебек ике ир каһарман ярты сәгать буенча, бер-берсенең билләреннән алган хәлдә, мәйданны урап йөриләр.

Тагы кинәттән, һич көтелмәгән бер секундта, башкорт каһарман сиздермәстән генә кысып ала да үзе җиргә ята, баш очыннан Хафиз баһадирны шундый көч белән селтәп җибәрә ки, ул, әллә кая барып, сул кулы өстенә бик каты егыла.

Халык шау-шу килә. Мәйдан кайный!

Безнең әткәй исә тиз генә бер якка чыга да Зариф остага кулын күрсәтә:

— Сынганмы, чыкканмы?

— Зарар юк, чыккан гына,— ди.

Мин ул вакыт бик бәләкәй идем, шулай да хәзерге кебек күз алдымда тора: Сабан туе элеккечә шаулап калды, әткәй күп баһадирларны җиңеп алган кызыл башлы сөлгеләр белән яшел чапанны бер як кулбашына салды да, икенче кулын кызыл билбау белән муенына асып, акрын гына кайтып китте.

Мин аңар сүз дәшәргә курыктым; әллә тирләгәнгә, әллә ачуланганга аның йөзе кара көйгән иде.

Ахрысы, бик гарьләнгәндер:

— Җитәр инде: заманында көрәштек, бусы актыгы булыр! — диде.

Һәм сүзендә торды: шуннан соң Сабан туйларына аяк атламады. (Тик телләрдә генә аның баһадирлыкларын әкият итеп сөйләргә калды.)

3

Аңа байтак заманнар үткән иде инде, шулай да ул көннәр бөтен авылның хәтерендә иде. Шуңа күрә башкортның безнең әткәй белән көрәшеп, аны җиңүен сөйләгәндә:

— Без боларны беләбез... — дип тордылар.

Әлемгол, ачуланып, халыкка күз ташлый да:

— Шулаймы? Сез татарлар да боларны беләсезме? Әмма менә җиңүче башкортның йөрәгендә аннан соң ниләр булганы сезнең төшегезгә дә кермәгәндер, ди, Хафиз агакай, ди, мин сине екканда хәйлә ясадым... Үзеңә дә, карап торучыларга да сиздермәстән, уң аягыңны бераз чалдым... Бу вакыт күңелемә шик килде. Шулай да үземне тыя алмадым,— ни булса, шул булыр, бәлки бер юлга Ходай кичерер дидем дә сине шул хәрәмләвем аркасында баш аша чөйдем... Күңел — әүлия, диләр бит, дөрес сүз икән: Сабан туеннан кайтып та җиттем, түшәккә дә егылдым: эчем бора, сул кабыргам астында нәрсәдер тырный, чәнчә башлый. Шуның белән өч ай акырып ятам, ашаганым — аш, эчкәнем су булмый... Шул каты хәстә чагымда: «Бу авыру Хафизга каршы хәйлә эшләп, аны рәнҗетүдән килгәндер, терелсәм, бурлы биямне аңа дога кылдырырмын»,— дип, нәзер әйткән идем. Терелдем. Нәфес — шайтан бит: «Әй, ул татарның рәнҗеше төшәме соң»,— дип уйладым. Бияне бирергә кызгандым. Берничә ел үткәч, тагы шул хәстә: эчем бора, сул кабыргам астында нидер тырный, нидер чәнчә... Һич түзәр хәлем калмады, бөтенләй ап-

тырадым. Шулвакыт әллә кайчан үлгән бабам үзенең зур ак сакалы, ак кәфене, ниндидер зур яшел таягы белән минем төшемә керә, миңа шелтәләп карый, ачулы тавыш белән: «Ахмак бала: сиңа җан кыйбатмы, бурлы бия кыйбатмы?» — ди. Үзе шунда ук гаиб була[1]. «Терелсәм, бер көн кичекми илтеп бирәм»,— дип, тагы нәзер әйтәм. Күрәсез, мин терелдем. Менә нәзеремне үтим.

Картлар бөтенләй хәйран калдылар. Сафа бабай башкортның аркасыннан кага:

— Китапка язган кебек сөйлисең: этлеккә генә түгел, яхшы сүзгә дә синең акылың, телең җитә икән,— ди.

Башкалар да рәхмәт укыйлар, яңадан чүгәләп дога кылалар.

— Хафизның бик авыр еллары иде. Улы белән кызыннан да аерылган чагы иде. Бурлы бия җиңел аягы белән килгән булсын! Бу йортка бәрәкәт китерсен диделәр.

Башкорт китә, картлар таралалар.

Сүзлек өстендә эш.

*Фатиха кылдыра, баһадир, Әбүҗәһел, иман, хәер-дога, хәрәмләде, гарьләнеп, әүлия, хәстә, рәнҗетү, нәзер, нәфес* сүзләренең мәгънәләрен аңлатмалы сүзлектән карагыз һәм аларның кешенең эчке дөньясын сурәтләүдәге әһәмиятен әйтегез.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әлемголның Хафизга бурлы бия китереп бирүе авыл халкына ничек тәэсир итә?
2. Мәйданда данлыклы көрәшче Хафизны җиңгәннән соң, Әлемголның кичерешләрен тексттан укып күрсәтегез.
3. *Бәхилләтү, дога кылдыру, иманга килү, рәнҗетү, рәхмәт уку* кебек гамәлләрне ничек бәялисез? Үз тормышыгыздан мисаллар китереп сөйләгез.

---

[1] *Гаип булу* — күздән югалу.

9

Шәп маллар аякланып туа, диләр.

Ахрысы, бу сүз дөрестер.

Без барып җиткәндә, колын үзенең әле бик ныгып бетә алмаган нечкә аяклары белән саклана-саклана басып йөри башлаган иде инде.

Бичаракаем, бик ачыгып туган, күрәсең: әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, әнкәсенең сөт белән тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.

Бу арада бурлы бия артык холыксызланып киткәнгә, мин аның янына барырга курыктым. Үзенең нуктасы белән аңа якын килә башлагач та, ул, баласын бирмәскә тырышкан ана арыслан кебек, әллә нинди яшел тавыш белән чинап, әткәй өстенә ташланмакчы булды. Йомылып тешләргә, чыелдап, колынының әле бер, әле икенче ягында йөгереп тибәргә итеп карады.

Ләкин безнең әткәй курку дигәннең нәрсә икәнен белми, маллар да аның болай икәнен аңлыйлар булса кирәк. Биянең дулавына, тешләргә, тибәргә омтылуларына карамастан, әткәй туры барды да муенына нуктаны ташлады, алай-болай иткәнче бурлы биянең башы калын нукта эченә кереп тә өлгерде. Мин аптырап, хәйран булып тик тордым. Шатландыммы, юкмы — белмим.

10

Тик өйгә алып кайтып, бияне кое баганасына бәйләп куйгач кына, мин үз-үземә исәп бирә алырлык булдым.

Колын, чыннан, гаҗәеп бернәрсә иде.

Аның ботлары ничектер җиңел атлыйлар. Бәкәлләре озын, шундый нечкә озын ки, мондыйлар тик чабышкы атларда гына була, диләр. Әле яңа гына кибеп килә торган койрыгы белән ялы, әз генә, кыска гына булсалар да, озаклап үреп, кабартып ясаган җефәк бәйләме

кебек үзеннән-үзе дулкынланып торалар. Түм-түгәрәк сырты өстеннән, нәкъ арка үзәк турыннан, бармак калынлыгы кара тасма кебек булып, койрыктан ялга җиткәнче кара җефәк йон сузылган. Озынча, акыллы башның киң маңгаендагы озын яра кашка — бу колынны мең миллион иптәшләре арасыннан бөтенләй аерып, матурлыгы белән ялгыз итеп күрсәтәләр. Бөтен гәүдәсе әйтерсең Ходайның үз кулы белән, фәрештәләрнең ярдәме белән тигезләп, матур итеп, коелып ясалган. Шундый сылу, шундый асыл сөяк булып яратылган.

Төсе хакында аптырап калдым. Кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел — ничектер күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора.

Бер самавыр кайнарлык вакыт үтмәгәндер, йортка бала-чага җыела башлады. Бары да, авызларын ачып, хәйран булып, бу асыл сөяк колынга карап каталар.

Кайдандыр, ишетеп, безнең Сафа бабай да ак сакалын җилбердәтеп килеп керде. Ул — бөтен тирә-якка ат тану белән дан тоткан кеше.

— Йа Ходай! Ни әйтер? — дип, мин аңа карап каттым.

Колынны күрүгә, бабайның йөзе ачылды:

— Сөбханалла... Сөбханалла... Күз тимәсен... Бу колын да үзенең элекке ике агасына охшаган икән,— диде.

Дәшми-тынмый тагы бик озак карап торды да:

— Шулай, шулай! Яңлышмыйм. Бу да нәкъ агалары кебек... — диде.

Әти, миңа белдермичә генә, әллә кайчаннан кечкенә генә көмеш кыңгырау алып куйган икән. Әни кызыл тасма бирде.

Карт акрын гына, оста гына килеп, колынны кинәт кенә кочаклап алды да:

— Бисмилла... Сөбханалла... Яман күздән, эт-бүредән Ходай сакласын,— дип, догалар укый-укый, минем

айгырымның муенына шул кызыл тасма белән кыңгырауны такты.

Тагы бераз читкәрәк китеп карады да эткәйгә:

— Беләсеңме, Хафиз, бу нәкъ агалары кебек булыр, төсе дә тиз арада алмачуарга әйләнер...

Сафа бабай тагы, теләкләр теләп, колынны мактады да минем колагымнан шаяртып тартты.

— Закир, бәхетең зур икән: башкортның бурлы биясе атаңны аякка бастырды, сиңа алмачуар колын бирде, бу колын ике агасы кебек асыл сөякләрдән... Күз тимәсен, бу да чабышкы булыр... — дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте.

Мин кая басканымны белмим. Бер көндә әллә ничаклы үскән кебек булдым: уенмыни?! Минем колыным бар. Ул айгыр! Төсе алмачуарга әйләнәчәк! Тирә-якта дан тоткан ике агасы кебек чабышкы булачак!

Әнә күрегез: ул ничек көмеш тавыш белән яңгыратып кешни! Ничек асыл сөякле гәүдәсе белән матурлап сикереп уйный!

## 11

Шул көннән алып Алмачуар минем тормышымның үзәге була. Шатлыкларым, кайгыларым шуннан чыга, шуңа кайталар. Төшемдә шуны күреп саташам. Иртән торуга, киенмәстән, битемне юмастан, мин абзарга Алмачуарны карарга, аның исәнлеген белергә йөгерәм. Исән, бик исән!

Ул, әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана, асыллана бара. Хәзер авылда аңа тел тидергән кеше юк. Һәркем аңа:

— Күз тимәсен, сөбханалла! Бигрәк асыл сөяк нәрсә икән! Яхшы нәселдән шул!.. — дип кенә карыйлар.

Тирә-якта асыллыгы, сылулыгы белән генә түгел, тавышы, җиңел, җитез, килешле һәм акыллы уйнавы белән минем Алмачуарга тиңдәш булырлык бер колын күренми дә, ишетелми дә.

## 12

Җәй, аның артыннан көз үтеп китә. Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы чаклар килә. Мин иртәгә Покрау бәйрәме дигән көндә, ничектер иртәрәк уяндым, шулай да торырга иренеп ятам.

Кайдадыр кемнәрнеңдер нәрсә хакындадыр ашыгыч-ашыгыч сөйләшкәннәре ишетелә.

Нидәндер йөрәгем жу-у итеп китте.

Колак салдым.

Әткәй белән әнкәй чаршау артында пыш-пыш сөйләшәләр. Тавышларында әллә ни бар: куркалармы, кайгыралармы, нәрсәдәндер, кемнәндер яшерергә телиләрме? Бернәрсә белмим.

— Син аңа белдермәскә тырыш! Ишетмәсен! — диде дә әткәй, кулындагы арканын җилкәсенә салып, тиз генә чыгып китте.

Мин тагы курка төштем.

— Ни бар, әнкәй, ни бар?..— дип, әнкәйнең итәгенә барып асылдым.

— Юк, балам, бернәрсә дә юк... Сиңа торырга иртә әле, бар, ят... Менә мин мичкә ягам да белен пешерәм... Самавыр кайнагач, эссе беленгә уятырмын,— диде.

Күңелем тынычланмый, ятсам да, күзгә йокы керми.

Әни мич алдында, чыж-пыж итеп, нидер кыздыра калды, мин аннан-моннан киендем дә урамга чыктым.

Каршыма Апуш килә:

— Их, малай, бәхетең бар икән... Исән калган бит,— ди. Мин шашып киттем:

— Ни бар?.. Ни булган? Кем исән?

Апушның күзләре дүрт булды:

— Әй тавык баш! Шуны да белмисеңме?.. Бүген тауга бер көтү бүре килгән. Дүрт колынның бугазын чәйнәп, каннарын эчкәннәр, үтереп киткәннәр... Синең Алмачуарың үлмәгән, тик азрак яраланган гына... — ди.

Башыма нидер сукты, телем тотлыкты, сүз әйтә алмый катып калдым.

Апуш, моны күргәч:

— Тиле, нәрсә торасың! Бар, йөгер! Әнә алып кайтып киләләр,— дип, түбән очка, күпергә таба күрсәтте...

Чыннан да, ул яктан бер көтү халык әллә ничаклы бияләр, тайлар, колыннар куып киләләр иде.

Үземне-үзем белмәдем, шул якка очтым.

Ни күрим!

Зур арбага безнең кола ат җигелгән: тәртә янына бурлы бия бәйләнгән, ул бертуктамый кешни, кайдадыр китәргә, ычкынырга азаплана.

Арба янында әткәй килә...

Якынрак баргач, тагы авыр хәл: минем Алмачуарым, аяк-кулы бәйләнеп, арбага салынган...

Ни эшлим? Аптырадым. Каттым...

— Әткәй, безнең колынны да үтергәннәрмени?! — дип кычкырып елап җибәрдем.

Әткәй мине, иркәләп, култыгына алды:

— Елама, Закир... Дүрт колынны үтергәннәр... Безнеке исән... Тик азрак арткы ботыннан тешләнгән генә... Шул ярадан кан күп акмасын дип кенә бәйләп, арбага салдык,— ди.

13

Яра тирән түгел икән. Минем бәхет җиңде: көн-төн карау аркасында, бер атна дигәндә минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды. Тик аның уң ботында бер илле чаклы яра булып, бүренең ике теш эзе генә ак җонлы булып сузылып калды...

Алмачуарым белән бергә мин дә авырган—йокымны, ашау-эчүемне югалткан идем: ул терелеп уйный башлагач, мин дә аңардан калышмадым. Кыш шулай үтеп китте.

14

Икенче яшькә чыкканда, бездә яз көне тайның ялын, койрыгын бөтенләй кыркалар: «кырыкмыш»

ясыйлар. Мин алай ямьсез итеп боздырасым килмәде: маңгай чәчен күзенә төшмәслек кенә ясап, тип-тигез кистердем.

Бу хәзер, алдан караганда, рус боярларының матур кызлары кебек күренеп тора. Ялны да башкалар кебек бөтенләй бетермәдем: бер чирек кадәрлерәк калдырып, үзеннән-үзе дулкынланып, күперенеп тора торган итеп төзәттердем генә.

Әнидән алып, ул ялга ике яклап чуклар, тасмалар тактым. Койрыкны да бүтән кешеләр кәбестә күчәне кебек ямьсезләп кыралар. Моңа да якын җибәрмәдем: сөяктән түбән ягын гына кистеләр дә матурлап түгәрәкләделәр. Кырыкмыш тайлар, бигрәк тә язгы сабан өстендә, йолыккан карга кебек чорсыз булып йөриләр. Минем Алмачуар исә кунакка барырга ясанган бояр егете кебек чибәр булды.

Мин моны Әпсәләм байларының берсендә, этиләр ялланып урак урырга йөргән чакларында күргән идем. Шулай итик дип сөйләп биргәч, эти карышмады:

— Их, балам, көенечкә генә булмаса ярар иде синең бу кылануларың,—диде дә бөтенләй мин әйткәнчә эшләде.

Авылда минем тайның болай матур кыркылуын күргәч, малайлар таң-хәйранга калдылар. Алдагы елларда башкалар да шулай ясый башладылар.

Сүзлек өстендә эш.

*Алмачуар, бурлы бия, бәкәл, нукта, Покрау бәйрәме, кырыкмыш, шөбһә, бер илле* сүзләренең мәгънәләрен аңлатмалы сүзлектән карагыз һәм фикер алышыгыз.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Закирның кичерешләре, сизгерлеге, матурлыкны таный белүе, эти-әнисенә, өлкәннәргә, иптәшләренә мөнәсәбәте нинди вакыйгаларга бәйләп сурәтләнә?
2. Үзегезгә иң ошаган урынны кабатлап укып күрсәтегез, ни өчен бу эпизодны сайлавыгызны дәлилләп сөйләгез.

3. Түбәндә бирелгән сүзләрнең төп мәгънәсен аңлатыгыз, аларның кулланылышы турында сөйләгез: *йомылып тешләргә; чабышкы ат; асыл сөяк; яхшы нәсел; күзләре дүрт булды; күз күреме җир; күз ачып йомганчы; кая басканымны белмим; тормышымның үзәге; йөрәгем жу-у итеп китте; шашып киттем.*
4. Сафа бабай образын ничек күз алдына китерәсез?
5. Сафа бабай, Әлемгол, Хафизларның сезгә кайсы сыйфатлары ошады? Тексттан аларның характерын, уй-кичерешләрен чагылдырган урыннарны табып укыгыз.
6. Апуш белән булган диалогтан соң малайның тетрәнүен язучы сурәтләгәнчә сөйләгез.
7. Укыган өлештән чагыштыруларны табыгыз һәм укып күрсәтегез.

**Мөстәкыйль эш.**

Алмачуарны ничек күз алдына китерәсез, рәсемен ясагыз.

## 15

Җәй, көз, кыш үтә. Яз килә.

Минем Алмачуар өченчегә керә. Авылда, бу яшькә җиткәч, тайларны «беренче сабанга керде» дип сөйлиләр. Акрынлап, җиңелчәләп җигә башлыйлар.

Мин үзем моңа якын китермәдем.

Безнең Алмачуардан башка ике атыбыз бар. Бурлы бия быел кысыр калды. Ул бура кебек таза, калын булып симереп китте. Берүзе биш атның эшен эшләрлек. Кола айгыр да аңардан калышмый. Шулай булганга, әткәй дә Алмачуарны юк-барга җигәргә дип тел кузгатмый. Сафа бабайның: «Бу колын ике агасына охшаган, чабышкы булыр»,— дигән сүзен ул да онытмый булырга кирәк. Ләкин гөлләр чәнечкесез булмый икән шул. Гөнаһ шомлыкка каршы: «Тарыны йомшакка чәчсәң, чүп басып харап итә»,— дигән дә, әткәй кысылдык башкортларыннан мәңге сабан-сука кермәгән бер җир, каты чирәм сатып алган. Тимер сабанны чыдатырлык түгел — урыны-урыны белән

ташлы, чыбыклы җирләре дә бар. Шуңа күрә әллә кайчаннан кузгалмый яткан авыр төрән сабанны тартып чыгаралар. Моны ике ат йөртә алмый. Дүрт, иң азында — нык, таза өч кирәк.

Үзара сөйләшкәннәр дә өченчегә Алмачуарны җигәргә булганнар. Моны ишеткәч, мин, еларга җитешеп, әткәйгә бардым.

— Ни бар? Кем тиде? — ди.

— Берәү дә тимәде! Ник минем Алмачуарны сабанга җигәсез? — дидем дә түзә алмый елап ук җибәрдем.

Минем тавышка әнкәй дә килеп керә.

Ул Алмачуарны миннән көнләшә булса кирәк. Кайчан гына шул турыда сүз чыкмасын, мине тиргәргә, каһәрләргә тотына. Әле дә әткәй ни барын сөйләп бетермәде, әнкәй миңа каршы кызып, ачуланып китте:

— Фу, илаһым, ди, нинди бәла-каза килгән дип торам... Бер тай өчен адәм шулчаклы акырыр икән, ди... Әллә аны гомер буена җикми асрар идеңме?Менә тилергән нәрсә!.. — ди.

Әткәй ачуланмый, кызмый, мине юатырга тырыша:

— Чү, Закир, алай юк өчен елап барма, ди. Бернәрсә дә булмас, без аны буразна яклап очка гына җигәрбез... Үзең ат куарсың... Карап кына йөртерсең,— ди.

Мин аның саен ярсыдым, аның саен елый бирдем. Ашарга чакырдылар — кермәдем. Самавыр кайнаган, диделәр — аңа да карамадым. Туктаусыз еладым да еладым; шулай елый-елый барып, эштән чыгып, бакча буендагы такта өстендә йоклап та калганмын.

* * *

Уянып китсәм, ишегалдында, түшәктә ятам. Төш ауган. Кояш түбәнәеп бара. Дөнья бик рәхәт кенә, талгын гына тора. Йортта бер кеше дә күренми. Сабаннар, арбалар да юк, капка тулы ачык тора.

Сикереп тордым да абзарга йөгердем.

Барсам, ни күрим?! Минем Алмачуар, озын тезген белән бәйләнгән хәлдә, улакның бер башыннан икенче башына йөреп тора.

Ахрысы, сагынгандыр: мине күрүгә кешнәп үк җибәрде.

Телләребез сөйләмәсә дә, без бер-беребезне бик тирән аңлыйбыз. Мин килеп күренүгә, ул шатланып ук китте; өстен, ял, койрыгын тазартканда, йөзеннән сыйпаганда, айгырым бертуктаусыз иһи... иһи... дип, йомшак кына кешнәп, иркәләнеп тора.

Улагын төзәттем, коега илтеп, су эчердем дә өйгә кердем.

Әнкәй ярым шелтә, ярым елмаю белән каршы алды:

— Елак малай! Җиндең бит, ахрысы!.. Вилдан абзыйларың да безнең белән бергә янәшә чирәм алганнар икән, шулар белән алмашлап сөрергә булдылар...— ди.

Шатлыгым йөрәгемнән тулып таша. Җир-күге, бөтен дөньясы — минем шатлыгымнан һәммәсе биилəр кебек тоела.

Бүген әни яныннан китмәдем. Ни кушса, барынбарын тыңладым.

— Утын керт диде — аны керттем. Каз бәбкәләрен Өзән елгага илтеп кайт диде — аларны илттем. Тавыклар йомырка салгандыр, ояларны кара диде — аңа йөгердем.

Әткәйләр киткәндә катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән, шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән, аларга ашарга илтергә кирәк булды.

— Бар, Мохтарга әйт, диде, аркылы агач белән тотарсыз да яланга икмәк белән катык илтеп кайтырсыз,— диде әнкәй.

Бер сүзенә карышмадым, тик:

— Мин үзем генә дә илтә алам, әнкәй,— дидем.

— Булдыра алмассың, катыкны түгеп әрәм итәрсең, икәү барыгыз,— дигәч, аңа да күндем.

Яланга баргач, безнекеләр янында сабан сөрә торган Апуш мине көлеп каршы алды:

— Ну, малай, эт икәнсең, җиндең бит, Алмачуарны җиктермәдең бит, ди. Әйдә, бирешмә, Закир, чабышкы буласы асыл сөякне сабанга җигеп әрәм иттермә,— ди.

* * *

Бу юлга җиңүен җиндем...

Әмма бу җиңүләр миңа бик кыйбат төшкән чаклар да булды.

Мин берәр төрле карулаша башласам, тыңламасам, хәзер күз алдыма Алмачуарны китереп куялар.

— Бик күп сөйләп тагын! Алай бик каршылансаң, Алмачуарыңны тотарбыз да урманга җигәрбез,— дип куркыталар.

Моңа җавап кайтарырга сүзем булмый, телем киселә: үземне җиксеннәр, аңа риза, тик минем Алмачуарыма гына тимәсеннәр.

Тирә-якта ат тану белән дан чыгарган Сафа бабай:

— Бу колын үзенең ике агасына охшар, алар кебек чабышкы булыр... — дигән иде. Һәммә кеше дә шулай юрыйлар. Урманга, таугa-ташка, сабан-сукага җиксәң, ул ничек чаба алачак. Аңарда нинди чабышкылык калачак?! Ни булса булыр, авырга җиктермим, минәм, чабыштырам, чабарга өйрәтәм, тирә-якта беренче чабышкы ясыйм!

## 16

Менә күптән көтелгән көн килеп җитте.

Бүген Сабан туе!

Андый-мондый гына түгел, тирә-якта бик сирәк була торган — бик зурысы, бик шәбе! Данлыклы чабышкылар җыелалар. Атаклы көрәшчеләр киләләр. Исемле йөгерек ирләр бүген көчләрен сынашмакчылар. Алмачуар белән минем өчен дә бүгенге көн, бәлки гомергә бер генә килеп китә торган зур көннәрдәндер.

Айгырым сыналмаган түгел. Өченче яшенә чыккач та, менемгә өйрәттек. Шуннан бирле авылыбызда үзара ат ярыштырулар күп булды. Әйтәсе дә юк, һичкемнең аты минем Алмачуарга якын килмәде — кузгалып китү белән, мин очам, башкалар күз күреме җир артта калалар.

Күрше авылларның атлары белән дә ярышкаладым. Болар арасында күп Сабантуйларында беренче, икенче килгәннәр дә бар иде. Алмачуар боларны да бик җиңел, бик уйнап уза иде.

Әмма, әмма бу Сабан туе башкарак. Әллә кайдагы, тау эчендәге башкортлар дан тоткан чабышкылары белән килгәннәр, диләр. Араларында бер Күк бияне бик мактап сөйлиләр, үткән ел Өфе каласында чаптырганда, бөтен атларны адәм көлкесенә калдырган, диләр.

Башкаларын уйламыйм да. Менә шул Күк бия мине куркыта. Кайдан гына килеп чыкты икән соң ул гөнаһ шомлыгы нәрсә?!

Әткәй белән Сафа бабай да минем хәлне бик аңлыйлар булса кирәк. Чаба торган атны бөтенләй башкача әзерләргә тиешле була икән: заманында күп чабышкы асраган Сафа карт, яз чыккач ук, әткәйгә моның юлларын өйрәтте: нәрсә ашатырга, ничек эчертергә, көн саен ничек аз-маз гына йөртеп кайтарырга — һәммәсен әйтеп бирде. Аның белән генә дә калмыйча, һәр көн диярлек үзе килә, карый, яңадан өйрәтеп китә.

Сабан туена бер атна калгач, бигрәк каты тотына башладылар. Печәннең корысын гына бирәбез, бүлеп-бүлеп солы салабыз, азлап-азлап апара суы эчерәбез... Әти иренми, көн-төн карый. Мин аңа ияреп йөрим. Ансыз да асыл сөяк булган Алмачуарым бу арада карап туйгысыз булып чибәрләнде. Ял, койрык җефәкләнеп, дулкынланып тора. Эч, каеш белән тарттырган кебек, нечкәреп, тип-тигез булып эчкә керде. Буе тагы да озыная төшкән кебек күренә. Аяк атлаулары шундый җиңел инде, әйтерсең ул җиргә басмый, бәлки күзгә күренми торган канатлары белән очып кына бара.

Ул электән дә ашауга бик назлы иде. Ахрысы, ярыш көннәренең якынаюын сизәдер, үзен үзе артык саклый башлады... Шуның белән бергә, аны тыюлар бик авырайды.

Мин башка һичбер малайны мендермим. Йөрергә чыкканда һаман үзем менәм. Шул вакытларда кайда гына булса да, нинди генә булса да, атланып кына барырга кирәк чакта да, башка берәр ат арттан килеп уза башласа, тыеп тотармын дип уйлама — авызлыкны тешләп ала да канатланып оча гына!

Бер дә шик юк. Алмачуар тиз арада Сабан туе буласын белә, анда үзенең чабачагын да сизә һәм шуңа бик нык әзерләнә. Минем әзерләнүем дә аныкыннан ким түгел.

Әткәй белән Сафа бабай, шаяртыпмы, чынлапмы, кайбер вакыт башка берәр малайны мендереп чаптыру турында сөйлиләр.

— Син яшьсең. Алмачуар да әле зур җирләрдә чабып өйрәнмәгән,— диләр.

Мин якын да килмим. Тагы әйтсәләр, күзләрем яшьләнә башлый.

Сафа бабай мине юата:

— Ярар, балам, ярар, ни күрсәң, үзең күрерсең, узсаң да — үзең, уздырсаң да — үзең! — ди.

## 19

Ялгыз каен бездән унбиш чакрым.

Башка елларда булса, җиде-сигез чакрымнан чаптыралар иде, быел төрле илләрнең данлыклы атлары килгәнгә, шулай ерактан куйганнар, диләр. Ялгыз каенга ничек килеп җиткәнне белмим. Бу бик артык газап булды. Әлбәттә, атлап кына барырга кирәк. Алмачуарны тыяр хәл юк. Алда яисә артта берәр ат күрсә, авызлыкны тешләп ала да оча гына. Мин барып җиткәндә, атларның күбесе андалар иде инде. Ерак китмичә, туктаусыз йөреп торалар.

Боларны күргәч каушап калдым: берсеннән-берсе сылу, берсеннән-берсе асыл маллар. Өметем азаеп ук калды. Болар бит берсе дә Алмачуардан ким түгел!

Теге данлыклы Күк бия дә килеп җитте. Күрүгә шуңардан күзләремне алмадым. Гаҗәп бер мал икән: кыска яллы, сирәк койрыклы, чандыр гәүдәле нәрсә. Очасы тар, бер якка бераз чалыш, аркасы бераз бөкрерәк. Әмма күкрәк дигәне бөтенләй арысланныкы — шундый киң, шундый нык күренә. Тезләре ике яккарак китеп тора, бәкәлләренә карагач, тагы хәйран калдым: алар шундый озыннар ки, мин гомеремдә андыйны күргәнем юк. Күзләре зурлар — уйнап, ялкынланып торалар. Өстенә кечкенә, кап-кара, башы бөтенләй ялангач, кулына камчы тотып, бер башкорт малае менгән.

Кечкенә булса да, күп чапкан малайдыр, ахры, бер дә каушамый, атның холкын белгәнгә охшый.

Чабышкылар арасында иң тыныч торганы шул Күк бия иде.

Атлар килеп бетте, Садыйк абзый безне тезә башлады. Бусы бик зур бәла икән: инде тигезләп тездем генә дигәндә, йә берәүнең аты кузгалып, алга китеп бара, йә баскан урынында тора алмыйча, кире чигенә. Күп азаплардан соң тезеп җиткерде:

— Берәү, икәү, өчәү! Һайди, туганнар! — дип кычкырып та җибәрде. Ул «һайди»нең «һ»сен әйтеп бетерә алмагандыр, атлар әйтерсең канатланып очтылар.

Башкалар кая киткәннәрдер, узганнардырмы, артта калганнардырмы — белә алмадым. Урыннан кузгалуга, без өч ат: мин, Күк бия, тагы бер җирән чабышкы, бер-беребезгә бәрелә язып, янәшә оча идек.

Аяклар җиргә тияме, әллә атлар яшерен канатлары белән һавадан баралармы — әле дә аерып җитә алмыйм. Агачлар, елгалар, зур-зур баткаклар — алда, ничектер, күзгә чалынырга өлгерә алмыйлар, без аларны яшен кебек үтеп тә киткән булабыз.

Аеркул дигән бер тайгак елга бар. Бу юлда иң куркыныч нәрсә шул, диләр иде.

Очкан кошлар кебек, без бер-беребезне таптап, узып, каулашып, ул баткаклы елгага өчәү килеп кердек, ләкин ярның янында Күк бия белән минем Алмачуар гына иде, өченче иптәш — җирән чабышкы малае белән баштүбән шунда баткакка чумды булса кирәк.

Инде икәү ярышабыз...

Көчләр бик тигез: бервакыт аның аты чак кына арттан бара, ләкин тагы бер каулый, минем атның башы Күк биянең койрыгы янына кала. Тагы бер баткак, минем башым әйләнә, үзем егылам кебек булам. Күңелгә шөбһә килә: күзне йомам да Алмачуарның ялларына тотынам. Ачсам, баткакны чыкканбыз, ләкин Күк бия миннән өч-дүрт сажин алдан оча.

Инде якынлыйбыз да бугай, авылның манаралары күренгән кебек була.

Гайрәт белән бер тартам, камчы белән уңга-сулга җан ачуы белән сугам. Алмачуарым «эһ» дип суырып ала да, күз ачып йомганчы, Күк биянең алдына барып чыга...

Менә авыл, әнә басу капкасы, менә сырт өстен каплаган кара болыт кузгала!

Чабышкы ияләре безгә каршы ат өстендә киләләр.

Арада әткәй дә күренеп кала.

— Һайди, Закир, тагы бер сук! Тагы бер! Тагы!

— Һайди, Алмачуар!

— Һайди, Күк бия!

— Һайди, Алмачуар!

— Һайди, Күк бия!..

Ике яклап безне каулыйлар... Кычкыралар, сугалар, шаулашалар.

Ләкин Алмачуар белән Күк бия бөтенләй диярлек янәшә киләләр.

Тагы бер тартып җибәрдем, тагы бер бөтен гайрәтем белән уңнан-сулдан сугам...

Алмачуар «әһ» дип бер суырып ала да, Күк бияне аршын ярым чамасы калдырып, мәйданга килеп тә керәбез...

Кара болыт икегә ярыла.

Күк биянең башы минем Алмачуарның кабыргасындарак булган хәлдә чикне дә узып китәбез.

Шау-шу, тавыш, тапталыш! Әйтерсең мәхшәр көне!

Старостаның бер кулында яшел чапан — бусы беренче килгәнгә, икенче кулында зур сөлге — бусы икенче килгәнгә билгеләнгән.

Тузан, шау-шу эчендә староста, ялгышмы, ничектер, чапанны Күк бияга сузды, минем Алмачуарның муенына сөлгене ташлады:

— Син икенче килдең бугай,— ди.

Ни эшләгәнемне белмәдем, күз алдым караңгыланды, камчы белән уратып-уратып старостаның йөзенә селтәдем дә, кызулык белән Күк биядән чапанны тартып алып, бу кара болыт эченнән чыгып, читкә киттем. Камчы тигәндерме, юкмы — белмәдем...

Аны карап торырга вакыт та юк: чабып килгән атны туктатырга ярамавы һәркемгә билгеле бит!

Ул арада Сафа бабай, әткәй, күршеләр килеп, мине ат башыннан кочаклап алдылар. Һәммәсе мактый, һәммәсе рәхмәт укый. Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап:

— Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең,— ди.

Әткәй Алмачуарны җитәкләп йортә башлады. Мин, яулыкны ташлап, кәләпүш кидем дә кайнашып торган халык туфанына барып кердем.

Малайлар мине куркыта башладылар:

— Камчы белән сугып, старостаның битен яргансың. Ну, бирер үзеңә дә кирәгеңне! — диештеләр. Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе, чыннан да, ярылган булса кирәк: бер күзе ак яулык белән бәйләнгән иде.

Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым. Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

— Мин — балачакта үзем дә ат менеп күп чапкан кеше... Алдан килеп тә, икенченең бүләген бирсәләр, җан түзәлми аңа... Мин сиңа ачуланмыйм, аргансың, бар кайт инде,— дип, миңа егерме тиенлек көмеш бирде.

Дөнья минеке иде. Бөтен тирә-якта дан тоткан Күк бияне узып килү Алмачуар өчен һичкемнең акылына килмәгән бер бәхет иде.

20

Ләкин бу бәхет тиз арада бик артык авыр бәхетсезлеккә әйләнде. Белмим, атымны кызу каулап яндырганмынмы, белмим, килеп җиткәч, староста белән талашып, туктап тору харап иткәнме — ни дә булса булган: Сабан туеның икенче көнендә Алмачуар аякларына баса алмас булды, ашавыннан, эчүеннән калды. Бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәтеп карап, бер атнага якын ыңгырашып ятты да җомга көн иртә белән сәгать унда дөньядан үтте.

Алмачуар җан биргәндә, мин аның баш очында идем. Елый алмадым. Йөрәгем таш булып катты. Шуннан соң дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым.

Алмачуар минем йөрәгемдә җиргә, күккә, адәмнәргә — бөтен нәрсәләргә булган мәхәббәтемне үзе белән бергә алып китте.

Сүзлек өстендә эш.

*Гайрәт, мәхшәр, туфан* сүзләренең мәгънәләре турында фикер алышыгыз, аларны аңлатмалы сүзлектән табыгыз.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Авыл халкының үзара аралашу, киңәшләшү, хәл белешү, бер-берсенә ярдәмләшү кебек борынгыдан килгән гадәтләре сезгә танышмы? Мисаллар китерегез.

2. Закирның күтәренке күңеле, җиңел хәрәкәтләренә охшаш хәлләр сезнең тормышыгызда очрыймы? Үз хисләрегезне кушып, тасвирлап сөйләгез.
3. Әсәрдә сурәтләнгән Сабан туе бәйрәме сезгә ошыймы? Тагын нинди милли бәйрәмнәрне беләсез?
4. Вакыйга ничек тәмамлана? Закирның кичерешләре турында сөйләгез. Сез хикәянең азагы нинди булуын теләр идегез? Хикәяне дәвам итеп, сөйләп карагыз.
5. *Гөлләр чәнечкесез булмый икән; җире-күге, бөтен дөньясы — минем шатлыгымнан һәммәсе бииләр кебек тоела; бу җиңүләр миңа бик кыйбат төшкән чаклар да булды; кузгалып киту белән, мин очам; авылның асты-өскә килә; хатын-кыз бертуктаусыз кайный; йөрәгем суга; йөрәгем таш булып катты кебек* күчерелмә мәгънәле сүзләрне ничек аңлыйсыз?

## «АЛМАЧУАР» ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Галимҗан Ибраһимов «Алмачуар» хикәясен 1922 елда яза. Кеше һәм табигать гармониясен тасвирлау әдипнең башлангыч чор иҗатында ук ачык төсмерләр таба. «Яз башы», «Диңгездә», «Табигать балалары», «Яшь йөрәкләр» һ. б. хикәя-повестьларында үтә нечкә күңелле, романтик рухлы, тәэсирләнүчән һәм эшчән әдәби геройлар белән очрашабыз.

Хикәянең башында геройның эчке кичерешләре, борчулары, үзенә генә билгеле булган күңел газаплары сурәтләнә, Әлемгол белән Хафиз — ике баһадир — Сабан туенда көрәшәләр. Озак еллар буе мәйдан батыры булып танылган Хафизны Әлемгол җиңә. Хафиз бу җиңелүне бик авыр кичерә, шушы хәлдән соң Сабан туйларына бөтенләй йөрмәс була. Ә җиңүче үзен ничек хис итә соң? Әйдәгез, аның үзен тыңлыйк:

— Әмма менә җиңүче башкортның йөрәгендә аннан соңниләр булганы сезнең төшегезгә дә кермәгәндер, ди. Хафиз агакай, ди, мин сине екканда хәйлә ясадым...

Бу вөҗдан газабы Әлемголны еллар буе әзәрлекли. Алай гына түгел, бу хәл аны авыруга сабыштыра... Ул авыруының сәбәбен әнә шул хәрәмләшүдә күрә. Аякка бассам, Хафизны бәхилләтермен — бурлы биямне илтеп дога кылдырырмын, дип нәзер әйтә. Еллар буе

эчке тартыш, каршылыклы уйлардан соң гына үзенең биясен китереп бирә ала. Язучы, шәхеснең эчке кичерешләре аша гамәл, гөнаһ мәсьәләләрен намус, вөҗдан белән бәйләп, әдәби герой мисалында күрсәтә алган.

«Алмачуар» хикәясендә иркен табигать кочагында яшәгән малайның саф күңеле, самими хисләре крестьян тормышының гадәти көнкүрешенә тыгыз үреп сурәтләнә. Хикәя халык авыз иҗаты әсәрләрендәгечә, сүз сәнгатенең бөтен байлыгын, бизәкләрен, төсмерләрен оста файдаланып иҗат ителгән. Андагы вакыйгалар җанлы булып күз алдына килә, әдәби геройлар — ихлас күңелле әйбәт кешеләр белән бергә яшисең сыман тоела. Әсәрдәге күренешләр төп герой Закир күзәтүләре, кичерешләре, уй-фикерләре, аның сүзләре аша хикәя ителә. Шул җирлектә сабыйның дулкынлануы, борчулары, сөенеч-көенечләре,— гомумән, бөтен барлыгы баланың самими хисләре чишмәсендә сугарылып бирелә. Закир тасвирлавында урыны-урыны белән әкиятләргә хас чалымнар да күренә: «...Ул әкияттәге баһадир кебек, ай үсәсен көн үсә, үзе көннән-көн матурлана, асыллана бара»,— дип, малай Алмачуарга карап соклана. Әмма хикәядә сүз бер Алмачуар турында гына бармый. Яшүсмернең формалашуында әйләнә-тирәнең, әти-әнисенең, олы кешеләрнең, үз тиңнәренең — һәммәсенең үз өлеше, үз тәэсире күренә. «...кунакка барырга ясанган бояр җегете кебек чибәр» итеп, Алмачуарның ялын кистерүе, тасмалар тагуы үзе үк баланың матурлыкны аңлавын, нечкә зәвыклы икәнен күрсәтеп тора.

Хикәядәге Сафа бабай образы да — гаҗәп үзенчәлекле ил карты. Сафа бабай үзенең мул тормыш тәҗрибәсен башкалар белән бик теләп уртаклаша; кирәк чакта ярдәм итә, хәл-әхвәл белешеп тора, киңәш бирә. Аның гамәлләрендә халыкның борын-борыннан килгән яхшы гадәтләре, уңай традицияләре урын алган.

Хикәянең тел-стиль чаралары гаять үзенчәлекле. Анда катнашкан һәр әдәби геройның үзенә генә хас сөйләме, сүз сайлавы, эндәшү рәвеше, килеш-торышы, төс-кыяфәте, ягъни индивидуаль сыйфатлары бар. Яшьтәше Апуш хәбәр иткәннән соң, Закир үзенең рухи хәлен болай аңлата: «Башыма нидер сукты, телем тотлыкты, сүз әйтә алмый калдым». Гүя шул уңайдан язучы тормышның һәрчак ал да гөл генә булып тормавын искәртә, түземлерәк булырга өнди.

Г. Ибраһимов әтисенең атлар яратуын җылы хисләр белән искә ала: «Атлар ярату миңа әтидән күчкән булса кирәк... «Алмачуар» дигән хикәям дә үз тормышымнан алып язылган дисәм дә була».

**Бирем.**

Әсәрне тулысынча укыгыз, үзара фикер алышыгыз.

* * *

**Пейзаж** (француз сүзе) — «урын, ил» мәгънәсендә. Матур әдәбият әсәрләрендә табигать күренешләрен сурәтләү пейзаж дип атала.

Матур әдәбиятта пейзаж вакыйгаларны һәм анда катнашучы геройларның хис-кичерешләрен ачуда кулланыла.

Галимҗан Ибраһимов — пейзаж остасы. Автор «Яз башы» хикәясендә табигать матурлыгын сурәтләү белән малайларның күтәренке күңелләрен күз алдына китерә. Хикәя герое Салихның табигатьне, туган якны өзелеп сөюенә сокланмый мөмкин түгел:

«...күлдә һичбер дулкын юк, ул бик тын, тоны булып, көзге кеби шома, тигез ялтырый, тик ялангa караган башы бик аз гына шадраланмакта. Ләкин аның безгә әһәмияте юк, без барыбер ул җиргә бармыйбыз. Күлгә килеп җиткәч, тагы рәхәтрәк, тагы кызыграк тоела башлады. Бик күп хатирәләрем багланган бу күлне бик күптән күрмәгәнгә, күл үзе дә, аның тирә-ягын чолгаган карт агачлар да, яшәреп, гөрләп утырган уҗым да миңа бүген аерым бер якынлык таныталар...»

Аның «Алмачуар» хикәясе дә пейзажга бик бай. Закирның туган җирен сөю хисләре матур сурәтләнә. Табигать күренешләре укучының зиһененә керә, Закир белән бергәләп, шул матурлыкка хозурланасың: «Яратам мин үзебезнең авылны, бигрәк тә яратам авылның төньягын каплаган зур тауларны! Аңардан да бигрәк яратам шул таулар өстендә мең еллар буенча шаулап утырган зур карт урманны!.. Бу урманның гөрләп утыруы, бигрәк тә аның язгы кузгалагы, көпшәсе, җәйге чәчәкләре, исәбе-хисабы булмаган җир җиләге, кура җиләкләре, карлыганнары, бигрәк тә көзге чикләвекләре минем күңелемне ул урманга тарталар, аны йөрәккә якын, бик якын, бик сөйкемле итәләр».

## *Һади Такташ*

## *(1901—1931)*

Һади Такташ үзенең бала чагын туган җире белән бергә сагына. Аның өчен Тамбов урманнары — бөтен иҗатына ямь биргән, тормышына кайнар сулыш өргән кадерле урын:

Белмим,
Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...—

дип сурәтли ул «Мокамай» шигырендә.

Такташ — табигать җырчысы. Ул үзенең үсү юлын да табигать күренешләреннән башка күз алдына китерә алмый:

Ак каенга асылып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым...

Аның һәр шигырендә табигатьнең гүзәл күренеше, туган халкы кичергән җанлы хәят ярылып ята. Шуларга әдипнең янәдән шаян юморы, күңел өзгәләнүе, ярсу хисләре өстәлә:

Ах,
Мин җир өстен артык сөйдем бугай,
Артык сөйдем аның гөлләрен;
Һәрбер буйга җиткән каен кызын
Усак егетеннән көнләдем...

(*«Үтеп барышлый»*)

Һади Такташ 1901 елның 1 гыйнварында элеккеге Тамбов губернасы Спас өязе (хәзерге Мордва Республикасының Торбеево районы) Сыркыды авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Башта ул туган авылы мәктәбендә укый, аннан соң үзләреннән утыз чакрым ераклыктагы Пешлә мәдрәсәсен тәмамлый. Әтисе Хәйрулла абзый, төплерәк һөнәр бирү өчен, улын Урта Азиягә, туган тиешле кешеләргә ияртеп җибәрә. Тик ул анда белем дә, һөнәр дә ала алмый, бай туганнары аны «йомышчы малай» итеп кенә күрәләр. Әмма Һади үзлегеннән укый, шигырьләр яза башлый.

Ул 1922 елда Казанга килә, монда аның иҗат эше җанланып китә: «Мәхәббәт тәүбәсе», «Мокамай», «Алсу», «Киләчәккә хатлар» кебек әсәрләре басылып чыга. Аеруча яшьләр шагыйрьне көтеп алалар, әдәби кичәләр оештыралар. Үзенең шигырьләрен ул сәхнәдә үтемле һәм ягымлы итеп башкара белә, тыңлаучыларда тирән тәэсир уята.

Такташ — балалар сөеп укырлык әсәрләр дә иҗат иткән әдип. «Тәүфыйклы песи», «Караборынның дусты» һаман да яратып укыла, шигырьләрендәге нәфислек һәм юмор балаларга бик ошый. Юмор кулланып, шагыйрь кеше әхлагын сафландыру, яшьләргә кисәтү белән аларны бәхетсезлектән, бәла-казадан саклап калуны күздә тота: «Мәхәббәт тәүбәсе», «Габдулла агай әкияте» әнә шундыйлар.

Такташ үзенең шигырьләрендә халык иҗатындагы сурәт-бизәкләр аша лирик җылылыкка, матур яңгырашка ирешә: таңкә карлар, ай, җил образларын ябатып куллана ул.

Каләмдәшләре дә аңа хаклы бәяне бирделәр. Әмирхан Еники: «Такташ — көчле талант, шигъріят чишмәсе»,— дип язды.

Такташ — кыска гомерле шагыйрь. Ул 1931 елның декабрендә вафат була.

Меңләгән йөрәкләр ташкын хисле шагыйрьне югалтуга озак ышана алмый. Шул кичерешләрдән туган сагынуны әдипнең якын дусты Хәсән Туфан шигырь юлларына салды:

Бәйрәмдә безнең тын табынга
Синең дә өлешең куела:
Беләбез — кайтмыйсың... шулай да
Кайтырсың шикелле тоела.

## АК ЧӘЧӘКЛӘР

Ул,
Эретеп туңган тәрәзәне,
Мыштым гына карый урамга,—
Ак чәчәкләр ява урамда...
Берәү,
Борын очын кулына кысып,
Сүгенеп узды кышкы салкыннан,—
Җил ияртеп китте артыннан...
Алар,
Чана тартып, җырлый-җырлый,
Тау шуарга икәү уздылар,—
Ә бераздан кире сыздылар...

* * *

Ак чәчәкләр ява.
Дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары
Ак кар булып җиргә коела...
Яз янгыны җиргә кабынганчы,
Кар астында йоклар урамнар;
Төне матур булса, төн үтүгә,
Таңнар алып килер бураннар...
Дөнья матур,
Шуның өчен дә бит
Сүгнә-сүгнә кайтам салкыннан;
Ә җил мыштым гына эндәшмичә
Ияреп килә минем артымнан...
Белмим, нигә, әллә гыйшкы төшкән,
Кайда барсам, шунда бара ул;
Өйгә кергәндә, җиргә ятып,
Чыкканымны саклап кала ул...
Шуның өчен дә мин чыкмый гына
Тәрәзәдән карыйм урамга —
Ак чәчәкләр ява урамда...

Ак чәчәкләр ява, дөнья матур,
Шундый матур булып тоела;
Күге зәңгәр, гүя йолдызлары,
Ак кар булып, җиргә коела...

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шигырьне дөрес интонация белән укыгыз.
2. Әсәр сезгә ничек тәэсир итте?
3. *Ак чәчәкләр* сүзтезмәсенә шагыйрь нинди мәгънә салган? Бу кайсы сурәтләү чарасына керә?
4. «Ак чәчәкләр»дә елның кайсы вакыты күз алдына килә? Шушы күренешне рәсем итеп ясагыз.

* * *

**Лирик герой.** Шигырьдә уй-хисләрне һәм эчке кичерешләрне үз исеменнән сөйләп бирүчене лирик герой дип йөртәләр.

«Ак чәчәкләр» шигырендә Һади Такташ бөтен күренешне лирик герой кичерешләрендә сурәтләп бирә.

## УРМАН

(*Кыскартып алынды*)

Миннән хәзер ерак булган,
Минем көтү көтеп йөргән урман!
Сәлам сиңа сөйгән улыңнан!
Синең бөтен җирең минем хәтердә;
Сагынсам да сине,
Яратсам да сине,
Кайта алмыйм әле хәзергә.

Көтүләрдә хәзер кем кәҗәсе
Алдан чабып йөри торгандыр;
Мин партизан булып киткәч, яланында
Кемнәр көтү көтеп йөргәндер...

Мин, юкәләр юнып, җырлый-җырлый,
Чабаталар үргән урында,
Кем ул җырлый-җырлый көннәр буе,

Ак юкәләр сырып кулында,
Утыра торгандыр ул шунда.
Урман!
Сагынсам да, синдә тиз булмам.

Юлларымның башы синдә, урман!
Яшьлек көнем синдә узган!
Синең яланыңда
Әткәй китте аклар кулыннан.

Урман!
Мин, партизан, сиңа кайтырмын!
Кайтырмын бер килер көннәргә;
Тик көтүче булып түгел,
Ә инженер булып эшләргә!

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Лирик герой язмышына урман сурәте ничек бәйләнгән? Шул юлларны укып күрсәтегез.
2. Шагыйрь күңелен тетрәткән нинди вакыйгаларны урман бизәгеннән аңлап була?
3. «Ак чәчәкләр» белән «Урман» шигырендә бәйләнеш бармы? Үзара фикер алышыгыз.
4. Сәнгатьнең башка төрләрендә (рәсем, җыр) урман күренеше ничек бирелә? Такташ тасвирлаган «Урман» белән аларның уртаклыгы яисә аерымлыгы бармы?

## КАРАБОРЫННЫҢ ДУСТЫ

### АХМАКЛАР

Сыер дигәнең бик ахмак нәрсә бит ул, яхшылыкны белми, аңарга ашарга гына булсын; корсак өчен кырык мәртәбә үләргә әзер. Яшь көтүче Әйдүк аларга:

— Ахмаклар, сыбызгы борыннар, мошнайлар, үзегез өчен бит, авылга аклар килсә, кызыл камыт киясегезне белмисезмени,— дип сөйләнеп маташса да, сыерлар авылга аклар киләсен, килгәч, аларга уңайсыз буласын

«Таңбатыр» әкиятенә Лотфулла Фәттахов рәсеме.



Г. Тукайның «Исемдә калганнар» әсәренә Байназар Әлменов рәсеме.



Г. Тукайның «Пар ат» шигыренә Фәрит Якупов рәсеме.

Г. Тукайның «Шүрәле» поэмасына Байназар Әлменов рәсеме.

Л. А. Фәттахов. Сабан туе.

Х. А. Якупов. Хөкем алдыннан.

А. М. Родионов. Икмәк.

С. О. Лывин. Кышкы күренеш.

аңларга теләмәделәр. Урмандагы кигәвеннәргә түзми, авылга таба чаптылар. Әйдүк белән Караборынны — эт малаен арытып бетерделәр.

## КАРАБОРЫН ТАНЫМАДЫ

Әйдүк көтүне бер җиргәрәк җыярга да аннан бәрәңге пешерергә уйлады. Караборын аның ут ягарга маташуын башын борып-борып карап маташты да кинәт колакларын торгызып өреп җибәрде. Әйдүкнең колаклары үрә торды:

— Инде аклар килеп җитте,— дип уйлады. Тик Караборын танымады, ялгышты. Килүчеләр Озын Хөсәен, Әйдүкнең атасы һәм берничә авыл егетләре иделәр. Алар ут янына килеп утырулары белән сүзгә башладылар.

Тәбәй Җамалый улы Ибрай:

— Байлар, сыйлап-сырлап, үзләренең хайваннарын алып калырлар. Бөтен бәла безнең өскә төшәчәк. Болар — большевиклар яклы, дип, ут өрүчеләр дә күп булыр,— диде.

— Шулай шул,— диде Әйдүкнең атасы, Ибрайның сүзенә кушылды. Озын Хөсәен башын салып уйлап торды-торды да:

— Безгә хайванкайларны үз яныбызга алып бару хәерлерәк булыр, анда аларның сөтләреннән дә файдаланып булыр,— диде.

Озын Хөсәеннең сүзенә барысы да кушылдылар. Әйдүкнең атасы «яшьләр»нең сыерларын күрсәтеп чыкты. Ә бераздан егермеләп сыерны көтүдән аерырга маташа башладылар.

## ГАЙНУ ӘБИНЕҢ КӘҖӘСЕ

Аклар отряды авылга, «мактаулы» гаскәргә ашатыр өчен, крестьяннарның соңгы сыерларын алырга килделәр. Гайну әби, авылның бер очыннан башлап йорт саен туктый-туктый:

— Алланың каһәре төште, әһем-м-м, соңгы кәҗәмне алырга килделәр, инде нишләрбез, майкушларым, әһем-м-м... — дип, яшьләрен җиң очына сөртә-сөртә сөйләнеп китте. Кәҗәсе, аның юклыгыннан файдаланып, күптән кызыгып йөргән яшь кәбестәләргә кунакка китте.

Аклар җыен җыеп маташмадылар. Староста белән эшне бетерделәр. Көтүне эзләп, тирә-якка чапкыннар чапты.

## ЯХШЫ КЕШЕЛӘР ТҮГЕЛ ИКӘН

Хәйрулла агай урамда җыелып торган бер төркем ак офицерларны читтән генә карап торды да үз эченнән генә:

— Яхшы кешеләргә охшамыйлар,— дип уйлады. «Болай гына йөри»,— дип уйласыннар өчен, кулларын артка куйган булып, әкрен генә йортына китте. Ә аннан, көтүне эзләп, урманга чапты.

## КАРАБОРЫН ОШАТМАДЫ

Урманда көтүне эзләп йөрүчеләр күбәйде. Теге егерме сыерны алып киткәч, Әйдүк тагын ялгыз калды. Аны, атасының аякларын төзәткән чакта, ыштырлары арасыннан ялтырап килеп чыккан револьвер гаҗәпләндерде. Ул Караборынга бу хакта:

— Беләсең, Караборын, минем әти комиссар булган,— дип мактанып куйды. Ә Караборын аның сүзен аңламады. Ул тагын да колак йоннарын үрә торгызып өреп җибәрде. Бу юлы урманнан, карана-карана, Вәли бай улы Габдулла килеп чыкты. Ул, Әйдүк янына килеп туктавы белән, тәмәке төрә башлады. Караборын бу кунакны нигәдер ошатмады. Ул, аның ботыннан кабып карарга уйласа да, соңыннан ул уеннан кайтты.

«Моңа кемлекне күрсәтәсе иде дә, ярый инде»,— дип капмаска булды. Габдулла агачлар арасына кереп югалды. Ә бераздан, Вәли бай улы Габдулла белән ике атлы килеп, көтүне авылга алып барырга куштылар.

## ЭТ БАЛАСЫ

Авылга җитү белән, көтүне Вәли байның ишегалдына яптылар. Ә Әйдүкне өйгә өстерәп алып керделәр. Өйдә бишләп офицер, Вәли бай, староста, тагын кемнәрдер чәйләп утыралар иде. Әйдүк килеп керү белән, староста:

— Әйт, кемнәр сыерларын алып киттеләр, кая алып киттеләр? — дип сорады.

Әйдүк әйтергә теләмәде, аңарга шулай кушканнар иде. Ул:

— Белмим,— диде.

Староста, аның колагына ябышып:

— Әйт, эт баласы! — диде.

Әйдүк җавап бирмәде. Аны, эт урынына кыйнап, урамга ташладылар. Ул, өстерәлә-өстерәлә, өенә кайтты. Караборын аны, койрыгын селкеп, шатланып каршы алса да, соңыннан, хуҗасының газапланганын күреп, бер-ике шыңшып алды. Әйдүкнең күңелен табу өчен, уң аягын күтәреп, Әйдүккә сузып карады. Алай да булмагач, Әйдүкнең кулларын ялый башлады.

## ОЗЫН ХӨСӘЕН

Төн.

Ае юк төннең йолдызлары болытларга күмелгән дә, саламга баткан йортлар караңгыда калганнар.

Әйдүк, Караборынны кочаклап, авып килә торган йортларының эргәләренә утырды. Башында чуалып йөргән уйлары берәм-берәм бутала башлады. Бүген аны кыйнаучы авыл старостасы, теге офицерлар аның күз алдына килеп басты. Аннан соң... ул уйларын икенче нәрсәгә борырга уйлады. Ничектер, үзен кыйнатуы оят кебек тоелды. Үзе дә сизми йодрыкларын йомарлады. Тик:

— Барыбер бернәрсә дә әйтмәдем,— дип юанды. Атасы белән Озын Хөсәеннең, бернәрсә дә әйтмәве өчен, мактаулары күз алдына килде. Ул әкрен генә елмайды. Ә соңыннан аның күз алдында Озын Хөсәен йөри башлады.

Ул Озын Хөсәенне беренче мәртәбә урманда очраткан иде. Күптән инде бугай... Ул ничектер агачлар

арасыннан чыкты да алар янына килеп утырды. Шул вакытта Караборын әз генә аның ботыннан эләктермәгән иде. Алар атасы белән әллә нәрсә сөйләштеләр. Икенче көнне ул тагын шулай килде. Бу килүендә авыл хәлләрен, авылдагы Әйдүкләр кебек ярлы кешеләрнең тормышларын, көнкүрешләрен сорашты бугай... Соңыннан... Әйдүкнең атасы белән алар нәрсәгәдер бик дуслашып киттеләр. Нәрсәдер, Әйдүктән качып, озак-озак сөйләшә башладылар. Әйдүкнең «Ходай тәкъдире, Алла кушканга без шулай» дип, бөтен кеше алдында бик юаш булып йөргән атасы үзгәрә башлады... Нигәдер уйчанланды, усаллана төште... Ара-тирә кемнәрнедер сүгә башлады. Соңыннан Әйдүк атасының Озын Хөсәен турында күрше Гыймадига сөйләп торганын ишетте:

— Гаҗәп кеше инде ул Хөсәен. Көне-төне урманда ач-ялангач йөрсә дә, үзенең эшен эшли. Безнең ишеләргә дус кеше инде ул Хөсәен. Син, Гыймади, аның сөйләгән сүзләрен ишетсәң иде, менә инде безнең кирәкләрне әйтә дә бирә.

— Җамалый, ул үзе кем соң?

— ...Ул... Сиңа, Гыймади, ышанам инде... Без синең белән утыз ел күрше булып тордык. Алай-болай бернәрсә дә булмады, үзара сүз булсын, ул кызыллардан берәү икән... Кызыллар, безнең авыллардан чигенгән чакларда, Озын Хөсәенне авылларда яшерен эшләргә калдырганнар. Ул, мондагы безнең ише ярлылардан кызыл гвардия оештырып, акларның артына төшәргә тиешле икән. Безнең урманнарның берендә сугышка кирәкле төрле әйберләр дә күп калдырганнар,— ди...

Икенче көнне күрше Гыймади да Озын Хөсәен белән дуслашты. Шулай итеп, авылда күп кенә егетләр, берәм-берәм, Озын Хөсәен белән дуслаша башладылар. Озын Хөсәен кичләрен авылга да килеп киткәли башлады. Әйдүк белән дә бик дуслашып киттеләр. Ул старостадан үзенең үчен Озын Хөсәен белән икәүләп алырга мөмкин булачагын уйлады да:

— Шулай бит, Караборын! — дип, Караборынны кочаклады. Караборын, үзенең ризалыгын белдереп һәм караңгыдан файдаланып, Әйдүкнең борынын ялап алды. Әйдүк аның борынына төкерде дә урыныннан торып кереп китте.

## АЛЫП КИТТЕЛӘР

Төн. Ае юк төннең.

Әйдүк, әллә кайда мич арасына кереп, бертуктаусыз җырлап утырган чикерткәгә эче пошып, аны эзләп маташты. Таба алмагач, бер-ике кычкырып карады, алай да булмагач, чикерткә кычкырган җиргә үзенең чабаталарын ыргытты. Чикерткә бераз туктап торса да, күп тә үтми, тагын җырлый башлады. Әйдүк инде эзләп маташмады. Идәнгә салам түшәгән җәйде дә йокларга ятты.

Әйдүк әле төш тә күреп өлгермәгән иде, кинәт уянып китте. Аның баш очында Озын Хөсәен белән атасы Җамалый торалар иде. Ул, Әйдүкнең башыннан сыйпап, нәрсә булганын сораштыра башлады. Әйдүк йокы аралаш сүзен кайдан башларга белми торганда, урамда Караборын ачы-ачы өрә башлады, һәм тәрәзә алдында ике күләгә күренде. Озын Хөсәен, балтырыннан нәрсәдер алды да, әкрен генә тәрәзә янына килеп карый башлады, ә бераздан бик каты ишек кагуы ишетелде.

— Ачыгыз!

Җавап бирүче булмады. Озын Хөсәен Җамалыйга шыпырт кына:

— Әйдә, сул як тәрәзәдән,— диде һәм тәрәзә янына ашыгып килде дә, штыгын алга очлап, тәрәзәгә якынаеп килгән солдатка атып җибәрде. Үзе, тиз генә тәрәзә рамасын ватып, урамга атылды. Җамалый, Әйдүкне кочаклап, нәрсәдер эшләргә теләгән иде. Ишек ачылып, ишектән кул фонаре тотып, бер офицер, дүрт солдат килеп керделәр дә, офицер револьвер токасы белән Җамалыйның башына сугып җибәрде. Җамалыйның башыннан кан елгалары йөзенә агып төштеләр. Усал солдатлар аны тирги-тирги бәйли башладылар. Әйдүк

нишләргә белми күзләрен зур итеп ачып карап торды-торды да, тиз генә атасына ташланып, аны кочаклап кычкырып елый башлады.

— Әти, сине кая илтәләр, нигә кулларыңны бәйләделәр? — диде. Аякларын кочаклады. Җамалый:

— Елама, улым, безне кызыллар килеп коткарырлар, — диде. Артык ирек бирмәделәр, усал солдатлар Әйдүкне, алып, идәнгә ыргыттылар да атасын алып киттеләр. Әйдүк җиргә капланып үкси калды...

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Укыган өлешнең эчтәлеген сөйләгез.
2. Такташның пейзаж тасвирлавында нинди үзенчәлекләр сизелә? «Төн. Ае юк төннең» җөмләсе ни өчен кабатлап бирелгән?
3. Хикәя эчендәге бүлекләрнең исемнәренә ничек карыйсыз? Аларның әсәр төзелешенә нинди бәйләнеше бар?
4. Озын Хөсәен турында сөйләгез. Әйдүк язмышына аның нинди катнашы бар?
5. Җамалый карт күрәше сездә нинди тәэсир калдыра?

## КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗЛАР

Бөтен кырларны тутырып, штыкларын кояшта ялтыратып, кызыллар киләләр... Аларның ат тояклары утлар чыгара. Алар Әйдүкнең атасын коткарырга киләләр. Әйдүкнең карт атасын аклар алып киткәнне беләләрдер алар...

Әйдүккә алар менә хәзер килерләр дә аның атасын аклар кулыннан коткарып алырлар төсле тоелды... Ләкин аның күз алдына атасының башыннан агып төшкән кан елгалары килеп төшү белән, ул, кинәт йокыдан уянган кебек, үксүеннән туктады да тиз генә Вәли бай йортына таба чапты...

## КЕЛӘТТӘН ТАВЫШЛАР

Әйдүк урам буйлап йөгереп барганда, аның артыннан кинәт берәү йөгереп килә кебек тоелды. Ул артына әйләнеп караган иде, аның күзенә Караборын чалынды. Караборын, башын түбән иеп, гүя Әйдүкнең кайгысын белгән кебек, әкрен генә атлап килә иде.

Әйдүк Караборынны авылда үзенең бердәнбер дусты итеп хис итте. Шуның өчен дә аны ул кочаклап алды. Караборынның инде рухы күтәрелде. Ул, койрыгын югары күтәреп, Әйдүктән алда бара башлады. Әйдүк башта, атасын Вәли байның йортында кыйный торганнардыр дип уйлап, Вәли бай йортына таба китте. Ул, Вәли бай йорты алдында солдатлар күрү белән, якын барырга кыймады. Туктап тыңлый башлады. Вәли бай йортында тавыш, шау-шу ишетелмәгәч, нәрсә уйларга да белмәде. Ерак түгел бер йорт янында өч-дүрт хатынның мыштым гына сөйләшеп утыруларын ишетте. Әкрен генә алар янына үтеп, бер чатка сөялде дә тыңлый башлады. Сүз Әйдүкнең аталары турында бара иде. Ләкин ул аларның сүзеннән атасының кайда булуын озак аңлый алмады. Соңыннан бер хатын:

— Әй Ходаем, нишләтерләр икән үзләрен, бик каты кыйнаганнар, ахры, ыңгырашу тавышлары бирегә кадәр ишетелә,— диде.

Икенче берсе:

— Мин, тавышларын ишетеп, якынрак барып тыңларга уйлаган идем, келәт янына сакчы куйганнар икән. Бара башлагач, кем ул, атам дип әйтте дә, буыннарым коелып китте. Тиз генә борылдым да өйгә кереп яшерендем,— дип, авыр сулап куйды.

Әйдүк аталарының Вәли бай келәтендә икәнлекләрен аңлап алды. Ләкин нишләргә?

Ул нишләргә белмәде. Аның күз алдына Озын Хөсәен килеп басты. Ул, бәлки, качкандыр, дип уйлады. Ләкин кайда хәзер ул? Әйдүкне дә, атасын да бердәнбер сөюче Озын Хөсәен кайда ул? Бәлки, урмандадыр?.. Ул тиз генә әйләнде дә урманга таба чапты.

## ТАҢ ШӘҮЛӘЛӘРЕ АРАСЫНДА

Таң атып килә. Авыл тынычсыз йоклый. Крестьяннар, кояш чыгу белән, соңгы сыерларыннан аерыласыларын уйлыйлар да кире яклары белән әйләнеп яталар. Тагын, тагын шулай итәләр. Куркыныч төшләр белән саташалар.

Вәли бай йортындагы кысык ут шәүләсеннән башка авылда бер яктылык та күренми. Офицерлар күптән инде йоклыйлар. Тик аякларын чишенми яткан кайберәүләр генә, төннең караңгылыгы эченнән, түземсезлек белән нәрсәдер көтәләр. Кояш чыгарга якынлый. Шәүләләре, көнбагыш чәчәкләренең телләре кебек, күк читенә сузылалар.

Келәт янына куелган акларның сакчысы ары-бире авыл читенә карангалады да бүрәнәләр өстенә утырды.

Кинәт, ерак та түгел, мылтык аткан тавыш һаваны яңгыратып җибәрде. Тагын, тагын мылтык тавышлары ишетелде. Акларның полковнигы эчке күлмәкләреннән, шинеленең бер җиңен генә киеп, келәт янына чабып килде дә сакчы солдатка ашыгып кына келәткә ут җибәрергә кушты.

Солдат, кесәсеннән шырпысын чыгарып, келәткә сөяп куелган киндер көлтәләренә ут төртте. Ут Вәли байның келәте янындагы буш керосин мичкәсенә күчте. Аннан югары үрмәли башлады.

Кызыл ут шәүләсе таң шәүләләренә кушылды...

## ЯНГАН ГӘҮДӘЛӘР ЯНЫНДА

Көтелмәгән мылтык тавышларына уянган крестьяннар нәрсә дияргә белмәделәр. Аларның күбесе кызыллар килеп басты дип уйлады. Бала-чагаларның уянганнары мич астына качып өлгерделәр. Крестьяннар, мылтык тавышлары басылгач кына, ярык-йорыклардан урамга карый башладылар. Анда үз егетләренең мылтыклар тотып йөрүләрен күргәч кенә урамга чыктылар.

Кызыл отрядның башында Озын Хөсәен иде. Ул Вәли байның йорты алдында куллары, аяклары бәйләнгән Вәли байдагы теге дүрт офицердан һәм егермеләп солдаттан нәрсәдер сорашып маташты. Соңыннан, бөтен халыкны ияртеп, янып, пыскып яткан келәт янына китте.

Келәт янында, кара җирне тырный-тырный, кечкенә Әйдүк үкси иде. Аның йөзе тузанга баткан, күлмәкләре өзгәләнгән.

Озын Хөсәен аны күтәреп алды да, шунда җыелган крестьяннарга карап:

— Менә кечкенә Әйдүкнең атасы, көтүче Җамалый карт, хәзер инде янып көлгә әверелеп килә. Аны ни өчен шулай утка яктылар? Чөнки Җамалый карт бөтен байларга, зур корсакларга каршы көрәшүчеләрнең берсе иде... — дип, крестьяннарга карап озак сөйләде. Соңыннан, солдатларга карап:

— Менә бу солдатларның күбесе — алданып, кайберләре аклар тарафыннан көчләнеп, гаскәргә алынган үз туганнарыбыз. Телиләр икән, хәзер үк үзләре теләгән җиргә китә алалар. Китәргә теләмиләр икән, безгә кушылалар. Кулларын чишегез! — диде.

Солдатларның кулларын чиштеләр. Араларыннан берәү, алга чыгып:

— Мин сезнең сафыгызга, үз туганнарым ягына чыгам һәм соңгы тамчы каныма кадәр көрәшергә вәгъдә бирәм,— диде. Башкалары да шулай ук әйттеләр. Озын Хөсәен, офицерларны күрсәтеп:

— Инде бу зур корсаклар, бу алтын погоннар ут эчендә янып ята торган иптәшләребез өчен хисап бирергә тиешләр, аларны хәзер үк ут янына тезеп куегыз! — диде.

Вәли бай, тезләнеп, халыкка кулын сузды:

— Җәмәгать, яхшы кешеләр, минем ни гөнаһым бар, намазымны калдырмыйм, нигә мине һәлак итәсез? — дип ялына башлады, ләкин Озын Хөсәен тагын үзенең сүзен әйтте:

— Хәзер үк ут янына тезеп куегыз! — диде.

Егетләр аларны утка якын бер җиргә тезеп куйдылар.

Озын Хөсәен:

— Кемнәр болардан үч алырга тели? — диюгә, унбишләп крестьян егете чыгып, аларга каршы тезелделәр. Кояш инде күптән җир өстенә карап торадыр иде.

## КЫЗЫЛЛАР

Кызылларның алдынгы күзәтчеләре бер татар малае белән зур гына кара борынлы этне тотып китерделәр. Бу — Әйдүк белән Караборын иде. Штабта татарча белүче булмагач, аның белән сөйләшер өчен, полктагы бер татар командирын эзләп таптылар.

Әйдүк авылларында булган вакыйганы командирга сөйләп биргүгә, Караборынның муенындагы муенсасын алды да муенса эченә тегелгән берничә кәгазь чыгарды. Моны Озын Хөсәен җибәргән иде. Язуларны полкның комиссары карап чыгу белән, Әйдүкне килеп кочаклап алды. Әйдүк нигәдер түзә алмады. Әкрен генә елап җибәрде. Ул комиссарны да, тирә-ягын чорнап алган командирларны да үзенең иң якын кешеләре итеп хис итте. Ә кичкә таба, Әйдүк китергән планнар буенча, кызыл гаскәрләр акларга таба һөҗүм итә башладылар. Һәм акларны ике яктан кысрыклап, фронтны өзделәр...

## СОҢГЫ САУБУЛЛАШУ

— Хуш, Караборын, без синең белән тагын тиз күрешмәбез инде. Ибрайны яхшы тыңла, ул синең Әйдүгең булыр. Аны мине яраткан кебек ярат,— диде дә Әйдүк Караборынны Ибрай кулына бирде. Үзенең күзләреннән ике бөртек күз яше агып төште. Караборын да, Әйдүк белән бик озакка аерыласын сизгән кебек, җиргә ятып ауный башлады. Аяклары белән Әйдүкне кочаклаган кебек итәргә тырышты. Әйдүк аны соңгы мәртәбә кочаклап, башыннан сыйпады да, Озын Хөсәен аны ике тәгәрмәчле арбага утыртты. Атлар кузгала башлады. Караборын, Әйдүкнең арбага утырып китәсен күргәч, аңарга таба тартыла башлады, Ибрай Караборынны никадәр җибәрмәскә теләсә дә булдыра алмады. Караборын аны өстерәп китте. Ләкин шунда карап торучы Ибрайның абзыйсы, җепне үз кулына алып, Караборынны җибәрмәде. Әйдүкләр ераклашкан саен, Караборын үзенең шыңшуын көчәйтте. Иң соңыннан бәргәләнә-бәргәләнә улый башлады...

## КАРАБОРЫН АНЫ ХӘТЕРЛӘМӘДЕ

...Еллар артыннан еллар үтте. Кышлар артыннан кышлар килде. Табигатьнең оста бакчачысы — кояш — үзенең киң кырларында гөлләр үстерде.

Зәңгәр-аксыл болытлар һәр җәйне киң кырларга яңгырлар ташыдылар. Тагын көз килде. Тагын яфраклар саргайды. Тагын салкын карлар кырлардан кырларга очтылар... Тагын карлар эреде дә, чәчәкләр уянды. Чәчәкләр һәр иртән кояшка табан әйләнделәр. Алар көн буе күзләрен кояштан алмый карап тордылар. Кояш иңгәндә, аның белән саубуллашып, караңгыга күмелеп калдылар... Авылларда гражданнар сугышы хакында озак еллар әкиятләр сөйләделәр.

Кояш иңеп килә иде. Төнәк авылының кояш батышы ягыннан берсе бик озын, берсе бик кечкенә ике кеше килеп, йорт алдына туктадылар.

Йортның эргәсе янында ятып торган Караборын, бу көтелмәгән шәһәр киемендәге кунакларны куркытырга теләп, урыныннан сикереп торды да, арка йоннарын торгызып, аларга ташланды. Ләкин, көтелмәгәндә, шәһәр кунакларының кечкенәсе аңарга:

— Караборын! — дип эндәште.

Караборын өрүеннән туктады. Аңа бу тавыш, ничектер, таныш иде. Әллә кайчан аңа кемдер шулай эндәшә иде. Кайчандыр шушындый бер кешене ул бик яратадыр иде. Ләкин ул инде үзенең Әйдүген оныткан иде.

Әйдүк, аңарга якынлашып, аның башыннан сыйпады. Әйдүкнең исе дә аңарга бик таныш иде. Ул нигәдер бу кешегә өрүе өчен оялды. Ул, җиргә ятып, корсагы өстендә Әйдүккә табан шуышып килә башлады. Ул да булмады, торып чабып китте, кинәт борылды да Әйдүкне аяклары белән кочаклап алды. Ләкин ул аның бергә куйлар көтеп йөргән дусты, иң сөекле дусты Әйдүк икәнен исенә төшерә алмады... Ул Әйдүкне оныткан иде. Бу Әйдүк аның өчен ниндидер онытылган, ләкин кайчандыр бик якын булган бер кешесе кебек кенә тоелды.

## КАРАБОРЫН ШӘҺӘРГӘ БАРМАДЫ

Алар өйдән кузгалу белән, өйне сырып алган авыл балалары, хатын-кызлар, крестьяннар — һәммәсе авылны чыкканга кадәр озата бардылар. Караборын да Әйдүк янында барды. Ләкин, авылны чыгып бераз бару белән, Караборын туктады, әйләнеп авылга карады. Әйдүк аны:

— Караборын, бире кил! — дип, күпме чакырса да, Караборын урыныннан кузгалмады. Җиргә ятып, аларның артыннан күздән югалганчы карап калды. Әйдүк, артына әйләнеп карый-карый, һаман Караборынны чакырды. Ләкин Караборынның аның артыннан шәһәргә барасы килмәде.

## ӘЙДҮКНЕҢ ЭЗЕ БУЕНЧА

Әйдүкләр күздән югалгач, Караборын нәрсәсендер югалткан кебек хис итте. Әллә ничек, бу күздән югалган кешесе якын кебек тоелды. Минут үткән саен, аның йөрәге тибә башлады...

— Кем иде соң ул кечкенә сөекле кунак? ...Киң, зәңгәр чәчәкләр сибелгән урман буйларында көтүләр йөри... Әнә кемдер еракта:

— Караборын! Караборын! — дип эндәште.

— Чү!

Ул бит күптән, әллә кайчан үзенең көтү көтеп йөрүен, аннан соң... бик кечкенә, бик сөйкемле Әйдүкне исенә төшерә алды. Бу күздән югалган кеше Әйдүк булмасын дип уйлады. Ләкин Әйдүк бик кечкенә иде...

Аннан соң, аның киемнәре дә мондый түгел иде...

Ул торып юлны иснәде. Юлдан үзенең сөекле дусты Әйдүкнең исен тапты. Аннан соң, юлны исни-исни, Әйдүкнең эзе буенча чабып китте.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Утлы, давыллы елларның кайсы вакыйгалары сезгә аеруча тәэсир итте?
2. Әйдүкнең уй-кичерешләрен тексттагыча сөйләп карагыз. Сез аның хәлен уртаклашыр идегезме?
3. Әйдүк белән Караборынның үзара дуслыгы ни өчен хикәянең үзәгенә куеп сурәтләнә?
4. Караборынның хәрәкәтен, аерылу газапларын ничек бәялисез? Текстка игътибар итик: «Әйдүкләр ераклашкан саен, Караборын үзенең шыңшуын көчәйтте. Иң соңыннан бәргәләнә-бәргәләнә улый башлады...»
5. Авыл халкына карата аклар ни өчен бик рәхимсез? Язучы бу күренешне ничек сурәтли?
6. Хикәядәге урман күренеше белән «Урман» шигыренең уртаклыгы нәрсәдә? Пейзаж безгә урман әдипнең уй-кичерешләренә, вакыйгалар үсешенә ничек тәэсир итә?

**Язма эш (сайлап алу өчен).**

1. Әйдүк һәм Озын Хөсәен образлары.
2. «Караборын — Әйдүкнең якын дусты». (Инша.)
3. Караборынның кичерешләрен сурәтләүдә авторның осталыгы. (Хикәя итү.)

# *Әмирхан Еники*

***(1909—2000)***

Әмирхан Еники 1909 елның 2 мартында элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Благовар районы) Яңа Каргалы авылында таза хәлле крестьян гаиләсендә туган. 1911 елда аларның гаиләсе үзләреннән кырык чакрым ераклыктагы Дәүләкән авылына күченә. Дәүләкән — Дим буендагы гүзәл табигать почмагы. Язучы әсәрләрендәге табигатьнең байлыгы һәм төрледән-төрле бизәкләре, мөгаен, яшьтән үк Дим кочагында үсүеннән, аны яратуыннан киләдер.

Беренче тапкыр аңа хәреф танытучы кеше әтисе Нигъмәтҗан була. «Тукайның Сәгыйть ага бүләк иткән «Су анасы» минем өчен чын мәгънәсендә тел ачкычы булды»,— дип искә ала ул «Сәгыйть Сүнчәләй — әйбәт шагыйрь, Тукай замандашы» дигән мәкаләсендә.

Утызынчы еллар башында Еники, Казанга килеп, университет каршындагы рабфакка укырга керә, «Кызыл Татарстан» газетасына эшкә дә урнаша, байтак язучылар белән шунда аралашып китә. Әмма Казанның тынычсыз чагында, кулга алулар көчәйгәч, 1936 елны Урта Азия якларына китә, тик Ватан сугышы башлангач кына, шәһәргә әйләнеп кайта һәм 1941 елның июль аенда фронтка китеп бара.

«Мин — сугыш вакытында әдәбиятка кайткан язучы. Дәһшәтле авыр елларда күргән-кичергәннәрем

моңа сәбәпче булгандыр дип беләм»[1],— ди ул үзенең иҗаты турында. Аның фронт шартларында язылган матур хикәяләре — «Мәк чәчәге», «Бала», «Бер генә сәгатькә». Соңыннан да сугыш темасына байтак әсәрләр яза. «Без дә солдатлар идек», «Рәшә» повестьларын укучылар яратып укыйлар.

Ә. Еники әдәбиятыбызны үзенең бик күп якты әсәрләре белән баетты. «Саз чәчәге», «Әйтелмәгән васыять», «Гөләндәм туташ хатирәсе», «Туган туфрак», «Төнге тамчылар», тагын башка күп кенә хикәя һәм повестьлары бер-бер артлы дөнья күрделәр.

1984 елда аңа «Юлчы» исеме белән чыккан хикәяләр җыентыгы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде, соңрак әдип Халык язучысы дигән олы, ихтирамлы исемгә лаек булды.

Өлкән язучыбыз Әмирхан Еники 2000 елның февралендә вафат булды.

## КУРАЙ

(*Кыскартып алынды*)

Күптән түгел Сәгыйть[2] дус миңа курай турында шушы легенданы сөйләде:

«...Бик борынгы заманда безнең җирләрдәге бер хан, үсмер малайларны берәм-берәм чакыртып, шулардан чәчен кырдыра торган булган. Әмма чәч кырган малайларның берсен дә хан кире кайтарып җибәрмәгән — һәркайсын шунда ук үтертә икән. Шулай итеп, ханның чәчен кырган күп кенә малайлар һәлак булганнар. Ни өчен хан аларны үтерткән?— моның сәбәбен берәү дә белмәгән. Менә көннәрдән бер көнне бер ялгыз хатынның бердәнбер малаена да чират җиткән: хан чәчен кырдырырга аны да чакырткан. Малай хан сараена китәр алдыннан, әнисе аңа төче икмәк пешереп биргән: «Мә, улым, тамагың ачкач, утырып ашарсың»,— дигән.

---

[1] *Еники Ә.* Хәтердәге төеннәр.— Казан : Татар. кит. нәшр., 1983.— 222 б.

[2] *Сәгыйть Агиш* — күренекле башкорт язучысы.

Малай, төче икмәкне кыстырып, сарайга киткән, хан янына барып кергән һәм, күп сөйләшеп тормастан, ханның башын бик әйбәт юешләп, үткен пәке белән чәчен кыркып төшергән. Менә шулчак ул гаҗәеп бернәрсә күргән: ханның башында имән бармак чаклы мөгезе бар, имеш!.. Хан да шүрәле сыман мөгезле, имеш!..

Малай эшен бетергәч, хан аңа әйткән: «Син инде минем мөгезне күрдең, ханның мөгезе бар икән дип сөйләп йөрерсең, шуңа күрә мин сине үтертәм»,— дигән. «Ярый,— дигән малай, бер дә каушап тормыйча,— тик син миңа шушы икмәгемне генә ашап алырга рөхсәт ит»,— дигән. Хан рөхсәт иткән. Малай төче икмәген иплəп кенә ашарга тотынган. Ул, ашыкмыйча, авызын чәпелдәткәләп, бик тә тәмле итеп ашый икән. Хан моның ашаганын карап тора торгач кызыгып киткән: «Икмәгең бик тәмле күренә, кая, миңа да әзрәк сындырып бир әле»,— дигән. Малай чамалап кына сындырып биргән. Хан ашый башлаган һәм, исе китеп, малайдан: «Нигә бу икмәк шул хәтле тәмле?» — дип сораган. Малай: «Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде шул!» — дип җавап биргән. Моны ишеткәч, хан шактый аптырап калган: «Алайса, без синең белән бер ананың сөтен капкан булып чыктык, без хәзер бертуганнар булабыз бит!» — дигән. Малай дәшмәгән. Ә хан уйланып: «Бертуганны үтерергә ярамый бит әле, менә хикмәт нәрсәдә! — ди икән.— Ләкин үтертмичә дә булмый, чөнки син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләп йөрерсең... Инде нишләтергә сине?..»

Малай бу юлы да дәшмәгән, һаман тәмләп кенә төче икмәген ашый биргән. Шуннан соң хан, бераз икеләнеп торгач, малайга әйткән: «Ярар, мин сине үтертмим, дигән. Ләкин бер шартым бар. Кырда кура дигән бер көпшә үсә, син аның кипкәнен чокыр башыннан табарсың. Менә шул көпшәне кисеп ал да, минем мөгез турында сөйлисең килгән саен, шуңа гына өрә торган бул... Аңладыңмы?.. Мөгез турында — ләм-мим!..

Телең кычыта башлады исә, көпшәне генә сызгыртырга тотын!.. Килештекме?»

Малай: «Ярый, риза»,— дигән, шуннан хан аны өенә кайтарып җибәргән.

Малайның вакыт-вакыт мөгез турында бик сөйлисе килеп китсә дә, вәгъдәсен бозмаган. Сөйлисе килгән саен, әлеге шул кырдан кисеп алган көпшәсен «гү-гү» өрергә тотына икән. Тора-бара ул көпшәнең түбән очына тишекләр дә ясаган. Тишекләргә баскалап, көпшәдән нечкә-калын тавышлар да чыгара башлаган. Шулай итеп, малай төрле көйләр уйнарга өйрәнеп киткән. Хәзер инде ул ханның мөгезен сөйлисе килгәндә генә түгел, ә телдән әйтә алмаган берәр уе, хәсрәте бар чакта да көпшәсен алып уйный икән. Искиткеч моңлы, матур уйнаган ул, кешеләр аны таң калып тыңлаганнар. Кеше теле әйтеп бирүдән гаҗиз хисләрне кузгатучы курай дигән гаҗәеп нәрсә әнә шулай туган, имеш!»

* * *

Бу легенданы яңарак ишетсәм дә, курайның үзен миңа бик яшьли күрергә һәм тыңларга туры килде. Безнең Дәүләкәнгә терәлеп кенә торган Яңа Көрмәнкәйдә курай уйнаучы бер карт бар иде — менә шул картны хәтерлим әле мин... Тик минем балалык хәтеремдә аның кураеннан бигрәк башка ягы ачык сакланган. Хикмәт шунда: Тимербай карт курайчы гына түгел, балыкчы да иде. Һәм без, Дәүләкән малайлары, Дим тугаена барган чакта, Тимербай картның, шундагы күлләрдә тар гына бүрәнә каекка утырып, сыңар ишкәге белән камышларны ера-ера нәрәтә куеп йөргәнен гел күрә торган идек. Ул кояштан, җилдән бакырга әйләнеп, какланып беткән, бик чандыр бер кеше иде. Балакларын тезенә чаклы сызганган, күлмәгенең алдын ыштан бөрмәсенә кыстырган, изүе һәрвакытта ачык, ә башында — беләүләнеп каткан түбәтәй... Аннары тагын шул ук ыштан бөрмәсенә бәйләп, ул

иске күн кынында кечкенә үткен пычак та йөртә иде. Бигрәк тә менә шул пычакка безнең күзебез яна иде, һәм, әйтергә кирәк, бу пычаклы бабайдан без әзрәк кенә курка да торган идек.

Соңыннан Тимербай карт, нәрәтәгә кергән бик шәп табан һәм кара балыкларны иске кәрзингә тутырып, өстен яшел үлән белән каплап, Дәүләкән урамында, ыштан балакларын да төшермәгән килеш сатып йөри иде.

Аннары инде, үсә төшкәч, мин аның курайда уйнавын да хәтерли башладым. Әйбәт, оста уйный идеме ул — мин әле белми идем, әмма өч-дүрт тишегеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, эче куыш, җип-җиңел, кибеп беткән көпшәдән шундый гаҗәеп озын көйләр чыгара алуына хәйран кала торган идем. Бер могҗиза булып тоела иде ул миңа, һәм мин, кем өрсә дә курайдан шулай көй-моң чыгара аламы икән дип, баш вата идем. Билгеле инде, минем курай дигән шул җип-җиңел көпшәне тотып өреп карыйсым да килә иде... Ләкин Тимербай карт кураен юри генә, карар өчен генә дә һичкемгә тоттырмый иде. Уйнап беткәч, ул кураеның башын ни өчендер ялаштырып ала да аннары күлмәк изүеннән каядыр эчкә үк тыгып куя. Бу да мине бик гаҗәпләндерә иде.

Әмма минем курай белән чынлап торып сихерләнүем тагы да үсә төшкәч, унөч-ундүрт яшьлек чагымда булды. Беләсез, бу шундый вакыт инде: күңел кыллары үзеннән-үзе тибрәлеп, йөрәктә җыр-моң туарга гына тора! Хыялның да бик җилкенгән, эзләнгән, очынган чагы!.. Нәкъ менә шушы чакларда миңа курайны еш кына ишетергә дә туры килде.

Безнең күршедә генә Миңнегәрәй исемле башкорт тора иде. Аның ике аты бар. Шул атларын тәңкәле камыт-эшлияләр белән читән тарантаска җигеп, поезд килүгә, Дәүләкән станциясенә чыга һәм, поездан төшкән кымызчыларны утыртып, Дим буе авылларына илтеп куя торган иде. Бу — аның төп кәсебе; атла-

рын һәрвакыт таза-көр тота, ә көз җитеп, беренче кар төшкәч, шул атларның берәрсен иярләп, төлке, бүре сугарга да чыга иде. Шуның өчен генә ул ике бурзай да асрый иде. Кыскасы, бик егет кеше иде безнең күрше Миңнегәрәй агай.

Менә шул Миңнегәрәй агайга базар көннәрендә Дим буеның берничә мулласы, әйтик, Шәрип авылыннан — Котлыяр мулла, Казанголдан — Исхак мулла, Япардан Сафуан мулла гел килә торганнар иде. Бу өч мулла бик дуслар иде, ахрысы, чөнки, кайчан карама, алар һәрвакыт бергә булалар иде.

Аларның базарда бернинди сату-алу эшләре юк, иртәнге якта чыгып, базарны бер әйләнәләр дә үзләре кебек тагын берничә мулланы яки бай башкортны ияртеп кайталар һәм Миңнегәрәй агайның түр сәкесендә көне буе диярлек ашап-эчеп, курай тартып, җырлашып утыралар... Ике ихата арасында тәбәнәк читән генә, ә күрше өйнең тәрәзәләре киңенчә ачык, шунлыктан барысы да — сәкедәге чирек-чирек кымызлары да, табак тулы итләре дә һәм кунаклар үзләре дә ап-ачык

күренеп тора. Гомумән, башкорт муллалары ашап-эчеп утыруларын бирәүдән дә яшермиләр иде. Исерә калсалар да гаеп итүче юк — мулла да кеше!

Менә шул ачык тәрәзәләрдән инде бервакыт, абзыкаем, курай белән җыр агыла башлый!.. Һәм мин шуны ишетүгә, барган җиремнән капкынга эләккәндәй, шып тукталып кала идем. Һич ычкына алмый идем мин ул татлы әсирлектән... Бөтен дөньямны онытып, ләззәтеннән, сызландыруыннан җыларга җитешеп тыңлыйм да тыңлыйм... Күз алдымда үзенең якты киңлекләре, тын түбәләре, ак тирмәләре, утлауда йөргән җылкылары белән кылганлы дала әкрен генә җәелә дә җәелә... Бик биектә бөркет салмак кына йөзә. Еракта ялгыз җайдак шәүләсе күренеп кала, әллә кайда гына әрлән сызгыруы ишетелгән кебек була... Һәм иң гаҗәбе: шул далада ак тастарлы җиңгәнең муенына корык салган бияне савып утырганын бик ачык итеп күрә торган идем. Бу шулхәтле ачык җанлы булып күз алдына килә, мин хәтта җиңгәнең ике тез арасына янтайтыбрак кыстырган агач чиләген дә, шул чиләккә биянең ике имчәгеннән алмаш-тилмәш бәреп төшкән нечкә генә сөтне дә күргәндәй була идем... Әнә шулай әллә кайларга алып китә, хыялый итә иде мине башкорт курае, башкорт җыры!..

Курайчыны берничә мәртәбәләр күрсәм дә, мин аның кайсы авылдан, кем икәнен белә алмадым. Аны шул муллалар үзләре базардан ияртеп кайталар иде. Аз гына кылый, аз гына шадра, озын буйлы бу агай, минемчә, бик шәп курайчы булгандыр. Бик дәртләнеп, бик рәхәтләнеп, ничектер җиңел итеп, гүя уйнап кына тарта иде ул үзенең кураен! (Аның сирәк кенә төкле ирене, кураен китереп терәмәс борын ук, үзеннән-үзе селкенә башлый иде инде.) Әмма шул ук вакытта ул кураеннан гаҗәп саф, гаҗәп иркен тавышлар чыгара белә һәм шуны искиткеч озын итеп, бормаландырып суза да ала иде. Кыскасы, тәмам җилеккә үтәрлек итеп уйный иде агаебыз!

Ә курайга кушылып, һәрвакыт Котлыяр мулла җырлый торган иде, һичшиксез, курайчыга тиң җырчы ул... Авызын ачар-ачмас, иреннәре арасыннан гына бер суза башласа, тавышы киң далага да сыймас кебек... Шуның өстенә гаҗәеп моңлы-матур җырлый иде бу мулла!.. Мин аны яхшы беләм, бездә дә аның булганы бар иде. Озын кара кәзәки кигән мәһабәт таза гәүдәле, елтырап торган кызгылт шома битле, сирәк кенә кара сакаллы бер кеше иде ул. Базардан базарга, кунактан кунакка гел бал, кымыз эчеп тә кызык сөйләп, җыр җырлап йөргән бу кешенең мулла булуына ышануы да читен иде. Елына ике килә торган гаеттән башка ул үзенең мәчетенә йөрде микән?.. Һәрхәлдә, мин аның чалма кигән чагын күрмәдем.

Озын сүзнең кыскасы, күрше Миңнегәрәй агай өенә җыелып, сәрхуш булып утыручы муллаларның җыр-курайларын миңа бер-ике җәй буена еш кына ишеткәләргә туры килде. Нәкъ менә шул чакта башкортның тиңсез бай, гүзәл, сихри җыр-моңнары минем кайрыланып өлгермәгән күңелемә гомерлеккә диярлек сеңеп калды да булса кирәк. Аннары озак та үтми мин, шактый яшь башымны алып, туган-үскән оядан, якты Дим буйларыннан ерак калага чыгып киттем. Ә бер өч-дүрт елдан соң теге муллалар да кайсы кая таралып, югалып беттеләр шикелле...

## «КУРАЙ» ХИКӘЯСЕ ТУРЫНДА

Хикәя курай моңын һәм моңнарга тиң талантлы җырчыларны чагылдыра. Эчтәлектә курайның тарихыннан башлап, аның халык арасында иң яраткан уен коралына әверелүе күрсәтелә. Курайның милли моңнарны бөтен нечкәлеге һәм тирәнлеге белән бирә алуын язучы хисләрне кузгатырлык ләззәт белән сурәтли. Әйтерсең, хикәяне укыганда ук, курай сызган моңнарны ишетәсең...

Курай — татар һәм башкорт халкының күптәнге уен коралы. Ул табигатьнең үзеннән табылган, һәм

кеше акылы аны уй-хисләрне айкарлык кодрәткә җиткергән. Шуңа күрә автор хикәяне әкият белән башлый.

Язучы талантлы курайчыларны халыктан таба. Дим муллаларын оеткан, уены белән хәйран иткән какча гәүдәле ябык кеше дә, Тимербай да хезмәт белән көн күрүче шәхесләр бит. Ә. Еники халыктагы шул хәзинәне, халыкның дулкынлы тормышын, матурлыкны тудыра алу кодрәтен моңнар ташкыны итеп бирә.

Курай аша халык көйләренең үсүен, милли музыкаль сәнгатьнең дә алга китүен сиземләп була.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Ни өчен хикәянең башында ук язучы әкият-легенда биргән? Бу әкиятнең төп эчтәлеккә нинди бәйләнеше бар? Шул турыда уйланыгыз.
2. Хикәяләүченең курайга һәм курай уйнаучы осталарга соклануын ничек аңлыйсыз?
3. Тимербай картның кайсы һөнәре сезгә якын тоела? Һөнәрдә кешенең нинди сыйфатлары ачыла?
4. Курай моңнары нинди хисләр уята? Текстка якын итеп, үзегез аңлаганча сөйләгез. Мисаллар китерегез.
5. Ни өчен халык җырлары тирән моңга, сагышка бай? Халкыбыз тарихына бәйләп, бу турыда фикер алышыгыз.
6. Сез курайда уйнаучы нинди талантларны беләсез? Үзара әңгәмә оештырыгыз.

**Мөстәкыйль эш.**

1. Кайсы уен коралларында уйный беләсез? Сыйныфны икегә бүлеп, ярыш оештырыгыз.
2. Курай турында нинди җырлар беләсез?

## БАЛА

(*Кыскартып алынды*)

Лейтенант Иванов ротасы урман эче буйлап зур саклык белән алгы позициягә таба китеп бара. Дошман самолётлары күренә калса, тизрәк агачлар арасына яшеренергә уңай булсын дип, кызылармеецлар киң ком юлның ике ягыннан пар-пар тезелешеп баралар.

Урман, үз-үзен тыңлагандай, хәрәкәтсез һәм тын. Кояш чыккан вакыт. Мәһабәт төз наратларның очлары ачык яшеллек белән яналар һәм, рәхәт бер талгынлыкка бирелеп, тик кенә торалар... Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле җилфердәшәләр... Ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята. Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга, һәм эзләр, яшькелт-кара тасмадай, артта сузылып кала. Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә сыланган кебек була. Озак килүгә дә, йөкнең авырлыгына да карамастан, тән — ниндидер бер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән тыныч бер рәхәтлек тоя...

Ротаның арткы рәтендә кызылармеец Зариф, алдан баручы иптәшләренең тигез генә тирбәлгән аркаларына карап, салмак кына атлап бара. Аның йөзендә тыныч ваемсызлык. Бары тик кысыла төшкән күзләре генә аның эчке уйларга йотылып баруын күрсәтәләр.

Бу иртәнең җылы тынлыгы, урманның өлкән гамьсезлеге каядыр якында гына мәрхәмәтсез сугыш, кан һәм үлем барлыгын онытып торырга мәҗбүр итә, гүя сөттәй ак томан ул дәһшәтләрне үз эченә яшерә һәм кешедән ераклаштыра. Бу тыныч һәм сөенечле хисләр белән сулый торган табигатьтә кеше, ничектер, үзе дә теләмәстән, алданучан була.

Менә Зарифның колагына кайдадыр якында гына ашлык суккыч машинаның гөрләве, эре көлтәләрне тартып алып йоткан чакта үкереп куюы ишетелгән кебек булды.

Ул: «Кайда сугалар икән?» — дип уйларга өлгерә алмады, командирның:

— Һава! — дип кычкырганы ишетелде. Рота минут эчендә юлның ике ягына, агачлар арасына яшеренде.

— Менә сиңа молотилка! — диде Зариф, бер агач төбенә ятып һәм алдануына башын селкеп куйды.

Самолёт ераклашты. Лейтенант команда бирде булса кирәк, алда яткан кызылармеецлар ашыгып тора башладылар. Зариф та урыныннан кузгалды. Ләкин ул бер адым да атларга өлгермәде, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, ихтыярсыз тукталды. Баланың берәр якын кешесен күрергә теләп, тирә-ягына каранды, ләкин якында һичкем барлыгы сизелми иде. Зариф, бик гаҗәпләнеп, янә балага карады — бала, чыннан да, ялгыз иде. Ул үзе биеклек кенә бер куак янына баскан, кечкенә кулына берничә бөртек җир җиләге учлаган, шуны кабарга әзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап тора. Озак елаудан аның күз төпләре шешенгән, түгәрәк битендә яшь юллары калган... Ләкин хәзер тынычланган, нинди хәлдә булуын оныткан, ахрысы: аяк астындагы җиләкләрне җыярга керешкән. Аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто, башында фетрдан тегелгән кара шапочка, аны кызыл тасма белән ияк астыннан китереп бәйләгән; аякларында озын сары оеклар белән сары ботинкалар һәм бер аягында галошы бар, икенчесен төшереп калдырган булса кирәк.

Зариф бу баланың дошман явыннан качып баручылардан югалып торып калганын бик тиз төшенде һәм аңарда кузгалган беренче теләк баланы тизрәк күтәреп аласы килү булды. Шул ук вакытта ул үзенең ротадан һич калырга ярамаганлыгын уйлап алды. Беренче хәрәкәте, ротасы артыннан китү өчен, юлга таба борылу булды. Ләкин ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып аның янына барды да җитез генә күтәреп алды.

Бала куркуыннан:

— Әни! — дип кычкырып җибәрде һәм, җиләген йомарлаган кулы белән Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп еларга керeште.

Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен

сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты. Шундый кыска вакыт үтүгә карамастан, рота шактый ераклашкан иде инде. Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.

Бала елап арган, күрәсең,— тиз арада аның елавы тавышсыз үксүгә әйләнде. Зариф кесәсеннән бер шикәр кисәге чыгарып, тузанын өргәләп, балага тоттырды. Бала башта башын селкегән булды, аннары, шикләнеп кенә, буш кулы белән шикәрне алды һәм йомарлап күкрәгенә кысты.

Зариф йомшак тавыш белән:

— Аша, аша! — диде һәм баланың аркасыннан сыйпап, сөеп куйды. Балага шул җитә калды: ул үксүеннән туктады, тынычланган кебек булды һәм, Зарифның кулында акрын гына селкенеп, тирә-ягына каранып бара башлады. Зариф баланың юка киеме аша йомшак тәнен, җылысын, тәмле исен тоя иде. Ниндидер бер ләззәтле сагыну белән шул йомшак тәнне, шул тәмле бала исен тагы да ныграк тоярга, ничектер үзенә сеңдерергә теләгәндәй, ул баланы акрын гына кыса, аркасыннан сыйпый... Һәм аның йөрәге төбеннән әйтеп биреп булмый торган сөенечле бер ярату хисе җылы дулкын булып күтәрелә бара иде. Зарифның да бит өч яшьлек Фәридәсе бар. Зариф та ата, һәм бәлки шушы минутта ул үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр, киресенчә, бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр. Ул, баланың йомарлаган кулын тотып, кипкән иреннәренә тидереп алды. Акрын, назлы гына:

— Әтиең, әниең бармы? — дип сорады һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте.

Бала ачык тавыш белән җавап кайтарды:

— Әнием дә бар, әтием дә бар... безнең әле тагын кәҗәбез дә бар. Бәтиләре ап-ак.

Зариф, елмаеп, балага күтәрелеп карады:

— Шулаймыни? Кара син, ап-аклар икән... Ә әтиең кайда соң?

— Китте.

— Кая китте?

— Белмисеңмени? Фронтка,— диде бала һәм аз гына тынып торганнан соң исенә төшкәндәй,— ул лейтенант,— дип куйды.

— Шулаймыни? Менә син нинди акыллы, этиеңнең кем икәнен дә беләсең. Ә... — Зариф кинәт сүзне бүлде. Ул: «Әниең кайда?» — дип сорамакчы булган иде, ләкин баланың исенә төшермәс өчен тыелып калды.

Бала Зарифка тәмам ияләшеп өлгерде, күрәсең. Ул, тарсынмыйча, әүвәл бер кулындагы ике бөртек җиләген капты, соңра икенче кулындагы шикәрен суыра башлады.

Кинәт бөтен урман эчен дәһшәтле гөрселдәү каплап алды. Җир буйлап тетрәү йөгерде, һәм һава дулкыныннан агачларның башлары селкенешеп куйдылар. Кайдадыр якында гына артиллерия атышы башланды. Зариф та, бала да бераз вакытка сүзсез калдылар. Ниндидер бер шомлы тынлык аларның эчләренә урнашкан кебек булды... Бала куркуыннан акрын гына калтырана башлады. Зариф аны үзенә кыса төште һәм аңа икесенең дә йөрәкләре бергә типкән кебек тоелды.

Бераздан бала елаган тавыш белән:

— Әни! — дип куйды.

Зариф акрын, сабыр тавыш белән:

— Елама, кызым, хәзер әниең янына барып җитәбез,— диде, һәм үз тавышы үзенә баз эченнән килгәндәй тонык, саңгырау булып ишетелде.

Бала, Зарифка сыена төшеп, бер кулы белән аның муенынннан урап алды. Зариф, белмим, баланы юатыр өчен, белмим үзенең эчке бер уеннан:

— Без кая барабыз?— дип сорап куйды.

— Әбиләргә кунакка,— диде бала җитди генә.

Зариф ихтыярсыз елмайды.

Шул арада алар юлның икегә аерылган җиренә килеп җиттеләр. Уңга аерылган юл белән рота китеп бара, сулдагысы исә якындагы станциягә илтергә тиеш. Биек һәм сирәк үскән наратлар арасыннан стан-

ция янындагы йортларның түбәләре дә күренә инде... Зариф хәзер, чыннан да, аптыраишта калды. Нишләргә? Дөресен әйткәндә, ул һич туктамастан ротасын куып җитәргә тиеш. Ләкин кулында сыенып утырган бала аны ике юл чатында тукталырга мәҗбүр итте. Баланы ут эченә кадәр алып барырга мөмкин түгел. Ул соңгы өмет белән тирә-ягына каранды. Ләкин һичберкемнең килгәне яки китеп барганы күренми иде. Берничә секунд ул бөтен акылын җигеп уйланды. Хәтере ялгышмаса, аңа рота китеп барган юлдан бер тапкыр үтәргә дә туры килгән иде, һәм бу юл будка яныннан тимер юлны кисеп үтәргә тиеш кебек иде. Ул станция белән будка арасын эченнән исәпләп алды һәм балага күтәрелеп карады. Бала, Зарифның нәрсә уйлаганын сизенгән шикелле, зур булып ачылган күзләре белән аңа бик җитди карап тора. Бу караш Зарифның икеләнүен өзде; ул үз-үзенә катгый рәвештә: «Өлгерермен!» — диде һәм, баланы кулында ипли төшеп, йөгерә-йөгерә станциягә таба китеп барды.

Менә станциянең платформасы күренде. Аның алдында кызыл эшелон тора, ул хәзер кузгала булса кирәк — кешеләрнең ашыгып вагоннарга менүләре күренә.

Зариф станциягә килеп җитте, йөгереп платформага төште һәм тирә-ягына карарга өлгерә алмады, кара киемле ябык бер рус хатыны:

— Балам! — дип кычкырып, Зарифка ташланды.

Бала:

— Әнием! — дип, бөтен гәүдәсе белән хатынга сузылды, һәм Зариф баланың үз кулыннан киткәнен сизми дә калды.

Төнлә белән олы юлны немец бомбага тоткан вакытта баласын югалтып, соңыннан аны эзләп-эзләп тә таба алмаган ананың шушы минуттагы хәлен аңлатып бирү мөмкин булмас иде. Ул йөрәгенә сыеша алмаган шатлыгыннан сүзсез, бары ыңгырашып, баласының кулларыннан, битеннән, чәченнән, күзләреннән үбәргә

кереште. Баланың кулыннан шикәре төшеп китте. Кемнәрдер алар янына җыела башлады.

Зариф баланы тапшыруга тирән итеп бер сулады, тирдән елтыраган маңгаен кулының сырты белән сыпырып куйды һәм ана белән баланың кавышу күренешенә бары соклану тулы караш кына ташлый алды. Бәлкем, шул секундта аның ана белән балага назлау сүзе әйтәсе, үзенең исә мактау һәм рәхмәт сүзе ишетәсе килгәндер. Ләкин ана беренче тетрәнүеннән айнырга өлгермәс борын ук, Зариф тимер юл буйлап йөгерә-йөгерә китеп тә барды.

Хатын, баласын күтәргән килеш, аның артыннан омтылып нәрсәдер кычкырды. Зариф, артына карап, бары кулын гына селкеде. Хәзер аның башында бер генә уй иде: ничек итеп ротаны тизрәк куып җитәргә, ничек итеп командиры алдына барып басарга һәм нәрсә дип әйтергә.

Менә алда тимер юл аша үтеп барган рота күренде. Зариф, мылтыгын иңеннән алып, тагы да кызурак йөгерә башлады. Бәхеткә каршы, рота тимер юлдан ерак түгел бер агачлык ышыгына барып туктаган иде.

Ниһаять, Зариф килеп җитте. Аз гына читтәрәк папирос тартып торган озын буйлы, чандыр гәүдәле командиры алдына килеп басты һәм, кулын чигәсенә куеп:

— Иптәш лейтенант!..— диде дә тынын ала алмыйча туктап калды.

Командир, Зарифның тирләп кызарган йөзенә текәлеп карап:

— Иң элек тынычланыгыз! — диде.

Бу сабыр тавыш Зарифка, чыннан да, тынычлык биргән кебек булды. Ул, тирән генә итеп бер сулап алганнан соң, сүзләрен артык бутамыйча, кайда һәм ни өчен юк булып торуын әйтеп бирде.

Командир шактый дәшми торды. Зариф менә хәзер каты шелтә алам дип селкенергә дә куркып тора иде. Ниһаять, командир папиросын җиргә ташлап, итегенең

очы белән аны озак кына изгәләде, аннан акрын тавыш белән сорап куйды:

— Баланы кемгә тапшырдыгыз?

— Әнисенә...

Шул минутта ротадан бер-ике йөз метр уңга агачлар арасына снаряд төшеп шартлады. Һавага төтен, туфрак, агач ботаклары күтәрелде. Командир икенче папирос чыгарып, ашыкмыйча гына кабызды, соңра алдында һич кузгалмыйча басып торган Зарифка:

— Сез зур изгелек эшләгәнсез,— диде.— Моның өчен мин сезгә рәхмәт белдерәм!

Зариф гаҗәпләнүдән күзләрен йомгалап алды. Командир моны күрде булса кирәк, аның җитди чырае таң шәүләсе төшкәндәй яктырып, йомшарып киткән кебек булды.

— Мин әйткәнне аңладыгызмы?

Зариф, дулкынлануыннан иреннәрен кысып, башын гына селекте.

— Инде хәзер урыныгызга барыгыз!

Ярты сәгатьтән соң рота, агачлыкны үтеп, ачык җиргә чыкты һәм, цепька таралып, алдагы ут позициясенә таба юнәлде.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. «Бала» хикәясе сездә нинди уй-хисләр тудырды? Вакыйганың иң тәэсирле урынын кыскача гына әйтеп бирегез.
2. Зариф күңелендә бала белән очрашу нинди кичерешләр уята?
3. Бала язмышы һәм сугыш. Әсәрдән алган кичерешләрегез турында фикер алышыгыз.
4. Баланың куркынган йөзенә игътибар итегез. Сабый учындагы берничә бөртек җир җиләге тәлгәше аның хәвефле язмышын сурәтләүдә нинди роль уйный?
5. Зариф белән командир арасындагы мөнәсәбәтне ничек аңлыйсыз? Монда солдатның сугыш анты белән кешелеклелек сыйфаты туры киләме?
6. Хикәядә тасвирланган табигать күренешен кабат укып, аның эчтәлекне һәм солдат хисләрен тирәнәйтүче сурәт булуын ачыклагыз.

# *Гадел Кутуй*

## *(1903—1945)*

Гадел Кутуй көләч йөзле, шат күңелле, тормыш сөючән язучы булган. Замандашлары аның шушы сыйфатларын сокланып искә алалар. «Бөтен бары белән ачык кеше, сүзгә юмарт кеше,— дип яза аның турында каләмдәше Әмирхан Еники.— Теләсә кем белән бик тиз таныша, бик ансат сөйләшеп китә. Теләсә кем алдында да үзен хөр, иркен тота, әмма һавалану яки ялагайлану кебек нәрсә юк иде аңарда. Сүзен, фикерен туры әйтергә ярата һәм... бик алай хәтер дә саклап тормый иде»[1].

Г. Кутуй 1903 елның 28 ноябрендә элекке Саратов губернасының Кузнецк өязе (хәзер Пенза өлкәсенә керә) Татар Кынадысы авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Аның әтисе Нурмөхәммәт абзый кустарьчылык тәртибендә эшли торган күн заводларында компаньон була. Соңыннан ул гаиләсе белән Самарага күчеп килә, анда мичкә ясау һөнәрен дәвам иттерә. Әнисе Динә апа шигъри җанлы булган; Кутуй, язган шигырьләрен элек әнисенә укып, аның фикерен ишеткән.

Туган авылында башлангыч мәктәпне тәмамлагач, Гадел Самарада укый башлый һәм беренче шигырьләрен рус телендә яза.

Кутуй күптәнге хыялы булган Казанга килә. Педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлегенә

[1] *Еники Ә.* Хәтердәге төеннәр.—Казан : Татар. кит. нәшр., 1983.— 138 б.

укырга кереп, 1929 елда аны уңышлы тәмамлый. Гадел, җиң сызганып, иҗат эшенә керешә, үзенең сәләтен проза әсәрләрен язуда таба. Утызынчы елларда «Вөҗдан газабы», «Солтанның бер көне», «Нишләргә?» хикәяләрен язып бастыра. Бу әсәрләрдә геройларның эчке дөньясы бик мавыктыргыч сурәтләнә. Шундый ук хис-кичерешләргә бай, Кутуйны язучы итеп таныткан әсәр — «Тапшырылмаган хатлар» (1935) повесте. Ул рус, инглиз, гарәп һәм башка телләргә дә тәрҗемә ителә.

Кутуй, Ватан сугышына китеп, рус һәм татар телләрендә чыга торган фронт газеталарында эшли. Үзенең тирән эчтәлекле хәбәрләре белән солдатларның игътибарын тиз җәлеп итә, аны сугышчылар көтеп алалар. Шигырьләр, хикәя һәм нәсерләр яза. «Сагыну», «Без — сталинградчылар» һ. б. әсәрләрендә ул солдатның фидакарь көрәшен, сагыну тулы күңелен нәфис сурәтләве белән уңышка ирешә.

Ни кызганыч, Гадел Кутуй туган илгә әйләнеп кайта алмады, 1945 елда Польша җирендә үлеп калды.

## САГЫНУ

(*Нәсер*)

Мин чит илдә матур гөлләр, хуш исле чәчәкләр исним. Ләкин күпме генә иснәмим, барыбер һава җитми, сулыш кысыла. Гүя үз илемнең энҗе чәчәкләре түгел, аның әреме дә бүген миңа шифа булыр иде.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин, шаулап аккан елгалардан, тирән коелардан алып, сап-салкын су эчәм. Әмма күпме эчсәм дә, сусавымны баса алмам. Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам. Гүя бу мөкатдәс елгаларның суларын түгел, хәтфә болынлыктагы чишмәләребезнең бер йотым суын да бүген мин ширбәт итеп эчәр идем.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин Карпат тауларына мендем, Финляндия күлләре янында ял иттем. Ләкин Эльбрус шикелле мәһабәт,

Казбек шикелле гүзәл тауларны, үз илемдәге Аккош күледәй сихри күлләрне очратмадым.

Синдәгедәй илаһи матурлык, синдәгедәй шагыйранә мәһабәтлек бер җирдә дә юк, туган ил!

Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара. Чит ил балалары миңа бәйләм-бәйләм чәчәкләр сузалар, чит ил картлары миңа хәмер тәкъдим итәләр, чит ил кызлары миңа җимешләр сузып елмаялар һәм ялваралар:

— Син безне үлемнән коткардың, инде кил, чибәр егет, кунак бул, бездә кал! — диләр.

Әмма мин елмая алмыйм, чөнки хәмерләре исертми, елмаюлары җылытмый. Мин юлымны дәвам итәм. Мин газиз илемне, аның ямьле бәйрәмнәрен, аның талган аякларны да биетә торган хәмерләрен, йөрәккә җылы өргән нечкә билләрен сагынам, гөнаһсыз балаларын күргәндәй булам.

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Мин горур атлыйм. Чөнки мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем. Мин ата-баба корган илемдәге изге йорт турында уйлыйм һәм, шунда тизрәк кайтып керер өчен, Берлинга ашыгам. Берлинга мин, илем белән аерылу кайгысын моннан соң һичкайчан татымас өчен, чиксез ачу белән барам. Ачуым шулкадәр көчле, сагынуым шундый татлы ки, мин түзмим, җырлап җибәрәм.

Иле ямьсез, суы тәмсез,
Өйгә кайтасым килә!—

дип җырлыйм мин.

Без мәйданга керәбез. Поляк яшьләре, безне котлап, үзләренең иң матур җырларын җырлыйлар. Әмма минем күңел еракта. Мин үзебезнең Кызыл мәйданыбызны сагынам һәм туган илдән килгән хатларны укыйм. Дусларым, кардәшләрем миннән, сагынасыңмы,

дип сорыйлар. Минем бугазыма төен тыгыла. Мин төенне йота-йота җавап язам:

Телеграм баганасы — олы юлга маяк ул,
Сагынасыңмы дип сорыйсыз — сагынмаган кая ул!

Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!

Сине сагынган саен, миндә көч-дәрт арта, рухым канатлана. Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: ...кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул.

Сагынган саен сагынасы килә. Сагынуым шундый көчле булганга, кайтуым да ышанычлы. Кайтыр булмасам, бу кадәр сагынмас идем.

Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

* * *

**Нәсер** (гарәпчә «проза», «чәчеп җибәрү» мәгънәсендә) — геройның киеренке, тирән хисләрен чагылдыра торган эмоциональ һәм ритмлы, кечкенә күләмле чәчмә әсәр.

Бу жанр безнең әдәбиятта сирәк күренә. Кутуй — нәсер остасы, 1944 елда, фашизмга каршы сугышып йөргәндә, ул ике нәсер яза: «Сагыну», «Без — сталинградчылар».

**Инверсия.** Җөмләдәге сүзләрнең гадәти тәртиптән үзгә урнашулары инверсия дип атала. Ул җөмләдәге аерым сүзгә ныграк басым ясау өчен кулланыла, үзенчәлекле аһәң тудыра.

«Сагыну» нәсерендә түбәндәге инверсияләрне күзәтергә мөмкин: «...мин чит илдә әсир булып түгел, җиңүче булып йөрим. Миңа һәр йортның капкасы, һәр өйнең ишеге ачык. Ләкин берсенә дә керәсем килми минем...

Чит илдә йөреп, мин ачык аңладым: ...кеше өчен үз иленнән дә изгерәк, үз иленнән дә кадерлерәк, үз иленнән дә гүзәлрәк ил дөньяда юк ул».

## «САГЫНУ» НӘСЕРЕ ТУРЫНДА

Нәсернең интонациясе үзенчәлекле, ул эчке тавышка, хисләр агышына корылган, лирик-публицистик тонга нигезләнгән. Аның үз көе, үз яңгырашы, үз ритмы бар.

Г. Кутуй бу жанрны яратып, аның хасиятләрен белеп яза. «Сагыну» нәсере шулкадәр җыйнак, шулкадәр төзек ки, аның бер генә урынын кыскартып та яисә өстәп тә булмас кебек.

Нәсернең үзеннән сагыну хисе ташып тора. Аның исеме дә «Сагыну» бит. Сагыну — кешенең иң татлы, иң ләззәтле, иң газаплы тирән хисе. Ана баласын сагына, егет сөйгәнен сагына, солдат туган җирен, әтиәнисен сагына. Сагынуның аянычлы кичереш икәнен халык үзенең җырларында да көйләгән:

Әҗәлгә дәва бар диләр,
Сагынуларга бар микән?!

Нәни Габдулланың үпкә катыш әнисен өзелеп сагынуын, онытылмас йөрәк ярасын Сибгат Хәким «Шагыйрьнең бала чагы» поэмасында гел кабатлап бара:

Әнием!
Кунак булып тиздән кайтырсың дип,
Юкка гына суырып үпкәнсең...

Нәкъ менә Кутуйның «Сагыну» нәсереннән сугышып арган солдатның ярсулы тавышы ишетелгән сыман була:

— Сагындым, бик сагындым сине, изге туган ил!

Чөнки аның сагыныр кешеләре бар, туган җирендә иркенәеп аккан мул сулы елгалары бар, ниһаять, бай яшел болыннары, саф һавалы калын, кара урманнары бар. Нечкә билле гүзәлләр, күтеп арган гөнаһсыз сабыйлар, кайгы эчкән аналар сагынуы эчтәлекне тирәнәйтәләр, солдат йөрәген җилкетәләр. Шуңа күрә Гадел Кутуй туган ил сүзенә эндәшне көчәйтә, сагыну хисе бөтен нәсерне чолгап ала.

Лирик герой — Ватанын немец фашизмыннан азат итүче солдат, халык улы. Аның кичерешләре, моңнары, яктылык теләгән күңеле, җирсегән уйлары, һаман да ышанып көткән өмете нәсернең эчтәлеген тәшкил итә.

Кутуй үзе дә сугыш кырларында ятып калды. Аның «Сагыну» нәсере — Ватан солдатына язма һәйкәл, ул — һәр солдатның бердәм йөрәк хисе.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Нәсернең интонациясе хикәя интонациясеннән кайсы ягы белән аерыла? Нәсер интонациясе турында ниләр әйтә алырсыз? Тексттан мисаллар китереп ачыклагыз.
2. Өндәү җөмләләр нәсердә нинди роль уйный? Тавышка игътибар итегез, аларны дөрес тон белән укыгыз.
3. Лирик геройның хис-кичерешләре сезгә ничек тәэсир итте? Туган ил образы ни рәвешле сурәтләнә?
4. Сагыну кешедә кайчан туа? Сагыну хисен характерлагыз.
5. Халык җыры әсәрнең эчтәлегендә нинди урын тота?
6. «Сагыну» нәсерендә сурәтләү чараларын билгеләгез. Аларның әһәмияте нидән гыйбарәт?
7. «Без мәйданга керәбез» дигән абзацтан ахыргача ятлагыз.

## РӨСТӘМ МАҖАРАЛАРЫ

(*Кыскартып алынды*)

### ЮГАЛУ

Бу озын хикәядә тасвир ителәчәк искиткеч вакыйгаларның төп каһарманы Рөстәм Асадуллинга 1942 елның язында унөч яшь тә тулмаган иде әле. Аның кинәт югалуы әтисе — химия укытучысы Һашим абыйны да, әнисе — география укытучысы Гайшә апаны да тирән кайгыга төшерде.

Рөстәм, гадәттәгечә, иртә белән дәрескә чыгып китте һәм шул китүеннән кайтмады. Әбисе, аны көтеп, ашсу әзерләде. Сәгать арты сәгать узды, ә Рөстәм һаман күренмәде дә күренмәде. Моңарчы, рөхсәт сорамыйча, һичбер кая китеп йөрмәгән акыллы баланың болай озак кайтмый торуы әбине бик тә борчыды. Ул телефон аша улы Һашимга шалтыратты.

— Һашим улым, Рөстәм юк ич,— диде ул.

— Ничек юк?

— Ни дип әйтергә дә белмим инде, улым. Сәгать 4 не сукты, ә Рөстәм...

— Юкка борчылма, әнкәй, кайтыр... Берәр түгәрәк утырышында калгандыр...

Һашим абый әнисен әнә шулай тынычландырды. Ләкин үзе шул ук минутта Рөстәм укый торган мәктәпкә шалтыратты. Директор аңа Рөстәмнең бүген дәрестә бөтенләй булмавын әйтте.

— Аңламыйм,— дип карады ата,— аның бит бер генә тапкыр да дәрес калдырганы юк иде...

— Әйе шул,— диде директор,— үзебез дә шуңа гаҗәпләнәбез. Рөстәм Асадуллин безнең иң яхшы, иң тәртипле укучыларыбыздан санала. Сырхаулады, күрәсең, дип уйладык.

Директорның борчулы сүзләр әйтүе Һашим абыйны чын-чынлап пошындырды. Ул, үз-үзен алдарга тырышып, Рөстәм өйдәдер инде дип уйлады. Шулай да өйгә кайтышлый милиция бүлекләренә һәм ашыгыч ярдәм күрсәтү пунктларына керде. Ләкин Рөстәм турында бертөрле дә хәбәр ала алмады. Ашыгыч ярдәм пунктыннан чыгып китәргә торганда гына, кемдер берәү телефон шалтыратты. Телефон трубкасын куйганнан соң, врач шоферга:

— Трамвай астында бала калган, киттек! — дип кычкырды.

Һашим абыйның йөрәге жу итте. Аның күз алдына кан эчендә сыкрап яткан Рөстәм килеп басты.

— Зинһар, мине дә алып барыгыз! — дип, врачка ялварды.— Ул — Рөстәмдер... Үтенәм!

Ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасы бик кызу барса да, Һашим абыйга ул акрын бара кебек тоелды. Ниһаять, алар Тукай урамына килеп җиттеләр. Һашим абый, җыелган халык төркемен ера-ера, яраланган бала янына йөгерде. Әмма бер кулы яньчелгән бала Рөстәм булып чыкмады. Һашим абый врачка булышты да, авыр уйларга чумып, өйгә юнәлде.

Бердәнбер улының кинәт юкка чыгуын кич белән Гайшә апа да белде. Ул, күз яшен агызып, күршеләргә йөгерде, мәктәпкә чапты, Рөстәмнең дус-ишләренә барып кайтты, ләкин хәсрәтле ана «юк», «белмим», «күрмәдем» сүзләреннән башка сүз ишетмәде.

Төн тынычсыз узды. Ана, шылт иткән саен, ишеккә йөгерде, улым менә хәзер кайтыр инде дип, тәрәзәдән күзләрен алмады. Ата, Рөстәм югала торган бала түгел, кайтыр дип, хатынын һәм әнисен тынычландырырга тырышты. Гайшә апа: «Ни булды минем алтыныма? Үзе кайтып керерме? Әллә, менә улыгыз дип, аның үле гәүдәсен күтәреп керерләрме? Нишләргә? Кайдан эзләргә үзен?»—дип, төне буе газапланды. Әле ары чапты, әле телефон шалтыратты.

Рөстәм беренче көнне дә, икенче көнне дә кайтмады. Аның югалуы турында газеталарда белдерүләр басылды, радио аша хәбәр бирелде. Рөстәмне табучыларга яки аның кайда икәнлеген әйтүчеләргә кыйммәтле бүләкләр, кайнар рәхмәтләр ышандырылды. Әмма юкка гына: Рөстәм үзе дә, аның турында куанычлы хәбәр алып килүче дә булмады.

Әйтергә генә ансат: күз алдында йөгереп йөргән бала кинәт, көпә-көндез, суга чумгандай юкка чыксын, имеш. Телләре кычыткан гайбәтче хатыннар бу турыда кеше ышанмаслык хәбәрләр дә таратып өлгергәннәр иде инде.

## ӘБИ ӘКИЯТЕ

Моннан берничә ай элек, кышкы салкын көннәрнең берсендә, Казанга Рөстәмнең әбисе килде. Аның килүен Рөстәм түземсезләнеп көтте. Кадерле кунакның кайчан килергә җыенуын ишеткәч тә, Рөстәм календарьда билге ясап куйды. Һәм көн саен иртә белән:

— Тагын биш кенә көн калды, тагын дүрт кенә көн калды!—дип әйтә торды.

Әби календарьда билгеләнгән вакыттан бер көн элек килде. Рөстәм моңа шатланды. Әбисен ул каршы чы-

гып алырга теләгән иде. Ә әби Рөстәм югында, Рөстәм кинода чакта килеп төште.

Әби аңа ап-ак җылы оеклар, ап-ак җылы киез итекләр, куян тиресеннән тегелгән ап-ак бүрек, ап-ак бияләйләр һәм бик күп итеп чикләвек алып килгән иде.

Шәфкатьле әбисен Рөстәм элек-элек тә күргән иде. Үткән елны ул бөтен җәйне аның белән бергә авылда уздырды. Ләкин ул чакта әби дә, Рөстәм үзе дә әллә ничек бер-берсен аңламыйлар, сөйләргә сүз тапмыйлар иде. Ә хәзер... хәзер бөтенләй башка... Рөстәм дәресләрен әзерләп бетерүгә, әби аңа һәр кич төрле-төрле көйләр җырлап җибәрә. Рөстәм башта әбинең җырлау рәвешен генә ярата иде, хәзер, ияләшкәч, аның көйләрен дә ярата. Моңлы итеп җырлый ул!

Шундый күңелле әбиеңне ничек яратмыйсың, ди. Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Ашка яки чәйгә утырганда, Гайшә апа беренче тәлинкәне, беренче чынаякны балага куя иде.

— Әбигә, әүвәл әбигә! — дип кычкыра башлады Рөстәм.

Ярата, бик ярата Рөстәм аны! Хәтта ул мәктәп буфетыннан алынган конфет, пәрәнникләрдән дә аңа өлеш чыгара. Ә экиятләре ни тора әбинең! Нинди матур сөйли ул аларны... Тыңлап туйгысыз! Андый экиятләрне Рөстәмнең китапларда да укыганы юк әле.

Кышкы кичләрнең берсе иде. Гайшә апа белән Һашим абый театрга спектакль карарга киттеләр. Өйдә Рөстәм белән әби генә калдылар. Шул кичне Рөстәм яңа экият тыңлады. Әби аны бик тәмләп, бик озын итеп сөйләде. Аның кыскача эчтәлеге менә болай иде.

— Абага — карап торырга гап-гади үсемлек. Исе дисәң — хуш исе юк, яфрагы дисәң — яфрагы да әллә ни түгел. Ләкин шул абаганың искиткеч бер хикмәте бар. Абага чәчәк атмый, диләр. Ялганлыйлар! Ата икән. Мең вә миллион абагалар арасында бер абага очрый, ди, менә шушы күп абагалардан сирәк очрый торганы яз көне, җиде төн уртасында, ике-өч секундка чәчәк ата,

ди. Ул чәчәк атканда, яшен яшьни, күк күкри, җен-пәриләр чыга, кара урман яктыра, ди. Бу вакыт абага шундый матур була, ди, аның йолдызлардай атып торган чәчәкләреннән күзләр чагыла, ди, аннан таралган хуш истән башлар әйләнә, ди.

Абага чәчәген өзеп, телләре астына кыстырырга өлгергән кешеләр кеше күзенә күренмәс хәлгә киләләр, ди. Дөньяда тереклек булганнан бирле, тылсымлы абага чәчәген өзеп, кеше күзенә күренмичә йөрергә теләүчеләр бихисап күп булган, ди. Ләкин андый абаганы табуы кыен икән. Кайберәүләр, илдән илгә йөреп, бөтен гомерләрен әнә шундый абаганы эзләп уздырганнар. Әмма юкка: йә таба алмаганнар, йә аның чәчәк аткан вакытына туры килмәгәннәр, йә чәчәк аткан чакта яшен яшьнәүдән, күк күкрәүдән, җен-пәриләрдән куркып, яктылык нурлары сугудан үлгәннәр.

Менә шуннан соң кешеләр абагадан ваз кичкәннәр, абага чәчәк атмый дип йөри башлаганнар. Әмма ул чәчәк ата икән. Бары тик аның ату вакытын туры китерерлек бәхетле, аның чәчәген курыкмыйча өзә алырлык батыр йөрәкле кеше генә юк дисәм, хата булыр... Борын-борын заманда андый бәхетле, андый гайрәтле бер кеше булган икән, ди. Ул бихисап вакыт кеше күзенә күренмичә йөргән, ди...

Эх, менә хәзер булсын иде ул кеше! Адәм ашаучы фашистларны берәм-берәм тотып ярсын иде ул кеше.

Шуннан соң әби Рөстәмгә абага чәчәген өзә алган батыр турында әкият сөйләде. Ай арты ай узды, әби авылга кайтып китте. Ә абага турындагы әкияте, мәңге онытылмаслык булып, Рөстәмнең хәтерендә калды.

## ЯЗ ҖИТКӘЧ

Абага турындагы әкият Рөстәмнең холкын да, тормышын да бөтенләй үзгәртеп җибәрде. Әкият аңа шулчаклы нык тәэсир итте ки, ул гел шул хакта гына уйлап йөри башлады. Аның абага чәчәген өзеп алырлык

батыр буласы килде. Ул элек тә күп укый иде, хәзер исә китапка тагын да ныграк ябышты. Көтепханәгә китаплар алмаштырырга барса, аның үтенеп сораганы бер генә булды: батырлар турындагы, табигать турындагы китап. Калын-калын романнарны укып чыкты ул. Робинзоннар, юлбарыс тиресе кигән витязьлар, үз йөрәген факел иткән Данколар, Әбүгалисиналар, диңгез асларында йөзгән капитаннар, айга очкан инженерлар, кеше күзенә күренмичә йөргән химиклар турында нинди генә романнар укымады ул. Ләкин мавҗаралары белән баш әйләндергән иң кызыклы китаплар да абаганы истән чыгара алмадылар. Киресенчә, яхшы әсәр укылган саен, абага тагын да тирәнрәк, тагын да көчлерәк дулкынландырды аны. Хәтта төшенә дә керә башлады ул. Абага чәчәге турында хыялланып йөри-йөри, Рөстәм үзен фронтта, сугыш мәйданында итеп хис кылды һәм язны көтте.

## СИХЕРЛЕ ЧӘЧӘКЛӘР

Ул уянганда, кич якынлашкан иде инде. Уяну белән, тәнендә ниндидер бер татлы рәхәтлек сизде. Кулларын-аякларын сузып, тәмләп киерелгән иде — дөп итеп җиргә төште. Имгәнү-фәлән булмады, шулай да бераз җайсыз төште булса кирәк, чишмә янына чатанлап барды. Салкын су йокыны таратты. Ашыйсы килеп китте. Аз-азлап кимерә-кимерә, актык сохарилар да юкка чыктылар.

Урман акрынлап караңгылыкка чумды. Бу вакыт Рөстәм абагалар янында иде инде. Әбисе аңа абага җиде төн уртасында чәчәк ата дигән иде. Яз көне, төннәр кыска чакта, җиде төн уртасы кайвакыт була икән? Теләсә кайчан булсын — барыбер түгелмени. Бу төнне Рөстәм йоклау түгел, күзләрен дә йоммаячак.

Шулай уйланып утырганда, тәнгә салкынча җил бәрде. Кайдадыр күктә каргалар чарылдады. Каты итеп күк күкрәде. Яшьнәп, кара урман аша яп-якты тасма

сызылып үтте. Ояларына ашыккан җәнлекләр чинавы ишетелде. Төнге янгын вакытында була торгандай ал яктылык җәелде.

Рөстәмне курку алды. Әмма аның куркуы кызыксыну, хәйран калу белән катнаш иде. Шуңа күрә урманнан качу, кая булса да югалып тору Рөстәмнең башына да кермәде. Моңарчы һичкайда күрмәгән, ишетмәгән дәһшәтле гүзәллекне татудан туган хис иде бу. Агач яфраклары һәм үсемлекләр, алтынга манчылгандай, ялтырап яна башладылар. Бөтен әйләнә-тирә иснәп туйгысыз хуш ис белән тулды. Бер сүнеп, бер кабынып торган яшен яктысы күзләрне чагылдырды. Рөстәмнең күзләре дүрт булды: ул берничә абагада нәфис бриллиант кашларыдай җем-җем итеп торган чәчәкләр күрде. Күз ачып, күз йомганчы, алар шундый үстеләр, чәчәктән яуган нурлар яктылыгында үлән арасына төшкән кечкенә генә инәне дә табарга мөмкин иде. Рөстәм бу тылсымлы чәчәкләрне ашыга-ашыга өзәргә тотынды. Аңарда комсызлык туды: тел астына гына кыстыру түгел, ул аларны, учлап-учлап, авызына тутырды һәм чәйнәми-нитми йота барды. Хәер, чәйнәргә кирәк тә түгел иде, чәчәкләр авызга эләгү белән, пешеп өлгергән җиләктәй эределәр һәм үзләреннән-үзләре югала бардылар.

Шуннан соң нәрсә булганын Рөстәм хәтерләми. Аның башы әйләнде: ул, хәлдән таеп, җиргә егылды.

## КЕМ ҪОРЫЙ?

Рөстәм белми калды: төн буе яңгыр яуды. Ләкин яңгырның да, яшен яшьнәүләрнең дә һичбер бәйләнешләре юк иде. Абага чәчәкләренең тәэсире ашказаны аша Рөстәмнең бөтен тәненә таралды, яшь тәнгә үзгәреш кертеп, аны изрәтте, йокыга талдырды. Рөстәм бер тәүлектән артыграк йоклады. Уяну белән, ул үзен шундый рәхәт, шундый җиңеләеп киткәндәй хис итте ки, урманнан ничек чыкканын да сизми калды. Ләкин

күтәренке кәеф озакка бармады. Инде өйгә ничек кайтып керергә? Тамак ач, өс-баш чыланган...

Бу вакыт Рөстәм трамвайлар туктала торган урынга килеп җиткән иде инде. Җәяү байтак киленде, килә-килә өс-башы да кибәргә өлгерде. Почмакта портфельле бер иптәш басып тора иде. Рөстәм аның янына килде һәм:

— Абый, сәгать ничә? — дип сорады.

Рөстәмнең соравы портфельле иптәшне сискәндереп җибәрде. Ул як-якка борылып карады, күзләрен уды, кул сәгатенә күз салды һәм сөйләнә-сөйләнә китеп барды: «Сәгать сигез... Ә кем сорый — белмим... Колагыма шулай чагылды, күрәсең...»

Рөстәм шатлыгыннан нишләргә белмәде. Сикерәсе, биисе килде. Димәк, әби ялганламаган, хыял чынга әйләнде. Димәк, Рөстәм, чынлап та, күзгә күренмәс кеше булды. Мөгаен шулай микән, теге иптәш сукыр түгел идеме дип, Рөстәм, трамвай вагонына асылынган ике малай янына йөгереп барып, дәүрәк күренгәненең борынына чиертте. Чиертү яхшы ук каты булды, күрәсең, малай:

— Нишләп син, Кылый, тик торганда борынга чиертәсең? Кутырым барын оныттыңмыни? — дип, юлдашына акырды һәм чалт иттереп аның яңагына сукты. Рөстәмгә бу кызык тоелды. Башланган кыйнашта ул әтәчләнгән шук малайны җиңәргә булышты. Борын эчендәге кутырны шакшылыктан күреп, янә бер тапкыр авырткан борынга чиертте.

Димәк, дөрес! Малайлар да аның күренмәс кеше булуын расладылар.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әби сөйләгән әкият Рөстәмгә ничек тәэсир итә?
2. Малай ни өчен көрәшкә омтыла? Аның максаты нидән гыйбарәт?
3. Әсәрдән диалогларны табып укыгыз, аларның эчтәлеген сөйләгез.
4. Абага үсемлеген күргәнегез бармы? Аның рәсемен ясагыз. Ничек уйлыйсыз: абага чәчәк атамы?

## ПАРТИЗАННАР ЯНЫНДА

Рөстәм килеп кушылган партизаннар отряды илле-алтмыш кешедән гыйбарәт һәм, фронттан шактый еракта торып, бары тик зур эшләр буенча гына хәрәкәт итә иде. Ул күперләр вата, эшелоннар шартлата һәм юлларны миналаштыра, дошман гаскәрләренең хәрәкәтен өйрәнә һәм, мөһим үзгәрешләр булганда, — шул турыда Кызыл Армия командованиесенә хәбәр бирә. Отряд, Женялар мәгарәсе шикелле үк, кеше аягы басмаслык җирдә һәм белмәгән кешегә килеп йөрүе кыен һәм куркыныч тоелган ике тау арасында урнашкан.

Партизаннар арасында элекке укымышлылар да бар: директорлар, гыйльми эшчеләр һәм укытучылар. Бу нәрсә аларның тормышларында да сизелә. Отряд взводларга бүленгән, һәр взводның нык эшләнгән һәм җыйнак блиндаж-йорты бар, йортлар арасында телефон уздырылган.

Рөстәм баштагы ике көнне танышып, кунак булып йөрде. Отряд мул яши иде, аның хәтта үз көтүе дә бар. Ләкин безнең каһарманыбыз, кухнядан бигрәк, «Дядя эфир» дип аталган партизан Иван Владимирович блиндажын яратты. Беренчедән, бүтән блиндажларга караганда, аның блиндажында иркен; икенчедән, монда радио бар. Элекке урта мәктәп директоры — Иван Владимирович — бүгенге көнне партизан «Дядя эфир» отрядның радисты да, аяк киеме тегүчесе дә һәм кирәк чакта пулемётчысы да икән...

Рөстәм иртә-кич радио тыңлады һәм шунда ук бүтән партизаннар белән дә танышты.

Отряд начальнигын күргәч, Рөстәм аның команда пункты дип аталган блиндажына күчте. Начальникны монда «Батя» дип йөриләр, мин, телебезчә булсын өчен, «Атакай» дип алам. Элек ул партиянең район комитеты секретаре булып эшләгән һәм, немецлар килә башлагач, әлеге отрядны оештырып, урманда калган.

Рөстәм «Атакай»ның йөзенә карады һәм анда үз этисе йөзенә охшаш сызыклар тапты: аның кебек үк озын буйлы, ачык шат йөзле, хәтта каләм очлаганда яки берәр нәрсә язганда, тел очын чыгарып күрсәтү гадәтләре дә бар, һәм кара күзләре дә, авыр сорауга җавап биргәндә, этисе күзләре кебек үк, аз гына кысылып куялар. Бу, бәлки, Рөстәмгә генә шулай тоелгандыр. Бәлки, ул күрәсе килгән этисен күңеленә ятышлы кешегә охшатырга теләгәндер.

Рөстәм команда пунктына килеп кергәндә, «Атакай», взвод командирларын җыеп, эш бүлә иде. Һәрбер командир, исеме чыккан саен, Кызыл Армиядәгечә, аягүрә торып басты һәм эш-задание тыңлап беткәннән соң: «Есть!» — дип җавап кайтарды. Беренче взводка «тел» табу тапшырылды.

— Ләкин гади «тел» түгел,— дип аңлатты «Атакай»,— безгә штабта эшләгән яки штаб тирәсендә әйләнгән, командование планнары белән таныш булган офицер дәрәҗәсендәге «тел» кирәк.

Икенче взводка тимер юлга разведка ясау, поездларның килү-китү вакытларын өйрәнү һәм миналар кую урынын тәгәлләү эше йөкләнде. Өченче взвод сул як шоссе юлындагы күперне шартлатырга тиеш иде.

Рөстәмгә болар һәммәсе дә кызык тоелдылар. Әгәр өчкә ярылырга мөмкин булса иде, ул өч взводның өчесе белән дә барыр иде. Дошман штабына кереп, менә дигән «тел» дә табар иде, ярдәмгә взвод хәтле взвод булганда, офицер түгел, хәтта полковникны да өстерәп китерер иде, тимер юлы разведкасы белән дә чыгар иде, күпер шартлату эшенә дә катнашыр иде.

Киңәшмә таралганда, Рөстәм кемнәр белән бару мәсьәләсен хәл кылмаган иде әле. Аңа «Тиктормас» кушаматы алган тәбәнәк буйлы, ләкин гаять тере яшь партизан очрады. Ул кая барса, мин дә шунда дип уйлады Рөстәм һәм аның белән бергә барырга булды.

Ләкин «Тиктормас» икенче взвод сугышчысы булып чыкты, ә икенче взводка тимер юлына бару эше

тапшырылган иде. Рөстәм борынын салындырды. Ул тынгысыз «Тиктормас» батыр мондый вак эшкә бармас, күпер шартлатырга барыр дип көткән иде. Шулай да биргән сүзеннән кайтмады.

Операциягә алар өчәү чыктылар — Рөстәм, «Тиктормас» һәм Тимофей Николаевич исемле тагын бер партизан. Партизаннар, отрядның кайда урнашуын дошманга сиздермәс өчен, операциягә караңгыда чыгып китәргә һәм караңгыда кайтып керергә тиешләр иде. Отрядта шундый тәртип куелган иде. Рөстәмнәр дә урманнан төнлә белән чыктылар.

Таң атканда инде алар, тимер юлы тирәсендәге куаклыкка барып җитеп, күзәтергә уңай табылган җиргә посканнар иде.

Разведчиклар иң элек бер ярты сәгать чамасы әйләнә-тирәне өйрәнделәр, күзгә чагылган һәрбер әйберне билгегә алдылар һәм, берьюлы икәү күз талдырмас өчен, нәүбәтләшеп-нәүбәтләшеп күзәтергә булдылар. Хәзер «Тиктормас» ял итеп алырга, ә Тимофей Николаевич күзәтергә тиеш иде. Ләкин «Тиктормас» урын җайлап ятса да, тынычлык саклый алмады: әле бер ягына, әле икенче ягына борылды һәм еракта күренгән станциягә күз текәп пышылдарга тотынды:

— Мин инде хәзер, институтны бетереп, мәктәптә укытыр идем. Балалар укытудан да изге нәрсә юк дип беләм мин. Синеңчә ничек, Тимофей Николаевич?

— Син нәрсә монда эчемне пошырып хыял итәргә килдеңме, әллә разведкагамы? Йә үзең йокла, йә миңа хәл җыярга бир.

— Йокла, йокла, кешенең ярты гомере йоклап уза, сиңа шул да аз, күрәсең... Сугыш бетте дисәләр, син нишләр идең, Тимофей Николаевич, ә? Мөгаен, бер атнага йокларга ятар идең...

— Туктыйсыңмы, юкмы?—Тимофей Николаевич учлары белән колакларын каплады, ләкин үзе сорау биргәнне сизми дә калды: — Ә син нишләр идең?

— Минме?— Мин,— диде «Тиктормас»,— бер атна буена йокламас идем, өйдәгеләргә дә йокы бирмәс идем, әти-әнием белән, сеңлем белән гел сөйләшеп кенә утырыр идем. Минем Эся, Эсенька исемле сеңлем бар, миннән ул алты яшьтә калды, быел мәктәпкә барырга тиеш иде. Беләсеңме, Тимофей Николаевич, алты яшьлек Эсенька, сугыш башланганны ишеткәч: «Кирәкми, сугыш кирәкми!» — дип илереп еларга керешге. Әле дә күз алдымда тора. Эх, исән булса, сугыштан соң мин аны уч өстендә йөртер идем...

Тимофей Николаевич ни өчендер борынын тартты һәм инәлде:

— Сөйләнмә, йөрәкне әрнетәсең... Минем балаларым бар. Сөйләшмичә генә искә төшерик...

Рөстәм дә өен сагынды, әти-әнисен, мәктәбен һәм укытучыларын күргән кебек булды. Үзен дәрескә баргандай хис итте. Быел ул җиденче класста булыр иде инде.

Ул, эче пошып, яткан урыныннан торды һәм аз гына йөреп кайту уе белән тимер юлга таба китте, анда барып җиткәч, шпалдан шпалга сикерде, шулай уйный-уйный станциягә якынлашты. Стрелочник будкасы очрады. Будка янында күкрәгенә автомат аскан немец солдаты басып тора иде. Рөстәм аңа тимәде, ләкин түзә алмады — битенә төкереп узды.

Менә станция. Биналар кайсы ишелгән, кайсы янган. Рөстәм тирәли сакчылар йөреп торган составларны карап чыкты, анда төялгән туп, танкларны санады һәм куен дәфтәренә ниләрдер язып куйды. Аннары блиндаж сыман подвалга керде. Бу станция комендантының куышы икән.

Рөстәм килеп кергәндә, немец коменданты, алдында яткан дәфтәргә карап, телефон аша сөйләшә иде. Сүз 1431 номерлы эшелонның кайчан килүе турында бара иде. Рөстәм үз дәфтәренә комендант дәфтәреннән күчермәләр ясады, бу станциядән узарга тиешле составларның номерларын язып алды.

Аннары ул икенче бер бинага керде һәм анда немец телеграфистының аппарат янында, бармак басып, нидер тыкылдатып утыруын күрде. Аның янына килеп карап торды. Түзмәде — телеграфистның аппарат өстендәге бармагына басты. Гомерендә беренче тапкыр очраган бу хәлгә телеграфист аптырап калды. Рөстәм тагын басты, тагын алды, тагын басты... Немец, күзләрен акайтып, як-ягына карады, бармакларын аппараттан алган иде, аппарат, колакка ят ишетелгән нокталар һәм сызыклар ясап, «тек, тек, тек, тик, тик» тыкылдый бирде. Рөстәм куркынган телеграфистның алдына: «Гомерең кыска синең. Шуны беләсеңме, юкмы? Моны сиңа мин — партизан Расад әйтәм»,— дигән язу куеп чыгып китте.

Чокырлы-чакырлы перронда ул стенага кадакланган немец газетасын күрде. Кайбер мәкаләләрне укып көлде һәм асларына «ялган», «ялган» дип язып куйды. Ишек янында кыңгырау-колокол асылынып тора иде. Нишләргә белмәгән Рөстәм берөзлексез шуны сугарга тотынды. Тавышка халык җыела башлады. Ул да булмады, Рөстәм, күзенә чалынган паровозга йөгереп менде һәм, этисе алып кайткан уенчык паровозны хәтерләп, бертуктаусыз сызгыртырга керәште. Машинист: «Бу ни хәл?» — дип, сызгыртуны туктатты һәм ишек янына килеп басты. Рөстәм бөтен көченә аны түбәнгә этеп җибәрде һәм яңадан сызгырта башлады. Ләкин ул моның белән генә калмады, ни булса шул булыр дип, рычагларның берсенә басты, паровоз, көрсенеп куеп, урыныннан кузгалды, ә Рөстәм сикереп төште. Бу вакыт:

— Тукта, кая барасың? Ник кузгалдың? — дип, паровозга таба станция начальнигы йөгереп килә иде инде: — Хәзер ашыгыч состав уза...

Рөстәм, бар инде хәзер туктатып кара дип, эчтән көлде дә, икенче якка, «Тиктормас»лар янына кайтып китте. Будкага килеп җитәрәк, ул поезд килгән тавыш ишетте, стрелка янында баягы немец солдатын күрде.

Поезд менә күренә дә башлады инде. Эшелон бу станциядә туктамаска тиеш иде, ләкин 5 минут үткәндерме-юкмы — Рөстәм бер составның икенче составка бәрелүен, зыңгылдаган металл, сынган агач тавышлары һәм ыңгырашулар ишетте.

Рөстәм, «Тиктормас»лар янына килеп, «Атакай»га хат язды, хатка станциядә ясаган күчермәләрне һәм бүтән мәгълүматларны кушты. Хатның ахырына: «Бүген мин монда кечкенә генә крушение ясадым. «Тиктормас» сөйләр»,— дип өстәде һәм партизан Расад дип имзасын кертте. Хатны «Тиктормас» янына куйды.

Икенче көнне станциягә безнең бомбардировщиклар очып килделәр һәм анда булган составларны бомбага тоттылар.

«Атакай» күпме генә тырышса да, Расад турында бертөрле дә мәгълүмат ала алмады. Аны күрергә, аның белән бәйләнеш тотарга ул үзенең кешеләрен дә җибәреп карады. «Тиктормас» хәтта район, шәһәргә дә барып кайтты. Кешеләр аңа:

— Ишеткәнебез бар, әмма күргәнебез юк,— диделәр.

— Үткән атнаны,— диде берәү,— немецлар сводка тапшырганда, кемдер берничә тапкыр: «Ышанмагыз, ялган бу»,— дип кычкырды. Шул Расад түгел иде микән?Немецлар бик эзлиләр, әмма ул тоттырмый, ди.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Сезгә Рөстәмнең нинди сыйфатлары ошый?
2. Тексттан фантастик элементларны искә төшерегез. Әсәрдә хыял белән чынлык ничек яраша?
3. Рөстәм үз хыялын ни рәвешле тормышка ашыра? Хыял турында ниләр беләсез?
4. Маҗаралы стиль турында фикер алышыгыз. Аның хыял белән бәйләнеше бармы?

**Мөстәкыйль эш.**

Маҗаралы (детектив) жанрда язылган нинди әсәрләр укыганыгыз бар? Үзара фикер алышыгыз.

# *Муса Җәлил*

## *(1906—1944)*

Муса Җәлил — немец фашистларына каршы батыр көрәше, ялкынлы шигъри әсәрләре — «Моабит дәфтәрләре» белән дөньяга танылган шагыйрь. Ул Ватан сугышына кадәр үк өлгергән язучы иде. Аның «Җиһан», «Хат ташучы» поэмаларын яратып укыйлар, «Җырым сиңа булсын», «Дулкыннар», «Сагыну», «Җир җиләгем», «Чишмә җыры» кебек лирик шигырьләренең күбесе җыр итеп җырлана.

Муса Мостафа улы 1906 елның 15 февралендә элекке Оренбург губернасы (хәзерге Оренбург өлкәсе Шарлык районы) Мостафа авылында крестьян гаиләсендә туган. Аның әтисе 1913 елдан вак сәүдә белән шөгыльләнеп карый, гаиләсе белән шәһәргә күчеп килә. Әмма көнкүрешен рәтли алмагач, кабат туган авылына әйләнеп кайта һәм 1919 елда вафат була.

«Мин башта авыл мәктәбендә, аннан, шәһәргә күчкәч, «Хөсәения» мәдрәсәсенең башлангыч классларында укыйм»[1],— дип искә ала Җәлил автобиографик язмасында. 1921 елда ачлык башлангач, ул тагын шәһәргә китеп бара, анда, базар малайларына ияреп, ике ай буе кайда туры килсә, шунда яши. Тик элекке укытучысы Нургали Надиев очрап кына аны бу бәладән коткара, Оренбург хәрби мәктәбенә укырга урнаштыра. Тик каты авырып китү сәбәпле, Муса аны тәмамлый алмыйча кала.

[1] *Җәлилов М.М.* Әсәрләр. 5 томда. 1 т.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 246 б.

Җәлилнең иҗат эше малай чагыннан ук башлана. Тәүге шигыре «Бәхет» (1919) «Кызыл йолдыз» газетасының беренче битләрендә үк басылып чыга. Бу — илебездә гражданнар сугышы еллары, нәни Җәлил туган халкының азат булып яшәвен тели.

1925—1927 еллар арасында ул Казанның татар рабфагын тәмамлый һәм, дәртләнеп, яшьләр белән эшләп китә, мәдәният эшләрен җайга сала. 1927—1933 елларда ул Мәскәү университетының әдәбият бүлеген уңышлы тәмамлап чыга, бер үк вакытта балалар журналларында («Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы») редактор була.

Җәлил туган халкының милли мәдәниятен үстерү өчен бик тырыша, Мәскәүдә оештырылган татар опера студиясе белән бергә ул Казанга кайта һәм анда әдәби бүлеккә җитәкчелек итә. «Алтынчәч» либреттосын яза, 1941 елда опера сәхнәгә куела, һәм тамашачы аны яратып кабул итә. Бу дәһшәтле сугышның беренче көннәре була. Озак та үтми, Җәлил дә фронтка китә.

Минзәләдә кыска сроклы политруклар курсын тәмамлагач, Җәлил Волхов фронтына җибәрелә, бу — иң хәтәр бөҗра, чөнки монда окоплар казып булмый, сугыш сазлыклар эчендә бара. Шагыйрь рус телендә чыга торган «Отвага» газетасының хәбәрчесе була. Әмма фашистларның һөҗүме көннән-көн көчәя. Шундый каты сугышларның берсендә Җәлил, авыр яраланып, 1942 елның 26 июнендә әсирлеккә эләгә. Фашист тоткынлыгында Җәлил аларга каршы көрәш башлый. Ул аларның ерткычлыгын утлы шигырьләре белән фаш итә. Шунысы бик мөһим: Җәлил шигырьләре әсир солдатларда ныклык һәм яшәү өмете уята. Шуңа күрә алар әсирләр арасында тиз тарала һәм, лагерьдан лагерьга күчеп, күңелдән ятлана. Җәлил үзенең ышанычлы иптәшләре: Гайнан Кормаш, Абдулла Алиш, Абдулла Баттал, Рушат Хисаметдиновлар белән бергә яшерен оешма төзи, аның җепләре фашистларның башка лагерьларына да сузыла. Җәлилчеләр поляк партизаннары белән дә элемтәгә керәләр. 1943 елның февралендә, фашистларның Көнчыгыш фронтына җибәрелгән легиончылардан торган беренче батальон, немец офицерларын кырып, белорус партизаннары ягына чыга. Бу әлеге яшерен оешма эше була.

Җәлил 8 августта яшерен оешманың соңгы киңәшмәсен үткәрә. 14 августта инде бөтен лагерьларда

восстание күтәрелергә тиеш була[1]. Әмма сатлык җан аркасында бөтен эш җимерелә, кулга алулар, җәзалаулар башлана. Көрәшче әсирләрне каты режимлы Шпандау, Моабит, Тегель кебек төрмәләргә ябалар. Иң соңгы җәза урыны — Плетцензее төрмәсе. Җәлил белән бергә 11 көрәшченең башы шунда киселә. Бу 1944 елның 25 августы була.

Җәлилнең кешеләргә карата ихлас мөнәсәбәте һәркемне үзенә җәлеп иткән, күрәсең. Шуңадыр, ахры, аны белгән һәр тоткын вөҗданы кушканча шагыйрьнең соңгы васыятен үтәргә тырышкан; «Моабит дәфтәрләре»нең илгә кайтуы шуны күрсәтеп тора бит.

Шагыйрь белән бер камерада утырган чит ил антифашистларының сүзләре гаҗәеп самими булулары белән сокландыра. «Моабит дәфтәрләре»н саклап, илчелеккә тапшырган Бельгия көрәшчесе Андре Тиммерманс Җәлил турында болай ди: «Мин кабатлап әйтәм, ул бик тыныч һәм бик батыр кеше иде, мин аны һәрвакыт ихтирам итә идем»[2].

Җәлил камерасына кереп йөргән, аңа үз китапханәсеннән Гёте китабын китергән рухани Юрытко сүзләре бик гыйбрәтле: «Акыллы, ягымлы, тәрбияле, зур укымышлы ул кеше, үлем көтеп торганын белгән хәлдә дә, үзен бик тыныч тотуы белән миндә гадәттән тыш әйбәт тәэсир калдырды»[3].

Туган халкы көрәшче улын беркайчан да онытмый. Җәлил һәм көрәштәшләренә куелган һәйкәл — азатлык яулаган батырларның гүзәл чагылышы ул.

### ҖЫРЛАРЫМ

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

---

[1] Муса Җәлил турында истәлекләр / Төз. Мостафин Р. Ә. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.— 241 б.

[2] Шунда ук. — 185 б.

[3] Шунда ук. — 247 б.

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мин кабыздым җырда ялкын итеп
Йөрәгем һәм хаклык кушканны.
Җырым белән дусны иркәләдем,
Җырым белән җиңдем дошманны.

Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның чуар пәрдәсе,
Шигъремдәге чынлык, ут һәм сөю —
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

Үлгәндә дә йөрәк тугры калыр
Шигъремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Җырлап үттем данлы көрәш кырын,
Җырлап килдем тормыш язына.
Соңгы җырым палач балтасына
Башны тоткан килеш языла.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

* * *

**Рифма** дип шигырь юлларының бер-берсенә аваздаш, охшаш иҗекләр белән тәмамлануын әйтәләр.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. «Җырларым» шигырен артист башкаруында тыңлагыз. Интонация, басым, шигъри ритмга һәм рифмага әһәмият бирегез. Мәгънәне дөрес әйтүдә шигырьнең форма элементлары нинди роль уйный?
2. Лирик геройның кичерешләре аша ниләр аңлыйсыз?
3. Ни өчен шагыйрь бу шигырен «Җырларым» дип атый? «Җырларым» нинди мәгънәви тирәнлеккә ия?

4. Шигырьдәге сурәтләү чараларын игътибар белән язып алыгыз. Аларның төрен билгеләгез.
5. Ни өчен шагыйрьнең җырга ышанычы зур? Җәлилнең үз тормышы «Җырларым»да ничек чагылыш тапкан?
6. Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
   Үлемем дә яңрар җыр булып.
   Әлеге шигырь юлларыннан нәрсә аңлыйсыз? Лирик герой кичерешләрендәге моң, сагыш һәм кыюлык турында ниләр әйтеп була? Уйланып карагыз.

**Мөстәкыйль эш.**

1. Шигырьдән мәкаль булып китәрлек юлларны табыгыз һәм дәфтәрегезгә күчереп язып фикер алышыгыз.
2. «Җырларым» шигырен яттан өйрәнегез.
3. Х. А. Якуповның «Хөкем алдыннан» картинасы буенча хикәя языгыз.

## КЫЗЫЛ РОМАШКА

Иртәнге таң нурыннан
Уянды ромашкалар.
Елмаеп, хәл сорашып,
Күзгә-күз караштылар.

Назлады җил аларны,
Тибрәтеп ак чукларын,
Таң сипте өсләренә
Хуш исле саф чыкларын.

Чәчкәләр, кәефләнеп,
Җай гына селкенделәр.
Һәм кинәт шунда гаҗәп
Бер яңа хәл күрделәр.

Ерак түгел моңаеп
Утыра ромашка кызы,
Тик чуклары ак түгел,
Кан шикелле кып-кызыл.

Ромашкалар бар да ак,
Аерылмый бер-береннән;
Ничек болай берүзе
Ул кызылдан киенгән?

Әйттеләр: «Син, сеңелкәй,
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нигә кызыл чукларың?
Нидән алсу төсләрең?»

Әйтте кызыл ромашка:
«Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.

Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.

Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик охшады Чулпанга.

Егет китте, мин калдым
Канын саклап чугымда,
Көн дә аны сагынып
Балкыйм мин таң нурында».

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шигырьнең эчтәлеген сөйләгез.
2. Ак ромашкалар арасында кызыл ромашканың үзенчәлеге нәрсәдә? Ни өчен шагыйрь кызыл ромашканы бизәп сурәтли?
3. Шигырьнең рифма, ритм һәм башка форма элементлары турында сөйләгез.
4. «Җырларым» белән «Кызыл ромашка»ның тематик якынлыгы нәрсәдә? Сезгә кайсы шигырь күбрәк ошады?
5. Көрәшче образының бирелешен ачыгыз. Шигырьнең үзенчәлекле чишелешен характерлап карагыз.
6. «Кызыл ромашка» шигыренең эчтәлеге буенча рәсем ясагыз, кемнеке уңышлы, шуны сыйныф почмагына яки музейга «Укучылар иҗаты» дигән бүлеккә куегыз.
7. Шигырь турында инсценировка язып, сәхнәдә уйнап карагыз. Сәхнәне ничек бизәр идегез?

## АНА БӘЙРӘМЕ

— Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Әйтсәгезче, зинһар, үз итеп,
Сагыш белән кипкән анага:
Кайда йөри минем улларым?
Ана күңеле тели белергә:
Кая илтә язмыш юлларын,
Җиңүгәме, әллә үлемгә?

Кѳньягыннан очып күгәрчен
Кайтып керде ана йортына.
— Син, күгәрчен, беләм күргәнсең;
Салма мине сагыш утына.
Сѳйлә дѳресен, кая зур улым?
Дѳньядамы бәгърем, күз нурым?
— Кайгы сиңа, ана, Кырымда,
Улың үлде сугыш кырында.

Катып калды ана, дәшмәде,
Ярсып чыкты кайнар яшьләре.
Кайгысыннан ѳлкән улының
Кѳмеш тѳсле булды чәчләре.

— Ѳч улымны, очар кош итеп,
Мин очырдым ерак далага.
Әйтсәгезче, якын дус итеп,
Кайгы белән сулган анага.

Кайталмады ѳйгә зур улым,
Сугышып үлде, бәгърем, күз нурым.
Уртанчысы, бәлки, исәндер,
Җил аңардан миңа исәдер?

Җил, уйнаклап, тәрәз тѳбендә
Нидер әйткән тѳсле кыланды.
— Әйтче, җилкәй, йѳргән җиреңдә
Күрмәдеңме минем улымны?

— Кайгы сиңа, ана, уртанчы
Улың үлде сугыш кырында.
Соңгы йѳрәк тибеше тынганчы
Алмаз кылычы булды кулында.

Ауды ана таеп һушыннан,
Парчаланган йѳрәк түзмәде.
Елый-елый улы сагышыннан
Сукырайды аның күзләре.

— Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым шомлы далага.
Әйтегезче, зинһар, үз итеп,
Хәсрәтеннән көйгән анага.

Ике улым үлде сугышта,
Бер өмитем калды тормышта:
Күрмәсәм дә бергә өчесен,
Мин күрермен, бәлки, кечесен?

Никтер очмый күктә күгәрчен,
Җил дә тынган, йоклый, күрәсең.
Тик яңратып урман буйларын,
Ишетелә быргы уйнавы.

Таң алдыннан ана уянды —
Җир тетрәткән тояк тавышына.
Тәрәзәгә килеп таянды,
Чик-чама юк аның сагышына.

Шыңгырдатып тавышын даганың
Бер ат килә, ярсый йөрәге.
Ат өстендә улы ананың,
Иң кечесе, өзелеп сөйгәне.

Күкрәгендә медаль алтынлы,
Кулларында җиңү байрагы.
Каршы ала котлап батырны
Таң нурлары, кошлар сайравы.

Күрмәсә дә, ана улкаен
Күңеле белән сизеп таныды.
— Балам! — диеп елап, ул аның
Күкрәгенә килеп сарылды.—

Кайттыңмы, улым, алтыным!
Куанычым минем, актыгым!
Карт ананың көмеш чәченә
Алтын яше тама батырның.

— Я, тынычлан, анам, борчылма,
Сиңа улың — синең актыгың
Алып кайтты алмаз кылычында
Ил саулыгын, җиңү шатлыгын.

Абыйларым канлы сугышта
Җиңү юлын сызып үлделәр.
Гомерләрен соңгы сулышта
Мәңге үлмәс данга төрделәр.

Калдырсам да күмеп еракта
Абыйларның батыр гәүдәсен,
Алып кайттым данлы байракта
Каннарының алсу шәүләсен...

Ана алды алсу байракны,
Күзен сөртте — күзе ачылды:
Каршысында тора гайрәтле,
Киң күкрәкле батыр лачыны.

— Өч баламны, очар кош итеп,
Мин очырдым иркен далага.
Сез килегез, якын дус итеп,
Күп кайгылар кичкән анага.

Күкрәк сөтем имезеп, тирбәтеп,
Мин өч лачын илгә үстердем.
Батыр көрәш җырын өйрәтеп,
Кошларымны кырга очырдым.

Ике улым кире кайтмады,
Кешнәп йөри кырда атлары,
Мин аларга бирдем канымны,
Алар аны ерак калдырды.

Изге Ватан өчен агызып,
Җиңү таңын җиргә кабызып
Алып кайтты илгә ул таңны,
Кече улым, батыр лачыным.

Ал медале аның путалы,
Куандырды анай карчыгын.
Һич үлмәгән төсле улларым,
Өем тулы кызлар, егетләр,
Туя алмыйм тыңлап җырларын,
Минем балаларым кебекләр.

Бер кайгырсам, ике шатланам,
Һәр тамчысы хәләл сөтемнең;
Илдә мәңге үлмәс ат белән
Үлә белгән уллар үстердем.

Сез килегез бу шат анага,
Аның бүген туган бәйрәме.
Агыла аңа картлар, балалар,
Өе тулы чәчәк бәйләме.

Ил шатлыгы белән төзелде
Йөрәгенең авыр ярасы.
Ил түрендә, гөлләр эчендә
Өч батырның туган анасы.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шигырьнең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше бармы? Ни өчен шагыйрь фольклорга мөрәҗәгать итә?
2. Ананың язмышын сурәтләгәндә, автор ни өчен *җил, күгәрчен, очар кош* кебек табигать образларын ала?
3. Җәлил шигырьләрендә фаҗига белән батырлык ничек яраша? Мисаллар китерегез.
4. Ана образы белән туган ил төшенчәсенең берлеге ничек сурәтләнә? Ана сагышы һәм ананың шатлыгы шигырьнең эчтәлеген кайсы яктан ача?
5. Диалоглар нинди роль уйный? Тексттан мисаллар китерегез.
6. *Сагыш белән кипкән ана; кайнар яшьләр; көмеш төсле чәчләр; шомлы дала; үлмәс дан; данлы байрак; алсу шәүлә; батыр лачын* тезмәләре нинди сурәтләү чараларына керә? Таблицага языгыз.

## *Фатих Кәрим*

***(1909—1945)***

Фатих Кәрим — Ватан сугышына үзе теләп киткән шагыйрьләрнең берсе. Аның поэзиясенең өлгереп җитүе дә сугыш чорына туры килә. Ул фронтта кайнар сугыш эчендә лирик шигырьләр һәм поэмалар иҗат итә. Ватан өчен авыр көрәш, туган җирне өзелеп сагыну хисләре аның поэтик әсәрләрендә чагылыш таба:

Идел буйларына тагын
Әйләнеп кайтсам иде.
Ал чәчәкләр арасында
Бер җырлап ятсам иде.

(*«Сагындым»*)

Бу — һәр солдатның уртак теләге, тормышка булган тирән мәхәббәте.

Ф. Кәрим фронтта сапёр, разведчик була. Һөҗүмгә баручы солдатларга алгы сафтан юл яра.

Фатих — табигать кочагында үскән шагыйрь. Яшьтән үк тирә-юньне күзәтүе, бай табигать белән берегеп яшәве аның поэзиясендә нык сизелә. Кеше белән табигатьне ул бербөтен итеп кабул итә.

Шагыйрь 1909 елның 9 гыйнварында Башкортстан Республикасының Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә туган. Фатих бик яшьли шигырь тыңларга, үзе дә язарга яраткан. «Әдәби әсәрләр язу теләге бала чагымнан ук йөрәгемә кереп урнашты»,—

дип яза ул. Сукыр әтисенең шигырьләре, апасы Мәрьямнең Дим буе табигатен тасвирлап язган шигъри әсәрләре аңа бик ошый. «Революция еллары башлангач, абыем Ярлы Кәримнең матбугатта чыгып барган шигырьләрен уку — болар минем әдәбият өлкәсенә таба юнәлеш ясавыма төп һәм башлангыч этәргеч булдылар»,— дип әйтүе аның тормыш юлын яктыртып җибәрә.

Ф. Кәримнең поэзиясе моң һәм хисләр агышыннан туа, укыган саен, җыр булып күңелгә керә, «Шомырт куагы», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Идел», «Сибәли дә сибәли» кебек лирик шигырьләрен укып туярлык түгел. Поэмаларыннан «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Идел егете» — бик тирән эчтәлекле әсәрләр; аларда моң да бар, яшәү өчен көрәшнең үтә киеренке мизгелендә ялтырап киткән кешенең ихтыяр көче сокландыра, әмма үлем фаҗигасе тетрәндерә, фашисттан үч алырга чакыра.

Ф. Кәрим җиңү көнен күрә алмады. Сугыш бетәр алдыннан, 1945 елның 19 февралендә, җаваплы сугышчан бурыч үтәгәндә һәлак булды. Балтыйк флотында хезмәт итүче яшь диңгезчеләр, аның каберен табып, мәрмәр такта куялар.

## ҮЛЕМ УЕНЫ

Сугышта үлем
Каршыңа килә,
Йоклап йөресәң,
Кычкырып көлә.

Кайчак бу үлем
Батырларны да
Бугазлап ташлый
Сугыш кырында.

Менә Сөләйман
Снайпер иде,
Исеме һәркайда
Макталып йөрде.

Орден алды ул
Төз аткан өчен,
Өч йөз фашистны
Озаткан өчен.

Беркөн Сөләйман...
Үлде үзе дә...
Үлсә дә үлде,
Торды сүзендә.

Торды сүзендә,
Ул сынатмады,
Бер ядрәсен дә
Бушка атмады.

Сугышта була
Батыр үлеме,
Дулкынландыра
Сизгер күңелне.

Авыр булды бик
Ул үлгән кичне,
Йөрәкне кысты
Үч алу көче.

Менә кабере,
Кабердә — тынлык,
Кабер өстендә —
Кадерле мылтык.

Кадерле мылтык
Гөлгә күмелгән,
Сөләйман аны
Кочаклап үлгән.

Бу яңа кабер —
Каен астында.
Каен янына
Майор басты да

Сөйләде янып,
Йөрәкне өзде,
Хәтта үзенең
Яшьләнде күзе.

Сулаудан тынды
Бар сугышчылар;
Хыяллар гына
Ерак очтылар;

Очтылар ерак,
Уктай омтылып,
Үчле ачуның
Яшене булып.

Бу үч яшене
Бервакыт сүнмәс,
Аның көченә
Бер фашист түзмәс!

Кабер кырына
Майор тезләнде,
Коңгырт күзләре
Кемне эзләде?

«Кил, Әхтәм, диде,
Кабер янына!»
Башлар борылды
Әхтәм ягына.

Мондый вакытта
Уйчан буласың...
Уйчан бер малай
Зурларча басып

Килде тын гына,—
Пилотка кигән,
Шинель итәге
Җиргә үк тигән;

Билендә каеш,
Бик кысып буган,
Патрон сумкасын
Алга ук куйган;

Юка иренле,
Ак һәм вак теше,
Күзе очкынлы...
Усалга охшый!

Гомумән, малай
Кечкенә буйлы,
Бу Әхтәм инде —
Партизан улы.

Әтисе хәзер,
Белмим, кайларда.
Хат-хәбәре юк
Соңгы айларда.

Йөридер җимереп
Немецлар юлын,
Эче пошканда
Уйлыйдыр улын.

Кем белсен, бәлки,
Көрәш юлында
Сөләйман кебек
Үлгәндер ул да.

Юк, юк... ул исән,
Ул кылыч кайрый,
Киң урманнарда
Җыры яңгырый.

Улы да аның
Безнең сафларга
Килеп кушылды
Илне сакларга.

Тора ул басып
Майор каршында,
Бәйсез хыяллар
Кайный башында.

Ул — Сөләйманның
Якын иптәше,
Снайперларның
Яшькә иң яше.

Тезләнгән җирдән
Майор кузгалды,
Гөлләр эченнән
Мылтыкны алды.

Яшь снайперны
Майор кочаклап,
Бирде мылтыкны:
«Мә, энем, сакла;

Синең кулыңда
Ул эшсез булмас,
Сиңа күренгән
Фриц котылмас!»

Әхтәм кулында —
Кадерле мылтык,
Кабер өстендә —
Дәһшәтле тынлык.

* * *

Озакка бармый
Тынлык сугышта,—
Җай гына эзли
Аяусыз дошман.

Шулай да бу төн
Тын үтте бүген,
Яшенсез булды
Дошманнар күге.

Җыр ишетелде,
Белмим, кайдандыр;
Таң аткач, хәтта
Кошлар сайрады.

Тын сулый таңда
Зәңгәрсу урман,
Ләкин һәр кеше
Мылтыгын корган.

Күк күкерәсә
Бер җирдә хәзер,
Ядрә яңгыры
Яварга әзер.

Шушы тын таңда
Әхтәм күренде,
Котелок тотып,
Ашка йөгерде.

Сипкелле повар
Зур чүмеч тоткан,
Ак түбәтәен
Кырын утырткан.

Повар, елмаеп,
Честь бирде аңа:
«Казаным иске,
Чүмечем яңа;

Апаң үстергән
Кишер, кәбестә,
Итләре аста,
Өресе өстә.

Чөгендереннән
Тешләр камаша;
Борычы да бар,
Сакланып аша.

Сакланып аша,
Бомба төшмәсен,
Котелогыңның
Төбен тишмәсен!»

Повар, такмаклап,
Куе аш салды,
Тагын честь биреп,
Озатып калды.

Тар сукмаклардан,
Чокырлар буйлап,
Кайтты снайпер
Нәрсәдер уйлап.

Кешенең уен
Белүе кыен...
Кеше уенда —
Шул ук киң дөнья.

Кеше сугышта
Суга да төшә,
Сугышта кеше
Утка да пешә.

Кеше сугышта
Ниләр уйламый,
Сугышта кеше
Үлә — еламый.

Сугышта куба
Иң яман ачу,
Мөмкин түгел һич
Аңардан качу.

Сугышта туа
Тиңе юк дуслык,
Дуссыз күңелдә —
Чиге юк бушлык.

Кайнар күз яше
Сугышта кибә,
Сугышта йөрәк
Ашкынып тибә.

Сугышта кеше
Сикереп уяна,
Эче пошканда,
Җырлап юана.

Җырда кайгы бар,
Җырда сагыш бар,
Җырларда шаулый
Таллар, камышлар...

Дөнья байлыгы
Җырларга тула,
Анда юк әйбер
Җырларда була.

Җыр ул аерылмый —
Һәрчак янында,
Башыңнан сыйпый
Үлгән чагында.

Тын гына җырлап
Таңгы тынлыкта,
Аш алып кайтты
Әхтәм окопка.

Яшел котелок —
Окоп читендә,
Снайпер Әхтәм —
Окоп эчендә.

Чак-чак күренә
Әхтәмнең башы,
Әхтәм кулында
Алюмин кашык.

Котелогыннан
Бу күтәрелә,
Борычлы ашның
Исе бәрелә.

Ашыйсы килгән,
Әхтәм, ашыгып,
Бу тәмле ашка
Сузды кашыгын.

Сузуы булды,
Шартлады мылтык,
Сүнгән ут кебек,
Югалды тынлык.

Елан тел — ядрә
Үтте сызгырып,
Әхтәм колагын
Уттай кыздырып.

Әхтәм сискәнеп
Яшерде башын,
Аяк астына
Түгелде ашы.

Яшел котелок
Үтә тишелгән,
Һәм ядрә аны
Бәреп төшергән.

Яшен яшьнәде
Немец күгендә,
Утыра Әхтәм
Окоп төбендә.

Окоп төбендә
Посып утыра,
Тикмәгә түгел,
Бер хәйлә кора.

Хәйлә кешене
Ат итеп җигә,
Сугышта хәйлә
Танкны җиңә.

Әхтәм, ашыгып,
Шинелен салды,
Аяк астыннан
Бер таяк алды.

Пилоткасын да
Салды башыннан,
Тагын бер тапкыр
Котырсын дошман.

Карачкы ясап,
Шул ук урынга
Бастырып куйды —
Алдап торырга.

Тора карачкы
Окоп янында,
Яшел котелок
Аның алдында.

Карачкы гүя
Аннан аш ашый,
Кайчакта хәтта
Селкенә башы.

Ә үзе Әхтәм
Икенче якта,
Куак астына
Сузылып яткан.

Кадерле мылтык,
Ул да тырыша,
Гүя җаны бар,
Кулга елыша.

Тын алмый Әхтәм,
Немецны көтә,
Канны кытыклап,
Секундлар үтә.

Менә башлана
Үлем уены:
Фриц траншейдан
Суза муенын.

Оптик приборда
Әхтәмнең күзе,
Ул, иренен тешләп,
Мылтыгын төзи.

Төзи фрицка
Бик тыныч кына;
Фриц та төзи,
Тик — карачкыга.

Күңел тын булса,
Ышаныч арта,
Әхтәм курогын
Тын гына тарта.

Ычкына ядрә,
Сызгыра шашып,
Актарып ташлый
Фрицның башын.

Әхтәм янында
Күгелҗем төтен;
Әхтәм ни уйлый,
Әйтүе читен.

Траншейда ята
Немец гәүдәсе,
Үлемнән тора
Фашист тәүбәсе.

Тишек котелок —
Аның ашы юк;
Фашист гәүдәсе —
Аның башы юк.

Нигә Әхтәмнең
Йомыла күзе?
Керфек астында —
Елмаю эзе;

Иркә елмаю
Балкый бу чакны,
Гүя Сөләйман
Аны кочаклый.

Офыктан кояш
Нурларын сибә,
Нурлар Әхтәмнең
Күзләрен үбә.

Кайгы булганда,
Ник моңаймаска;
Шатлыгың булгач,
Ник елмаймаска!

Ник елмаймасын,
Ул бит яшь әле,
Ул бу дөньяда
Бик аз яшәде,

Аның атларга
Атланасы бар;
Ерак юллардан
Хат аласы бар.

Озак яшәр ул,
Яшәр, макталыр,
Кош кебек очып
Килер хатлары.

## «ҮЛЕМ УЕНЫ» ПОЭМАСЫ ТУРЫНДА

«Үлем уены» поэмасын Фатих Кәрим 1942 елда язган. Кырык икенче ел — Ватан сугышының дәһшәтле, иң авыр чагы. Безнең армия әле чигенүләр, зур югалтулар белән газап чигә иде.

Ф. Кәрим үзе дә — фронтовик шагыйрь, разведчик. Сугыш тынган арада ул берсеннән-берсе гүзәл әсәрләр яза. Язучы бу шигъри әсәрләрендә үзе күргән, үзе кичергән вакыйгаларны тасвирлый. «Үлем уены» — шундый реалистик әсәрләрнең берсе. Еллар узар, әмма немец фашизмына каршы халкыбыз алып барган трагик яңгырашлы героик көрәш киләчәк буыннарга легенда итеп сөйләнер. Ул көрәш балаларны да читләтеп үтмәде. Алар, үзләренә генә хас самимилек һәм наян тапкырлык күрсәтеп, җиңүгә зур өлеш керттеләр. Поэманың нәни герое Әхтәм — шул буын баласы. 12 яшьлек солдатның хәйләсе укучының күңел кылларын кузга-

та, аның хәвефле язмышына теләктәшлек, сугыштагы җиңүенә ихлас куану, сөенү хисләре тудыра.

Сугыштагы фаҗига үзәкне өзәрлек. Арысландай ирләрнең трагик көрәше, коелган каны хисабына гына җиңү килә, чиксез авыр югалтулар белән килә. Сөләйман — шундый батырларның берсе. Автор аны күмү, соңгы саубуллашу моментына игътибарны туплый.

Поэманың эшләнеше бик матур. Ул җыр кебек агыла, җиңел музыкаль стиле белән үзенә тарта. Бала характерына ятышлы, аның уй-хәрәкәтләрен төгәл бирә торган кыска иҗекле юллардан тора.

Гомумән, Ф. Кәрим шигъри талантка ия, табигать аны иленә тугрылыклы солдат, туган халкының шигырь остасы итеп яраткан.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Әсәрне дөрес итеп, тиешле тон белән укырга өйрәнегез. Шигырьнең эшләнешенә игътибар итегез: ритм, рифма ничек бирелә? Шагыйрьнең стиле турында фикер алышыгыз.
2. Әхтәм турында ниләр уйлыйсыз? Аның килеш-килбәтен, эш-шөгылен, хәйләле тапкырлыгын характерлагыз.
3. Ни өчен ул фашизмга каршы сугышка омтыла? Малайны шуңа этәргән сәбәпләр нидә?
4. Сөләйман белән Әхтәмнең мөнәсәбәте ничек сурәтләнә? Әсәрне укыгач, сугыш дәһшәтен ничек күз алдына китерәсез?
5. Әхтәмнең партизан әтисе турында хикәяләү сездә нинди тәэсир калдыра? Малайны алда ниләр көтә?
6. Шагыйрьнең яшәү һәм үлем турындагы уйлануларына карата үзара фикер алышу оештырыгыз. Бу эпизод әчтәлекнең бөтенлегенә ничек йогынты ясый? Сугыш, фаҗига, дуслык төшенчәләрен ничек аңлыйсыз?
7. Җыр турында шагыйрьнең фикерләве сезнең хисләргә ничек тәэсир итте? Ни өчен Ф. Кәрим көрәштә җырны аерып куя? Сезнең моңа карашыгыз ничек? Тексттан мисаллар табып, дәфтәрегезгә языгыз.

**Мөстәкыйль эш.**

1. Поэмадан мәкаль булып китәрлек җөмләләрне табыгыз. Аларны күңелдән ятлагыз. Шуңа охшаш мәкальләр уйлагыз.

2. Немец фашизмына каршы балаларның көрәше турында нинди китаплар укыганыгыз бар? Күңелегезне кузгатканы кайсы әсәр булды?
3. Үзегезгә ошаган строфаларны ятлагыз.

**Язма эш.**

«Нәни солдатның тапкырлыгы» темасына инша языгыз.

## СИБӘЛИ ДӘ СИБӘЛИ

Төнге җилдә көзге яңгыр
Сибәли дә сибәли;
Янымдагы иптәш кенә
Миңа берни сөйләми.

Уема да кертмәдем мин
Аның бу төн үләсен,
Разведкадан кайткан чакта
Тиде немец пулясы.

Өс-баш юеш. Көрәкләргә
Үзле балчык сылаша;
Кабер казыйбыз тынлыкта,
Җил генә ыңгыраша.

Кайгыдан каралып торган
Япь-яшь нарат төбенә
Япь-яшь иптәшне күмгәнне
Күрә бары төн генә.

Япь-яшь иптәшне күмәбез,
Беркем берни сөйләми;
Көзге төндә яңгыр гына
Сибәли дә сибәли.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шигырьне дөрес интонация белән укыгыз. Солдат хисләренә кагылган үлем фаҗигасен ачуда шагыйрь кайсы тасвири чарага таяна? Үзегез аңлаганча сурәтләп сөйләгез.

2. *Җил, төн, яшь нарат* образларының эчтәлек төзүдәге вазифасын әйтегез. Сезнеңчә, бу поэтик образларның һәлак булган солдат белән уртаклыгы нәрсәдә?
3. Шигырьнең исеменә игътибар итегез. Ни өчен «Сибәли дә сибәли»? Сугыш хәвефен хәтерләтмиме ул? Тагын ничек уйлыйсыз?

## КЫР КАЗЫ

Тирән окопта каршылыйм
Икенче язны;
Язгы таңда безнең якка
Кайта кыр казы;

Кайта диңгез артындагы
Ерак илләрдән,
Һәм яши ул төнбоеклы
Тонык күлләрдә.

Әй кыр казы, түбәнәйт тә
Очкан юлыңны,
Бүләк итеп китче миңа
Бер каурыеңны.

Каләм ясап каурыеңнан,
Язгы ялкында
Ут эченнән языйм бер җыр
Сөйгән халкыма.

Дәһшәтле сугыш кырында
Сөйгән халкымның
Мин кояшым итеп йөртәм
Йөрәк ялкынын.

Халкыма бәхет, дан даулап
Үтә көннәрем;
Анабыз җирне кочаклап,
Бәлки, үләрмен.

Үлсәм, җырларымда калыр
Сөю, сагышлар;
Кыр казы йөзгән күлләрдә
Шаулар камышлар.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. «Кыр казы» шигырендә солдат хисләре ничек бирелә?
2. Шигырьдән күчерелмә мәгънәдә килгән сүзләрне табып, дәфтәрегезгә языгыз.
3. Шагыйрь һәм халык. Шигырьдә ул ничек бирелә?
4. «Кыр казы» исеменең эчтәлекне ачуда нинди бәйләнеше бар?
5. Шигырьне ятлагыз.



# *Мостай Кәрим*

***(1919—2005)***

Мостай Кәрим — башкорт халык язучысы. Ул — шагыйрь, проза әсәрләре язучы һәм драматург та.

Мостай Кәрим (Мостафа Сафа улы Кәримов) 1919 елның октябрендә Башкортстан Республикасының Чишмә районы Келәш авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Аның бала чагы бай табигатьле туган авылында, эш сөючән авылдашлары арасында уза. Шунлыктан чал тарих буе килә торган халык йолаларын, гадәт-шөгылен ул үзе күреп, аларны дәвам итүче буынның вәкиле булып үсә. Әсәрләрендә дә борынгы гореф-гадәтләр зур урын алып торалар.

Мостафа 1935 елны авылдагы тулы булмаган урта мәктәптә укый, аннан рабфакка керә. 1937—1941 елларда ул Башкорт педагогия институтының тел һәм әдәбият факультетында белем ала. Бөек Ватан сугышында катнаша, әдәбиятка ул сугыштан соң килә.

Мостай Кәрим үз урынын шигърияттә таба. Аның шигърияте киң һәм күпкырлы. Бер төркем шигырьләр циклы «Европа — Азия» дип атала. Бу шигъри әсәрләре Европа белән Азияне тоташтыручы кыя шикелле. Шагыйрь туган җир газизлеген, халкының мәшәкатьле тормышын, чал тарихын иңләп ала: «Туфрагым, һавам, суларым», «Яшьлек хатасы», «Болгар дәфтәреннән» шигырьләре әнә шундыйлардан. Аның шигырь җыентыклары күп телләргә тәрҗемә ителгән.

Мостай Кәримнең 1981 елда «Озын-озак балачак» повесте басылып чыга. «Алдан әйтелгән сүз»ендә

автор укучыларны искәртеп куя: «Бу китап,— дип яза ул,— могҗизаларга ышанучан, сәеррәк, шаукымлырак, беркатлырак, чаярак кешеләр турында». 1989 елда чыккан «Ярлыкау» җыентыгы исә берничә повестьны үз эченә ала. Язучы бу әсәрендә кеше язмышын, аның шактый катлаулы борылышларын, гыйбрәтле якларын күрсәтә.

Мостай Кәрим 2005 елның 23 сентябрендә Уфада вафат була.

## ОЗЫН-ОЗАК БАЛАЧАК

(*Кыскартып алынды*)

### КЕШЕ ТУДЫРЫРГА

Минем Олы инәемне «кендек әбисе», ә үземне «кендек бабасы» дип йөртәләр. Мин бәләкәймен әле. Олы инәемнең камзул кесәсенә буем чак-чак җитә. Ул тылсымлы кесәдән тәмле-томлы нәрсәләр һичвакытта да өзелми. Йә берәр шакмак шикәр, йә дүрт-биш бөртек йөзем җимеше, йә перәнник валчыгы, йә кипкән шомырт, йә куырылган борчак була. Хәтта ара-тирә бакыр тәңкәләр дә чылтырап куя. (Без акчаның кодрәтен күптән беләбез!) Турганы белән бер хәзинә инде ул кесә — бетмәс-төкәнмәс хәзинә.

Әле дә кулымны тыгуым булды, зур гына ике өрек учыма килеп тә эләкте. Берсен шунда ук уртыма кыстырып куйдым. Бездә тәмле нәрсәне берьюлы гына комсызланып ашый торган гадәт юк. Без аны рәхәтләнеп суырып кына йөрибез. Икенче өрекне бүген генә киеп чыккан яңа чалбарымның кесәсенә яшердем. Анысын кайткач, сеңелем белән энемә бүлеп бирермен. Бәлки, шуннан башлап минем чалбарымның да кесәсе тылсымлыга әйләнер. «Юмарт кулга мал керер»,—ди Олы инәем.

Без Түбән оч Кара Йомаголларга китеп барабыз. Аның бичәсе бәбигә чирләгән. Безгә, безгә дип ни инде, Олы инәемә йөзе көл кебек агарган Кара Йомагол үзе

килеп хәбәр итте. Итте дә, җавап-фәлән көтеп тормыйча, кире чыгып йөгерде. Бу инде кунакка чакыру гамәле түгел. Кунакка чакыручы башта җайлап түргә уза, урындыкка утыра. Ашыкмый гына дога кылалар. Йорт-җирнең, мал-туарның иминлеген сорашалар. Хәтта ут күрше булсын, барыбер сорашалар. Шулай тиеш. Мин моның буш йола гына түгеллеген бары үскәч аңладым. Әйе, кунакка чакыручы синең дөньяң имин, кәефең урынында икәнен үз колагы белән ишетергә, үз күзе белән күрергә тиеш. Чөнки күңеле китек адәмдә кунакка йөрү кайгысы булмау ихтимал. Шуны да әйтергә кирәк: безнең авыл кешеләре, туган-тумачадан тыш, дәрәҗәгә, абруйга, мөлкәткә карабрак аралаша, һәркемнең үз коры[1] бар. Һәр корның үз җыры бар:

Байлар, байлар бал эчә,
Урта хәлләр сыра эчә.
Безнең кебек ярлылары
Бәкегә ятып су эчә.

Минем этием сыра эчүчеләр корында. Монысын яхшы беләм. Әле яңа гына өй-кура юнәтеп, бәке тирәсеннән узмаган Кара Йомагол, әлбәттә, безнең салкын суыбызны да уртлаганы юк. Ә минем этием бал эчүче кайбер йортларның тупсасы аша да атламаган. Йә чакырмаганнардыр, йә чакырылып та бармагандыр. Мөгаен, үз корының түр башында утырырга күнеккән горур зат өлкәнрәк дәрәҗәле чит корның ишек төбенә төшәргә теләмәгәндер. Бу хакта мин хәзер, үзем балалар атасы булгач, шулай уйлыйм.

...Олы инәем белән безгә урыс капкалы, калай түбәле, биек болдырлы өйләрнең дә, җиргә сеңеп беткән балчык алачыкларның да ишекләре шар ачык. Бәгъзеләре, беләм, ачмаслар да иде, ачтыручылары бар. Һәр өйдә диярлек язына-көзенә, иртәсенә-киченә, явымына-аязына карамый, үз вакыты җиткәч, кеше туа. Шул кешене каршы алырга без кирәк.

---

[1] *Кор* — табын, даирә.

— Шул баланы гел үзеңә ияртеп йөртмәсәң булмыймы, көндәшем? — диде бая Кече инәем.

— Юк, Вазифа, шул сабый якын-тирәмдә булса, хатыннар җиңелрәк бәбәйли сымак.

— Инде...—Кече инәем сәер генә көлеп куйды,— шулкадәр дә сихерләр икән бераүне бераү.

— Ирем кисәге — итем кисәге. Бар сихере шунда.— Шуларны әйткәч, Олы инәем көрсенеп куйгандай итте. Бәлки, көрсенмәгәндер дә.

Нәрсә ул «ирем кисәге — итем кисәге»? Моның төп мәгънәсен мин бик күп еллар үткәч, талпынып-талпынып күбәләк кар яварга бары бер генә көн калгач төшенәчәкмен.

— Ихтыярыңда... — диде Кече инәем, гаепле кеше сымак башын иде.— Ни кылсаң да, син хаклы.

— Һәркайсыбызның үз хакыйкате, үз иманы, Вазифа. Без икебез бер дөреслек белән яши алмыйбыз. Хаклы булсам да, мин үзем өчен генә хаклымын...

Инәемнәр сөйләгән бу сүзләрнең һәрберсен аерым-аерым аңлыйм, ә бөтенесе бергә кушылгач, аларның мәгънәсе минем башыма сыймый, төрле якка чәчелә дә һавада эреп югала. Шулай да күңелемдә сагыш катыш билгесез шом торып кала. Йөрәгемне килеп-килеп уртага бүлгән ул шом бик озак еллар буенча мине ташлап китмәячәк. Чөнки шул ике хатын сыны бөтен юлларым буйлап мине озата барачак. Ике мәхәббәтнең шәүләсе булып гел генә ике сагыш ияреачәк миңа.

Әйе, мин берьюлы ике ананың мәхәббәтен татыдым һәм үземнең бер мәхәббәтемне аларның икесенә тигез бүләргә тырыштым. Үземне үзем уртага аердым. Торабара мин моның рәхәтен генә түгел, үземә аңлашылып та җитмәгән әчке газапларын да кичерәчәкмен. Әмма газаплары татлы булачак.

...Әлегә мин, уртымдагы өрекне суыра-суыра, Олы инәем яныннан тыр-тыр йөгерәм. Менә Кара Йомаголларның капка төбенә дә килеп җиттек. Келәт алдында бау ишеп торган хуҗа, эшен ташлап, атлый-йөгерә

килеп капка ачты. Олы инәем туп-туры өйгә юнәлде. Өйгә кереп йөрергә миңа ярамый. Монысын күптән беләм. Төптән юан Кара Йомагол, шешенке кабаклары астындагы кысык күзләрен челт-челт йомып, Олы инәемә инәлде:

— Малай була күрсен инде, зинһар, ди, тәүге бала бит. Мәңге онытмам, әбекәем.

Олы инәем Кара Йомаголның йомшак кына аркасыннан кага:

— Ярар, ди, сайлап алырга туры килсә, син теләгәнне сайлармын. Бар, эшеңдә бул.

— Шулай итә күр инде, зинһар өчен,— Кара Йомаголның нигәдер иреннәре калтырый.

Ул, кире келәт янына килеп, эшенә керешә. Мин аннан ерак түгел түмәр башына менеп утырам. Үз дәрәҗәмне, урынымны яхшы беләм — мин кендек әбисенең улымын. Вак-төяккә кысылып бармыйм, олыларның аяк астында уралмыйм. Үзем теләгән җирдә әдәпле генә утыра бирәм, сабырлык күрсәтәм. Шуңа күрә бәби туар өйдә олылар да миңа «әй малай!» дип эндәшергә җөрьәт итми. Исемемне тутырып әйтәләр.

Байтак утыргач кына, Кара Йомаголга сүз кушам:

— Нәрсә ишәсең?— дим.

— Аркан. Бау ишкәндә вакыт тиз үтә ул. Очы да, чиге дә юк аның — иш тә иш кенә.— Кара Йомагол йомык кешеләрдән санала, аның авызыннан сүзне көрәк белән каерып алырга кирәк диләр. Бүген теле телгә йокмый. Бераз тынып тора да дәвам итә:— Бау ул, энем, дөньяның тоткасы. Бау булмаса, бөтен дөнья таралып төшәр иде.

Чынлап та, дөрес әйтә бит. Бар әнә, җепсез-баусыз көн күреп кара. Бу сүзләре белән шаккатыргач, Кара Йомагол тынып калды. Ишә-ишә дә ул йорт ягына колак салып, сагаеп тора. Тагы ишә.

— Арканыңны кайчан ишеп бетерәсең инде?— дим, эчем поша башлагач.

— Ишәм әле, малай туганчы...

— Oho! Әгәр ул тиз генә тумаса?

— Туар. Ә юкә миндә бер йөк, хет биш көн иш...

Өйдән Олы инәем бер-ике тапкыр чыгып күренде, бер яшь хатын өч көянтә суга барып кайтты. Көн инде кичкә авышты. Теге өрек әллә кайчан авызда эреп юк булды. Аның чикләвеге абайламастан кызыл сандыкка төшеп китте. Эчемдә минем бернәрсә дә юк. Тик әлеге өрек чикләвеге генә дөбер-дөбер тәгәрәп йөри. Бая су ташыган килен көтү алдыннан гына безгә ашарга чыгарды. Каты-котыдан булса да тамак ялгап алгач, күңел күтәрелеп китте.

Кара Йомагол янә эшенә тотынды, ә мин шул ук түмәр башына менеп кунакладым. Хәзер аның арканы, сузсаң, мөгаен, мәчет аена җитәр иде. Күп иште.

— Ә шулкадәр озын арканны син нәрсә эшләтәсең?

— Хәбибулланың унҗидесе тулганчы, ул шушы келәттә сакланачак. Унҗидесе тулгач, аңа тапшырачакмын.

— Ә унҗидесе тулгач, нигә аңа аркан кирәк?

— Нигә дисеңме? Алайса, тыңла...

Кара Йомаголның кысык күзләре кинәт зураеп китте дә ниндидер тылсымлы нур чәчә башлады. Нур тәүдә аның итләч йөзенә таралды, аннан соң ул ишеп торган аркан буйлап йөгерде. Әйтерсең әнә ул бөгәрләнеп-бөгәрләнеп яткан нәрсә хәзер саргылт юкә бау түгел, ә шушы ямьсез кешенең ике күзеннән агылып чыккан нур тасмасы. Үрелеп тотмакчы итәм шул тасманы, әмма, мин кагылсам, тылсымы югалыр дип шикләнәм.

— Алайса, тыңла... — дип кабатлый Кара Йомагол. Аның тавышы да элеккечә тамак төбеннән чыелдап түгел, күкрәгеннән, тирәннән гөрләп, ургылып чыга. Торганы белән җыр җырлый диярсең... Хәзер миңа моңа кадәр адәм күзе күрмәгән, адәм колагы ишетмәгән сер ачылачак. Мин сабыр гына көтәм. Ә ул, йорт ягына колак салып, беравык катып кала. Ләкин тынлыктан башка нәрсә ишетелми. Хәбибулла әлегә

билге бирми.— Әнә күрәсеңме офыкны?— Кара Йомагол ияге белән еракка күрсәтә.— Шуның аръягында Урал дигән биек тау бар, тау түбәсендә адәм үтмәслек кара урман, урман эчендә түп-түгәрәк аклан, түп-түгәрәк аклан эчендә түп-түгәрәк күл булыр. Күлнең аркылы-буе җитмеш колач, ә төбендә төп юк, имеш. Ул күлдә балык та, бүтән төрле җәнлек-җанвар да юк, имеш. Анда бары алтын яллы, көмеш тояклы, җилдәй җилләр, коштай очар, теләгән җиреңә җиткерер, уйлаган уеңны башкарыр, үткәнеңне кайтарыр, көткәнеңне китерер, адәм белән адәмчә сөйләшер, Ходай белән Ходайча серләшер бер Акбүзат яши, ди. Елның иң кыска төнендә, чикләвек чәчәк аткан сәгатьтә, юкәдән бал тама башлар мәлдә, үлән кыяклары ширбәттән тулышкан чакта, күлнең өстен уртага ярып, алтын ялын чайкый-чайкый, Акбүзат килеп чыгар, ди. Таң сызылганчы, һичнәрсәдән өрекми-курыкмый акланда үлән утлап йөрер, ди. Шул арада кем дә кем аның муенына җитмеш колач озынлыгы корык салып өлгерә, ат шуныкы булыр, ди. Көндез йолдыз күрерлек, төнен җанварауларлык, эчендә ут янса да уфтанмас, өстенә тау ауса да сыктамас ир-егет кенә корыклый алыр, ди, ул атны. Ай үсәсен көн үсәр оланым, ел үсәсен ай үсәр, яше унҗидегә җитәр, иңенә җитмеш колачлы шушы арканны салыр да чыгып китәр ырыс[1] толпарын ауларга. Морадына ирешер, иншалла... Менә нәрсәгә кирәк булачак бу аркан!

Мин эчемнән көнләшеп куям. Хәбибулланың эшләр көйле. Үзе әле тумаган да, аны инде кара урман эчендәге түгәрәк күл буенда керт-керт үлән утлап йөргән Акбүзат көтә, атны корыкларга аркан да әзер. Була бит котлы кешеләр!

Чынлап та, әле батып барган кояш яктысында ялтырап яткан алтын-саргылт бау нәкъ унҗиде елдан соң ак толпарның муенына уралачак. Туачак Хәбибулла

[1] *Ырыс* — бәхет, кот.

да минем күз алдыма алтын чәчле, көмеш тырнаклы галәмәт зур пәһлеван булып килеп баса.

Әңгәмәсен сөйләп беткәч, Кара Йомагол нишләптер күңелсезләнеп калгандай итте. Өй ягына омтылып карады да кире туктады. Тагы ишәргә керешге.

Җиргә сыек зәңгәр төшә башлады. Тып-тын зәңгәрлек. Әйтерсең су өсте шулай тынып калган. Мин уем белән яңадан теге күл янына китеп олактым. Аның ярында әле тумаган Хәбибулла түгел, мин үзем корык тотып утырам, менә-менә су астыннан атның матур башы күренер. Әйе, әнә ул килеп тә чыкты, әче тавыш белән кешнәп тә җибәрде: «И-һа-һа-һау!..»

— Туды! — дип сөрәнләде Кара Йомагол. Үзе чүгәләп төште.— Туды! Минем малай туды!!!

Ул, атылып торып, өй ишегенә ташланды, кинәт кире борылды. Йөгереп янә келәт янына килде. Кызу-кызу арканын ишәргә тотынды. Кулларына күз иярми. Кендек әбисе чыгып сөенче алганны Кара Йомагол чыдам гына көтеп торырга тиеш тә бит, күрәсең, чыдый алмый, исәр.

Ә мин түмәр өстендә, аякларымны сәлендереп, кымшанмый да утыра бирәм. Чәбәләнүдән ни файда? Хәбәре килер. Бер тугач, кире әллә кая китмәс. Шулай да Олы инәем нигә күренми соң әле? Күңелемә шик төшә башлый. Кара Йомаголның куркынган күзләре тагы кабаклары астына кереп бата. Ул кинәт эшеннән туктала. Көрсенә. Хәзер инде матур аклан да, аклан уртасындагы күл дә, күлдән чыгып килгән Акбүзат та кайдадыр рәшә эченә чумып кала. Җирдә уралып яткан нур тасмасы кабаттан гади юкә арканга әйләнә, инде мин өй ягына карарга да куркам, менә ишек ачылыр да, аннан Кара Йомагол өчен коточкыч бәла килеп чыгар сымак. Хәер, алай булмас, анда минем Олы инәем бит.

Баягыдан да көчлерәк һәм ачыграк яңа тавыш өйдән тышка бәреп чыкты. Кара Йомагол дертләп китте. Минем буыннарым буйлап нindидер рәхәтлек

йөгерде. Бу тавыш тиз генә тынар өчен яралмаган булып чыкты.

...Байтак заманнар узгач, аяз иртәдә имән төбендә яткан чагымда берәүнең дөнья белән хушлашу авазыннан соң нәкъ шушы үткер тавыш, минем янымда яңадан терелеп, җанымны тетрәтәчәк...

Менә болдырга минем Олы инәем чыгып басты.

— Сөенче, Йомагол! — диде ул, тораташ төсле селкенми дә.

— Кем бар?— Тегесе «ә» дигәнче Олы инәемнең алдына килеп тезләнде.

— Ике улың.

— Икәү? Берьюлымы? Нигә икәү? Икенчесе ни исемле? Олы инәем көлеп үк җибәрде:

— Исәр, берәүгә караганда икәү яхшырак ла... Исеменә генә калгач, анысын табарсың инде.

— Әйе, әйе, яхшырак, икәү яхшырак. Исемен табарбыз. Аллаһы әкбәр!— Тезләнгән көе ул дога кылды.— Сөенчесенә, әбекәй, сиңа бер сарык. Юк, ике сарык! Аллаһы әкбәр! — Ике кулы белән янә битен сыйпады.

— Арык атның күгәне киң, диме. Шашма! Бер бәрән бирсәң, хәттин ашкан.

Безнең эштә бу хәл — игезәкләрне әйтәм — бары икенче тапкыр гына булды. Бүресе улады Кара Йомаголның! Бер бәрән генә, әлбәттә, азрагын азрак та. Кендек әбисеннән узып, мин нәрсә әйтә алам?

Олы инәем, болдырдан төшеп, Кара Йомаголның аркасыннан какты:

— Бәхет-тәүфыйклары белән килсеннәр бу дөньяга. Малайларыңның игелеген күрергә язсын. Ә хатының торганы белән инә арыслан. Бичәләрнең кеме кем икәнлеге бала асраганда сынала. Кадерен белеп яшә.

Бәби тугач, боларның эше бетте инде, әлеге сөенче бәрәнен җитәкләрләр дә кайтып китәрләр дип уйлыйсызмы? Юк шул. Безнең кадер, тормышның рәхәте бәби тугач башлана. Ул рәхәтлек атна буена бара. Хәтта ашып та китә.

Менә ничек була ул.

Бәби туган йортка, аның мөлкәтлеме, мөлкәтсезме булуына карамастан, икенче көнне үк сый агыла башлый. Күрше-күлән, туган-тумача, дус-иш, таныш-белеш хатыннар, тиңдәшләр, ахирәтләр, кодагый-кодачалар бала анасына күчтәнәч ташый. Берәүләр кызу табада коймак, икенчеләр бәлеш, өченчеләр кыстыбый, дүртенчеләр тутырган тавык, бишенчеләр катлама, алтынчылар бавырсак, җиденчеләр... тагы әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр китерә. Һәркем хәленнән килгәненчә дә, артыгын да тырыштыра, үзендә булмаганны күршедән әҗәткә алып тора. Менә нинди сыйлар белән хөрмәтлиләр яңа туган баланы!

Иртәдән кичкә кадәр түрдән самавыр төшми. Түр башында мамык мендәр өстендә кендек әбисе утыра, аның янында кем дисезме — мин. Бер атна буена шулай утырабыз. Хәтта ашып та китә. Бу күркәм тормышны тик бер генә нәрсә боза. Ул да булса — бәби мунчасы. Бала тугач, көн саен мунча ягалар. Олы инәем Ходайның биргән һәр көнендә, башкалар керep чыккач, мине алып барып мунча чаба. Үсәрсең, ди. Кыен булса да түзәргә туры килә. Бер кыенның мең рәхәте бар. Мунчадан кайткач, без янә түр башына менеп кунаклыйбыз. Тирләп-пешеп, баллап-майлап чәй эчәбез...

Иртәгә мин Кара Йомаголның түр башында булачакмын. Ә бүгенгә миңа бары бер тустаган җылы сөт белән бер сынык икмәк кенә бирделәр. Аннан соң келәт идәненә йокларга салдылар. Бер кышка куян тиресе дә чыдаган, диләр. Бер төнгә түзәрбез. Яңа көндә яңа тормыш башланачак.

Һәм шулай булды да. Уянганда ук, минем танавымны ярып, кыздырылган май исе бәреп керде. Тик бер атна узгач кына, Кара Йомагол сайлаган ак бәрәнне ияртеп, өйгә кайтып киттек. Олы инәем мине, мин, муенына бау тагып, ак бәрәнне җитәкләп алдым.

Әлбәттә, гелән бәйрәм, гелән туй гына да булып тормый. Тикәй[1] көннәр дә еш килә. Чөнки адәм тууда без көтмәгән тоткарлыклар килеп чыга. Шул чакта мин үз тиңдәшләрем белән туйганчы уйнап калам. Бара торгач, уен да туйдыра. Эч поша башлый. Яңа туган бәбинең үзе хакында, сөрәнләп, дөньяга хәбәр салуын ишетәсем, куанычтан бөтенләй юләрләнеп калган аталарның кыланышын читтән генә күзәтәсем, моңача ямьсез генә күренгән хатыннарның баладан соң ямьләнеп, нурланып киткән йөзен күрәсем килә.

Яшь ананың тәү тапкыр бала имезгәнен чаршау ярыгыннан карап торганым бар минем. Әле күзе дә ачылмаган кып-кызыл җан иясенең иреннәре алсу имчәккә тиюе була, ананың аксыл йончу маңгае кинәт балкып, яктырып китә. Алар, шул түшәктә яткан килеш, гүя акрын гына югарыга, һавага күтәрелә. Түшәге дә, имеш, түшәк түгел, ак болыт. Болыт эчендә, ләззәткә чумып, икәү йөзә — ана һәм бала. Нигә шулай икән — үтә рәхәт булганда кеше йә оча, йә йөзә сымак? Болар кинәт җиргә егылып төшмәсеннәр дип куркып, мин чытырдатып күзләремне йомам һәм чаршау яныннан китеп барам.

Авылда озаграк бала тумый торса, минем бер сихерле чарам бар. Башкача чыдарлык әмәл калмагач, соңгы чиктә мин шуңа килеп төртеләм.

Безнең бакчада бер чикләвек куагы үсә. Бу агач бездә тылсымлы исәпләнә. Әгәр җиде төн уртасында аның чәчәк аткан чагына тап булсаң, әгәр бер чәчәкне өзеп өлгерә алсаң, әгәр уч төбеңне үткер пәке белән ярып, шул чәчкәне тирең астына кыстырсаң, сине һичнинди адәм заты күрмәячәк. Бер рухка әйләнәсең дә куясың. Теләсәң кая бар, теләсәң нәрсә эшлә — сине һичкем тыя алмаячак. Соңрак, беләккә көч, йөрәккә тәвәккәллек керә башлагач, әтиемнең сакалмыек кыра торган иң үткер пәкесен тотып, күпме

---

[1] *Тикәй* — эш көннәре.

җәйге төннәрне мин шул чикләвек төбендә үткәрмәдем! Күзгә күренми торган затка әйләнгәч, мин нәрсә эшләячәгемне яхшы беләидем: җир шарындагы бөтен буржуйларны берәм-берәм кырып бетерәм дә изелгән колларны азат итәм.

Чикләвек, әлбәттә, миңа күренеп чәчкә атмады. Әмма мин аннан соң да, кара чәчләремне еллар соры көлгә әйләндереп беткән заманда да, чикләвекнең чәчкә атачагына ышандым, ышаначакмын. Шуңа ышанмасам, яшәвемнең кызыгы калмаган булыр иде.

Хәзергә минем төннәр буе бакчада ялгыз утырырлык кыюлыгым да, бөтен буржуйларны кыйратып, барлык колларны азат итәрлек дәрманым да юк. Теләгемне ялварып сорарлык телем генә бар. Әтием өйлә намазына киткәч, көннең иң изге мәлендә, мин, бакчага чыгып, чикләвек куагы алдына тезләнәм. Ул серле агач минем дә, Ходайның да телен аңлый төсле. Шуңа күрә, ике кулымны югары күтәреп, аның аша күктәгенең үзенә эндәшәм. Алла белән ничек сөйләшергә кирәклекне беләм мин. Ул шаштырып мактаганны ярата. Моны мин әллә кайчан инде Олы инәемнән төшенеп алдым.

— Әй Ходаем,— дим мин.— Кодрәтең дә, рәхимең дә чиксез синең. Бар өметебез синдә генә. Изге ихтыярың белән сабыйлар тагы, тагы, тагы дөньяга яралсын. Сиңа иман китерер гөнаһсыз җаннар тусын! Теләкләремне кабул ит! Ишетәсеңме, мине, Тәңре?!

Чикләвек яфраклары бердәм кыштырдап куя. Монысы инде — минем үтенечем иясенә барып юлыкты һәм кабул кылынды дигән сүз.

Ходай вәгъдәсендә тора. Ике-өч көн үтми, авылның кайсыдыр очында йә берәр малай, йә берәр кыз туа. Әлбәттә, мин, әрсезләнеп, Алланы артык еш борчырга тырышмыйм. Бая әйткәнемчә, ул — минем иң соңгы чарам.

Дөньям шулай ипле генә бара. Тамак сыйга тиенеп тора. Олы инәемнең камзул кесәсенә генә түгел, минем

чалбар кесәмә дә кот керде. Энем белән сеңелемә аннан өлеш чыгып кына тора. Дустым Әсгать тә очраганда буш калмый. Шулай да көйле дөньяның ара-тирә көе киткәләп куя. Барысы да шул малайлар аркасында. Минем шулпа өстендәге өре төсле яшәвемнән көнләшеп, алар мине үчекли, хәтта кыерсыта башладылар. Башта: «Кендек бабае! Кендек бабае!» — дип ирештерделәр. Монысына артык исем китмәде. Дөресе шул булгач, ни кыласың? Әйдә, әйтә бирсеннәр!

Тик моннан ары булганы минем намусыма нык сукты. Баягы явыз малайлар берзаман мине, бөтенләй мәсхәрә итеп, коры «Кендек»кә торгызып калдырдылар. Урамга чыгар хәлем юк, уң яктан да, сул яктан да тик бер генә сүз ишетәм:

— Әй Кендек!

— Нихәл, Кендек?

— Бәби коймагы тәмлеме, Кендек?

— Кендегеңне күрсәт әле, Кендек!

— Кендек! Кендек! Кендек!

Хәтта арабызда иң юаш, иң тыйнак исәпләнгән Аркылы баш Хәмитҗан да тел-теш күрсәтә башлады.

Байтак ара мин үз яшьтәшләремнән бизеп тордым. Алар да миннән суындылар. Тик бер Әсгать кенә ташламады.

Хәзер инде авылда яңа кеше туу да миңа, элекке кебек, куаныч китерми. Олы инәемә дә сирәгрәк иярәм. Барасым килмәгәндә, ул да нытытып кыстамый.

— Үсә башлавың шушы микәнни? — дип, бары битемнән генә сөеп ала. Ул башка барлык кешеләрнең аркасыннан кага, бер мине генә битемнән сөя. Аның йомшак кулы битемә кагылгач, мин бөтенләй бәләкәч булып калам. Барлык әрнүләрем берьюлы юк була. Күңелемә тынычлык кайта. Үсеп буйга җиткәч тә, тәүге мәхәббәт газапларын татып, акылдан шашканда да шулай булачак: йомшак кына бармаклар яңагыма тигәч тә йөрәгемдәге әрнүләрне алып ташлаячак, һәм мин яңадан сабыйга әйләнәчәкмен.

Гомер узган саен, хагы да, нахагы да артта кала торды, яхшысы да, яманы да онытыла барды. Ә «Кендек»не бирәү дә онытмады. Ул миңа гомерлеккә тагылды. Күп кеше авылда минем чын исемемне дә белми. Үзем дә күнектем. Кемдер бирәү миңа ерактан язып-ялгышып үз исемем белән эндәшсә, мин башта тирә-ягыма каранып алам, миңамы икән дим. Шуннан гына җавап бирәм. Ә «Кендек» тирә-якта берәү генә. Бәлки, үтә начар да түгелдер әле. Минем кушаматым миңа хәтта ошый. Ә ияләшкәнче күпме җәфа, күпме бәла, күпме күз яшьләре китерде ул миңа. Хисапсыз. Мин аңа каршы канга батып көрәштем, үземне аямый көрәштем. Тешем-тырнагым, җаным-тәнем белән карыштым. Мин карышкан саен, ул ныграк ябышты.

Беренче канлы сугыш менә шулай булды.

С ү з л е к  ө с т е н д ә  э ш .

*Гамәл, иминлек, хакыйкать, иман, инәй, сер, нур, җөрьәт, офык, тәүфыйк, дәрман, кодрәт, рәхим, ялвару* сүзләрен аңлатмалы сүзлектән карагыз. Бу сүзләрне кертеп, диалоглар төзегез, үзара сөйләшеп тикшерегез.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Нәни геройның дөнья белән танышуын, тирә-юнь тормыш күренешләренә карашларын уртаклашасызмы? Аңа карата сездә нинди хисләр туды?
2. Халыктагы гадәтләргә ничек карыйсыз? Бала туу тантанасы ни өчен зур сөенеч? Туу һәм үлем турындагы төшенчәләргә үз уйларыгызны кушып сөйләгез.
3. Кара Йомагол сөйләгән Акбүзат әкияте нәрсәне белдерә? Аның чын тормышка мөнәсәбәтен ачыклагыз. Кара Йомаголның күңел байлыгы, эшчәнлек сыйфаты сезгә ничек тәэсир итә?
4. Олы инәйнең шәфкатьле булуын, гореф-гадәтләрне үстерүдәге ролен сөйләгез. Аның киң күңелле, кешелекле табигате тормышка, яшәешкә ниләр өсти?
5. «Кендек» кушаматына ничек карыйсыз? Халык гадәтләре белән бәйләнеше бармы?

## ИСКӘНДӘР ӘСГАТЕ

Әсгатьләр урамын «Губернатор урамы» дип йөртәләр... «Монда губернатор үзе яшәгән, имеш...» дип уйламагыз тагын. Кайчандыр, әллә йөз ел әүвәл шушы урам шәрәмәтеннән, тройкада җилдереп, губернатор узып киткән, имеш, диләр. Шулкадәр зур түрәнең көймәсе туздырып узган тузанда коенып, рәхәтлектән горурлыкның чигенә җиткән бәндәләр шунда ук үз урамнарына яңа исем кушканнар — «Губернатор урамы». Әйтергә кирәк, биш кенә йорттан торган бу тыкрыкның «Кәҗәләр төбәге» дигән элекке исеме дә тиз генә онытылмаган. Губернаторлар, байлар, түрәләр күздән төшеп, түрдән тәгәрәгәч, «Кәҗәләр төбәге»н яңадан ябыштырырга маташучылар да булган бугай. Ләкин «губернаторлар», һәр йортның нигез буенда кәҗәләр күшәп ятуга карамастан, бу мәсхәрәне кабул итмәгәннәр, бердәм кире какканнар. «Губернатор урамы» авылдагы «Туң морҗа», «Өч этәч», «Ябалак», «Черчә» исемнәрен йөрткән башка төбәкләргә ишмени? Тегеләрнең һәрберсеннән мескенлек, наданлык, томаналык аңкып тора.

Бу урам үзе, асылда, ике нәрсә белән — фәкыйрьлек һәм тәкәбберлек белән аерыла. Биш йортның дүртесендә кәҗә белән тавыктан башка мал заты юк. Тик Әсгатьләрнең генә сыңар күзле биясе, бер сыеры белән яшь үгезе бар. Ярлылык ата-бабадан мирас булып калган, аның кадерен беләләр монда. Ә кукраерга дигәндә, бала-чагасына кадәр кикриген катырырга тора. Әйтерсең аларның һәрберсе, — ким дигәндә, чын губернатор нәселе. Җитмәсә, торып килеп мактанчыклар. Һәр «губернатор»ның, төптән уйлап карасаң, башкаларда юк бер хикмәте килеп чыга. Алар суккан бүре башмак чаклы, алар тоткан җәен бүрәнә буе, алар аткан үрдәк торна чаклы була. Тик нишләптер үзләре бер дә генә котаймыйлар, һич кенә дә кәперенер урыны булмаган чатан Шәрәй дә хәтта мактанып җибәрә. «Чатан күп

йөрер, дип, минем турыда әйткәннәр ул. Менә шушы ярман сугышыннан алып кайткан агач аяктан уңдым бит: талмый да, сызламый да, өшеми дә, тирләми дә.

Бүтәннәр бер кием чабата туздырганда, миңа бер сыңары җитә»,—дип шапырына.

Бәләкәй чакта «Губернатор урамы» — минем өчен чит бер дөнья, андагы кешеләр тоташ бер сер иде. Ул һавалы фәкыйрьләрнең сәер кылыкларын мин соңрак, олыгая төшкәчрәк кенә төшендем. Тәкәбберлек аларның коралы, калканы, таяныр терәге булган икән. Башкаларның мөлкәтенә, дәрәҗәсенә, көченә нәрсәдер каршы куярга кирәк бит. Алар шул коры мин-минлекне китереп бастырганнар. Бахыр, горур, әкәмәт «губернаторлар»! Мин сезнең бөтенегезне дә сагынып искә алам —тереләрне дә, мәрхүмнәрне дә...

Шул «губернаторлар»ның берсе Әсгать иде.

...Мин «Губернатор урамы»ннан Тау артына бозау эзләргә китеп барам, үзләренең капка төбендә хас та җитен төсле ап-ак чәчле Әсгать басып тора. Күзләре дә җитен чәчәгенә охшаган — зәп-зәңгәрләр. Мин аны беләм. Тик әлегәчә бер тапкыр да бергә уйнаганыбыз юк. Бу миңа йә таш ыргытыр, йә телен чыгарып үчекләр, йә «Кендек»тән салдырып исем атар дип, үземчә җавап кайтарырга әзерләнеп киләм.

— Әй малай, уңайла болай! — дип боерды теге, такмаклап.

— Үзең уңайла. Мин бозау эзләргә барам,— дип чәйнәштем мин.

— Шүрләмә, сиңа булмас һичнәрсә, мин кешегә тимим,— диде Әсгать. Мин туктадым. Үзем, хаҗәте килеп чыкмагае дип, уң йодрыкны йомарлап, артка яшереп куйдым. Ике күзеннән зәңгәр нурлар чәчә-чәчә, «җитен баш» үзе миңа таба уңайлады. Килеп җиткәч тә, учын җәеп минем танау астына китереп терәде.

— Нәрсә исе килә?

Мин авызны йомып, аптырап калдым. Әгәр яман ният белән булса, ул уч төбен түгел, йодрыгын иснәтер

иде. Сугыш чыгарырга чамалаган малайлар шулай йодрык иснәтәләр.

— Йә әйт инде, нәрсә исе килә? — дип кабатлады.

— Эт исе,— дип, авызын капларга уйлаган идем дә, тегенең хәйләле елмаюы тыеп калды.

— Юкчы, бер ис тә килми,— дип баш чайкадым.

— Син яхшылабрак иснә,— дип үҗәтләнде теге,— танавыңны җыерыбрак...

Ярылып беткән пычрак уч төбен мин, бара торгач, чынлап иснәргә тотындым. Әмма аерып кына әйтерлек ис таба алмадым.

— Их, син,— дип кимсетмәкче итте мине Әсгать,— шуны да белмисең... Күмәч исе, май күмәче. Әле генә күмәч ашап чыктым.

Монысы да мине шаккатырды — тапкан мактаныр нәрсә! Аның күмәч ашавы миңа бик хаҗәт ди әнә. Харап икән!

— Ашасаң ни... Мин бозау эзләргә барам.

— Мин дә сиңа бозау эзләшимме?

— Эзләшсәң ни...

Сай чокыр дигән җиргә җиткәндә, без Әсгать белән җитәкләшеп китеп бара идек инде. Шул арада ул мине арбап, кулга ияләштереп алды.

— Әй, тукта әле, ыштан кесәңдә синең нәрсә кабарып тора ул?!

— Икмәк катысы.

— Булмас, йә таштыр әле.

— Менә ышанмасаң,— дип, мин кесәдәге зур гына икмәк катысын чыгарып күрсәттем,— бозау алдатырга. Менә...

— Бозауны ни аны болай гына, алдатмый гына куып кайтырбыз. Әйдә, икмәкне утырып ашыйк.

— Үзең әле генә май күмәче ашадым дип мактандың...

— Күмәч кенә тамакны туйдырмый шул, аны икмәккә кушып ашарга кирәк.

— Ә нигә соң кушып ашамадың?

— Икмәк булмагач...

Әкәмәт бу дөнья. Берәүләрдә гел генә күмәч, икмәк юк, икенчеләрдә икмәк бар, күмәч юк. Бездә, әйтик, күмәч бары җомга көнне генә була. Әсгать минем кулдагы икмәк кисәгенә йотылып карады да иреннәрен ялап, авызын чапылдатып куйды.

— Мә, аша,— дип, сыныкны аңа тоттырдым. Кисәкне ул сак кына уртага сындырып, яртысын миңа сузды. Мин баш чайкадым.

— Икмәктән туйган адәм дә булыр икән,— дип, арык ботларын сузып, үлән өстенә утырды. Күлмәк итәген тез башларына әйбәтләп япты да ашыкмый гына ашарга кереште. Итәгенә төшкән валчыкларны шунда ук алып каба барды.

— Икмәкне басып ашарга ярамый,— дип аңлатты миңа.— Басып ашасаң тукландырмый ул. Әгәр бер валчыгын җиргә төшерсәң, язык була. Язык булгач, тәмугта яндыралар үлгәч.— Ул соңгы кабымын чәйнәп йотты. Тик урыныннан торырга ашыкмады. Туенып, күңеле хушланып алгач, ул гыйбрәтле бер әңгәмә сөйләп ташлады:

— Әтием әйтә, борын-борын заманда бер патша дала буйлап сыбай[1] китеп бара икән, ди. Бара торгач, моның корсагы ачкан. Куенындагы икмәген алып, атыннан төшми генә ашарга керешкән бу. Вакыты кыстау булган, ди, патшаның. Актык кабымны каптым дигәндә генә, бер валчыгы җиргә тәгәрәп төшкән. Патша шунда ук ияреннән сикергән дә әлеге валчыкны эзләргә тотынган. Әй эзләгән, әй эзләгән. Өч көн, өч төн буе, мүкәйләп, бөтен тирә-якны кыдырып чыккан. Тәки таба алмаган. Дүртенче көнне өенә кайтса, бөтен сарайны кара кайгы баскан, ди. Моннан нәкъ өч көн элек патшаның иң яраткан улы суга төшеп үлгән икән. Ходай каһәренең тагы да яманрагы

[1] *Сыбай* — ат өстендә.

төшүдән куркып, патша әлеге икмәк валчыгы төшкән урынга куш манаралы мәчет салдырган, ди. Моннан соң аны Ходай ярлыкагандырмы, юктырмы — анысы безгә мәгълүм түгел...

Әнә нинди нәрсәләр белә бу сәер малай!

Шыкыр-шыкыр шыкырдап, баш өстеннән түбәннән генә бер төркем саескан очып үтте. Монысын мин дә беләм: инә саескан балаларын очарга өйрәтә. Үткән атнада гына сыерчыклар белән карлыгачлар бала очырган иде. Бүген — саесканнар. Мин җәһәт кенә бер таш табып, саесканнарга төбәп ыргыттым:

— Саескан, саескан, күкәй эчкән, май эчкән!

— Тидерсәң соң! — дип сикереп торды Әсгать.

— Тисә, тия бирсен, сандугач балалары түгел әле.

— Саесканга да үз баласы газиз. Аның да эчендә җаны бар. Бөтен нәрсәләрнең дә җаннары бар — агачларның да, ташларның да, үләннәрнең дә... Җаннары булмаса яшәрләр идемени алар? Безнең бармак киселсә, кызыл кан ага, агач ботагын кырыксалар, ак кан ага. Тимергә тимерне суксаң чыңлый бит, әйеме. Шул — тимернең елавы була инде.

Белмәгәне юк бу Әсгатьнең. Адәм затыннанмы икән бу? Аның җитен чәче, зәп-зәңгәр күзләре, сары керфекләре мине бераз шомландырып та куя. Бөтен төбәктә бердәнбер ак малай ул — кара тавык оясында үскән ак үрдәк баласы төсле. Бишектә чакта аны пәри алыштырмадымы икән? Пәри шулай үзенең баласын калдыра да кеше баласын алып китә, ди бит. Булмас ла! Калган тагы пәри баласына шундый акыллы, шундый әйбәт булырга!

Без Сай чокырны да, Тирән чокырны да бер итеп, бөтен Тау артын әйләнеп чыктык. Юкәле кул урамына барып җиттек. Мөкеш чишмәсенә төшеп су эчтек. Әллә ничә бозау очраттык, ә безнең Акмаңгайның эзе дә юк. Арып-талып, өйгә әйләнеп кайттык. Кайтсак, безнең койма күләгәсендә Акмаңгай сузылып ята. Тиз генә капканы ачып, бозауны курага куаладык.

Алачык тирәсендә нәрсәдер мәшәкатьләнеп йөргән Олы инәем мине мактап каршы алды.

— Менә рәхмәт, улым, зур үстең инде, кул арасына керәсең.

— Мин түгел, Олы инәй, бозау зур үскән...

— Алайса, икегез дә зур үскән.

— Олы инәем, бу Әсгать исемле малай. Ул миңа бозау эзләште.

— Аңа да рәхмәт. Болай булгач, өчегез дә зур үскән. Барыгыз әнә, баздан алып, кунагың белән салкын катык эчегез.

— Икмәкләпме?

— Икмәге дә шунда, алачыкта.

— Ярар, мин кайтыйм инде,—дигән булды Әсгать,— өйдә йә йомырка пешергәннәрдер.

Моны ишетеп калган Олы инәем, хәйләкәр елмаеп, Әсгатьне кыстарга ук тотынды:

— Аш-ашка, урыны башка. Йомыркага да урын табылыр. Катык савытларыгызга берәр кашык каймак та салып бута.— Монысын ул миңа әйтте.

Әсгать башкача инәлтмәде... Алачык эченә җиләскә утырып, без тиз үк кашыкларны биетергә керештек. Үз савытын ялап куйгач, кунагым миңа яңа хәбәр салды:

— Күмәч турында бая мин шыттырдым. Ачлыкны адаштырыр өчен генә әйтелгән алдакчы сүз ул. Йомыркасы да шулай. Без икенче атна инде көненә бер тапкыр умач уып кына торабыз. Әти мәчеттән кайтмый, олы абыем калага китеп олакты. Дөньяны без Ибрай белән икәү генә алып барган булабыз.— Хәзер инде тавышында баягы тәкәббер гамьсезлекнең әсәре дә юк. Минем каршыда бәләкәч кенә бабай утырган да үзенең аһ-зарын сөйли.— Безнең тәндә хәзер бер тамчы да май калмады. Кичә Ибрай белән икәү корсакларны ачып, әллә ничаклы кояшта кыздырып карадык. Бөрчек тә май чыкмады. Шуннан мин, агаемны үчекләп, җыр чыгардым. Кешегә сөйләмәс булсаң, сиңа да әйтәм.

— Икмәк өсте, ант! — дидем мин.

— Болай да, ант итмәсәң дә ышанам.

Ибырашка-дурашка
Артын ачкан кояшка.
Ике кадак мае чыккан
Күчтәнәчкә күмәчкә.

— Кызыкмы җыры?

— Кызык, Ибрай нәрсә диде соң?

— Чабата калыбы белән башка тондырды. Менә орысы әле дә бүлтәеп тора. Бетәр әле, мәңгегә бармас. Ә төртмә җыр калыр. Аңа калып белән сугып булмый.

Әсгать беркатлы малай булып чыкты. Аның эчендәге тышында икән. Сер артыннан серен чишә генә бирде.

— Минем кушаматым «Сары черки»,— диде.— Төсемә карата да, телемә карата да кушылган ул. Телем әче минем. Тартай теленнән таба дигәндәй, шул телем аркасында эләгеп кенә тора миңа. Ә кушаматтан мин гарьләнмим. Исем атаудан бер җир дә кимеми. Харап икән —«Сары черки», имеш...

— Минем дә кушамат бар ла ул,— дигән булдым мин, аннан калышмаска тырышып.— Тик, әйтсәләр гарьләндерә.

— И-и-и-и-һи,— дип күтәреп алды Әсгать,— синең кушамат бер дигән — Кендек! Дөньяда иң кирәкле әйбер — кендек ул. Арт арбаны ал арба белән нәрсә тоташтыра? Кендек! Иң гайрәтле ир узаманына нәрсә диләр? Дөнья кендеге, диләр. Аның өстәвенә, син авылда бәби туган саен, өйдән өйгә, сыйдан сыйга йөреп, күпме игелек күрәсең — шул кендек аркасында!

— Кара аны, тагын бер исем атасаң сугышам,— дип искәрттем мин.

— Исәр син, синең кушамат миңа эләксә, мин мактаныр гына идем.

— Бик мактанасым килеп тормый әле,— дип кырт кистем мин. Ул да сүзне ары сузмады.

Шулай да «Кендек»не Әсгать авызыннан ишеткәндә, мин чыгырдан чыгып гарьләнмәдем, аны тыюым да

ачудан түгел, ә «кунак булсаң, тыйнак бул» дигәнне аңлатуым гына иде. Ә бүтәннәр әйтсә, йә әйтергә уйласа, җенем кузгала. Шуннан соң күп тә үтми без Хәмитҗан белән, көзге этәчләр сыман, канга батып сугыштык бит инде. Ләкин «Кендек», бара торгач, миңа нык ябышты, теш белән умырып та, тырнак белән куптарып та алырлык түгел. Ул мине җинде, мин җиңүче алдында баш идем...

Бер көн эчендә Әсгать мине бөтенләй сихерләде. Ул кайтып киткәч тә, үзен сагына башладым. Моннан ары без ташлашмас дуслар булдык.

Әсгать бәхетле затлардан түгел. Гомер буе аның башы бәладән чыкмады. Корбан бәйрәме алдыннан гына аңа бер-бер артлы ике җәфа килде.

Көтү кайткач та, бакча артыннан гына чыгып, Әсгатьләргә бардым. Болар, агасы Ибрай белән икәүләп, арткы абзарга мал ябып йөри. Үгезләре абзарга күндәм генә керә, ә сыерлары карыша. Үгетләп тә, чыбыклап та карыйлар — тыңламый. Ахрысы, сыерлары үз абзарыннан бизгән. Аптырагач, Ибрай сыерны атланып та әйдәп карады. Барып чыкмады. Теге кинәт бер якка тайчанды да пешмәгән сыбайлыны тирес өстенә атып бәрде. Аңа шул таман да. Үзе ул кешедән көләргә, адәм котыртырга бик әвәс.

Энесе шунда ук такмаклап та алды:

Атың арык, Ибырай,
Артың ярык, Ибырай!
Ат дигәнең пар мөгезле,
Тоз ялый да су сорай.

Ибрай, акаеп, Әсгатькә килә башлаган иде, энесе елт кына сүзне икенчегә борды:

— Үгез көчлеме, сыер көчлеме? — диде ул.

— Үгез! — дидек без Ибрай белән берьюлы, чөнки ир затының көчлерәк икәнен бот буе малай да белә.

— Әйдәгез, алайса, сыерны тарттырып кертәбез.

— Ничек?!

— Койрыгын үгез койрыгына бәйлибез дә! — Ибрайның баш юка аның. Мондый җөпле фикер аның уена бервакытта да киләчәк түгел, ләкин абый кеше алны бирмәгән булды:

— Тинтәк, юньсез! Агаең башында яралган акылны әйтеп ычкындырырга кем кушты сиңа?

— Әллә инде.

— Агаең исән чакта ким-хур булмассың, энем, баш түгел бездә — хәзинә.— Китте, китте бу «губернатор», кукраеп. Бу сүзләрен ул бигрәк тә минем колакка төбәп әйтте бугай.— Бар, китер монда үгезне!

Әсгать юаш ала үгезне сыер янына куалап китерде. Ибрай үз куллары белән койрыкны койрыкка ныгытып бәйләде. Әсгать, үгезнең мөгезеннән тотып, җай гына эчке абзар ягына уңайлады. Сыер, киресенчә, дүрт аягын да терәп, җиргә ябышты. Үгез дә буй бирмәде, егетлеген итте, бар куәтен җыеп, алга омтылды. Ике хайванның да койрыклары, сузылып, нечкәргәннән-нечкәрә барды. Дәрманга дәрт өстәп, Ибрай озын чыбык белән үгезнең сырт буена сыдырды. Ала мәхлук, үрә сикереп, алга омтылды. Нәрсәдер шырт итте. Баксаң,

үгез койрыгы булган урында бер карыш чамасы гына йөнтәс кыркынды серәеп тора иде. Кыркындыдан атылып кан килеп чыкты. Үгез яман итеп үкереп җибәрде дә, бөтен кураны бер итеп, үрсәләнеп чабарга кереште. Өй кырындагы утыртма читәнгә килеп бәрелде, читән авып төште. Шашып котырган бичара хайван Тау артына чыгып качты.

Без өчәүләп үгез артыннан торып йөгердек. Тик эңгер төшүгә генә аны кире алып кайттык. Ул шулчаклы чабудан, сызланудан тәмам йончыган иде. Башын да күтәрә алмый. Авызыннан туктаусыз селәгәй ага.

Чалмасын киеп, мәчеткә ястү намазына барырга дип чыккан Искәндәр агай безне капка төбендә каршы алды. Бу үгез маҗарасын Әсгатьнең апасы күреп торган иде. Эшнең асылын атасына җиткергәндер, күрәсең. Шуңа да Искәндәр агай бәйнә-бәйнә сорашып тормады:

— Кайсыгызның этлеге бу?— дип, кулындагы үгез койрыгын селтәп куйды.

— Әсгатең уйлап чыгарды,— диде Ибрай.— Башка да кергән нәрсә түгел иде, эти.

— Әлеге син! Атаң яхшы, инәң яхшы, эттән туган эт баласы! — Мәчет карты, оятсыз, әшәке сүзләр әйтеп, кече улының колагыннан эләктереп алды. Икенче кулындагы үгез койрыгының канлы юан башы белән Әсгатьнең аркасын каезлый-каезлый, абзар эченә алып кереп китте. Ястү намазы урынына карт үзенең кече улын — тәнендә бер тамчы да май әсәре калмаган Әсгатьне — хәлдән тайганчы ярды. Ибрай шунда ук каядыр шылды. Әсгатьнең ыһ дигән тавышы ишетелмәде, тик үгез койрыгы гына чыелдады. Бөтенләй күз бәйләнә башлады. Абзар эченнән Искәндәрнең ак чалмасы килеп чыкты.

— Сиңа нәрсә калган монда? Бар өеңә кайт! — дип җикеренде миңа. Әмма тукталып тормады, ары китте. Ишек төбендәге комганны тибеп очырды да өйгә керде.

Мин посып кына Әсгать янына кердем. Ул тирес өеме өстендә капланып яткан. Ара-тирә сулкылдап

куя. Аңа әйтер бер сүз дә таба алмадым. Баш очына тезләнеп утырдым. Ул, акрын гына кулын сузып, минем тез башымны капшады. Шулчак якында гына Олы инәемнең мине чакырган тавышы ишетелде.

— Мин монда, Олы инәем!

— Кайда?

— Абзар эчендә. Искәндәр агайлар абзарында! — үзем тавыш бирәм, торып китәргә үземнең әллә хәлем, әллә зиһенем җитми.

Олы инәем абзар авызына килеп туктады.

— Нәрсә эшләп утырасың монда, кеше абзарында, эңгер төшеп беткәч?

— Әсгатьне атасы үтергәнче тукмады. Үгез койрыгы өчен. Ул тора алмый хәзер.

«Нинди үгез, нинди койрык?» — дип төпченеп тормады ул. Ыңгырашып яткан Әсгатьне караңгыда капшанып килеп тапты да җай гына кулыннан тартып торгызды.

— Әйдә, улым, өйгә керик.

— Әл-лә аркам! — дип кычкырып җибәрде Әсгать. Олы инәем, җитәкләп, аны өйгә алып керде.

Искәндәрләрнең түр ягында сукыр лампа яна. Йорттагы барлык җан иясе чаршау эчендә, ахрысы. Шылт иткән тавыш юк. Бу якта бер Искәндәр генә сәке өстендә тезләнеп дисбе тартып утыра.

— Дисбеңне куеп тор әле, Искәндәр! — диде Олы инәем, тавышын күтәрә төшеп. Теге тыңламады.— Сиңа әйтәмче! — дип кабатлады.

Карт дисбесен куймады, шулай да тартудан туктады. Алга сузылган ике кулының бармаклары төймә тоткан көе бөгәрләнеп, катып калды.

— Әйдүк, җиңги. Хуш... — диде, тешен кысып кына.— Түрдән уз.

— Иманың бармы синең?— Ул Әсгатьнең буй-буй булып кан сауган аркасын ачып күрсәтте.—Ерткыч син. Алай дисәң, ерткыч та үз баласын бу кадәр үк изеп, имгәтеп ташламас. Син аннан да кансызрак. Ходайдан

курыкмасаң, адәмнән оялыр идең. Болай булгач, синең мәчеттән чыкмый намаз укуың корысын!

— Хода гамәленә тел тидермә, җиңги! Тәңре каргышы төшә күрмәсен...

— Ә син адәм баласын рәнҗетмә. Адәм каргышы төшсә, гүреңдә дә урын таба алмассың.

Олы инәемнең болай ачуланганын мин бер тапкыр да күргәнем юк иде. Әйтерсең ул — бәбкәләрен яклап, тилгәнгә ташланган ана каз. Бәбкәсе дә үзенеке түгел бит әле. Үзенеке түгел димен дә... Мөгаен, Олы инәем Әсгатьнең дә кендек әбиедер әле.

— Кара аны,— дип кисәтте картны,— бармак белән чиертәсе булма балага. Аның күңеленә хәзер ачу чәчсәң, соңрак нәфрәт урырсың. Иң яман каза — ата белән бала дошманлыгы.

Искәндәр карт бүтәнчә әрепләшмәде. Башка кеше аңа шулайрак тел тидерсә, карт пыр тузар иде. Минем Олы инәемә каршы әйтә алмый шул. Авылда аңа берәү дә каршы әйтми.

— Әй, кем бар анда чаршау эчендә?— дип кычкырды Искәндәр.— Кунак килгәнен ишетмисезмени?Самовар куегыз!

Теге якта нәрсәдер кыштырдады, нәрсәдер шалтырады, ләкин җавап булмады. Олы инәем Әсгатьне, кулыннан тотып, сәкегә утыртты да, без кайтып киттек.

— Өзелгән үгез койрыгы төзәләме, Олы инәем?— дип сорадым мин, кайтып барышлый.

— Төзәлә. Бөтенесе дә төзәлә. Тик өзелгән өмет белән калган хәтер генә төзәлми.— Аның бу соңгы сүзләрен мин, әлбәттә, аңлап бетермәдем.

Икенче бәла Әсгатькә иртәгә гает дигәндә килде. Бәйрәм көнне төштән соң урамдагы бөтен малайлар, Акманай суына ат йөздерергә барабыз дип, алдан сөйләшеп куйдык. Мортаза абыем миңа да күк алашаны биреп торырга вәгъдә итте. Акманайда ат йөздерү — үзе бер тамаша ул. Анда барганчы, һәр малай үз атын кыргычлап тазарта, ялларын тигәнәкләрдән әрчи, хәтта,

кызлар чәче сымак, толым-толым итеп үреп тә куя. Купшыраклары әлеге толымнарга төрле-төрле тасмалар да тагып җибәрә. Безнекеләр алай кыландырганны яратмыйлар. Мин күк алашаны буем җиткәнчә җирдән, буем җитмәгән урыннарын өстенә менеп кыргычладым. Сыладым-сыйпадым да Әсгатьләргә киттем. Әсгатьнең инде аркасындагы кутырлары кубып төшә башлады, йөзендәге кара янган урыннар да саргылтзәңгәргә әйләнде. «Нишләдең?» — дип сораганнарга ул: «Үгез сөзде»,— дип җавап кайтарды. Миңа да шулай әйтергә кушты. Бахыр үгез өстенә юк гаепне ташлап, нигә алдашабыз икән без?Монысын мин аңлап җиткермим әле.

Кара уртасында кияү куенына керергә әзерләнгән кәләш сыман бизәлгән сыңар күзле кара бия гамьсез басып тора. Бия түгел, торганы белән кәртинкә. Ике колагына чигелгән чуклы кульяулыклар бәйләнгән, ялына аллы-зәңгәрле тасмалар кушып үрелгән, хәтта алгы бәкәлләренә ак чүпрәкләр уралган, койрыгына эреле-ваклы тәңкәләр тагылган. Үзе кара сөлек төсле елкылдап тора. Тик күз генә берәү. Анысы да, гамәлгә калгандай, чылт-чылт йомылып, эрен агыза, каһәрең. Бу кадәр бай җиһаз кара биягә каян килде икән дисезме? Чамалавы кыен түгел: малайлар ике апасының да бирнә сандыгына ярыйсы гына тирән чумып чыккан булырга тиеш. Йә алай да түгелдер. Йә апалары үзләре биреп торгандыр. Әсгать хәл эчендә калганнан соң, алар бөтенесе дә йомшара төште.

Шундый итеп бизәнеп-төзәнеп, купшылыкның чиген узган кыска муенлы кара биянең юкә нуктасын ике яктан Ибрай белән Әсгать тотып алган. Алар, такмак әйтеп, бер урында сикергәләп биеп тора:

Һайт, кара юрга! Һайт, кара юрга!
Аккош муен, нечкә бил.
Җилне узып җил дә җил,
Һайт, кара юрга!
Тавис койрык, шәм колак,

Бер адымы биш булыр,
Аны менгән узаман
Хан кызына иш булыр.
Һайт, кара юрга! Һайт, кара юрга!
Алтын тояк, ефәк ял!
Бер мөлаем караш сал!
Сал! Сал! Сал!

Шушы кадәр олы мактауны кара бия азагына чаклы баш та какмый, койрык та кыймылдатмый, үтә тыныч, үтә сабыр тыңлап торды. «Бер мөлаем караш сал! Сал! Сал!» дигән ялвару сүзләрен ишеткәч кенә, дертләп киткәндәй итте. Шулай да җырның күрәләтә ярамсак булуы ошамады бугай биягә. Әсгать ягына кинәт башын борып, тегенең сул колагын төбеннән үк умырып та алды, ә иртәгә гает иде...

Быелгы бәйрәмнең кызыгы булмады. Мин кан төкереп үткәрдем, дустым гомерлеккә сыңар колаклы булып калды.

...Кичкә табан күк алашаны Тау артына чыгарып тышаулыйм дип барганда, «Губернатор урамы»на кереп, Әсгатькә сугылдым. Ул да кара биягә атланып чыкты. Тирән чокыр аръягына илтеп атларны тышаулагач, без үлән өстенә утырдык. Мин дустыма дигән күчтәнәчемне алмакчы булып кесәмә тыгылдым, ләкин баллы чәкчәк тоташы белән укмашып киндергә ябышкан иде. Кесәне бөтенләй әйләндергәч кенә без аны куптарып ала алдык. Күчтәнәчнең яртысын бүлеп, Әсгать миңа сузды.

— Бугазыма җиткәнче тыгындым, менә! — дип, авызны ачып күрсәттем.

Ул һәрвакыттагыча, ашыкмый гына, кадерләп кенә ашарга кереште.

— Миңа бүген тагы эләкте,— дип хәбәр салды дустым, колаксыз яңагын сыйпап.

— Нәрсә өчен?

— Җыр өчен. Иртән торганда этием башы-күзе белән каз мамыгына баткан иде. Төнлә аның мендәр тышы ертылган икән. Мин шунда ук әйтеп куйдым:

Әтиемнең мендәре —
Пыр-пыр итә йоннары,
Әти үзе пыр туза
Мендәреннән элгәре.

— Һи, авызыңа шайтан төкергере! — дип, кыптыр ката белән җибәрде. Җан җиргә килеп тиде. Бөгелдем дә төштем. Үзем дә исәр инде, бер телемне тыя алмыйм.

Минем каршыда утырган җитен чәчле, сыңар колаклы Әсгать кинәт караганда бер тоткасы төшкән самоварга охшап китә. Батып барган кояш нурлары да, самовар җизендә чагылып уйнаган шикелле, аның чәч арасында җемелди. Тау астында, түбәндә, күзгә күренер-күренмәс кенә, сыек зәңгәрлек төшә.

— Әнә ул зәңгәрлек,— ди Әсгать,— күктән коела. Көн буе күк йөзе кыза да, кичкә таба, аннан кубып, шулай зәңгәр тузан сибелә.

Әлбәттә, дөресен әйтә ул. Югыйсә каян чыксын ул зәңгәрлек? Җирдән күтәрелсә, бары бу күтәрелер иде. Җир йөзендә ниндидер моңсу тынлык ята. Югарыда болыт та, түбәндә җил дә юк. Шул тынлыкны ярып, моннан ерак түгел тугай юлы буйлап кемдер, үтә моңлы, үтә зарлы итеп, җыр җырлап үтте. Сыбай бара булырга тиеш ул. Җәяүле кеше болай ук иркен, болай ук ямансу җырлый алмас иде. Мин үзем дә, атка атлансам, йә шашып дәртләнәм, йә яман моңаям.

Без җырның бары соңгы сүзләрен генә ачык итеп ишетә алдык:

Чуртан үрли суның үренә,
Кеше керми кеше гүренә...

— Шәйхи малае Рамазан бу.— Әсгать җырчының тавышын шунда ук танып алды.—Атасы мәрхүм турында зар елый ул.

Бөтенесен дә белә бу Әсгать...

Моннан бер атна гына әүвәл бар авылны тетрәткән шундый хәл булды. Кашафетдин белән Шәйхулла исемле агалы-энеле ике кеше Лекаревка дигән рус авылы

янында Дим аша күпер салып ята икән. Күпер менә-менә бетте дигәндә, Кашафетдин, ялгыш басып, суга егылып төшкән, йөзә белмәгән агасын коткармакчы булып, Шәйхулла Димгә сикергән... Шул чумудан башкача калыкмаган. Кашафетдин, алай-болай итеп, ярга килеп сугылган. Ә Шәйхулла гаип булган. Өч көн үткәч кенә, аның гәүдәсе кайдадыр Дим түбәнендә килеп чыккан. Ул башы белән елга төбендәге иске багана очына барып сугылган булган. Шуннан һушы китеп батып үлгән.

Рамазанның тавышы күптән тынды, ә сүзе белән моңы күңелдә торып калды.

Кеше керми кеше гүренә...

— Әсгать, Әсгать,— димен мин оеп утырган дусыма,— ә бит уйлап карасаң, Шәйхи үз гүренә түгел, агасының гүренә кергән. Үләргә Кашафетдин агай тиеш булган.

— Әллә инде,— Әсгать баш чайкады,— монысын мин белмим. Олы инәеңнән сорарга кирәк. Кеше тууы турында ул бөтенесен дә белә, үлем турында да, мөгаен, беләдер.

Ләкин бу турыда мин Олы инәемнән сорамадым. Үлем турында төпченгәнне яратмый ул.

Байтак сүзсез утыргач, Әсгать ниндидер серле дә, шомлы да тавыш белән сөйләргә тотынды.

— Мин бит монда үзем өчен яшәмим, бүтән бер малай өчен яшим. Сер саклардан булсаң, ике серемне сөйлим сиңа. Антмы?

— Икмәк өсте.

— Син бит үрге очтагы чем-кара чәчле, чем-кара күзле Фәридә исемле ятим кызны беләсең. Аларның йорты биек...

— Беләм.

— Шул Фәридәне үги әнисе көн саен йә тирги, йә тукмый. Минем шикелле бәхетсез ул. Без — ятим Фәридә белән икәү бер ишбез. Миңа ул хакта әнә теге Әүлия чишмәсе янындагы яшен суккан куш каенның берсе әйтте. Дөньяда минем иң кызганган кешем — әнә

булсам, мине чит ояның чебеше урынына шулчаклы кыерсытырлар идемени? Беләм мин, бер кыенның бер ансаты булачак. Әнә тегеннән, Каенлыкул ягыннан гына өрелеп килер дә ул өермә мине алып та китәр. Гарасат купкан саен, мин абзар башына менеп, көтеп торам. Тик әлегә вакыты җитмәгән. Монда әчәсе суым эчелеп, йотасы утым йотылып бетмәгән.

Минем йөрәгем жу итеп китте:

— Алайса, сине пәри алыштырган булып чыга... Алайса, син — пәри баласы...

— Юк, пәри баласы ак булмый, кара була. Әйтәм бит, мине монда бүтән дөньядан, бәхетлеләр иленнән китереп ташлаганнар. Мине юллап табачаклар барыбер...

Моннан соң бик күп давыллар булды, өермәләр узды, әмма алар минем дустыма тимәделәр. Әсгать үзе дә кабатламады бу хакта — бервакытта да. Мин дә хәтерләтмәдем.

Язмыш белән бәхәсләшеп, без үсә бардык. Буйга җиттек. Әсгать уйчан табигатьле, сабыр холыклы егет булып китте. Бәләкәй чакта аны атасы: «Шайтан сабагына йөрмә!» — дип, мәктәпкә барудан тыйды, соңыннан үзе күңел салмады. Ул хәреф таныр-танымас көе калды. Үзе бөтен авылда чәчән телле сүз остасы, җыр, такмак чыгаручы булып дан алды. Шул әче теле, тапкыр сүзе аркасында аңа ара-тирә тукмак та төшкәли торды. «Язгына күрә җәзасы»,— дип, ул телен дә тыймады, җәбер-җобырга да исе китмәде.

Берзаман бөтен ил өстенә көрән өермә ябырылды. Ул, өерелдереп-өерелдереп, җиләк кебек егетләрне ерак якларга алып китте. Бәхет иленнән түгел, бәхетсезлек иленнән килгән иде бу гарасат. Ул, киресенчә, безне рәхәтлек дөньясыннан хәвеф дөньясына олактырды. Әсгать тә инде ефәк үләнле газиз туфракның үз аягы астында икәнен күптән аңлаган иде. Шул өермә каккалап-суккалап безне ир итте. Кайсыларыбызга әҗәлдән, кайсыларыбызга даннан өлеш чыкты. Әмма, бөтенесеннән дә югарырак күтәрелеп, туган туфракның изге нуры тереләрнең рухын, үлеләрнең гүрен яктыртты.

Бик күпләребезне утлы өермә кире әйләнеп кайтмас җирләргә алып китте. Әсгать тә хәбәрсез гаип булды. Юк, моңа ышанып булмый. Ул хәбәрсез югала торганнардан түгел иде. Күрәсең, аның күзләренең зәңгәрлеге кайдадыр күкләрнең зәңгәрлеге белән барып тоташкандыр. Үлгәндә ул җирдә ятып, тартышып, чәбәләнеп, чырай сытып үлмәгәндер; йә атта җилеп барганда ияр өстеннән атылып төшкәндер, йә самолётта очып килгәндә һавада дөрләп янгандыр. Ул яхшы күңелле, матур кеше иде. Чибәр түгел, матур иде. Яхшы күңелле матур кешенең ямьсез үлүе мөмкин түгел. Ул шагыйрь иде. Шагыйрьнең ямьсез үлүе мөмкин түгел.

Әсгатьне заман чоңгылына бөтенләй батты дисәм дә, байтак еллар узгач, аның турында, күзгә күренмәс җил сыман, колак ишетмәс нур сыман, бер хәбәр ил өстеннән сак кына тирбәлеп үтте. Аны галәм төпкеллегенә юл ярган азамат ирләрнең берсе китергән, диделәр. Имеш, баягы галәм азаматы ерак галактикаларның ерагында планетадан планетага сикереп атлап барган җитен чәчле, зәңгәр күзле, сыңар колаклы яшь егетне шәйләп алган. Кулында аның сүнмәс чырагы бар икән. Шул чырагы белән егет җиһандагы сүнгән йолдызларны берәм-берәм яңадан кабызып, сүнә барганнарына ут өстәп йөри икән. Монысына ышанырга була. Чөнки ул шагыйрь иде. Димәк, шагыйрь үзенең төп эшенә тотынган...

С ү з л е к   ө с т е н д ә   э ш .

*Фәкыйрь, тәкәббер, мирас, котаймый, мөлкәт, язык, чәчән телле, гарасат, газиз* сүзләрен аңлатмалы сүзлектән карагыз.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Сезгә Әсгатьнең кайсы сыйфатлары күбрәк ошады? Аның әтисенә, абыйсы Ибрайга, гомумән тирә-юньгә карашы күңелгә ничек тәэсир итә?
2. Әсгать белән хикәянең герое ничек дуслашалар? Ул дуслыкның нигезендә нәрсә ята? Үз тәҗрибәгездән чыгып, чагыштырып карагыз.

3. Әсгатьнең аң үсеше, һәр җан иясенә җылы карашы, мәрхәмәтле булуы нинди фикерләр уята? Тексттан мисаллар китерегез.
4. Искәндәр агайның улына биргән җәзасы белән килешәсезме? Яхшылык белән явызлык турында фикер алышыгыз. Үзегез кичергән, күргән хәлләр белән чагыштырып сөйләгез.
5. Олы инәйнең сүзләрен анализлап, аңа үзегезчә бәя бирегез: «...тик өзелгән өмет белән калган хәтер генә төзәлми».
6. Балалыкка моң, сагыш өстәгән фаҗигале хәлләргә Әсгатьнең, хикәя героеның карашлары ничек? Сез аны уртаклашасызмы?
7. Халык моңнары повестьның эчтәлегенә ни рәвешле сибелгән? Рамазан, Әсгатьләрнең җырлары шәхеснең формалашуында нинди әһәмиятле бизәк булып тора? Тексттан укып, бергәләп тикшерегез.
8. Әсгатьнең ике сере аның кайсы сыйфатларын ачып бирә? Нәрсә ул сер? Сезнең сер саклауга карашыгыз ничек?
9. Ни өчен бу әсәр «Озын-озак балачак» дип исемләнә? Кушма сүзне ничек анализларсыз: сезнеңчә, озын — нәрсә, озак — нәрсә?
10. Балалык хыялы белән чынбарлык арасында нинди бәйләнеш булыр? Үзегезчә бәя бирегез. Сез нинди хыяллар белән яшисез?
11. Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» повесте ни өчен автобиографик әсәр? Автобиография нәрсә ул? Исегезгә төшерегез.

**Мөстәкыйль эш.**

Тексттан мәкаль-әйтемнәрне, җор сүзләрне табып, дәфтәрегезгә языгыз. Эчтәлекне ачуда аларның нинди әһәмияте бар?

## «ОЗЫН-ОЗАК БАЛАЧАК» ПОВЕСТЕ ТУРЫНДА

Мостай Кәримнең бу повесте — тирә-юнь хәлләренә күз ташларга, кешелек, яшәү һәм үлем турындагы мәңгелек төшенчәләр тирәсендә уйлануларга, тирән фикерләү дөньясына этәрә торган әсәр. Яшәүсез үлем юк, үлемсез яшәү юк. Моңа бер генә хакыйкать җавап бирә ала: табигатьнең яратылышы шулай. Мәңгелек үлчәменә әверелгән мондый контраст төшенчәләр беркемнән бәйсез, һәркайсы үз юлы белән баручы юнәлешкә әверелгән.

Повестьның персонажлары, вакыйгалары бик реаль, фаҗигасе дә, шатлыклары да, шаянлыгы һәм җитди хәлләре дә укучының йөрәген җилкетергә, хис ташкы-

нын кузгатырга җитә кала. Язучы аны халыкның борынгысыннан, тарих иңкүлегеннән иңләп килә, балачак яшәеше аша, аның самими хыяллары һәм сабыйлык гаделлеге белән инандыра, озын-озак балачакның эчкерсез, ихлас якларын ача. Чыннан да, яшәү төшенчәсенә үз хыялларын, үз үлчәмен биргән малайлар, Әсгать белән повестьның герое, укучының киңәшчесенә, якты хисләр тудыручы якын кешесенә әйләнә.

Әсәрдә Олы инәй образы бик үзенчәлекле. Ул — үткән белән хәзерге буынны бәйләүче, тормыш ыгызыгысына юнәлеш биреп, өлкәнен дә, яшен дә гаделлеккә өндәүче ил анасы. Әсгать һәм хикәяләүче малай образлары Олы инәй белән тулыланып китә, аларның эш-шөгыле, дөньяга карашы, инанган нечкә җанлы ил анасы тәэсирендә формалаша, яхшыны начардан аерып карарга өйрәнә. Болар Олы инәйнең гыйбрәт бирә торган мәкаль-төшенчәләрендә чагылыш таба шикелле: «...Иң яман каза — ата белән бала дошманлыгы... Тик өзелгән өмет белән калган хәтер генә төзәлми».

Балачак шуклыгы, ихлас самимилек еш кына фаҗигага, үлем белән аралаша; көтмәгәндә яшьлекнең ашкынулы омтылышы, катлаулы хәлләр белән очрашып тору укучыны хис-кичерешләр чоңгылына ташлый. Әмма бирелгән өзекләр моңсулык кына түгел, яшәү дәртен кузгаталар; балачакның хыялга байлыгын, шук-наянлыгын кызыксынып, әсәрнең эчтәлегенә чумып укыйсың.

Балалар дөньясы — бары дөреслекне генә кабул итә ала торган якты дөнья ул. Аның хакыйкате шул. Әсгать — үтә беркатлы, әмма эчке байлыгы һәм моңнары белән хәйран итә торган халык баласы.

Балачакның газаплары да, куаныч-сөенечләре дә — ерак тарихның бизәкләре, һич онытылмый торган тормыш ул.

**Язма эш (сайлап алу өчен).**

1. Моң һәм сагыш, шәфкатьлелек һәм рәхимсезлек турында хикәя төзегез. Үзегез укыган текстка таянып, дәлилләп күрсәтегез.
2. Шагыйрь җанлы Әсгать турында план төзеп, кечкенә инша языгыз. Анда үзегезнең дә караш-уйлануларыгыз чагылсын.
3. Бүлек буенча сценарий языгыз. Иң уңышлы чыкканын сәхнәдә уйнап карагыз.



## *Шәүкәт Галиев*

## *(1928—2011)*

Шәүкәт Галиев — балалар әдәбиятында шаян шигырьләре белән мәгълүм шагыйрь. Ул тормышның кызыклы якларын табып, балалар белән бүлешә, аларны рәхәтләнеп көлдерә, шул ук вакытта гыйбрәт бирә, яхшыны начардан, затлыны затсыздан аерып күрсәтә. Шуңа да шагыйрь сурәтләгән хәлләр үтемле булып йөрәккә керә, онытылмый, гел укучыны үзенә тарта.

Ш. Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында крестьян гаиләсендә туа. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, колхозда эшли. Туган җирен ихластан яратып, аның салкынын һәм ялкынын, кырыс тормышын җанга якын итеп кабул итә: «Туган ягым, аның табигате,— дип яза ул,— сүзгә күчереп бетерә алмаган җыр булып күңелдә яңгырап тора»[1].

Аның малай чагы сугыш елларына туры килә: «Авыр еллар иде. Мин яланаяк җир сөреп йөрдем. Өметләнеп җырлый-җырлый иген иктем. Ул елларның уңышы сыек иде... Күңелгә төшкән орлыклар күпьеллык һәм мул булып чыкты»[2]. Шагыйрьнең

[1] *Галиев Ш. Г.* Сайланма әсәрләр. 5 томда. 5 т.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2002.— 337 б.

[2] Шунда ук.— 188 б.

«Әткәйгә хат» (1958) поэмасы сугыш чоры балаларының барысына да моңсу һәйкәл булып тора. Күрәсең, әткәсен югалту, еллар үткән саен, әдипнең күңел сагышына әйләнеп, каләм иҗатына әтәргән.

1953 елны ул Казанга килә. Кичке урта мәктәпне тәмамлагач, белемен тирәнәйтү өчен, Мәскәүдә Язучылар берлегенең Югары әдәби курсларында укый. Шул ук вакытта иҗат эше белән дә шөгыльләнә, төрле елларда «Чынлык», «Шалт, Мөхәммәтҗан!», «Фикердәшкә», «Сөенечләрем, көенечләрем» кебек шигырь җыентыклары басылып чыга.

Ш. Галиев татар балалар әдәбиятын үстерү юлындагы нәтиҗәле хезмәтләре өчен, 1972 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә, 1982 елда Халыкара бүләк — Х. К. Андерсен исемендәге Почётлы дипломга һәм 1995 елда «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән олы исемгә лаек булды.

Шәүкәт Галиев 2011 елның 7 маенда Казанда вафат булды.

## ШӘВӘЛИ МАҖАРАЛАРЫ

### ШӘВӘЛИ СӘГАТЕ

Миңа булды бит әле
Әтиемнең сәгате!
Сәгате дә сәгате —
Әйбәтнең дә әйбәте!

Әйтерсең лә яхшы ат,
Чаба гына, сыптыра —
Өйдә ничә сәгать бар,
Һәммәсен узып тора!

### ҖИЛ ТЕГЕРМӘНЕ

Җил тегермәне
Җилпенеп тора,
Бүрәнәләре
Селкенеп тора!

Куркып та куям
Мин моны күреп,
Очып китмәсен
Вертолёт кебек!

## АТЛАП ЧЫКТЫМ ИДЕЛНЕ...

Сызгандым да балакны,
Таяндым да таякны,
Суздым гына аякны —
Атлап чыктым... Иделне...

«Булмас, булмас»,—диденңме?
Кем ялган сөйли, минме?
Чын-чынлап чыктым инде,
Нәни иде Иделе —
Башланган җире иде!

## ШӘВӘЛИ ХӘЙЛӘСЕ

Усал эт күргәч,
Ул болай диде:
— Мин тәмле түгел,
Ашама мине!..

## ШӘВӘЛИ НИЧӘ ЯШЬТӘ?

Бу сорауга заманында
Ул болай җавап биргән:
— Биш тулырга унбиш минут —
Дөп-дөресе шул! — дигән.

Инде яңадан сорыйсы
Вакыт та җитте менә.
— Унбиш тулырга биш минут! —
Ди хәзер җитди генә...

## СЕРЕН БЕЛДЕМ СОҢЫННАН

Кара бәрән ап-ак мичне
Шытыр-шытыр кимерә.
Әйтерсең лә акшар ашап,
Кирпеч ялап симерә!..

Мичтән куып бәрәнне,
Бирәм пешкән бәрәңге.
Бәрән бәрәңге капмый,
Мичтән дә шәпне
тапмый.

Ашамасын — әйтерсең лә
Акшар ашап көч керә!
Китаптан укып, мин моның
Серен белдем соңыннан:
Сөяккә ныклыкны бәрән
Алган акбур онынннан!

Җай табалмагач һич тә,
Борыч сиптек без мичкә.
Борынына борыч кергәч
Төчкерә дә төчкерә.

...Акбур ваклап, бәрәннәргә
Салам да мин бер учлап,
Үземнең ашны борычлап
Ашыйм хәзер тынычлап!

## УЗЫП КИТТЕМ МИН АВТОБУСЛАРНЫ

Әй барам, барам,
Барам берзаман,
Барам бик кызу,
Барам бик яман.

Аяк астында
Уйный тик тузан.
«Эһ» тә итмичә
Барсын да узам.

Узып киттем мин
Автобусларны,
Велосипедта
Чыккан дусларны.

Троллейбусларны,
Самосвалларны,
«Жигули»ларны
Уздым аннары.

Артта калдырдым
«ЗИЛ»ны, «Волга»ны,
«Запорожец»ны
Әйтмим дә аны!

Ышанмыйсыңмы
Моңа әллә син?
...Туктаган иде
Алар һәммәсе!

## ТАНЫШ ШОФЁР

Таныш шофёр — Шәриф абый
Очрый һәр иртә,
Машинасын туктата да
Утыртып китә.

Таныш шофёр — Шәриф абый
Йөри бик ерак,
Эше шундый, кичкә генә
Кайтасы урап.

Кичкә кадәр йөрергә соң
Вакытлар кайда —
Күрше авылдан Шәвәли
Тәпиләп кайта...

## АТ «ЙӨРТҮЧЕ» МАЛАЙ

Мотоциклны бирдек —
Мотоциклда йөрде.
Аннары соң ул безнең
Атта йөргәнне күрде.

«Бик гади техника!» — дип,
Шәһәр кунагы көлде.
«Ат йөртү соң эшме?» — дип,
Урындык куеп менде...

Уйнап кына атланды,
«Булды бит!» — дип мактанды.
Боргаланды, кыланды
Һәм төшеп тә капланды.

Аһ-ваһ килеп ятты да
Аксап-туксап кузгалды.
— Кайда моның тормозы? —
Диеп кенә сорады.

Әйттек кунак егеткә:
— Озак булыр аңлату,
Тормоз белү — бернәрсә,
Кирәк атны ярату.

Машинаң кебек итеп
Ярату җитми хәтта —

Ат та сине танысын,
Яратсын сине ат та!

Әйтү бушка китмәде,
Төшендерү ярады —
Беренче кат ул атның
«Фара»сына карады...

## ЯЛГЫШ АДЫМ

Трамвайга асылынып
Йөргән чакта шаярып,
Уйлагандыр — егетлек,
Өлгерлек бу, чаялык!

Бер аяк белән баскан,
Бер кул белән ябышкан.
Бик тә хәтәр ярышкан,
Бик тә хәтәр ялгышкан...

Калган ялгыш адымда —
Ялгыш баскан аягы.
Сакланып кына атлый —
Хәзер култык таягы...

## СВЕТОФОРНЫҢ ӨЧ СҮЗЕ

Урамнарны
Күзәтеп,
Узганнарны
Кисәтеп,
Чатта тора
Светофор,
Сакта тора
Светофор.

Янып тора
Өч күзе,
Күреп тора
Ич безне.
Әйтеп тора
Өч сүзне:
— Кузгалма! — ди
Кызыл күз.
— Сабыр! — дия
Сары күз.
— Ярый! — дия
Яшел күз.

Без дә аңа
Карыйбыз,
Күзебезне
Алмыйбыз,
Ни әйткәнен
Аңлыйбыз:
— Кузгалма! — ди
Кызыл сүз.
— Сабыр! — дия
Сары сүз.
— Ярый! — дия
Яшел сүз.

## АКЫЛ ТЕШЕ КЕМГӘ ЧЫГА?

Абый нигә дәшми дисәм,
Ник яңагын тоткан дисәм,
Бүген аңа
Акыл теше чыккан икән!

Сорадым мин әниемнән:
— Акыл теше кемгә чыга?
Әни әйтте:
— Әйткән сүзне тыңлаучыга.

Сорадым мин әтиемнән:
— Акыл теше кемгә чыга?
Әти әйтте:
— Үз сүзендә торучыга.

Сорадым мин әбиемнән:
— Акыл теше кемгә чыга?
Әби әйтте:
— Укып гыйлем җыючыга.

Сорадым мин үз-үземнән:
— Сабырлыгың чыдар микән?
Ай-һай әле
Сиңа ул теш чыгар микән?..

## КҮКТӘ НИЛӘР БАР?

Барган җирдән тукталам да
Күк йөзенә карыйм мин,
Бик озак итеп карыйм мин,
Ниләр барын таныйм мин.

Син дә шулай карыйсыңмы,
Мин күргәнне күрәмсең—
Әнә Аккош һәм Каракош,
Әнә Козгын, Күгәрчен...

Кәлтәне дә, Еланны да
Күрәм күкнең түрендә,
Бар Жираф та, Арыслан да,
Бар Куян да, Бүре дә!

Юк дисеңме, ышанмыйсың,
Ялганлый, дип көләмсең?
Исемнәрен белмәсәң дә,
Җисемнәрен күрәсең!

Әнә үгез көтүчесе
Үгез бозауны эзли,
Ай, этләре белән укчы
Читтән Төлкене күзли...

Күрәсең Мичне һәм Кызны,
Көянтәне, Табакны,
Күрәсең тагын Йөкчедән
Бер читкә качкан Атны...

Әллә һаман ышанмыйсың,
Әллә һаман көләсең?
Бу бит — йолдыз исемнәре,
Күктә шуны күрәсең!

## ТЫЛСЫМЧЫ МАЛАЙ

Орчыгын алып әбинең
Тота да менә шулай,
Терсәкләрен кагып-кагып
Уйнап җибәрә... курай!

Рояль итә дә куя ул
Өстәлне күз алдында.
«Клавишлар»ына баскалап
Моңлана үзалдына.

Урындыкны тотса, Ренат
Гармунга әйләндерә.
Телисең икән, биетеп,
Янында әйләндерә!

Йә линейка-скрипкада
Сыздырырга керешә.
Кыланышлары үзенә
Бигрәк инде килешә.

Ул нәрсәгә кагылса да
Көйләр агыла сыман...
Болар тиздән чынга ашар,
Көлмәгез тылсымчыдан!

## МАГНИТОФОН ОНЫТМЫЙ...

Ун яшь тулгач Хәнифкә,
Бик күп булган теләкләр.
Иң соңыннан бабасы
Магнитофон сөйләткән.

Күңелләре нечкәреп
Тыңлап тора әнисе —
Өч яше тулган көндә
Шигырь сөйли Хәнифе!

Тыңлый Хәниф үзе дә,
Тик аңламый берни дә...
Ишетсә дә көн саен,
Бу телне белми лә!

Үзе ни сөйләгәнне
Үзе төшенми торгач,
Аптыраган улына
Әтисе була тылмач...

Күрсәң иде малайның
Ничек гаҗәпләнгәнен:
— Кара әле, яшь чакта
Мин татарча белгәнмен?!

«И туган тел...» — ди Хәниф
Магнитофон аркылы.
Бер белгәнен онытмый —
Магнитофон акыллы!

## ТУГАН ТЕЛ

Туган тел — иң татлы тел,
Туган тел — иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма —
Туган телне онытма!

## БЕЗ — ТУКАЙ ОНЫКЛАРЫ

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без —«Туган тел»дән туганнар —
Без — Тукай оныклары!

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Шагыйрь ни өчен үзенең шигырьләрен көлкеле итеп яза? Шул турыда уйлап карагыз, үзара фикер алышыгыз.
2. Дөньяны танып белү, гыйлем, белем эстәүгә кайсы шигырьләрне сайларсыз? Аларның шигъри эшләнеше, ритм, рифма турында фикер алышыгыз.
3. «Ялгыш адым», «Ат «йөртүче» малай» шигырьләрен анализлагыз, аларның шигъри эшләнешләре турында ниләр әйтә алырсыз?
4. Тапкырлыкны, җорлыкны күрсәткән шигырьләрдә («Шәвәли сәгате», «Җил тегермәне», «Шәвәли хәйләсе», «Узып киттем мин автобусларны» һ. б.) балалар дөньясы ничек сурәтләнә?
5. Туган тел турындагы шигырьләрнең язылышын, рифмалашуларын тикшерегез. «Туган тел», «Без — Тукай оныклары» шигырьләрен яттан өйрәнегез.
6. Шәүкәт Галиев шигырьләренең кайсы яклары сезгә ошады? Укыганда аларның нинди үзенчәлекләренә төшенә алдыгыз?

**Язма эш.**

1. Шәвәли образын ачу өчен, киңәйтелгән план төзегез.
2. Шәүкәт Галиевнең тагын кайсы шигырьләрен укыганыгыз бар? «Әткәйгә хат» поэмасының бер өлешен укып, фикер алышыгыз.

## ДУСЛЫК БАЛЫ

Дустым миңа алып килгән
Күчтәнәчкә башкорт балы.
Янәшәгә мин дә куям —
Җыйган татар бал кортлары.

Гәрәбәдәй якты икән,
Икесе дә татлы икән:
Синең бал да кәттә икән,
Минем бал да яхшы икән!

Кысташабыз алмаш-тилмәш,
Макташабыз алмаш-тилмәш,
Очрашабыз алмаш-тилмәш —
Бик күңелле дустың килгәч!

Кыр-болыннар янәшәләр,
Гөлчәчәкләр янәшәләр.
Бал кортлары әрле-бирле
Шәт кунакка йөрешәләр?

Син дип, мин дип бүлешергә
Гөл илендә чикләр юк бит.
Касәләре көнгә ачык,
Гел дә ачык — бикләр юк бит.

Синең балкорт, минем чәчәк
Күптән инде кушылгандыр.
Синең көйме, минем җырмы —
Җан уртаклык шушындадыр?!

«Сезнең бал шәп!»,
«Сезнеке!» — дип
Макташыйк без бергә килеп.
Туганнарча йөрик шулай,
Сезгә барып, безгә килеп.

Бозылмый да, картаймый да
Безнең татар-башкорт балы —
Гәрәбәдәй якты булсын,
Мәңге булсын дуслык балы!

**Сораулар.**

1. Шигырь ни өчен «Дуслык балы» дип исемләнә?
2. Сез дуслыкны ничек аңлыйсыз?

## САБАНТУЙДА ҖИҢЕЛГӘН МАЛАЙ

Җилкенеп чыкты уртага,
Үзе дә белми нидән —
Ахры, мәйданга ашкыну
Җитмеш бабадан калган.

Карыйлар җиде яшьлеккә,
Көрәшче итеп зурлап,
Алды ул иплэп сөлгене,
Бик оста гына урап.

Уйламый кем алдында да
Һич артка чигәрмен дип,
Ышанып, көч тоеп чыккан,
Әлбәттә, җиңәрмен дип.

Аңа каршы баскан малай
Озынрак шул бер башка,
Үзең ега алмасаң да,
Тырыш син егылмаска.

Җиңү телиләр дус-ишләр,
Тирә-күршегә чаклы;
Дәрт биреп тора тавышлар —
Танышлар аның яклы.

Әмма көрәш — көрәш инде,
Җиңгәннәр өскә чыга,
Көчленеке замана дип
Әйткән дөрескә чыга...

...Мәйданга беренче керде,
Беренче бирешүе,
Горур атлап чыгып килә,
Сизелми килешүе.

Җиңелү гарьлеген бүген
Егетләрчә җиңәчәк.
Аһ итәр әле Сабантуй,
Котлар аны киләчәк!

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Җиңелгән малайны характерлагыз. Аның көрәшенә ничек карыйсыз?
2. Сабан туе сездә нинди истәлекләр калдырды?
3. «Сабан туе» рәсеменә игътибар итегез. Анда көрәш ничек сурәтләнә? Үзегезнең Сабан туе уеннарында, көрәштә катнашканыгыз бармы? Фикер алышыгыз.

## ТАБЫШМАКЛАР

1

Башка җирләре бик дөрес,
Бер генә ялгыш монда:
Түгел никтер урынында
Мөгезе — борынында!

(*Мөгезборын.*)

2

Авызына башны тыгып
Карадым, курыкмадым.
Аннары башына менеп,
Рәхәтләнеп йокладым.

(*Мич.*)

3

Сакаллы булып туган ул,
Сакаллы сабый булган.
Парикмахерга кермәгән,
Сакалын кистермәгән.

(*Кәҗә.*)

4

Бар җирне кызылга буяр,
Әмма канга буямас.
Кайчан гына атса да ул,
Беркем куркып уянмас.

(*Таң.*)

5

Бик күп телләрне белсә дә
Сөйләшми бер телдә дә.
Өйрәним дисәң өйрәтә,
Карышмый беркемгә дә.

(*Сүзлек.*)

6

Йөртәләр аны һәрвакыт
Каты-каты типкәләп,
Җан-фәрманга йөгерә ул,
Тормый бер дә үпкәләп.

(*Футбол тубы.*)

7

Көзме, кышмы, язмы, җәйме,
Тыңламый, нишләтәсең —
Кар-буранда, җил-яңгырда
Салмый ул эшләпәсен.

(*Кадак.*)

8

Су өстендә җәяү йөрим,
Тып-тып басып атлыйм мин,
Иң тирән җирдән үтәм,
Әз генә дә батмыйм мин.

(*Боз өстендә.*)

### 9

Морзе әлифбасы белән
Тукылдата тук-тук-тук:
— Тик торганым юк, юк, юк,
Шуңа күрә мин тук, тук!

(*Тукран.*)

### 10

Эшне генә ярата ул,
Булганы юк уенда;
Аннан башка үткәрәләр —
Үзе килми туена.

(*Сабан.*)

**Бирем.**

Табышмак кичәсе уздырыгыз.

## «ШӘВӘЛИ МАҖАРАЛАРЫ» ТУРЫНДА

Шәүкәт Галиев — балаларга үзенең җырлап торган кыска, тапкыр шигырьләре белән таныш шагыйрь. Аның юморы шигырьнең бөтенлеген, эчтәлек белән форманың бердәй тыгызлыгын белдерә торган үзлеккә ия.

«Шәвәли маҗаралары» күңелне үзенә тарта торган шигырьләрдән тора. Шәвәли—юмористик образ. Ул шуклыгы, җорлыгы белән рәхәт көлдерә, дөньяны юмор аша күзәтергә, аны танып белергә өйрәтә. «Серен белдем соңыннан» шигырендә малайны мичнең акбурын ашаган бәрән гаҗәпләндерә. Тик соңыннан, акшарның сөяккә ныклык бирүенә төшенгәч кенә, аның канәгатьләнүен, үзенә яңа дөнья ачкан кебек сөенүен күрәсең.

Аңлау, белергә теләү балаларда бик көчле. Шуңа күрә аларда күп сораулар туа, аңа тиң җавап көтелә. «Акыл теше кемгә чыга?» шигырендә шул ук наян Шәвәли моны да тиз отып ала, кешенең үсүе һәм үзгәреше аңа бик өметле дә, кызык та тоела. Баланың зиһенендә үзе белән чагыштырып карарлык уй туа. Әйтерсең бу шук

малай дөньяны иңләп йөри. Аңа бөтен нәрсә яңа, бар предметлар, хайваннар, өлкән кешеләр ачыш бирә, ул гел тормышның шаулы агымында сурәтләнә.

— Кузгалма! — ди
Кызыл сүз.
— Сабыр! — дия
Сары сүз.
— Ярый! — дия
Яшел сүз,—

«Светофорның өч сүзе» шигырендә.

Белем эстәү турындагы шигырьләрне байтак китерергә мөмкин. Чөнки баланың тиктормас табигате һаман ачышка омтыла. Юмор аша бирелгән тапкырлык — балаларның төп сыйфаты. Автобусларны узып киткән Шәвәлинең җавабы көтелмәгәнчә килеп чыга, малайның тапкырлыгы ирекле-ирексез елмайта.

Шәүкәт Галиевнең күңелсез якларны тәнкыйтьләгән шигырьләре дә юморга байлыгы, конкретлыгы белән кызыклы; алар бала табигатен, бала карашларын һәм гомумән бала характерын бик дөрес чагылдыралар. Әнә шул дөреслек зурларны да үзенә җәлеп итә, уйландыра, мөлаем елмайта. «Таныш шофёр», «Җил тегермәне» шигырьләрендә малайның шук-шаянлыгы, дөньяны сиземләве бик табигый. Аның чагыштырулары да заманча: җил тегермәне малайга очарга торган вертолёт булып күренә. Заман агышын бала конкрет предметлар аша тоя, предмет белән генә уйлый. Бу исә бала характерын ачуда бик кулай стиль үрнәге бит.

Малайлар әхлагындагы кимчелекләрне көлке чемета, мораль проблемаларына шагыйрь аеруча игътибар бирә. Мотоцикл белән атны аера алмаган шәһәр малае («Ат «йөртүче» малай») аттан тормоз эзләп көлкегә кала. Яисә трамвайга асылынып йөргән баланың аяксыз калуы («Ялгыш адым») йөрәкне әрнетә.

Балалар — киләчәк кешеләре. Алардагы омтылыш, рухлану хыял дөньясын үстерүгә ярдәм итә. Ниләр генә эшләми, ни генә уйлап тапмый нәни кеше! Аның өчен өстәл дә рояльгә әйләнә, орчык та курай моңнарын сыза башлый. Болар — малайның киләчәк өметләре, чынга ашардай хыяллары лабаса.

Хәсән Туфанның шагыйрьгә биргән бәясе һәр заманга туры килә: «Шәүкәт мәктәбеннән,— дип яза ул,— безнең киләчәгебез булган балалар тапкырлыкка, дөньяны танырга өйрәнеп чыгалар. Зурларның Хуҗа Насретдиннары, Шомбайлары булса, балаларның да Шәвәлиләре бар инде» («Киләчәккә барырлык иҗат» мәкаләсеннән). Мөгаен, Шәвәли, Котбетдиннәр һәр яшь буынның яраткан геройлары булып калыр.

* * *

**Юмор һәм сатира.** Тормышта очрый торган яраксыз күренешләрдән җиңелчә көлеп, дусларча тәнкыйтьләү **юмор** дип атала. Юмор белән елмаеп яисә чәнчебрәк тә көләргә була, ул фикерне укучыга елмаю аша үтемле җиткерә. Шәүкәт Галиев иҗаты тулысынча диярлек юмор белән сугарылган. «Шәвәли маҗаралары»нда ул, балаларның шуклыгын, җорлыгын сурәтләү белән бергә, аларның җитешсез якларыннан җиңелчә көлә белә.

Юмор әдәбиятның барлык төр (хикәя, роман, шигырь, комедия, мәсәл һ. б.) әсәрләре өчен дә хас.

Юмор белән сатира арасында аерма шактый зур. **Сатира** (латин сүзе) чынбарлыктагы зарарлы күренешләрне фаш итү, алардан ачы көлүне белдерә. Г. Тукай — татар поэзиясендә иң көчле сатирик. «Сорыкортларга», «Пыяла баш», «Мактанышу», «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» әсәрләрендә ул җәмгыятьнең черекләгеннән, аның икейөзле милләтчеләреннән, байларыннан ачы көлә. Ике генә юллык «Ишан» шигырендә нинди үткен сатирик портрет пәйда була:

Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма
чорналган;
Кибән чалма кибек башта: ишан булган, имеш,
хайван.

## *Габделхәй Сабитов*

## *(1931—1995)*

Габделхәй Сабитов исеме әдәбиятта илленче елларда күренә башлый. Башта шигырьләр язу белән мавыкса да, үз кыйбласын ул драма һәм хикәя жанрында таба.

Габделхәй Вәли улы Сабитов 1931 елның 28 июнендә Татарстанның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында крестьян гаиләсендә туган. Аның бала чагы киң күңелле, эшчән авылдашлары арасында үтә, әсәрләрендәге тирән кичерешләре, соклану-әрнүләре, шәхси күзәтүләре авыл тормышын сурәтләү белән баеп китә. Үзенең «Ми-ха-ха» исемле кечкенә хикәясен язучы: «Очрашырбыз дип уйлаганым юк иде. Һич көтмәгәндә шәһәр урамында яшьлегем, бала чагым белән очраштым»,— дигән сүзләр белән башлап китә дә елкылдап торган тайның риясыз кылган маҗаралары белән таныштыра.

Габделхәй, туган авылында башлангыч белем алгач, Күзкәй урта мәктәбендә укый. Берничә ел укытучы булып эшләгәч, Минзәлә район газетасы редакциясенә күчә, аннан соң М. Горький исемендәге Мәскәү әдәбият институтына укырга керә һәм драматургия бүлегендә белем ала.

1960—1965 елларда Г. Сабитов Казан телевидениесендә әдәби-драматик тапшырулар буенча өлкән редактор була, аннан соң республика балалар журналы «Ялкын», «Чаян» журналы редакцияләрендә эшли. 1970 елдан тулысынча әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә башлый.

Габделхәй Сабитов хикәяләрендә табигать белән кешенең берлеген сизеп торасың. Табигатькә, Җиргә соклану алар өчен борчылу хисе белән үрелеп бара. Аның чит ил укучысын да сокландырган «Айбаш» хикәясендәге ат образы туган җир туфрагының кадерен искәртә, аның изгелеген йөрәккә сала. Габделхәй Сабитов әсәрләренең һәркайсы укучы күңелен тибрәндерерлек, андагы вакыйгалар уйландырырлык, гыйбрәт бирерлек итеп язылганнар.

Г. Сабитовның гомере озын булмады. Ул 1995 елда безнең арабыздан китте.

## ЯРСУЛЫ ЯЗ

Әллә нинди булды быелгы яз.

Елдагыдан үзгә соңарып-сагындырып кына килде дә, март ахырларында кинәт ярсынып, изүләрен чишеп җибәрде. Ике-өч көн эчендә юлларда кара чыкты, күпер төпләрендә, мәктәп яннарында күлдәвекләр ясалды.

Рәхимсез кышкы төннәрне җылы морҗа эчләрендә, кара мунча төнлекләрендә посып уздырган йолкыш чыпчыклар шул күлдәвекләрдә корымлы канатларын юа, күгәрченнәр төшеп су эчә.

Үзенең чабуларын киң җәеп, Үрәзмәт авылын итәгенә тезеп утырткан Чапан-тау инде кардан арчылып килә. Тау иңендәге яшь каеннар, кар суларын буйга сеңдереп, бөре бүрттерә.

Уяна дөнья! Елмаеп-көлеп уяна. Ул кояшы дисәң, көннең көнозын класс тәрәзәсеннән китмичә, авыз ерып тора. Парта өстен кызган табадай кыздыра да Гөлүсә белән Гамилнең беләкләрен пешерә. Бармак изәп, тышка чакыра, тел күрсәтеп үчекли:

— Чыгасыгыз килмиме?! — янәсе. — Утырыгыз, алайса, контроль эш дигән булып икегә өчне кушып!

Кемгә ничектер, әмма Гамил өчен контроль эш — иң уңай, иң кулай эш. Тәмамладыңмы, бер минут тотмый Галләм абый. Әмәлен китерү өчен генә чәпчегән була:

— Нәрсә бик ашыгыч? Тикшереп чыктыңмы? Хаталарын Галләм абый чүпләсен дидеңме әллә? Ярый, хуп!

Гамил, эшен төгәлләп, һәркемнән элек кул күтәргәч, бүген дә каш җыерган булды. Журнал өстендә яткан күзлеген алып киде дә сәгатенә күз төшерде.

— Һе! Егерме минут. Күпер төбендә кар яна, ди, әнә. Сүндерүче кирәк, ди... Кая, китер...

Инде хәзер ни буласын алдан ук белеп тора Гамил. Кузгала башлауга, Гөлүсә итәктән тартачак. Үтермә, янәсе, калдыр караламаңны!

Уйлыйм дисә, башына тай типмәгән. Башкалардан тизрәк тә эшли ала. Тик уйларга иренә. Кояш коткысына бирелеп, кыектан тамган тамчыларны санап утыра. Күрше эшләсә, икебезгә дә җитәр, ди, күрәсең.

Әмма Гамил бүген күрше хакын хакламады. Барлык каралама кәгазьләрен җыеп бөгәрләде дә, укытучы өстәлен узышлый, чүп савытына ташлап китте. Җиргә төшкән чыпчыкны эләктерергә тырнак чарлап торганда, чыпчык очып киткәч, мәче баласы ничек караса, Гамил кулындагы дәфтәргә шулай карап калды Гөлүсә.

Бу карашның мәгънәсен Галләм абый сизми калмады, әлбәттә. Класстагы бер генә хәрәкәт тә, бер генә ишарә дә ычкынмый аның очлы күзеннән. Әмма ул кайчак сизсә дә шулай сизмәгән булып кылана. Тик котылдым дип куанма! Барыбер, җаен китереп, читтән суктырачак.

Ул дәфтәр битеннән җәһәт кенә күз йөртеп чыкты:

— Һе! Бер өтереңне карга чукыган. Сания апаңа әйтермен. Чиреккә билге чыгарганда чигереп калыр!

Бусы инде, гадәтенчә, өркетеп куюы гына. Йөзеннән үк күренеп тора: бик канәгать үзе малайның эшеннән... Әнә маңгаендагы тирән җыерчыклар, кинәт язылып, авыз читләренә күчте. Хәзер өч төсле каләмен кулына алып, зур итеп «биш»лесен куяр. Аннары боргалап-бөдрәләп имзасын...

Галләм абый, нинди билге куярга белмәгәндәй, дәфтәр бите өстендә каләмен уйнатып торды да күзлек өстеннән сөзеп карады.

— Нәрсә, җим көткән чебеш кебек, күзләреңне ялтыратып торасың?! Бар, кайт.— Аннары киная белән

өстәп куйды: — Гөлүсәгә тынычлык кирәк. Эш башларга синең киткәнне көтәдер!

Гөлүсә ягына күз салгач, чак кына пырхылдап көлеп җибәрмәде Гамил. Аның кыяфәте һаман да әлеге шул мәчене хәтерләтә. Тик хәзер чыпчык аулаган чагы түгел, башына әбәк-чәбәк төшкәч, колагын шомартып, муенын җыерган чагы. Борынын дәфтәргә төрткән дә мәсьәлә чишәргә керешкән.

Мәче тек мәче инде. Ни тәүфыйклы булып күренмәсен, барыбер үз эшен эшләп куйган, явыз. Әйберләрен җыештырырга дип килеп утыруы булды Гамилнең, парта утыргычында нәрсәдер шытырдап куйды, шунда ук чалбар төбеннән юеш бәреп керде...

Торып караса, үзенең авторучкасы! Урталай сынып, карасы утыргычка җәелгән. Ә Гөлүсә ерылырга торган авызын чак җыеп утыра. Галләм абый әйткәндәй, ярый, хуп! Бәйрәм ашы — кара-каршы булмагае!

Үзләре салган сукмактан ындыр артлатып өенә кайтканда, Гөлүсәдән ничек итеп үч алу турында уйлады Гамил. Әмма ник бер юньле уй килсен башына. Ничә әйтсәң дә, шул яз шаукымы...

Йөзгә йомшак канатлы талгын җил бәрә. Яз җиле, кояш җиле! Ферма каралтылары ягыннан баш әйләндергеч хуш ис — җиләкле печән исе, әчкелтем силос исе килә. Тургайлары дисәң, тәмам шашынганнар. Көннең көнозын:

— Тюр-р-р... тюр-р-р...

— Тюр-р-р... тюр-р-р...

Тамаклары ничек армыйдыр да, канатлары ничек талмыйдыр.

Әллә ничек бик ярсулы да, бераз ямансурак та быелгы яз. Башка язлар болай түгел иде кебек. Карлары-яңгырлары булды, яудылар да уздылар, сулары-ташулары булды, ташыдылар да тындылар. Тик беркайчан да тургай җырларының бу кадәр ашкынулы булганы юк иде, көннәре дә бу кадәрле ямансу тоелмый иде. Ә быел...

Әллә нәрсә булды малай күңеленә. Кайгы дисә, кайгырыр сәбәбе юк, сагыш дисә, сагыныр кешесе юк. Ә шулай да күңел нәрсәдер юксына, нәрсәдер көтә...

Кайда икән соң бу тургай? Күпме эзләсәң дә табармын димә. Бәйләнчек кояш күз ачарга ирек бирми. Сыйныфта теңкәгә тиюе җитмәгән, хәзер дә бер тотам арттан калмый, баскыч төбенә кадәр Гамилне озата килде. Ишеккә әнисе кыстырып киткән чыраны алып өйгә керсә, әрсез кояш тагын анда. Тәрәзәдән кереп, өй эчен тутырган. Өстәлдәге самовар, капкачыннан чагылып, түшәмгә үк менеп кунаклаган. Гәрәбәдәй сары нарат стеналар үзләреннән нур чәчкәндәй балкып тора. Тәрәзә төбендәге яран гөленең йодрык кадәрле чәчәгеннән ак буяулы борыска алсу шәүлә төшкән...

Гамил, самовардан җылымса су агызып, гөлгә сипте. Аннары, юынып, тиз генә капкалады да дәресләренә утырды.

Әмма бүген кояшы гына түгел, бөтен дөньясы каныкты малайга. Дәфтәрен ачып салуы булды, караватастында йомырка баскан ана каз шактый каты итеп балтырын чукып алды. Күчеп утыргач та тынгылык бирмәде. Кыштыр-кыштыр килеп, оясыннан төште дә, үз телендә нәрсәдер сөйләнә-сөйләнә, ишеккә юнәлде.

— Ач ишекне, малай актыгы, һава сулап керәм! — дигән көне инде.

Аны чыгарып җибәрүгә, ала сарык баскычка менеп сөрән салды. Гөлбәчкә ябылган бәрәннәр, әниләренең тавышын ишетеп, артларына ут капкандай кычкыра башладылар:

— Эм-мә-ә!..

— Эм-мә-ә!..

Аларны чыгардыңмы инде, бераз карап тормый һич мөмкин түгел. Хәйран тамаша кыйланалар. Әниләренең әле уң, әле сул ягына чыгып, кызган табага баскандай каударланалар, имчәк тапкач, бер тезләнеп, бер торып, башлары белән төртә-төртә, комсызланып суыралар. Ул койрыклар дисәң, күз иярмәс тизлек белән,

бөдрә камчыдай бөтерелеп-уйнаклап тора. Шулкадәр дә тәмле микәнни соң ул ана сөте!

Бер чыккач, әйләнеп керә алмыйча, баскычта озак торды Гамил. Өй кыегыннан тып-тып тамып торган салкын тамчыларны учына җыйды. Шундый саф, шундый эре тамчылар!

Өй буенда алар тамган урында карлар, чәйдә эрегән шикәр кебек, суланып-саргаеп ята. Тик нишләптер күлдәвек ясалмый. Кар астына китә баралар, күрәсең!

Су! Кар астына су төшкән!

Башына шундый уй килүгә, бәрәннәрен дә, казын да, дәресләрен дә онытты малаең. Тиз генә киенеп чыкты да, көрәк алып, тыкрыкка, артлатып кайта торган әлеге сукмакка йөгерде.

Ул казыган кое шунда ук саргылт су белән тулды. Инде хәзер кое авызына көрәк каплап, юеш кар җәясең дә саклык белән генә өстен таптыйсың. Шуннан соң көрәгеңне алгач та җимерелми ул кар капкач!

Әйдә, Гөлүсә күрше, рәхим ит! Кайтышлый итек-читекләреңә су чумыра кит. Аларны киптергәнче, уйнарга чыга алмыйча, тәрәзәдән карап утыруы ничегрәк булыр икән!

Эшен төгәлләгәч, Гамил, сукмактан ике адым читкә чыгып, көрәк сабы белән кар өстенә язу язды. «Сак булыгыз! Мина!» Аңлаган кеше аңласын да әйләнеп уза бирсен. Ә Гөлүсә һавадан тургай санап йөрергә ярата. Чумып карасын әйдә. Әнә үзе, кайтып та килә!

Гамил, көрәген тотып, Гөлүсәнең юлына аркылы төште:

— Эләктеңме, Гөли! Ручкамны сындырып, үч алмакчы идеңме? Бушат сумкаңны, сөякләреңне тутырып үтилчегә илтәм!

Куркып калыр, гафу сорар дип өмет иткән иде, кая ул. Җитмәсә әле, канга тоз салып, такмаклап тора:

— Исең китәр бу эшкә — чалбар төбе юешкә! Бүлмә юлны, ашыгам.

— Ашыккан ашка пешкән, бозлы тозакка төшкән.

— Бәйләнмә дим, Гамил-Галәкә. Ашап, яңадан мәктәпкә барасым бар.

— Көтәләр ди сине анда, кирәкле кишер яфрагы!

— Көтәләр икән шул менә!

— Кемнәр?

— Койрыклы җеннәр! Репетиция була. Ата-аналар җыелышына концерт хәзерлибез.

— Каян килгән артистка!

— Артистка шул. Күр менә, күргәнең булмаса!

Бөеренә таянды да, кечкенә генә ап-ак итек-читекләре белән юеш кар чәчрәтеп, бөтерчектәй бөтерелеп куйды, кыбырсык. Килешеп тә тора икән үзенә. Непнечкә билле, тез тиңентен генә язгы пәлтәсе дә, башына бәйләгән аллы-гөлле, буй-буй шарфы да өздереп килешә. Ә бигрәк тә әлеге шул уенчыктай җиңел ак читекләре! Әйтерсең ак бәкәлле колын! Баскан өстенә басып, сикереп чабарга җилкенеп тора. Үзе әрләшкән була, ә күзләре... Бернинди усаллык, бернинди дошманлык әсәре юк лабаса күзләрендә. Озын керфекләр арасына яшеренгәннәр дә менә-менә көлеп җибәрергә торалар.

Керфекләре дисәң... Туа-тумыштан терәлеп торган күрше булып, бер урам чирәмендә аунап, шушы көннең шушы сәгатенә кадәр ничек искәрмәде икән Гамил бу керфекләрне. Бик кызык, бик әкәмәт икән бит алар. Шундый озын, шундый куелар, әйтерсең аерым бөртекләр түгел, ә тоташкан кара элпәләр — кара күбәләк канатлары...

Гамил нәрсәгәдер гаҗәпсенеп, авыз ачып торган арада, Гөлүсә җәлт кенә култык астыннан чыгып шылды... Чапсын әйдә, карлы суга чумасы килгәч!

Тик... Әллә кинәт кенә әлеге ак итек-читекләрне кызганып куйды Гамил, әллә кызыйның нәзек кенә аякларын аяды, әллә инде һавадагы тургайлар бер-бер киңәш бирделәр үзенә, чокырга барып төштем дигәндә, артыннан куып тотты:

— Көлең күккә оча хәзер, кыбырсык! Кара әнә уң ягыңа! — Гөлүсә кар өстендәге язуны укыды да тагын чыркылдап көлде, тагын Гамил кулыннан ычкынып йөгерде:

— Исең китәр бу эшкә, бу эшкә...

— Әһә! Минадан коткарып калган өчен рәхмәтең шулмы?— Гамил, ике-өч сикерүдә, кызыйны яңадан куып җитте, кар йомарлап, аллы-гөлле шарфына төзәде.

— Ого-онь по врагу!

— Тиеп кенә кара! Әнә абый!

Борылып караса, чыннан да, мәктәп ягыннан Галләм абый төшеп килә иде. Сул кулында бер кочак дәфтәр, уң кулында таяк. Протезлы аягын юеш кардан сөйри-сөйри, авыр гына атлап кайта... Ялганчы чокырына бөтенләй килеп җитә язган. Тагын дүрт-биш адым атласа...

Шулчак, ниндидер яман хәл туасын аңлап, Гамил тәмам бөрешеп калды. Әгәр протезлы аягы белән дә төшсә... уеннан уймак чыгачак! Чирек гасыр буе төзәлеп җитмичә, әле һаман да еш-еш кына ачылып, карт укытучының теңкәсенә тия торган авыр яра нинди фаҗига китермәс!

Кычкырып туктатсаң... Кешегә чокыр казыган өчен, кызган табага бастырачагы көн кебек ачык. Ә болай авыз ачып торсаң...

Гамил, кинәт кенә урыныннан кубып, укытучы каршына йөгерде, атылып барып, үзе казыган чокырга үзе төште.

— Һи, кара инде! Бер юньсез ялганчы чокыр казыган икән бит монда...

Галләм абый, бер Гамил кулындагы көрәккә, бер сулы чокырга карап, шактый вакыт сүзсез торды. Аннары аның маңгай җыерчыклары, әкрен-әкрен язылып, авыз читләренә күчтеләр:

— Бәла аяк астында була дип әйтәләр иде, хак икән бит, әй! Әйт иптәшләреңә, шаярмасыннар алай! Кешегә чокыр казып, үзләре төшүе дә бар бит...— Кузгалып китә башлагач, яңадан тукталып өстәде: — Күмеп куй бу чокырны. Бер башсыз малай аркасында кеше имгәнүе, мал аягы сынуы бар...

Һәй көлде дә инде Гөлүсә! Кулларын чәбәкли-чәбәкли, чокыр кырында утырган Гамил тирәсендә бии-бии

көлде. Хәтта күзләреннән яшьләр чыгып, «кара күбәләкләре» чыкланды.

Көлеп арыгач, кар йомарлап, Гамилнең башына тондырды да ак бәкәлле колын кебек сикерә-сикерә китеп барды. Малайның колак төбендә язгы сулар челтерәве генә яңгырап калды.

Менә хәзер ул, итекләре кипкәнен көтеп, тәрәзәдән карап утыра. Өйдә кояш, өйдә яз галәмәтләре. Тышта йөреп, шактый туңган бәрәннәр җылы гөлбәчкә кереп йокыга талдылар. Оядагы каз, ягымлы гагылдап, «га-га» дип, үзенең әле йомырка эчендәге бәбкәләрен иркәли.

Хәтта ике тәрәзә арасында кышның кыш буе хәрәкәтсез яткан күбәләккә дә яз кояшы җан өргән. Ул үзенең кара бәрхет канатларын лепелдәтеп очарга талпына.

Тик әле иртәрәктер шул. Табигать уянганны сизеп, болай гына, йокы аралаш кына талпынуыдыр. Алдадыр әле уяныр, очар көннәре...

Сүзлек өстендә эш.

Бу сүзләрнең мәгънәләрен аңлатмалы сүзлектән карагыз: *каралама, борыс, гөлбәч, кулдәвек, бәкәл, элпә.*

**Сораулар һәм биремнәр (хикәяне тулысынча укыганда).**

1. Гамил кичерешләрендә яз ничек сурәтләнә?
2. Язның кешегә тәэсирен автор ничек тасвирлый? Сезгә ул нинди уй-сагышлар, нинди куаныч-сөенечләр алып килә?
3. Гамил белән Гөлүсә мөнәсәбәте нинди уй-фикерләр уята? Ул мөнәсәбәтнең самимилеге, җылылыгы нәрсәдә? Үз фикерегезне әйтеп, бәхәс оештырыгыз.
4. Гөлүсәнең портретын, җиңелчә хәрәкәтләрен сөйләп аңлатыгыз. Кызның рәсемен ясагыз, аннары үзара чагыштырып карагыз.
5. Гамилнең нинди сыйфатлары әйбәт, ә кайсы сыйфатлары белән килешмисез? Тургай җыры, язгы авазлар аның ашкынулы хисләренә ничек тәэсир итә?
6. Галләм абыйның кайсы сыйфатларын югары бәялисез? Ни өчен?

**Мөстәкыйль эш.**

1. Язучы телендә мәкаль һәм әйтемнәрнең кулланылышын күзәтегез. Хикәядән аларны табып, дәфтәрегезгә языгыз һәм, шул мәкаль-әйтемнәрне, җор сүзләрне кертеп, үзегез җөмләләр уйлагыз.
2. «Ярсулы яз» сезнең кайсы истәлекләрне яңартты? Ярсулы яз белән йөрәк кичерешләре арасында нинди уртаклык бар? Үз уйларыгызны кушып, телдән кыска гына хикәя төзегез.

**Сораулар һәм биремнәр (хикәяне икегә бүлеп укыганда).**

1. Язның характерлы билгеләрен язучы нинди сүзләр белән белдерә? Тексттан сайлап, укып күрсәтегез.
2. Язгы табигать Гамил күңеленә ничек тәэсир итә? Автор аны кайсы юлларда, нинди сүзләр ярдәмендә белдерә?
3. Укыган өлештән күчерелмә мәгънәле сүзләрне табыгыз.
4. «Бәйрәм ашы — кара-каршы булмагае» дигән сүзләр бу урында ни өчен кулланылган?
5. Галләм абыйны нинди кеше итеп күз алдына китерәсез? Шул турыда сөйләгез һәм фикер алышыгыз.
6. Гамил белән Гөлүсә диалогын кабат укыгыз, бу сөйләшүдән аларның үзара мөнәсәбәте, күңел байлыгы, эчке дөньясы ничек ачыла?
7. «Һавадан тургай санарга ярата», «Баскан өстенә басып, сикереп чабарга җилкенеп тора», «Гамил тәмам бөрешеп калды» дигән җөмләләр ни өчен кулланылган? Үзегез аңлаганча сурәтләп сөйләгез.

**Мөстәкыйль эш.**

1. Әсәр сезнең күңелегезгә ничек тәэсир итте? Яз күренешләрен күзәтүдән тупланган тәҗрибәгезне кушып, кечкенә хикәя иҗат итегез.
2. Текстта сурәтләнгән күренешләрнең берәрсен дәфтәрегезгә рәсем итеп ясагыз яки телдән тасвирлауны дәвам итегез (ана каз хәрәкәте, бәрәннәр сурәтләнгән урын, учына язгы салкын тамчыларны җыеп, яз күренешеннән тәэсирләнеп басып торган Гамил).
3. Хикәянең соңгы ике абзацын кабат укыгыз. Автор күбәләк образы аша нәрсә әйтергә тели? Гамил белән Гөлүсә хисләрен күрсәтүдә аның роле бармы? Ничек уйлыйсыз?

## *Нәкый Исәнбәт*

## *(1899—1992)*

Нәкый Исәнбәт (Нәкый Сираҗетдин улы Закиров) 1899 елның 29 декабрендә (яңа стиль белән 1900 елның 10 гыйнвары) Башкортстан Республикасының Салават районы Малаяз авылында мулла гаиләсендә туган. Аның туган авылы мәңге яшел чыршы һәм наратлар белән бизәлгән Урал итәгенә урнашкан. Шунда ул башлан-гыч белемне ала. 1910 елдан Уфада «Хәсәния» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә укый. Балачакта дикъкать белән кат-кат укылган әсәрләр аның зиһенендә яңа матур уйлар тудыра. Озакламый Нәкый үзе дә шигырьләр яза башлый. «Шүрәле» исемле беренче шигырен язганда, аңа ун гына яшь була. Озакламый аның шактый калын шигырь дәфтәре шәкертләр арасында тарала. Тәүге шигырьләренә Шәехзадә Бабич үзе фатиха бирә. 1914—1916 елларда «Аң» һәм «Сөембикә» журналларында поэма һәм драма әсәрләре басылып чыга.

Нәкый Исәнбәт мәктәпләрдә укытучы булып эшли һәм халык авыз иҗаты белән мавыга. Унике яшеннән башлап, ул дәфтәренә мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар җыя башлый. Гомере буе туплаган халык авыз иҗаты әсәрләрен аерым җыентыклар рәвешендә бастырып чыгара («Татар халык мәкальләре» (өч томда), «Татар халык табышмаклары», «Балалар фольклоры»).

Нәкый Исәнбәт — тел галиме дә. Күп еллар дәвамында татар теленең фразеологик байлыгын җыйнап, сүзлек итеп бастырды.

Аның «Уракчы кыз», «Бормалы су», «Гармунчы егет», «Син сазыңны уйнадың» кебек күп кенә шигырьләре җыр булып яңгырый.

Нәкый Исәнбәт күп санлы драма әсәрләрендә теге яисә бу чорга караган вакыйгалар яктылыгында халыкның тарихын, гореф-гадәтләрен тирәннән сурәтли: «Хуҗа Насретдин», «Җирән чичән һәм Карачәч сылу», «Миркәй белән Айсылу», «Гөлҗамал», «Мулланур Вахитов», «Муса Җәлил» әсәрләре шундыйлар. Ул оста тәрҗемәче буларак та танылды: Пушкин, Мольер, Низами, Шекспир әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Туган әдәбияты, мәдәнияте һәм сәнгате өлкәсендәге игелекле хезмәтләре өчен Нәкый Исәнбәткә Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм «Татарстан Республикасың халык язучысы» дигән исем бирелде.

Татар халкының рухи тормышында, сәнгать һәм әдәбиятында Нәкый Исәнбәт иҗаты күренекле урын алып тора.

Өлкән язучыбыз Нәкый Исәнбәт 1992 елның 15 сентябрендә Казанда вафат була.

## ХУҖА НАСРЕТДИН

Комедия биш пәрдәдә

(*Кыскартып алынды*)

Катнашучылар:

Хуҗа Насретдин.
Гөлбану — хатыны.
Сәлви — кызы.
Хаммат — Сәлвинең сөйгәне.
Алчын — егет.
Зөбәрҗәт — Алчынның сөйгәне.
Сәхилә — карчык.
Бики — сәүдәгәр.
Ахун.
Колый тархан.
Җиһангир — легендар илбасар, уң аягы аксак.
Зәйнәгый — аның баш вәзире.
Низамый — казый.
Гыймай — баскак.
Дәрвиш.
Сачтараш.
Ике Касыйм.
Атамыш.
Карт.
Яшь кеше.
Җарияләр.
Гаскәр.
Халык.

Вакыйга урта йөзләрдә Болгар шәһәрендә һәм аның янындагы Тимерче бистәсендә бара.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ИКЕНЧЕ СӘХНӘ

Болгар шәһәрендә казый диванханәсе[1]. Артта рәшәткә, аның уң ягында баганага «гауга барабаны» эленгән. Тагын арттарак, чокыр аша бөкре күпер. Болгар манаралары һәм Кара пулат (Черная палата) биналары күренә.

#### Беренче чыгыш

Хуҗа, Колый тархан, Бики керәләр. Багана төбендә туктаган ишәкнең башы күренә.

Хуҗа. Һәп! Тукта шунда, ишәгем! (*Ишәкне барабан астына рәшәткәгә бәйли.*)

Бики (*арып, ахылдап, ачуланып*). Уф! Ишәгем дияргә, синең ишәгеңме әллә ул?

Колый. Ә хөлләсе минеке, бикасап[2] синеке!

Хөкем залына узалар.

Бики. Салмый бит! Көчкә генә алып килдем, ярый ла сез атта! Уф!

Колый. Салдырырбыз! Монда чаклы китердек, капты инде.

#### Икенче чыгыш

Шулар ук һәм казый Низамый.

Бар да. Әссәламегаләйкем!

Низамый. Вәгаләйкемәссәлам! (*Тәбәнәк диванга утыра.*) Җиһангир хәзрәтләренең фәрман шәрифе үзгәрә, Болгар йортындагы шәригате исламиянең хөкем мәҗлесен ачык дип игълан итәм. Бисмиллаһиррахма-

[1] *Диванханә* — зал.

[2] *Бикасап* — бәрхеткә ука белән чигелгән яхшы чапан.

ниррахим!.. (*Салават әйтеп, яшел тышлы зур китапны ача.*)

Хуҗа (*алгарак чыгып*). Исәнме?

Низамый җавап бирми.

Хуҗа (*халыкка*). Кара, кара! Менә син ашат хайванны! Казый булгач, сәлам дә алмыйсыңмы?..

Колый (*Бикигә*). Нәрсә ул? Казыйны әллә үзенең югалткан ишәге дип беләме.

Хуҗа. Койрыгы, ярый, чапан астында булсын диик, колаклары ничек чалма астына сыйган соң моның?

Колый (*Бикигә*). Әллә ни сөйли бит бу...

Бики (*Колыйга*). Тимә, казыйның ачуын китерсен әле!.. Аннан без өстәрбез!

Хуҗа халыкка якын, алга килеп утыра, аршын тоткан ике Касыйм килеп керә.
Бер-берсен тота-тота, сүз бүлеп сөйләшәләр.

Беренчесе. Казый әфәнде...

Икенчесе. Казый хәзрәт...

Низамый. Туктагыз! Сәлам юк, дога юк, тагын килдегезме? Сезгә хөкем булды түгелме соң: алып ташлагыз юл өстеннән шул үлгән этнең үләксәсен!

Беренчесе. Мин алып ташламыйм, минем өлешемдә ятмый ул.

Икенчесе. Өлешемдә ятмый...

Низамый. Йа Ходა! Миңа тапшырылган мәхәлләдә, олуг Җиһангир хәзрәтләре белән мин үтә торган юл өстендә, эт үләксәсе ятсын, имеш! Ике йорт арасын үлчәгез дә эт кем ягында ятса, шул алып ташларга тиеш дидек түгелме? Менә. (*Китабын ача.*) Бер кыйлда[1] әйткән: мондый вакытта бер генә түгел, җиде кат үлчәргә кирәк, дигән!

---

[1] *Кыйл* — әйтелгән сүз.

Беренчесе. Җиде түгел, җитмеш үлчәдек!

Икенчесе. Үлчәдек!

Беренчесе. Менә аршын, мин сиңа әйтим, ул якка да алты чыга...

Икенчесе. Алты чыга!

Беренчесе. Бу якка да алты чыга!

Икенчесе. Алты чыга!

Беренчесе. Юл уртасына яткан этне ник мин алыйм?

Икенчесе. Ник мин алыйм?

Беренчесе. Син карап тор, энем Касыйм,
Синең өчен мин эт ташыйм!..

Икенчесе. Минем ягым алты аршын!

Беренчесе. Минем як та алты аршын!

Икенчесе. Мә, мин өстим ярты аршын! (*Суга.*)

Беренчесе. Мә, мин бирим алты аршын! (*Суга.*)

Икесе бергә. Син дә Касыйм, мин дә Касыйм,
Синең өчен мин эт ташыйм!

Аршын белән сугышалар.

Низамый. Тотыгыз үзләрен! Ике ахмак! Моның өчен хөкем бар, шәригать бар! Менә! (*Бармагына төкереп, китабын ача.*) Бер кыйлда әйткән: аршынның йөзе белән чыкмаса, кыры белән үлчәп карарга кирәк, ягъни мәсәлән.

Беренчесе (*аршын селкә-селкә*). Кыры беләнме? Әһә, хәзер кыры беләнме? Кирәкми? Хөкемең шул төсле булса, үләксә юл өстендә ята бирсен.

Икенчесе. Мин дә риза түгел. Бер дә дөрес хөкем булмады бу. Болай булгач, Тимерчедәге Хуҗа Насретдинга гына хөкемгә барасы калган икән.

Низамый. Ул нинди Насретдин, ягъни мәсәлән?

Беренчесе. Ул безнең шундый бер хикмәтле кеше инде. Халык менә, мулла белән казыйлар хөкеменнән риза булмаса, аңар бара. Ул, мин сиңа әйтим, кыл кебек өзә дә бирә инде.

Колый. Безнең Хуҗамы? Хуҗамы? Әнә утыра ул, Хуҗа Насретдин.

Әйләнеп аңа карыйлар.

Беренчесе. Сөбханалла! Менә ул үзе дә монда, казый хәзрәт!

Низамый (*урыныннан торып, Хуҗага якын килеп, аны карап чыкканнан соң*). Хуш, безнең хөкемебездән риза түгелсез икән, хәким кешегезнең хөкемен ишетеп күрик!

Беренчесе. Хөкем ит, Хуҗа, менә безнең урамда...

Икенчесе (*бүлеп*). Безнең урамда...

Хуҗа. Ансын ишеттек. (*Урыныннан торып, илтифатсыз бер вәкарь белән казый урынына барып утырып, күзен йомган килеш китабын ачып, бер җиргә бармагын төртә.*) Урам кем карамагында?

Беренчесе. Урам мәхәллә карамагында.

Хуҗа (*тагын ачып, төртеп*). Мәхәллә кем карамагында?

Икенчесе. Мәхәллә? Мәхәллә, әнә казый әфәнде карамагында.

Хуҗа (*үз кыяфәтенә кайтып*). Шулай булгач? Нәрсәгә кычкырышасыз сез? Үләксәне дә казый әфәнде алып ташларга тиеш була.

Низамый (*сикереп китеп*). Ә?

Хуҗа. Шуның белән юрган да китте, тавыш та бетте. (*Торып китеп, үз урынына утыра.*)

Беренчесе. Менә дөрес хөкем!

Икенчесе. Менә бу хөкем ичмасам! Менә рәхмәт! Без монда, ике күрше, ике Касыйм, безгә казый куша дип, урам үлчи-үлчи...

Беренчесе. Син дә Касыйм, мин дә Касыйм,
Сынып бетте безнең аршын...

Икенчесе. Ә ул казыйның үз өстенә төшә икән! Йә, күрше, бир кулыңны, килешик!

Беренчесе. Үбешик! Менә безне дә килештерден, Хуҗа! Менә рәхмәт!

Көлешәләр, чыгалар.

**Өченче чыгыш**

Казый, Низамый, Хуҗа, Колый тархан, Бики.

Низамый (*үзалдына*). Ә мин эт үләксәсе күтәреп калдым! Яхшы хөкем! Ай-һай, кем икән бу Хуҗа Насретдин дигәннәре! Өсте-башы җилле күренә, сак булырга кирәк! Нинди дәгъва белән килде икән бу?(*Алга чыккан Бикине күреп, аңа.*) Хуш?

Бики. Хөкем ит, казый әфәнде. Иң элек шушы Хуҗа дигән кеше былтыр миннән вакытлы файдаланырга җир алып чәчте, әле булса түләгәне юк. (*Кәгазь суза.*)

Низамый. Дөресме?

Хуҗа. Әйе. Биргән җире таш булды, биргән орлыгы пыш булды, шытмады.

Бики. Минем анда эшем юк. Менә язышкан шартнамәсе, йорты салынган, тәкъсир.

Низамый (*шартнамәне карап*). Ник түләмисез, Насретдин әфәнде?

Хуҗа. Мин түләмим дигәнем юк. Каян чыгарган ул?(*Бикигә.*) Күпме бурычлы соң әле мин сиңа?

Бики. Илле өч сум.

Хуҗа. Соң шулай диген аны. Иртәгә егерме биш, аннан иртәгә тагын егерме биш сумын бирсәм, күпме кала тагын?

Бики. Өч сум.

Хуҗа. Соң шулай булгач? Өч сум өчен минем йөземне ертып, казый әфәнде алдына килеп, тавыш күтәреп йөрергә оялмыйсыңмы?

Колый. Кара, кара, ни ди ул? Туктале, синең кылмышларың ул гына түгел, чыгар гаризаңны, Бики!

Бики (*гаризаны биреп*). Менә, казый хәзрәт, шуның өстенә ул минем туксан тугыз алтынымны алды.

Низамый (*гаризаны карап*). Сөбханалла! Насретдин аларны Алладан алдым дип дәгъва кыла... Хуш, нинди соң бу Насретдин? Ягъни Аллаһы Тәгалә хәзрәтләреннән алтын сорап алырлык әүлиялыгы заһир кешемени?

**Бики.** Каян әүлия булсын Насретдин! Гомерендә бер мәчеткә кергәнен күрдек, анда да сыңар аягын күтәргән килеш намаз укыды.

**Низамый** (*гаҗәпләнеп*). Сыңар аягын күтәреп? Сөбханалла! Мәчеттәме? Хуш? Ни өчен сыңар аягыңны күтәрдең син, Насретдин?

**Хуҗа.** Ул шуның өчен: минем бер аягымның тәһарәте юк иде, тәкъсир, суым җитмәде!

**Низамый** (*гаҗәпләнеп*). Алла! Алла!

**Колый.** Әйе, әйе. Мин дә бар идем анда. Ул намаз намаз булмады, казый хәзрәт. Бервакыт сәҗдәгә китүебез булды, мулланың «нишлисең, Хуҗа» дип кычкырып җибәрүе булды. Аны бу ахмак арттан чабуыннан тарткан икән.

**Низамый** (*шаккатып*). Ә?

**Бики.** Әле ул алай гынамы? Мулла аңардан, ни өчен тартасың, дип сорый, ул аңа, ни өчен икәнен беләсең килсә, артымдагы кешедән сора, ди.

**Низамый.** Ләхәүлә! Ник алай, сәҗдәгә киткәч, мулланың чабуыннан тарттың син, Насретдин?

**Хуҗа.** Мин каян белим? Башта минем үземнең арттан чабуымны тарттылар, аннан мин аныкын!

**Бики.** Шул мәсхәрә аркасында бөтен мәчет шау килеп көлешеп, намаз бозып таралдык.

**Колый.** Бозмаслыкмыни? Мин үзем дә шуннан соң мәчеттә бер ай намаз укый алмадым. Ничек сәҗдәгә киттем, күңелгә шул килә дә тора.

**Низамый.** Диванамы ул?

**Бики.** Улмы? Алтынны да ул йөздән ким булса алмыйм дип ант итте, без аны сынар өчен туксан тугыз алтын санап алдына ыргыттык, ул, аны алып, антына ханис булды. Шәригать буенча хәзер йөз таяк орып, шул бурычым белән алтынымны алып бирегез, тәкъсир.

**Низамый.** Димәк, туксан тугыз алтын синеке?

**Бики.** Янчыгына чаклы минеке. Мин ансын да бер алтын биреп алдым.

Хуҗа. Шулай булгач?.. Мин шул янчыгы белән йөз алтынга хисаплап алдым да аны. Мин ничек антымны тотмаган булам?..

Низамый. Әстәгъфирулла! Гакыл ирешерлек эш түгел бу! Бер яктан, ул алтын да тоткан, икенче яктан, алтынны да шуыткан! Беленде: бу адәм авызыннан шайтан сөйли, артында шайтан тора, әгаһ[1] булыгыз, бервакытта да шайтан котырыгына иярмәгез, мөселманнар!

Хуҗа (*казый янына торып килеп,арттан колагына*). Каһәр суккан шул шайтан, артымнан гына килә дә шушы минутта өстемдәге шул бикасапны сиңа салып бирергә куша, казый хәзрәт... (*Бикасапны алдына куя.*)

Низамый (*тотлыгып*). Хәер, хәер, ни әйтә идем әле? Ә... Әйе... Әллә нидә бер генә шайтан сүзен тыңлап кую да ярый шул. Белмәссең, бәлки, ул синең күңелеңне сынар өчен, юри яхшылыкка димләп куяр! (*Үзалдына.*) Уф... буталдым мин бу адәм белән! Ә бикасабы яхшы! (*Тегеләргә.*) Мәгълүм булды, җәмәгать! Бу бер дивана адәм, имеш. Аллаһы Тәгалә, бер хак дивананың догасын кабул итеп, аңар алтын иңдергән булса, ни гаҗәп!

Бики. Ничек? Сез шушы ялганчының сүзенә ышандыгызмы?

Хуҗа. Ул үзе ялганчы, казый әфәнде. Ул әле оялмас, шушы бикасапны да үзенеке дияр.

Бики. Бикасапны? Әлбиттә, минеке.

Хуҗа (*казыйга*). Менә күрдегезме? (*Бикигә.*) Болай булса, син әле минем менгән ишәгемне дә үзеңнеке диярсең. Оятың җитсә әйт!

Бики. Ишәкме? Ул да минеке!

Хуҗа (*казыйга*). Менә күрдегезме, нинди адәм белән эш итәсез!

Низамый (*Бикигә*). Җитте! Синең бер ялган адәм икәнең мәгълүм булды. Син, аның диваналыгыннан

---

[1] *Әгаh (әгяh)* — белеп торучы, хәбәрдар булучы.

файдаланып, бөтенләй көпә-көндез суярга җыенган адәм икәнсең. Синең үзеңә йөз таяк лазем[1] булды. Хөкем тәмам.

Бики (*елап*). Гафу боерыгыз, казый хәзрәт. Сезгә атабыздан калган кечкенә бер әманәт бар иде. Иң элек шуны алыгыз әле! (*Янчык суза, читкә.*) Ала бит, ала, ай Алла! Алдымы?..

Низамый (*алып*). Амин! Әманәт җан саклар. Таяк өстеңнән төште.

Бики (*кесәсенә сугып, куркып*). Һай! Йөз өстенә тагын йөз китте, менә бәла!

Низамый. Сезнең ни гарызыгыз бар, тархан?

Хуҗа. Тарханны монда мин алып килдем. Утын китергән өчен, миңа бирәчәге бар иде, тәкъсир.

Колый. Кара, кара, син алып килдең?Тора тор! Иң элек җавап бир әле син, өстеңдәге хөллә кемнеке?

Хуҗа. Хөллә?Менә хөлләгә дә ия табылды. Синекемени ул, тархан?

Колый. Минеке, минеке. Диванага сабышып, шәригатьтән котыла алмассың! Син аны урладың! (*Казыйга.*) Өстеннән хөлләмне салдырып алып бирегез дә шәригать буенча кисегез шул угрының кулын!

Хуҗа. Яхшы кара. Ялгышмыйсыңмы?Охшаганмы соң?

Колый. Ничек охшаган гына ди? Үзе! Менә Бики шаһит. Кара чабуларын! Төймә бавын! Валлаһи, минеке!

Бики. Валлаһи, анықы!

Хуҗа (*гаҗәпләнеп*). Шулаймыни? Алай булгач, ул тирес чүмәләсе өстендә йоклаган исерек син буласың?

Колый (*катып кала*). Тирес өстендә?Кем?..

Низамый. Сөйлә, Насретдин. Каян килде сиңа бу хөллә?

Хуҗа. Табылдык хөллә ул, казый әфәнде.

Низамый. Ничек табылдык?

---

[1] *Лазем* — тиеш.

Хужа. Шулай без беркөн Хаммат белән кайтып киләбез. Безнең борынга әллә каян бик сасы бер ис килә. Нәрсә икән бу дип гаҗәпләнеп бардык. Анда, елга башында, тирес түгелгән. Хаммат әйтә, әнә тирес өстендә үләксә ята, шуннан бу ис, ди. Янына барсак, тирескә борынын төртеп берәү йоклап ята. Үзе исерек. Янындагы агачка шушы хөллә эленгән...

Низамый. Хуш, син аның кем икәнен танымадыңмыни?

Хужа. Танырга бит, аның йөзе адәм карагысыз. Бите әллә нәрсә! Черегән йомырка бәреп киткәннәр аңа, казый хәзрәт.

Низамый (*чабуы белән борынын басып*). Мин буылдым, фу, Насретдин әфәнде, кыскарак сөйлә, фу!

Хужа. Сез әле монда буыласыз, ә мин анда ничек? Миңа аны уятырга кирәк бит инде. Тор, мин әйтәм, нәҗес! Көпә-көндез шулай ятарга ничек оялмыйсың? Шулай дип, моның артына бер типтем, уянмый. Шуннан Хаммат,— аның аягында үкчәсе җиз дагалы күн итек,— шундый бер типте, җир селкенде дип торам, уянмый. Тукта, мин әйтәм, бу дуңгызның хөлләсен алып китәләр бит, иясе сорау белән кайтарып бирермен дип, кызганып алып киттем. Син идеңмени ул? Мә, ал хөлләңне. (*Сала башлый.*)

Колый. Юк, тукта... Ялгышмыйммы? (*Карый.*) Бу минеке түгел. Карале, менә син!

Хужа. Түгел дисеңме?

Колый. Дөрес, минем хөлләм югалды. Ләкин бу минеке түгел!..

Хужа. Юк, юк. Син минем өчен бер дә оялма, тархан. Синең өстеңдә минем хакым йөргән кебек, минем өстемдә дә синең хакың йөри күрмәсен. Кара чабуларын! Төймә бауларын! Тотып кара!

Колый (*тота*). Әйтәм бит, бөтенләй минеке... Бөтенләй минеке түгел! (*Читкә.*) Менә каһәр суккыры. Кулым белән тотам, ала алмыйм.

**Хужа.** Чынлап та, моны синең өстеңдә бер күргән идем шул, мә хөлләңне. (*Аңа ыргыта.*)

**Колый.** Валлаһи, бу минеке түгел. Алла сакласын! Тирес өстендә!.. Гомердә күргәнем юк!..

**Низамый.** Яхшы. Тынычлап киегез, Хужа. Сез, тархан, хәзер аның бурычын түләгез, аннан ялган төһеммәт[1] тотканыгыз өчен ун алтын салым түләгез.

**Колый.** Аңамы?

**Низамый.** Юк, миңа. Аннан гафу үтенегез!

**Колый.** Тархан башым беләнме? Юк, ансы гомердә булмас! (*Бикигә.*) Кая, юкмы соң синдә акча?.. (*Үзе читек балтырыннан табып алып, елак тавыш белән.*) Мә! (*Кулын сузган Хуҗага да биреп.*) Мә!

**Низамый.** Башка гарызлар юкмы? Әссәламегаләйкем вә рәхмәтулла! Хөкем тәмам! (*Тора.*)

**Колый** (*буш янчыгын селкеп*). Әйе... Тә-мам! (*Янчыгын җиргә күтәреп суга.*)

**Низамый** (*арткы рәшәткә ягыннан чыгышлый, үзен озата килгән Хуҗага*). Һәй, Хужа, кара, бу ишәкнең башы барабанга тия күрмәсен!

**Хужа.** Тисә, ни була?

**Низамый.** Тисә, ләхәүләңне укы. Гауга күтәрелә. (*Хуҗаның иңсәсендәге бикасапны тотып куеп.*) Бикасап — минеке!

**Хужа.** Синеке, синеке! Ястүдән соң әтәч азан әйткәч тә килеп алырсың! Гауга күтәреләме?.. (*Барабанның каешын ишәк муенына кидереп, элгечен каптырып куя. Барабанны чиртеп, Колый белән Бикигә карап.*) Ишеттегезме, казый ни әйтеп чыгып китте сезгә? Бу ишәк шәригатьнең юлы белән, минем кулым белән шушы барабанга бәйләп куелды. Кем дә кем бу ишәккә тисә, кубачак гауга аның башына булыр, һәй! Каяле, мин дә ишәгемә салам алып килеп салыйм әле! (*Чыгып китә.*)

---

[1] *Төһеммәт (төһмәт)* — яла ягу, кешегә гаеп тагу, гаепләү, шик астына алу.

## Бишенче чыгыш

Колый, Бики, Ахун.

Ахун (*елаган тавышы ишетелә*). Ай-яй, яй, яй! Һәлак булдым мин, һәлак булдым!.. (*Килеп керә.*)

Бики. Кил тизрәк, нәрсә мыжлыйсың?.. Әйт, күрдеңме Җиһангир хәзрәтләрен? Әйттеңме аңа шул ләгънәт кеше турында?

Колый. Әйт тиз: шул этнең башын кисәргә куштымы, юкмы ул? Ник дәшмисең? (*Йөзен күреп.*) Туктачы! Сиңа ни булды?

Бики (*йөзенә кулын селкеп чигенә*). Ахун! Син күкле-яшелле булгансың бит! Нәрсә, күкерт ашатып чыгардылармы әллә?

Ахун (*иреннәре дер-дер итеп торгач*). Күкерт! Башым китте минем! Бәхил булыгыз, оланнар! (*Елап җибәрә.*)

Бики. Нәрсә, кабул итмәдемени?

Колый (*кызып*). Әйтмәдеңмени мулла икәнеңне?

Ахун (*кулын селки*). Әйттем, ул да түгел, фил, фил!

Колый. Фил! (*Куркып.*) Нәрсә, син шул мәхәлләңә ярыйм дип, әллә филе турында сүз әйттеңме? Нишләдең син?

Ахун. Үзе сорады, мин әйттем, әйтүемә, йөзе капкара киселде. Син мулла гына түгел, бикмулла икәнсең, алай булса, менә мин сиңа өч мәсьәлә бирәм, көн батуга, килеп җавап бирерсең, бирә алмасаң, башың (*ышкып күрсәтә*) кых! диде...

Колый. Өч мәсьәлә дисең? Нәрсә, нәрсәләр?

Бики. Йә, йә! Әйт беренчесен!

Ахун. Беренчесе: җирнең уртасы кайда?

Колый. Җирнең уртасы?

Ахун. Әйе лә, йә, йә? Башым ярылып бара, әйтегез, оланнар. Кая соң ул җирнең уртасы?

Бики. Җирнең уртасы! Юк-юк, без йөргән җирдә очрамады. Икенчесен әйт!

Ахун. Икенчесеме? Шуннан Җиһангир хәзрәтләре сакалын учлап тотты да, шушы сакалымда ничә бөртек йон бар, дип сорады.

Колый. Ләхәүлә! Җиһангирның үз сакалындамы?

Ахун. Йә, йә, син әйт, Бики: ничә бөртек?

Бики. Әйе, диванага алтыннарымны бирдем дә, инде синең белән Җиһангирның сакалын санарга калдым!

Колый. Өченчесен әйт!

Ахун. Өченчесе шул, диде, минем ялгыш уемны күрсәт, диде.

Колый. Җиһангир хәзрәтләренең ялгыш уен күрсәтергәме? Синамы?

Ахун (*Бикигә*). Йә әйт инде, син әйт: моңа ни дип җавап бирим мин?

Бики. Миңа бик якын торма, ахун. Валлаһи, мин сәясәткә тыгылмыйм!

Ахун. Эчемә ут төште, янам бит мин, оланнар! Бүген кич башым киселәчәк! Син әйт, тархан.

Колый. Әйтәм, бире утыр син. (*Ахун утыра.*) Юк, юк, син ят, шунда сузылып ят. (*Ахун ята.*)

Колый } (*икәүләп баш очында дога кылалар*).
Бики } Инна лиллаһи вә инна иләйһи раҗигун!

Ахун (*башын тотып*). Алла, башым! (*Тәгәрәп төшә.*)

Колый. Сакал! Кемнең сакалы бит! Шундый вакытта сәясәткә тыгылмасаң ярамаган! Менә монда безне Хуҗа нишләтте диген, шуны әйт! Тор, гариза яз, өстеннән Җиһангирга керәбез.

Ахун. Гариза?

Бики. Әйе, күрмисеңмени, кара җәяүгә калдым! Ике йөз алтын ул! Яз!

Ахун. Гариза? Юк, син әйт, күренәме сиңа минем башым? Миңа калса, сакалым бар, башым юк кебек.

Колый. Калдыр аны, җавабын уйлый торсын, бер гариза яздырып алырбыз, ул кул гына куяр, әйдә. (*Чыгалар.*)

**Алтынчы чыгыш**

Ахун, Хуҗа.

Ахун (*ялгыз*). Сакалы. Уртасы... Кояш байый, йа Алла! Шул җирнең сакалы кайда? Кайда шул Җиһангирның уртасы! (*Карый.*) Тукта, менә Хуҗа килә. Шул дошман аркасында бу бәлагә уралдым. Әгәр дә мин бу сорауларны аңа биреп карасам, ә? Сиздермичә генә? Менә акыл! Әйтсен дивана! (*Мендәр асларын күтәреп карап, нидер эзләгән була.*) Ә?

Хуҗа (*аны күреп, янына килеп, иелеп карый*). Ә?

Ахун (*икенче башка барып, мендәр күтәреп карый*). Ә?

Хуҗа (*шулай ук карашып*). Ә? Ниең төште, ахун? Ни эзлисең?

Ахун. Ә, ни, шуны уйлый идем әле, Хуҗа. Бәлкем, аны син дә уйлагансың: мин әйтәм, бу җирнең уртасы кайда икән? — дим...

Хуҗа. Кара син аны. Нөҗүм гыйлеме[1] белән дә шөгыльләнәсең икән син. Алай булгач, күккә карап та уйлыйсың булыр?

Ахун. Күккә карап уйламыйм уйлавын, алай да, менә әле синең сакалыңны күргәч, бер уй килде: ничә бөртек йон бар икән?

Хуҗа. Син Коръәндә бар нәрсә дә бар дип сөйлисең бит, анда әйтсә әйткәндер минем сакалым турында!..

Ахун. Коръәннең бөтен серенә бәндәнең гакылы ирешми, Хуҗа!

Хуҗа. Ярый, мәсьәлә бит, гадәттә, өч була. Өченчесен дә ишетик.

Ахун. Өченчесен дисеңме? Өченчесен менә син әйт: минем ялгыш уем нәрсә?

Хуҗа (*читкә*). Уйлаган идем аны: аңа бу мәсьәләләрне Җиһангир биргән! (*Аңа.*) Синең ялгыш уеңны әйтергәме? Әйтәм. Менә син хәзер, бу дивананы юма-

---

[1] *Нөҗүм гыйлеме* — (астрология, астрономия урынына) йолдызларга карап, фалчылык белән шөгыльләнү.

лап, өч мәсьәләгә җавап алыйм да Җиһангиргa шуларны әйтеп котылыйм, Хуҗа моны сизми дә калыр дип уйлыйсың.

Ахун (*хәйран булып*). Тфү! Алланың каһәре кеше икәнсең! (*Алдына тезләнә.*) Инде, инде үзең барысын да беләсең, коткар мине, Хуҗа Насретдин әфәнде!

Хуҗа. Әфәнде түгел, абзый дип сөйләш! Ярый, мин сине коткарырмын, ләкин син элекке кебек һаваланмассыңмы?

Ахун. Булган эш булган, инде моннан соң бетте, абзый, бетте!

Хуҗа. Моннан соң минем эшемә тыгылып, минем белән булышмассыңмы?

Ахун. Бетте, җизнәм, бетте!

Хуҗа. Ярый, алай булса, сал чапаныңны!

Ахун. Чапанымны? Карале, мин сиңа бүләккә башка нәрсә табармын...

Хуҗа. Алай булса, хуш!

Ахун. Тукта, мә! (*Хуҗа туктый.*) Мә! (*Салып бирә.*)

Хуҗа (*аркасына әйләнеп*). Яхшылап кидереп бир!

Ахун (*як-ягына карап алып, кидерешә*). Уф!

Хуҗа. Инде чалмаңны да салып бир!

Ахун. Чалманы? Ә, юк!.. Чалма — руханиларның киеме. Пәйгамбәр таҗы. Анысы булмый!

Хуҗа. Ә, шулаймы?

Ахун. Уф, болай мине дә үзең шикелле диванага саптырасың икән син. Тукта, чалманы да бирәм мин сиңа! (*Суза, кире алып.*) Ә, юк, булмый... Җиһангир хәзрәтләре янына ничек барыйм мин? Түбәтәйчәнме?

Хуҗа. Аңа син бармассың, мин барырмын.

Ахун. Син үзеңме? Тукта, ничек? Минем өченме?

Хуҗа. Нишләп синең өчен йөрим ди мин? Илем өчен: тимерчеләр аңа сине илче итмәделәр, мине илче иттеләр.

Ахун. Әһә, шулаймыни? Ярар, ул чагында әлеге өч җавапны да минем өчен син бирерсең.

Хуҗа. Мин бирермен!

Ахун (*чалмасын сала*). Юк, әйт: җавапны син бирерсеңме?

Хуҗа. Мин инде, мин.

Ахун (*чалманы биреп*). Тфү, тфү! Пәригә яулык, миңа саулык! Мә! Мине тотма, моны тот! (*Китә-китә.*) Менә котылдым!

Хуҗа (*чалманы кия, Ахунның артында биленә таккан төенчекне күреп*). Тукта, артыңда ул ни?

Ахун. Ә, улмы, каз иде.

Хуҗа (*килә*). Пешкән казмы? (*Шарт итеп җебеннән өзеп ала.*)

Ахун. Алла, тукта...

Хуҗа. Нәрсәсен тукта! Син бит аны бүләккә дип пешерткәнсең. Хәзер казны да мин алып барам инде.

Ахун (*аңгыраланып*). Казны да алгач, бу ничек була инде?

Хуҗа. Бумы? Бик һәйбәт була бу. (*Төенчекне чишә, каз белән йомыркалар килеп чыга.*) Кара, нинди симез каз, йомыркалар да бар. Булды бу, юләр. (*Пәкесен чыгарып, казның ботын кисеп ала.*) Монда Җиһангирга да, миңа да җитәр. (*Ашый.*)

Ахун. Ботын кисә! Ашый. Әстәгъфирулла, нишли, ахмак! Җиһангир хәзрәте үзе дә уң аякка аксак, аңа тагын шушы казны илтеп бирерсеңме?

Хуҗа. Аксакка аксак каз, аңгырага ул да юк. Синең өчен ач йөрмәм бит инде мин. (*Ашавын дәвам итә.*)

Ахун. Үзен мәсхәрә иткән өчен, Җиһангир башыңны гына өзәр!

Хуҗа. Өзсә, минекен өзәр, сиңа нәрсә? (*Ашый.*)

Ахун (*алга узып, бер Хуҗага, бер халыкка карап*). Ашый!.. (*Буылып көлә.*) Ярый, аша! Алып бар әле син аңа сыңар аяклы казыңны!.. Өч мәсьәләгә җавап та бир. Аннан соң ул синнән филе турында сөйләтер. Әләктеңме, ахмак! Ул гына җитмәсә, без менә хәзер Бики байлар белән бергә бик һәйбәтләп синең өстеңнән кем икәнлегеңне язып менгезик. Беттеме башың?

Барыйм, тизрәк гаризаларына кул куйыйм да берьюлы эшне бетерим! (*Кычкырып.*) Миңа китсәм дә буламы?

Хуҗа. Бар, бар! Синең миңа нәрсәгә кирәгең бар? Кеше ашаганны йотып тору яхшы кешенең эше түгел.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Комедияне рольләргә бүлеп укыгыз. Һәр персонажның характерыннан чыгып, дөрес тон белән укырга өйрәнегез.
2. Өченче пәрдәдәге персонажларны әйтегез. Ханлыкның өстен көчләрен характерлагыз: Колый тархан, Низамый.
3. Бу бүлектә Хуҗаның нинди сыйфатлары бирелә? Үзегез аңлаганча анализлап карагыз.
4. Бики байны характерлагыз. Аның кайсы сыйфаты көлке тудыра?
5. Хуҗа белән Ахунның диалогы сезгә ничек тәэсир итте? Диалогка исем уйлагыз.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче чыгыш

Тышкы пәрдә күтәрелә.
Эчке пәрдә алдында дүрт каравыл белән Атамыш.

Атамыш. Ишекчеләр! Урыннарыгызга! Җиһангир хәзрәтләре чыга.

Җиһангир. Сөйлә, вәзир.

Зәйнәгый. Ишек артында сезгә баш оручылар көтә.

Җиһангир. Халыкмы? Халыкны аны курку белән өмет арасында тотарга кирәк, вәзир! Бүләкләрен алыгыз да куыгыз үзләрен! Мин монда хан булып утырырга килмәдем. Һиндстанны басып аласым бар, әнә үзләрен таларга Гыймай баскагым биредә калыр. Иртәгә сәфәр. Ә бүген минем ял итәсем килә, вәзир!

Зәйнәгый, торып, сәхнә төбенә карап, ике мәртәбә кул чаба. Музыка. Арткы баскычтан шәл ябынган ике кыз, йөгереп төшеп, Җиһангирга сәлам ишарәсе биргәч, җыр һәм музыка астында бии башлыйлар. Алар кием һәм чырайлары белән берсе — көнне, берсе төнне сурәтләп, җыр һәм музыка астында, бер-берсен куышып әйләнәләр. Җиһангир кул гына селки. Бар да чыга.

**Өченче чыгыш**

Җиһангир, Зәйнәгый.

**Җиһангир.** Шатраныжны китер!

**Зәйнәгый.** Рәхим итегез. (*Шахматы корулы кечкенә өстәлчекне китерә.*)

**Җиһангир** (*тезеп*). Әйтче, вәзир: бармы бу илдә, ичмасам, күңел ачардай берәр кеше?

**Зәйнәгый.** Монда, Тимерчедә, Хуҗа Насретдин дигән бер көлке дивана бар икән, ишеткәнсездер?

**Җиһангир.** Әйе.

**Зәйнәгый.** Гаҗәп дәрәҗәдә көлке бер дивана, имеш. Хәтта... (*Җиһангирга төбәлеп*) уен сездә калды, хәтта олыларга туры әйтүдән дә тайчанмый, имеш.

**Җиһангир.** Әйе, миңа дәрвиш ул хакта сөйләде... Фил белән йөрик! (*Йөри.*)

**Зәйнәгый.** Әмма кызы ифрат дәрәҗәдә гүзәл, имеш...

**Җиһангир.** Мин ул кызны тотып китерергә баскагыма боердым. Шаһ! Тукта! Бу ни?

**Зәйнәгый.** Сезнең данлы сугыш филегез икесе дә куркыныч астында, тәкъсир.

**Җиһангир.** Минем филләрем? (*Шахматны бер кулы белән бозып, боерып.*) Вәзир! Хәзер ул Насретдин тотып китерелсен! Әгәр дә ул чын дивана булмыйча, юри генә диванага салынган булса, башы шул урында өзеләчәк!

**Дүртенче чыгыш**

Җиһангир, Зәйнәгый, Хуҗа.
Хуҗа кереп баса, сакчылар аның юлына сөңге тоталар.

**Җиһангир** (*ачуын көчкә тыеп*). Рөхсәтсез минем дәргяһемә[1] керәләрме?

**Зәйнәгый** (*ашыгып, каршы барып, теш арасыннан*). Кем син?

[1] *Дәргяһ* — капка төбе, ишек төбе, бусага.

Хуҗа. Җиһангир хәзрәтләренең боерыгы буенча, кояш батуга килеп җитүче.

Җиһангир. Һа, алай булса, бу теге... Ахун? Тимерчедәге минем филемне алдырырга йөрүче? Узсын, узсын! (*Хуҗага мәсхәрәле бер карап алып, үзалдына.*) Һи! Үз башын үзе минем кылычыма орырга дип килгән! Ни дәрәҗәдә ахмак кеше!

Хуҗа, килеп, аның алдында кулын күкрәгенә куеп, тиешле тәгъзим күрсәтә, кулында төргәге белән каз.

Ничек? Ул хәзер миңа тезен дә чүкмиме? (*Хуҗага ачулы карап.*) Алай? ! Мин куйган өч мәсьәләнең өчесенә дә җавап бирергә килдең инде син?

Хуҗа. Әйе.

Җиһангир. Аһа! Әмма берсенә генә булса да җавап бирә алмасаң, синең башың бит... (*Садистлык белән кулларын Хуҗаның башына табан сузгалый, бармаклары тырпаеп йөри башлый.*) Нинди шарт куелганын беләсеңме син?

Хуҗа. Беләм.

Җиһангир. Аһа! Ярый, ишетик! Беренчесен әйт аңа, вәзир.

Зәйнәгый. Җирнең уртасы кайда?

Хуҗа. Әнә капкада минем ишәгем тора. Чык та шуның уң арт аягын күтәреп кара. Тояк эзе кайда булса, җирнең уртасын тап шунда.

Җиһангир (*гаҗәпкә калып*). Ничек? Тукта?!. Ышанмыйм!

Хуҗа. Ышанмасаң үлчә. Әгәр бер ягыннан бер ягы артык яки ким чыкса, аннан соң сөйләшербез.

Җиһангир. Карагыз әле моны! Ишәк тоягы, ә? Икенче мәсьәлә ни инде, вәзир?

Зәйнәгый. Ә, ә... Сезнең сакал шәрифләрегез турында...

Җиһангир. Әйе. (*Хуҗага.*) Менә минем сакалымда ничә бөртек йон бар?

Хуҗа. Сезнең сакал шәрифегездәме? Каяле... шул ишәгемнең койрыгы бик пычрангач, мин аны кисеп алган идем... (*Кесәсеннән чыгара.*) Менә шул койрыкта ничә бөртек йон булса, синең сакалыңда да шулчаклы йон бар.

Зәйнәгый ике кулы белән башын тотып чүгә.

Җиһангир. Ишәк койрыгы?.. Нәрсә сөйли ул, ахмак? Тукта! Мин моның белән килешә алмыйм!

Хуҗа. Килешмәсәң, моннан бер төк, синнән бер төк йолкып санап карыйк! Нәкъ шулай булмаса, башымны кисәргә бирәм!

Җиһангир (*вәзиргә акрын*). Ничек дисең моңа син, вәзир? Шулай ук мин һаман әле аның башын кисә алмыйммыни?

Зәйнәгый (*аңа*). Сезнең кулыгызда өченче соравыгыз бар!

Җиһангир. Әйе, әйе. Ул юньсез минем ялгыш уемны күрсәтергә тиеш! (*Хуҗага.*) Ярый. Син боларыннан котылдың, ләкин синең алдыңда өченче сорау бар: күрсәт, минем ялгыш уем нәрсәдә?

Хуҗа. Күрсәтәм: син хәзер үзеңне Тимерче Ахуны белән сөйләшәм дип уйлыйсың.

Җиһангир (*бердән кәефе килеп*). Дөрес! Уйлыйм да һәм сөйләшәм дә! Ләкин бит син, шартыбыз буенча, минем ялгыш уемны күрсәтергә тиеш идең? Йә?

Зәйнәгый. Отылдыңмы? Йә?

Хуҗа. Менә шул мине Тимерче Ахуны дип уйлавың үзе ялгыш инде, тәкъсир. Мин үзем Ахун түгел, мин ул бистәнең Хуҗа Насретдин дигән кешесе генә. (*Чалмасын сала.*)

Җиһангир (*шаккатып, үзе тезенә сугып, урыныннан сикереп торып*). Хуҗа Насретдин! Тукта! Ничек? Кая соң ул Ахун?.. Карале син аның йөзен, вәзир! Ахун түгелмени соң ул?

Зәйнәгый (*карап*). Киеме шул. Ләкин йөзе...

Җиһангир. Ул түгел? Ә? (*Килеп карый.*) Чынлап та, бу ул түгел! Мин бу кешене беренче күрәм!.. Алай булса,

ахун үзе җавап таба алмагач, үзе урынына моны җибәргән! Карале моны син! Хуҗа Насретдин! Ә? Ха-ха-ха! (*Карашалар, үзе алдында Хуҗаның да кыйшайганын күреп, үзен үзе тота алмыйча, нык көлә башлый.*) Ха-ха-ха!

Хуҗа (*тәмле кеткелдәп җибәрә*). Ха-ха-ха-ха-ха!

Җиһангир. Юк, ничек мин моның башта ук Ахун түгел икәнен белмәдем, ничек ялгыштым соң?

Хуҗа (*Җиһангир алдында сыгылып торган вәзирне күреп алып*). Ул шуның өчен: сезнең алдыгызда, гадәттә, тиешеннән артыграк иеләләр, шуңа күрә сез аларның чын йөзләрен күрми каласыз.

Җиһангир (*үзалдына*). Юуук... Бу дивана түгел! (*Хуҗага.*) Ярый, ләкин син бу кыюлыкны өстеңә алган кеше булгач, Ахун урынына безгә илче дә булып килгән буласың.

Зәйнәгый (*Хуҗага*). Олуг Җиһангир сезнең белән сәясәтчеләр телендә сөйләшмәкче була. Боерыгыз, илче! (*Тәхет янында бер тәбәнәк бүкән белән акбур куеп, Хуҗага урын күрсәтеп.*) Әһ-һем!

Хуҗа. Кых-хым! (*Бүкәннең бер ягыннан килеп утыра.*)

Җиһангир акбурны ала да бүкән өстенә бер түгәрәк сызык сыза. Хуҗа акбурны ала да сызыкны урталай бүлә. Җиһангир уртага хәнҗәр кадый. Хуҗа төргәктән бер йомырка ала да хәнҗәр янына куя.

Җиһангир. Аңлашылды, илче! Безне вәзиребез белән калдырып торыгыз!

Зәйнәгый (*аңа ишарә белән*). Әһ-һем!

Хуҗа (*торып китеп, ишеккә җиткәч, вәзиргә әйләнеп*). Кых-хым! (*Чыга, вәзир озата чыга.*)

**Бишенче чыгыш**

Җиһангир, Зәйнәгый.

Җиһангир (*тиз генә сикереп барып, иелеп карый*). Һа! Йомырка!.. (*Зәйнәгый кергәч.*) Йә, вәзир, безнең сөйләшүебездән син ни аңладың?

Зәйнәгый. Сез, бер түгәрәк сызып, бөтен дөнья бер минеке генә булырга тиеш дидегез.

Жиһангир. Дөрес!

Зәйнәгый. Ул сезгә: тора тор! Әнә синең чигең, менә безнеке дип, аны бүлеп чыкты.

Жиһангир. Дөрес!

Зәйнәгый. Сез аңа: ул чагында мин көч белән басып алдым! дип, уртага хәнҗәрегезне кададыгыз.

Жиһангир. Дөрес!

Зәйнәгый. Ә ул менә ни өчен йомырка чыгарып куйды?

Жиһангир. Ни өчен?

Зәйнәгый. Аңлый алмадым, тәкъсир!

Жиһангир. Аңлый алмадың! Ә мин баш вәзирем булган кешенең үткенрәк акыллы булуын таләп итәм! Мин моның өчен аңа алтын түлим. Шуны да аңлый алмаган, ә?

**Жиденче чыгыш**

Жиһангир, Зәйнәгый, Хуҗа.

Жиһангир. Хуш! Сөйлә, Насретдин: безнең Тимерчедәге ата филебез исәнме?Халык яхшы карыймы? Ашату авыр-фәлән дип зарланмыйлармы?

Хуҗа. Бик зарланалар, тәкъсир.

Жиһангир (*бармагы белән ымлап чакырып, аңа сузыла төшеп*). Ә?.. Зарланалармыни? Алайса, алар миннән риза түгел?

Хуҗа. Бер дә риза түгел!

Жиһангир (*кылычын тотып*). Ничек риза түгел?

Хуҗа. Ничек риза булсын, бер генә фил ич ул, җитмәсә, үзе ата фил. Берүзенә генә күңелсез ич аңа, эче поша. Ашаса, аш үтми, ни ашаса, шул җитми. Менә инде ул ата филнең янына тагын бер ана филеңне дә җибәрсәң, бер мәрхәмәтең урынына, ике мәрхәмәтең булыр иде, диләр.

Жиһангир (*көлеп*). Һай, шулай дисеңмени әле син? Безнең биредәге ана филебез дә бик пошына башлады. (*Зәйнәгыйга.*) Әллә бу җирнең һавасы килешмәде. Ябыга, тутыйларым!

Хуҗа. Шулай булыр. Безнең икълимгә[1] бер әләксәң!.. (*Төенчегеннән чишеп, тәлинкәгә салынган казны Җиһангирга суза.*) Мәрхәмәт итеп алсагыз ла, кечкенә генә күчтәнәчебез иде.

Җиһангир. Бу ни?

Хуҗа. Күрмисеңмени? Каз.

Җиһангир (*карап*). Каз? Бу бер дә каз булырга туры килми. Кайда соң моның тагын бер аягы?

Хуҗа. Ничек тагын бер аягы? Шаяртасыз! Каз һәрвакытта да сыңар аяклы гына була.

Җиһангир. Ничек ул сыңар аяклы гына? Тукта...

Хуҗа. Белмим. Безнең шәһре Болгар иленең казлары шулай була. Ышанмасаң, әнә артыңдагы тәрәзәдән кара, шунда сарай чишмәсе янында торалар түгелме соң? Әнә, әнә бер каз, күрәсең, сыңар аяклы.

Җиһангир (*карап*). Һәй, хәрәмче! Ул бит салкыннан шулай бер аягын күтәргән! Ул ике аяклы.

Хуҗа. Ялгышасыз, тәкъсир. Ул сыңар аяклы.

Җиһангир. Вәзир! Ал шул таякны, чыгып ор шул казны, әгәр дә ул син оргач та ике аяклы булмаса...

Хуҗа (*вәзир кулыннан таякны ала*). Тукта, шушы таяк белән оргачмы?

Җиһангир. Әйе.

Хуҗа. Гаепләштән булмасын, тәкъсир, бу таяк белән мин сиңа орсам, син ике генә түгел, дүрт аяклы булырсың! Һап! (*Таягын Җиһангирның баш очында селтәп җибәрә. Җиһангир, куркып, дүрт аяклап җиргә төшә.*) Менә күрдегезме?

Җиһангир. Һай, тот үзен, чынлап ора күрмәсен тагын ул дивана! (*Торып утыра, тыела алмый көлеп.*) Җиде икълимдә йөреп, мин мондый адәм күргәнем юк иде. Ха-ха-ха! (*Хуҗага.*) Ни кәсептәге кеше син?

Хуҗа. Игенче.

---

[1] *Икълим* — борынгы бүленештә Җирнең экватордан алып төньяк Котыпка кадәр булган арасы, Җидедән бер өлеше.

Җиһангир. Менә ничек? Әйтче, синеңчә, кем зуррак: игенчеме, патшамы?

Хуҗа. Әлбиттә, игенче.

Җиһангир. Ни өчен «әлбиттә»?

Хуҗа. Игенче патшасыз тора ала, менә патша игенчесез торып карасын!

Җиһангир (*вәзиргә акрын*). Ишетәсеңме? Ул минем бакчага таш ата. Юк! Минемчә, ул бер дә дивана түгел!

Зәйнәгый (*аңа*). Акыллы кешенең сездәй патшага шундый сүз әйтүе мөмкинме?

Җиһангир. Хәзер без аны сынап карыйк! (*Хуҗага.*) Синең соңгы җавабың безгә ошамады. Илчелек әдәбен боздың. Сиңа җәза: хәзер син, минем каршымда нинди дә булса бер гаеп эш эшләп, миннән гозер-гафу үтен, ләкин кара: гозер үтенүең гаебеңә караганда да кабахәтрәк булып чыксын. Аңладыңмы?

Хуҗа. Аһ, хәзрәтегез миңа шундый авыр җәза бирә ки, моны уйлар өчен, бер тәүлек вакыт кирәк. (*Маңгаена бармагын куеп, читкә әйләнеп, уйлаган була.*)

Җиһангир. Бер тәүлек? Мин сиңа бер минут бирәм! (*Вәзиргә акрын.*) Күрәсеңме, җәясе бушады. Аның тапкырлыгы бик зур түгел.

Хуҗа. Бер минут? Аһ, җаным, көтеп алган ул минутыбыз җитте... (*Җиһангирның артыннан килеп, биленнән кочып, йөзен үзенә каерып үбә. Җиһангир шаккатып каерылып китмәкче булганда, Хуҗа җибәрмичә.*) Җаным... Тагын бер, бер генә!.. (*Йөзен каерып, Җиһангирны күреп, курыккан булып.*) Ай! Бу сезмени?..

Җиһангир (*күзләрен бер йомып, бер ачып, кылычын алып, җәеп җибәрә*). Бу нинди җир күтәрмәс кабахәтлек?.. Мин сорыйм синнән!

Хуҗа (*тезләнеп*). Гаеп миндә, падиша! Кичерегез! Мин сезне, артыгыздан күреп, яулыкчагызга карап, хатыныгыз дип белдем!

Җиһангир. Хатыным дип белдең! Син? Мине?.. Синең бу гозерең гаебеңнән мең мәртәбә кабахәтрәк! (*Кылычын җәеп, башын алырга килә.*)

Хуҗа (*аягына басып, тыныч*). Гаебемнән дә кабахәтрәк булса, димәк, мин сезнең җәзагызны үтәдем!

Җиһангир (*хәйран булып*). Ә?

Зәйнәгый (*сынсыз булып, тәхет алдында тәгәрәп, эчен тырнап көлә*). Ай, үземне тота алмыйм!.. Ай ханиям, ай ханиям!.. Ха-ха-ха!..

Җиһангир (*вәзир янына килеп, эченә кылыч кыны белән төртеп*). Карале... Ул мине хатыным дип белгән! Ах-ах!.. Ха-ха! (*Ачуланмакчы була да көлүенә буылып, өзек-өзек туктый.*) Син көләсең, мин... ачуымнан буылам. Ах-ха... ха-ха! (*Кинәт ачуын җиңә алмыйча.*) Ах-ха... ха-ха-ха! Юк, төчкерәмме, көләмме, нишлим мин бу кеше белән! Ах-ха-ха-ха-ха! (*Кинәт вәзиргә кыны белән суга.*) Туктыйсыңмы, юкмы син ахырында! Вәкаремне саклый алмыйм мин бу кеше белән! (*Хуҗага.*) Ни өчен Хуҗа диләр соң сине?

Хуҗа. Ә мин кышын балалар укыткалыйм.

Җиһангир. Син хәлфә икән?Минем ишәгемне укытырга аласыңмы?

Хуҗа. Алам. Бер ун ел мөддәт белән булса.

Җиһангир. Ярый. Әмма ләкин шарты шул: беренче дәрәҗәдә галим ясарга.

Зәйнәгый (*бармагы белән Хуҗага төртеп күрсәтеп көлә башлый*). Ха-ха-ха-ха!

Хуҗа. Ун ел эчендә баш вәзиреңнән дә галимрәк булыр.

Җиһангир (*кинәт кенә турсаеп калган Зәйнәгыйга карап*). Ха-ха-ха! Һай вәзир, һай вәзир!.. (*Хуҗага.*) Хуп. Аена сиңа ун алтын. Укыта алмыйсың икән, башыңнан колак кактың!

Хуҗа. Риза.

Җиһангир. Риза? Ә? Риза? Ха-ха-ха. (*Тәхетенә табан юнәлә.*) Шыр дивана икән бу! (*Кычкырып.*) Яз, вәзир, аңа шартнамә.

Зәйнәгый (*кечкенә өстәлне тәхет алдына чыгарып, каурый каләм белән яза. Хуҗага*). Бу кайсы ай әле? Яңа аймы?

Хуҗа. Белмим, ай алып, ай сатканым юк.

Зәйнәгый. Дивана. Синеңчә, яңа ай тугач, искесен нишләтәләр?

Хуҗа. Нишләтсеннәр? Кыркалар, кыркалар да йолдыз ясыйлар.

Зәйнәгый. Һай дивана! Кулыңны куй! (*Кул куйдырып алып, Җиһангирга.*) Шартнамә әзер, Җиһангир хәзрәтләре.

Җиһангир (*алып*). Хуп! (*Мөһерен басып бирә.*)

Зәйнәгый (*кәгазьне Хуҗага китереп*). Рәхим ит! Шуның белән ишәкләргә баш итеп билгеләндең! Аңлыйсыңмы, ишәкләргә! Ха-ха-ха!

Хуҗа. Аңлыйм. Шуның белән син дә минем кул астымдагыларның берсе булдың, алайса! (*Кәгазьне куенына сала.*)

Җиһангир (*тәхеттә эчен тотып тыела алмыйча*). Ай вәзир! Ай вәзир! Ха-ха-ха! Юк! Чыдый алмыйм мин бу кеше белән. Беләсе иде, ничек дип белә икән ул мине? Күпме торам икән мин аның каршында?

Зәйнәгый. Ә сез... Ә сез аңардан үзегезне бәяләтегез...

Җиһангир. Дөрес. (*Хуҗага.*) Миңа кара, Хуҗа. Яхшы кара. Мине сатсалар, күпме бирер идең син миңа?

Хуҗа. Сиңа бирергә? Кара син аны! Коштан казымны, игеннән тарымны алды, һаман мин бирим! Үзең ни бирәсең соң миңа?

Җиһангир (*Зәйнәгыйга*). Ишеттең, ни ди ул?

Зәйнәгый (*аңа акрын*). Сез аңа билегездәге кәмәрне вәгъдә итегез дә, ул ни бәя бирсә дә, дөрес түгел диегез, кәмәр үзегездә калыр.

Җиһангир. Рас әйтәсең. (*Кәмәрен чишеп, Хуҗага.*) Монда кара, Хуҗа: менә минем кыйммәтле кәмәрем. Син минем бәямне дөрес җиткереп бирсәң — бу сиңа. Күпме торам мин?

Хуҗа (*карап, чамалап*). Җиде йөз алтын.

Җиһангир. Җиде йөз! Тинтәк! Ә минем бар кигән киемнәрем генә җиде йөз алтын тора.

Хужа. Җиде йөз алтын торамы? Дөресме?

Җиһангир. Дөрес.

Хужа. Дөрес булгач, кәмәр минеке. (*Ала.*)

Җиһангир. Тукта, тукта, ничек синеке булды ул?

Хужа. Шулай. Мин аны синнән отып алдым.

Җиһангир. Тукта, тукта... Син минем киемнәремә генә җиде йөз бирдең бит әле. Мин үзем күпме торам соң?

Хужа. Үзең? Үзең син бер тиен тә тормыйсың, тәкъсир. (*Кәмәрне бәйли.*)

Җиһангир (*Зәйнәгыйга*). Аллаһы әкбәр! Киңәшеңә рәхмәт! Китте кәмәр! Ләкин мин дәүләт билгесе булган бу кәмәрне аңа бирә алмыйм, ничек кире кайтарып алырга соң?

Зәйнәгый. Башка нәрсә белән алыштырасыз гына.

Җиһангир. Алыштырып карыйк... (*Хужага.*) Һай, мин ашыга төшкәнмен, бу әманәт кәмәр икән, Насретдин. Ни теләсәң, аны сора, ләкин моны калдыр.

Зәйнәгый. Җиһангирның дәүләте киң, бирер әйберсе табылыр, сора.

Җиһангир (*боерып*). Сиңа әйтәм, сора!

Хужа. Ничек итим икән? Сорамас идем инде, ачуыгыздан куркам, күңел өчен генә сорасам сорыйм инде, алайса: бер генә көнгә миңа шушы тәхетеңне бирерсең!

Җиһангир (*сикереп торып, тәхетен икенче баштан тотып*). Тәхетемнеме? Сиңа? Синең хан булып карыйсың киләмени, һәй багыш? (*Зәйнәгыйга.*) Кызык, нишләр иде икән ул хан булса?

Зәйнәгый (*аңа акрын*). Ничек? Әллә сез чынлапмы?..

Җиһангир (*аңа*). Тәкъдир үзе бирде бу кызыкны! Бүген бу дивана белән ял итәсем килә минем! Нишли ала ул! (*Хужага.*) Ярый, мин сиңа бер көнгә тәхетемне бирергә булдым, ләкин гаскәремнән башка.

Хужа. Вәгъдә? Игълан ит!

Җиһангир. Әй! (*Ишарә бирә.*)

Кереш музыкасы.

### Сигезенче чыгыш

Җиһангир, Зәйнәгый, Хуҗа, Низамый, вәзирләр кереп, тәхет каршында тезләнеп утыралар.

Зәйнәгый. Сарай бикләре, вәзирләр! Тынлык! Олуг Җиһангир хәзрәтләре сезгә ярлыгын боера.

Җиһангир. Җиде икълимнең бигe — Җиһангир, сүзем: мин — Җиһангир, гаскәри эшем белән мәшгуль булуым сәбәпле, шушы эт елында, сәфәр аеның дүртенче киченнән таң чулпаны калыккангача, гаскәремнән башка, барлык тәхет-хөкем эшләрен, тәкъдирнең хөкеме белән, бу илнең хаким кешесе Хуҗа Насретдинга тапшырдым. Таҗым һәм хөлгатым аныкы. Шул мөддәт эчендә аның барлык әмерләрен минеке шикелле җиренә җиткерeңләр! Хуп! (*Таҗын Хуҗага салып бирә. Үзе яланбаш калып, түбәсе артында, монгол гадәтенчә, бер үрем чәч толымы күренә. Хуҗа, кәмәрне биреп, таҗны кия. Җиһангир ишектә Зәйнәгыйга акрын.*) Син аның барлык хәленнән миңа хәбәр биреп торырсың!.. (*Чыга.*)

### Тугызынчы чыгыш

Шулар ук Җиһангирдан башка.

Вәзирләр (*көйләбрәк*). Сәлам сиңа, Насретдин хан! Сәлам сиңа, Насретдин хан!

Зәйнәгый. Сарай бикләре, вәзирләр, тынлык! Насретдин хан сезгә беренче ярлыгын боера.

Хуҗа. Җиде икълимнең ханы — Хуҗа Насретдин, сүзем: Тимерчедәге безнең ата филебез, бирeдәге ана филебезгә бик каты гыйшык тотып, койрыгыннан саргая башлаган икән, бөтенләй сарыга сабышмасын өчен, ашыгыч рәвештә бирегә, сөеклесе янына кайтарылсын! Мин беттем! Барыгыз!

Вәзирләр ашыгып чыгалар. Ишектә тавыш.

Ул ни анда тагы?

Зәйнәгый. Сезгә хөкемгә киләләр, тәкъсир. Тархан белән Ахун. (*Чыга.*)

**Унынчы чыгыш**

Хуҗа, Колый тархан, Ахун, Бики, Низамый.
Ахун, Колый тархан һәм Бики, җирдән тезләре белән үрмәләп, тәхет алдына киләләр. Хуҗа таҗын артын алга киеп, чугын битенә төшерә.

Ахун (*кәгазь тоткан кулын күтәреп*). Сезгә гаризабыз бар иде, тәкъсир. (*Аңа суза.*)

Хуҗа (*аягы белән тибәреп*). Телдән генә сөйлә.

Ахун (*еламсырап*). Ай, Алланың җирдәге күләгәсе! Вай, газиз динебезнең терәге! Бисмиллаһи, хәзрәтеңә мәгълүм булсын, илебездә бер бәдбәхет, динсез адәм заһир булды. (*Елый.*) Шул! Бер дә чыдар хәлебез калмады... Имамнардан көлә! Сезнең затыгызга тел тидерә! Халыкны котырта! Илебезне шул яманнан коткарсагыз иде, тәкъсир!

Колый. Ул бурычын түләми, ялган ант итә. Угры ул, тәкъсир!

Бики. Бик яман, бик бозык фигыльле кеше. Хөкемне алдады ул, тәкъсир.

Хуҗа. Кара син явызны. Ни атлы соң ул?

Ахун. Аның аты — Хуҗа Насретдин.

Хуҗа. Ә? Дөньяда андый атлы кеше дә бармыни? Ишеткәнем юк иде.

Бар да. Бар, бар, бар, бар!..

Хуҗа. Кайда соң ул хәзер?

Ахун. Ул, минем чапанымны урлап киеп, сезнең сараегызга кереп китте. Сак булыгыз! Ул сезгә дә яман нияттә булмаса, бире килергә дә кыймас идек, тәкъсир!

Хуҗа. Сез аңа миннән нинди хөкем сорыйсыз соң?

Бики. Без аның дүрт кат тиресен инә белән тунатуыгызны сорыйбыз!

Ахун.
Колый. } Илгә гыйбрәт булсын. Итәкләрегездән үбеп үтенәбез, тәкъсир.

Хуҗа. Итәгемнән үп, әмма кесә тирәсеннән үпмә! (*Бикигә.*) Син бикасаптан! Бикасаптан! Хөлләдән җитеш, тархан! (*Чабуын кайтара.*) Ахун, авызың юганмы? Үп монсын.

Колый (*Бикигә*). Нәкъ минем хөллә!

Бики. Нәкъ минем бикасап!

Ахун (*шулай ук*). Тач минем чапан!

Хуҗа (*Низамыйга*). Казый! Коега тычкан төшсә, тазарту өчен шәригать ничә чиләк су чыгарырга куша?

Низамый. Кырык чиләк, ханым-солтаным.

Хуҗа. Әнә чатта җәмәгать коесы бозылган. Халык суга интегә. Шунлыктан хөкем сезгә шул: намуслы кеше өстенә яла ягу, әләк, гайбәт белән шөгыльләнгәнегез өчен, дүртегез дә бүген кырыгар чиләк су чыгарып, шул коены әрчеп, тазартып эшкә кертегез.

Зәйнәгый. Эшләрен тәмам иткәч, нишләтергә кушасыз?

Хуҗа. Сакалларын кыркып, өйләренә кайтарып җибәрегез! (*Йөзен ача.*)

Зәйнәгый. Мәрхәмәт ит, Насретдин хан!

Ахун (*йөзен күтәреп*). Насретдин хан?..

Бики. Сөбханалла!

Низамый. Ләхәүлә! Һәлак булдым, һай, һай!

Йөзтүбән төшәләр.

Бар да (*аягына егылып*). Коткар үзең, коткар, Насретдин хан!

Хуҗа (*үзенең аягын кочкан Бикинең аркасын тәхет итеп утырып*). Белмәдегезмени? Әләк төбе — һәлак! Сез, минем дүрт кат тиремне тунату артыннан йөреп, үзегезнекеннән яздыгыз. Алар дүртесе дә минем өстемдә.

Ахун. Ай-вай, Насретдин хан! Алла тәкъдирче, бәндә сәбәпче! Мин, үз кулым белән чалма, чапанымны сезгә кидереп, Җиһангир хәзрәтләренә җибәрүем белән, сезнең хан булуыгызга сәбәпче булдым. Инде мин үзеңнең Ахуның. Бәлфараз, шулай булгач, илтифат итеп...

Хуҗа (*бүлеп*). Илтифат итеп, кое тазартырга җибәрәм! Илтегез үзләрен коега! (*Аларны сакчылар алып чыгып китәләр.*)

Еракта халык гүләгән тавыш.

Хуҗа. Ул ни анда, вәзир?

Зәйнәгый. Халык кычкыра, хан!

Хуҗа. Кычкыра, димәк, бугазлары буш. Икмәк амбарларын ачыгыз!

Зәйнәгый (*тәрәзәгә*). Тынычланыгыз! Насретдин хан сезгә кайнар икмәк җибәрә. (*Үзалдына.*) Менә юләр хан! Аларны суктырасы җирдә...

Хуҗа. Ник шаулыйлар тагын?

Зәйнәгый. Эчәргә дә сорыйлар, тәкъсир.

Хуҗа. Ашагач, эчәсе килү табигый, эчерегез.

Зәйнәгый (*тәрәзәгә*). Тынычланыгыз, Насретдин хан сезгә баздан мичкәләр тәгәрәттерә. (*Хуҗага.*) Алар сездән кием дә сорыйлар, тәкъсир.

Хуҗа. Өләшегез соң...

Шау-шу үсә.

Тагын ни җитмәде?

Зәйнәгый. Кызларына ефәк оек, энҗеле башмак, үзләренә туй арбасы, йөгерек ат...

Хуҗа. Юк инде, монсын алдадыгыз, вәзир әфәнде. Халык аны сорамас. Ашаттым, эчерттем, киендердем — минем эш бетте.

Тыштан «Яшәсен Насретдин хан!» дигән хор ишетелә.

Хуҗа. «Яшәсен» диләрме? (*Тәрәзәгә.*) Җәмәгать! Теләкләрегезне кабул итеп, үлгәнче яшәргә булдым. Тынычлап кайтып китегез.

Тышта көлеш тавышлары.

(*Зәйнәгыйга.*) Ләкин карагыз, барабан астындагы ишәк минеке, өркетә күрмәсеннәр!

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Зәйнәгый, Җиһангир белән Хуҗаның диалогы сездә нинди тәэсир калдыра? Хуҗага хас сыйфатлар соклану тудырамы? Әсәрдән өзекләр кулланып сөйләгез.
2. Хуҗаның халык белән уртаклыгы нәрсәдә? Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләрне искә төшерегез.
3. Хуҗаның Зәйнәгыйга (баш вәзиргә) биргән характеристикасын тексттагыча сөйләгез.

4. Хуҗа Насретдин ханны характерлагыз. Хан булгач, аның кайсы сыйфатлары аеруча тулырак ачыла?
5. Бу пәрдәдә Бики, Ахун, Колый тархан, Низамыйларның Хуҗага мөнәсәбәтләрен ачыклагыз. Ни өчен аларның килеш-кыяфәтләрен, хәрәкәтләрен сурәтләүдә сатираның көче арта бара?

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук сарай.

### Ундүртенче чыгыш

Хуҗа, Зәйнәгый.

Хуҗа (*Зәйнәгыйга*). Ә, бу ни бу?

Зәйнәгый (*коты очып*). Гауга барабаны кагылды!

Хуҗа. Яу килде? Тукта...

Зәйнәгый. Мин дә әйтәм бит! Яу, яу! (*Чыгып чаба.*)

Каңгырган вәзирләр, җарияләр керә.

Хуҗа (*тәхеткә басып*). Качыгыз! Яу килде, яу, яу!

Бар да. Яу килде! Яу, яу! Ах, ах! (*Буталыш, чыгу, ыгы-зыгы.*)

Хуҗа. Чыгыгыз, чык! Әй! Итәгенә басмагыз анда гүзәл ханбикәнең. (*Бар да чыгалар.*)

Хуҗа (*ялгыз*). Шәп булды! Кайчан мин узам, кайчан ишәгем уза. Барабанны зур кактык, хуш. Хуҗа Насретдин, ахыры ничек булып чыгар моның? Хәзер син дөньяның зур сугыш остасының берсе булган Җиһангир белән бергә-бер чыгасың! Чү! Менә вәзир килә.

### Уналтынчы чыгыш

Хуҗа, Җиһангир.
Хуҗа дәшми, дисбе тарта.

Җиһангир. Ник дәшмисең син?

Хуҗа дәшми. Еракта барабан тавышы.

Җиһангир. Ишетәмсең, барабан! Ихтимал, минем гаскәрем биредә юклыктан файдаланып, анда... Йә? Ник әйтмисең? Габдулла хан киләме?

Хуҗа. Белмим.

Җиһангир. Ничек белмисең син?

Хуҗа. Шулай. Белмим бер сүз, беләм ике сүз.

Җиһангир. Шулаймы? (*Көч белән ачуын тыеп.*) Давыт галәйһиссәлам үз кулы белән койган шушы изге кылычым белән ант итеп әйтәм, йә син миңа хәзер турысын сөйләрсең, яки... сөйләмисең?

Хуҗа (*аңа карап торганның соңында*). Туры сөйләр идем, син яратмассың, ялган сөйләр идем, үзем яратмыйм.

Җиһангир. Ах, шамакай! Бер көнлек хәлифә! Бу илнең иң тапкыр кешесе син идең бит әле! Кая соң ул синең телең, тутый?

Хуҗа. Әйе, минем бер таныш тутыем бар иде, әнә хәзер теле аркасында читлектә утыра.

Тагын барабан тавышы ишетелә.

Җиһангир (*күккә карап*). Йа Тәңре! Синең хөкемеңне җир йөзендә җирләштерәм дип, кулыма кылыч алган бер ханың булдым, шушындый түбән, карасөяк бер диванаңны тәхетемә җибәрдем, ул затсыз әнә синең имамнарыңны кое казырга җибәрде! Бәлки, шул язығым өчен миңа мондый бәлаләрне җибәрүеңдер...

Хуҗа. Бәласе бәла... бәласе артыннан казасы иярә әле аның.

Җиһангир. Иманыңны укы, чүк муеныңны, башың алынды синең, куркак, кара баш! (*Күзен йомып, кылычын селтәп җибәрә, тышта барабан. Җиһангир бер күзен ачып.*) Ничек? Ул һаман шулай утырамы? Минем кылычым астында?.. (*Шикләнеп.*) Языкка төшермә, йа Тәңрем, бәлки, ул чыннан да синең якын адәмнәреңнең берседер!.. (*Кылычын кынга тыга.*) Минем өчен Аллаңа сыен, дивана. (*Тыңлап.*) Нәрсә? Туктады түгелме барабан?

Хуҗа (*халыкка*). Әйтәм бит, үзе үтерә, үзе үлемнән курка. Явызның арты һәрвакыт куыш була аның!

Җиһангир. Ә?

Хужа. Без өйләнгәч, төн кыска булды, дим. Без хан булдык, фетнә куба. (*Тора.*)

Җиһангир. Фетнә? Алай булса, бу — халык күтәрелеше? Ялган!

Хужа. Сезгә ялган, миңа чын. Сиңа берни дә булмас, синең өчен монда мине суярлар, мин — хан. (*Таҗын алып бирә.*) Рәхим ит таҗыңны.

Җиһангир (*этәрә*). Йа Тәңре, сөякләрем шунда калырмы минем?

Хужа (*елак тавыш белән*). Үлүеңә күрә күмүе булыр...

**Унсигезенче чыгыш**

Хужа һәм бер яктан Алчын, Зөбәрҗәт, Гөлбану, икенче яктан Сәлви белән Хаммат керәләр.

Бар да. Һай, әти! Һай, Хуҗам! Һа-һа-һай! Һай!

Хужа. Нәрсә һай?

Хаммат. Барабан бит ишәк муенына киелгән! Ул аны күтәрә дә җиргә суга, күтәрә дә җиргә суга!

Алчын. Ул халык! Бар да: яу басты да яу басты! Ә теге аксак... Ха-ха-ха!..

Хужа. Булыр, булыр, кияүләр. Бер ишәк шәһәреңә шундый бер эш ясар, мең акыллы кеше хикмәтен төшенмәс. Алай да безгә көләргә иртә, монда әле аксагы китсә, баскагы калды.

Тояк тавышлары.

Менә! Киләләр!

Гөлбану. Ай Алла, харап булдык! Нишлибез?

Хужа. Көлке көлә җитте, арттан куа җитте.

Алчын. Арысланы китте, аюы килә.

Сәлви. Аюмы? Үлгән булып ятсаң тими, ди.

Гөлбану (*Сәлвигә*). Юкны сөйләмә, син инде бала түгел!

Хужа. Тимә, хатын, кыз дөрес сөйли, үземә охшаган, акыллы булыр. Йә бар, калдырыгыз әле мине, тегендә чыгыгыз, чык!

Хуҗадан башкалар чыга.

Үлгәнгә аю тими! Ә?(*Тәхеткә утыра.*)

### Унтугызынчы чыгыш

Хуҗа, Гыймай, Ахун, Колый, Бики, Низамый.

Гыймай. Үрә кат! Шым! Миңа белергә кирәк. (*Хуҗага.*) Бу гауганы синме куптардың?

Ахун. Шул бәдбәхет! Барысына да шул гаепле!

Хуҗа. Нишләп мин гаепле булыйм? Ишәк гаепле.

Колый. Кара, кара, хәзер ишәккә сылтамак була, ә? Моның өчен дөньяда юк бер җәза тиешле аңа, баскак!

Гыймай. Моның өченме! Тукта! Моның өчен сине... борыныңнан тишеп үтерергә кирәк!

Хуҗа. Минем борынымның ике тишеге бар, өченчесен тишәргә хаҗәт юк.

Ахун. Кара, кара, саескан! Нәрсә сөйли! Иманыңны укы!

Гыймай. Үрә кат! Дөнья белән бәхилләш, Насретдин!

Хуҗа. Дөнья белән мин бәхил, үкенечен куймадым, менә хатын белән, белмим. Рөхсәт итегез, аның белән бәхилләшеп чыгыйм.

Гыймай. Сиңа бер минут миһләт[1]!

Хуҗа чыга.

Низамый. Олылардан кое казыттыра!

Бики. Сөйләмә, сакалларыбызны кисә башлады бит!

Гыймай. Шым утыр! Монда мин баскак! Ни өчен барабанны ишәк күтәреп киткән? Ул шуңа җавап бирсен!

Елаш ишетелә.

Нинди елаш анда? Карагыз!

---

[1] *Миһләт (мөһләт)* — кичектерергә рөхсәт бирү.

### Егерменче чыгыш

Шулар ук һәм Гөлбану.

Гөлбану. Аһ! Ваһ!

Бики (*сискәнә*). Хатыны елый.

Гөлбану (*кулында буш ташаяк, елап керә*). Ләгънәт төшсен, сезнең өчен шушы яшемдә ирдән калдым... Аһ! Аһ!..

Гыймай. Миңа карап сөйлә, ни булды?

Гөлбану. Яныма чыкты, уф, янам, Гөлбану, дип, шушы торган ташаякны күтәреп эчүе булды...

Низамый (*ташаякны алып*). Шунымы?.. Карагыз, Алланың күрсәткән гыйбрәте бу: үзенә әзерләнгән агуны үз кулы белән күтәреп эчкән!

Колый. Төбенә хәтле чөмергән бу!

Гөлбану. Башына җиттегез Насретдинымның! Ташаягыгызны башыгызга каплагыз! Үлде бит, кара янды! Аһ-аһ! (*Чыга.*)

Ахун (*ташаякны алып*). Кара син ахмаклыгын! Үзенә хөкем чыкканны да көтмәгән, без дә сиңа шуны эчергән булыр идек бит!

### Егерме беренче чыгыш

Шулар ук һәм Хаммат, Алчын, Сачтараш,
Сәлви, Зөбәрҗәт.
Хуҗаның паласка салынган гәүдәсен күтәреп чыгалар.

Тавышлар. Чүгез, чыгаралар! Күрәсең, иманын да әйтә алмаган, нинди газапланып үлгән!

Гыймай. Куегыз!

Хуҗаны идәнгә сузып салалар.

Колый. Ләхәүлә, бите ничек сузылган! Шулай ук үләрбез микәнни?

Ахун. Иннә илләһи вә иннә иләйһи раҗигун! Инде, абыстай, үлгән артыннан үлмәк юк! Үлмәк юк!

Гөлбану (*елаган булып*). Ничек еламыйсың! Шул күлмәктән башка кияргә күлмәк юк, күлмәк юк! (*Артына әйләнеп бара да сөйрәлеп калган итәгенең очын күтәреп күзен сөртә.*) Барыбер салмыйм күлмәген. Аһ, аһ, аһ!

Ахун. Гөнаһсын дәвер кылдырырга кирәк. Фидиясен карарга кирәк. (*Сакалын күтәреп.*) Мәрхүм дивана кеше иде. Кем өстендә булса да кичелмәгән бурычлары калмадымы?

Бики. Калды: иң элек янчыгы белән хисаплап, йөз алтын.

Гөлбану. Аһ!

Сәхилә. Минем дә йөз алтын.

Колый. Минем дә...

Гөлбану. Аһ, аһ!

Алчын. Һәммәгезнең дә шул бер йөз алтын бит инде ул. Аны да әнә казый әфәнде Хуҗа файдасына хөкем итте.

Гөлбану (*куанып*). Аһ!

Алчын. Күрәсез, Гөлбану апа борчыла, мәрхүм изге кеше иде, рәнҗеп ятмасын, кичә алсагыз, бурычларыннан кичегез!

Гөлбану (*сызланып*). Аһ, аһ!

Бики. Тагын илле өч сум, йорты миндә дигәндәй... Сәлви сылу хакына кичмәсәк...

Гыймай. Үрә кат! Монда мин баскак! Бу гауганы ул күтәрдеме? Иң элек ул шуңа җавап бирсен!

Ахун. Бәлеш! Үлек ничек җавап бирсен?..

Гыймай. Тик тор! Ни өчен ул барабанны ишәгенә тагып җибәргән? Ишәге өчен ул җаваплымы?

Бики. Гафу боерыгыз, ишәк аныкы да түгел, минеке!

Гыймай. Синекеме? Әһә! Алай булгач, бу гауга өчен дә син җавап бир!

Бики. Бәрәкәт! Бу үлгәч тә мине тоттырып ята, тагын мин гаепле булдыммы?

Ахун. Сабыр. Ишәк Насретдин мәрхүмнеке, барабанны аңа ул таккан, бу эшкә ул җаваплы.

**Гыймай.** Насретдинныкы булса, Насретдиныгызны алыгыз да чыгып китегез моннан! Сез әле миннән үлекне хөкемгә тарттырасызмыни? Күтәрегез! Әнә сезгә ишек. Һарш!

**Бики.** Ишәкне дә бирдем, үлеген дә миннән күтәртәсезмени?

**Ахун.** Чү! Дивананың рухы сукмасын, яхшы гына алып чыгыгыз үзен.

Хуҗаны үзенекеләр күтәрешеп, ишеккә юнәләләр.

**Хаммат.** Белмим, без бу ишеккә ничек сыярбыз?

**Тавышлар.** Күтәрә төшегез, җәмәгать! Төшерегез, төшерегез! Юк, алай да булмый... Туктагыз, без кырыйдан... Болай да булмый. Куегыз әле мәетне... Ничек чыгабыз бу ишектән, җәмәгать?

**Хуҗа** (*иң элек бер тезе күтәрелә, бар да каты сискәнә, аннан үзе торып утыра*). Җәмәгать! Мин үзем исән вакытта әнә теге арт ишекне киң ачып чыгып йөри идем. Шуннан алып чыгыгыз, шуннан!

**Ахун.** Ләхәүлә!.. Мәет терелде. Укыныгыз, укыныгыз!

**Картлар.** Йа алай! Йа Алла! Һай, һай!

Паника. Хуҗа, кулларын сузып, өсләренә килә.

**Ахун.** Әйберен сорый... Бирегез (*чапанын ыргытып чигенеп бара*).

**Колый.** Валлаһи минеке түгел. Ал хөлләңне! Мә!.. (*Хөлләне ыргытып, артка таеша.*)

**Бики.** Нинди куркыныч! Тотма, җибәр... Мә бикасабыңны! (*Бикасапны ташлап кача.*)

**Сәхилә.** Абау! Йөз алтының да кирәкми! А, аһ!

**Ахун.** Рух сукмасын, рух, рух! Төренегез!

Картлар чапаннарын башларына кайтарып төренәләр.

Җибәр! Җибәр! (*Качалар.*)

**Гыймай** (*чукмарын күтәреп*). Ай! Миңа килмә! Үрә кат! Алгары һарш, һарш! Ай!

Барысы да качып бетә.

Хаммат. Ха-ха-ха! Менә без җиңдек!

Хор (*Хуҗа Насретдинны уртага алып җырлыйлар*).

Яшә, яшә, Хуҗа Насретдин!
Син — үлемсез халык хикмәте.
Һәр кыенны ерып чыгучы,
Көлке — синә дөнья михнәте.
Яшьләр өчен шатлык син,
Картларга да тансык син,
Халык үлмәс — син үлмәс,
Мәңге яшә, Насретдин!

Пәрдә.

* * *

**Комедия** (грек сүзе) — социаль һәм көнкүрештә очрый торган ямьсез күренешләрдән көлеп язылган сәхнә әсәре. Монда язучының үткен күзәтүчәнлеге, тапкыр сурәтләве, сәхнә кануннарын оста белүе күренә.

**Көлү** — тәнкыйтьнең үзенчәлекле формасы. Укучыга ул аеруча көчле йогынты ясый, начардан көлдерә, аны ахыргача фаш итә.

Сүзлек өстендә эш.

*Бәлфараз, тархан, заһир, тәкъсир, ханис, гарыз, тәкъдир, җәллад, әүкат, дисбе, кәмәр* сүзләрен аңлатмалы сүзлектән карап, мәгънәләрен ачыклагыз.

**Сораулар һәм биремнәр.**

1. Укылган өзекләрнең эчтәлеген сөйләгез.
2. Колый һәм Низамыйларны сурәтләгәндә, ни өчен көлү фаш итү дәрәҗәсенә җитә?
3. Хуҗа образын тулырак сөйләгез. Аның характерын ачуда юмор нинди роль уйный?
4. «Хуҗа Насретдин» ни өчен комедия төренә керә? Комедия нәрсә ул? Нинди комедияләр укыганыгыз бар?

**Мөстәкыйль эш.**

Уку елы башында үткән Хуҗа Насретдин мәзәкләрен хәтерегезгә төшерегез. Алар комедиянең эчтәлегенә туры киләме? Үзегез дә шундый мәзәкләр җыегыз.

**Язма эш.**

Үзегез белгәннәрне дә файдаланып, Хуҗа Насретдин образын тулырак характерлагыз. Әсәргә катлаулы план төзеп, инша языгыз.

## «ХУҖА НАСРЕТДИН» КОМЕДИЯСЕ ТУРЫНДА

«Хуҗа Насретдин» — бик халыкчан комедия. Чөнки автор аны фольклор мотивларына нигезләнеп иҗат иткән. Хуҗа — Көнчыгыш халыкларында бик таралган образ. Ул XIV гасырдан ук халык телендә яшәп килә, аннан соң XVII—XVIII йөзләрдә Идел буена килеп керә. Һәр халык аңа үз гадәтләрен бирергә омтыла. Безнең халыкта да Хуҗа җор телле, тапкыр, зирәк булуы белән яратып сөйләнә. Гадел табигатьле, үткер акыллы үлмәс шәхес булып яшәвендә дәвам итә.

Хуҗа — комедиянең төп образы. Ул бөтен драматик вакыйгаларны әйдәп бара, әсәрнең конфликты да аңа бәйләнешле үсә. Комедиянең һәр персонажы: Бики бай, Низамый казый, Колый тархан, Ахун, соңгы пәрдәләрдә Җиһангир хан — һәркайсы Хуҗа белән үткен диалогка керә. Хуҗага каршы торучылар — барысы да изүче сыйныф вәкилләре; автор ерак тарихны, урта гасырны алган. Хуҗа тискәре геройлар белән тартыша, бәхәсләшә, үзенең үткер акылы, хикмәтле шаянлыгы белән һәрчак җиңүче булып кала. Хуҗаның гадел хөкеме Ахунны да, Колыйны да бер-бер артлы көлкегә калдыра. Шунысы үзенчәлекле: көлке әсәрдә ике юнәлештә хәрәкәт итә, берсе — Хуҗа характерында, аның көлкесе фаш итүгә корылган. Икенчесе тискәре персонажларның төп сыйфаты булып килә. Хуҗа белән бәхәстә аларның чын йөзләре пәрдәдән пәрдәгә ачыла бара. Әсәрнең иң югары ноктасында Хуҗа Җиһангир хан белән алыша. Монда хәрәкәт ае-

руча кискенләшә. Хуҗаның халыкка казна байлыгын өләшүе, акыллы идарәче булу өстенә, аның тәвәккәл икәнен дә күрсәтеп тора. Шуңа күрә тамашачы аннан яратып көлә, төрле хикмәтләренә сөенә. Сәлви, Хаммат, Алчыннарның яшьлек бәхете дә Хуҗа тапкырлыгы белән хәл ителә. Мондый уңай персонажлар эчтәлекне киеренке алып баруда, Хуҗаның зирәк сыйфатларын ачуда бик әһәмиятле.

«Хуҗа Насретдин» — җитди әсәр. Көлкеле итеп бирелгән образлар комедиянең эчтәлеген тирәнәйтәләр, реалистик сурәтләнеше белән укучыны һәрчак кызыксындыралар.

**Үткәннәрне кабатлау.**

1. Дәреслектәге кайсы язучының әсәре сезнең күңелегезгә аеруча тәэсир итте? Ни өчен? Шул турыда әңгәмә корыгыз.
2. «Уку — күңел нуры» мәкаленә бу китаптагы әсәрләр туры киләме? Фикерегезне дәлилләп әйтегез.
3. Яттан өйрәнгән шигырьләрне сөйләгез.
4. Дәрестә өйрәнелгән язучыларны нинди уртак фикер берләштерә?
5. Үтелгән әсәрләргә нигезләнеп, нинди темаларга инша язар идегез? Исемлеген төзегез. Шул исемлектән үзегезгә ошаган теманы сайлап, инша языгыз.

## ЭЧТӘЛЕК

*Халык авыз иҗаты* . . . . . . . . . . . . . . . 4
Таңбатыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Үги кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Гөлчәчәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Ай белән Кояш . . . . . . . . . . . . . . . 43
Арыслан, Бүре, Төлке . . . . . . . . . . . 44
Әкиятләр турында . . . . . . . . . . . . . . 45
Мәзәкләр турында . . . . . . . . . . . . . . 49
Мәзәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51

*Абдулла Алиш* . . . . . . . . . . . . . . . 54
Сертотмас Үрдәк . . . . . . . . . . . . . . 56
Нечкәбил . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Койрыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . 70

*Габдулла Тукай* . . . . . . . . . . . . . . 77
Исемдә калганнар . . . . . . . . . . . . . . 77
«Исемдә калганнар» әсәре турында . . . . . . 99
Автобиография һәм биография . . . . . . . . 101
Шүрәле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 101
«Шүрәле» поэмасы турында . . . . . . . . . . 106
Чагыштыру . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Пар ат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
«Пар ат» шигыре турында . . . . . . . . . . 110
Шигъри сөйләм . . . . . . . . . . . . . . . 111

*Фатих Әмирхан* . . . . . . . . . . . . . . 112
Нәҗип . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 114

*Галимҗан Ибраһимов* . . . . . . . . . . . . 130
Алмачуар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
«Алмачуар» хикәясе турында . . . . . . . . . 153

*Һади Такташ* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Ак чәчәкләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Караборынның дусты . . . . . . . . . . . . . . . . 160

*Әмирхан Еники* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 174
Курай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
«Курай» хикәясе турында . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

*Гадел Кутуй* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
«Сагыну» нәсере турында . . . . . . . . . . . . . . . . 193
Рөстәм маҗаралары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 195

*Муса Җәлил* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Җырларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Кызыл ромашка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Ана бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214

*Фатих Кәрим* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 219
Үлем уены . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
«Үлем уены» поэмасы турында . . . . . . . . . . . . . 226
Сибәли дә сибәли . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
Кыр казы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229

*Мостай Кәрим* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Озын-озак балачак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
«Озын-озак балачак» повесте турында . . . . . . . . . 264

*Шәүкәт Галиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 266
Шәвәли маҗаралары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 267
Табышмаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
«Шәвәли маҗаралары» турында . . . . . . . . . . . . . 279

*Габделхәй Сабитов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 282
Ярсулы яз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 283

*Нәкый Исәнбәт* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Хуҗа Насретдин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 293
«Хуҗа Насретдин» комедиясе турында . . . . . . . . . . 332

Учебное издание

**Залялиева** Мадина Шайхиевна
**Адгамова** Гульчачак Мирзагитовна
**Сибгатуллина** Диляра Шариповна

**ЛИТЕРАТУРА**

Учебник-хрестоматия
для 5 класса
основной общеобразовательной школы
с татарским языком обучения

Издание пятое

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

**Җәләлиева** Мәдинә Шәйхи кызы
**Әдһәмова** Гөлчәчәк Мирзаһит кызы
**Сибгатуллина** Диләрә Шәриф кызы

**ӘДӘБИЯТ**

Татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең
5 нче сыйныфы өчен
дәреслек-хрестоматия

Бишенче басма

Мөхәррире *В. Г. Гомәрова*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вәҗиева*
Техник мөхәррире һәм
компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректорлары *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*,
*Т. Н. Сәгъдуллина*, *А. А. Дәүләтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 16.07.2011. Форматы 60×90 $^{1}/_{16}$.
Шартлы басма табагы 21,0 + вкл. 0,5 + форз. 0,25.
Тиражы 9000 д. Заказ Р-902.

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

***Кайларда соң шушы***
***Әкияттәге***
***Иң дә ямьле, асыл ил? – дисәм,***
***Йөри торгач белдек:***
***Бу дөньяда***
***Иң матур ил – безнең җир икән!***

*Хәсән Туфан*

9 785298 020671